КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

# Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Килә тын сукмактан үтәсем... *Шигырьләр.* ................................3
Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. Ике рәссам. *Повесть.* .......................................................................8
Гөлназ ГАРИПОВА-ДЕНИЗ. Күкләрне туз дип белдем лә... *Шигырьләр.* ................................34
Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ. Кояшы бар күңел өметле ул... *Шигырьләр.* ......................................89
Рәис САФИН. Язмыш сукмаклары буйлап. *Повесть.* ..................................................................93

«СЕЗ ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Асия ЮНЫСОВА. Сылукай. *Бәян.* ...............................................................................................39

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөлназ НУРИЕВА. Соңарганчы, бер тын алсаң иде... *Шигырьләр.* ........................................130

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Улугбәк ХАМДАМ. Бер чынаяк су. *Хикәя. (Үзбәкчәдән Факил САФИН тәрҗемәсе.)* ..........134

ПУБЛИЦИСТИКА

Римзил ВӘЛИЕВ. Нокталы өтер, ягъни милләтне саклау серләре. ........................................140

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Венера МАКАРОВА. Борынгы мифның яңача укылышы. *(Илгиз Зәйниевнең «Мәдинә» әсәренә бәяләмә);* Илгиз Зәйниевнең «Өйләнәм. Тат» комедиясендә көлке үзенчәлекләре. ................157

*Фотоархив:* Флүс Латыйфиның тууына – 80 ел. .......................................................................166

2023 ЕЛ – ДАСТАННАР ЕЛЫ

Түләк китабы. *(Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВАның кереш сүзе белән).* ...................................168

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

Марсил КАДЫЙРОВ. Кәҗә белән юлбарыс хикәяте. ...................................................................185

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

«Татар моңын яшәтерлек яшьләр килә...» *(Венера Гәрәеваның тууына – 80 ел).* ..................188
Хушлашмый да китеп барды... *(Фәннур Сафинның тууына – 75 ел).*
*Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* .......................................................................................189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........................................................................................190

Казан утлары
*№ 6 (1208) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.05.2023, график буенча 31.05.2023, басылып чыгу вакыты 06.06.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-1397. Тираж 5682.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2023 ел



Фирүзә
Җамалетдинова

# КИЛӘ ТЫН СУКМАКТАН ҮТӘСЕМ...

## Юатчы, заманым

Суына көннәрем, ялганга сыена,
Заманмы юл бирә шайтанга, өрәккә?
Шул халкым күтәреп урынын бар иткән
Мөнбәрләр ишелә минем дә йөрәккә.

Анда сүз күшегеп, бөрешеп тарала,
Шомнары җанымда атыла вулкандай.
Мине соң бу җирнең кемнәре ишетсен? –
Ярсыйсың, диярләр, әллә ни булгандай...

Мин хөкем италмыйм беркемне. Хакым юк!
Тик үзем белгәнчә яшәргә теләвем.
Богаулы кулларның, телләрнең бәһасен
Күзаллыйм берзаман кемнәрдер түләвен.

Заманга юл бирү күпләргә килешә,
Чигенү чикләрен билгели кемнәрдер.
Әллә соң җан зәгыйфь?! Күрәсең, безләрдә
Ил йөген күтәрмәс салынкы иңнәрдер.

Шулай да без бар бит, үлмәгән, дигәндә,
Күзенә карарга кыймыймын ирләрнең.
Ни көтәм яфрактай җилпенә-өзелә,
Мин табын бетерә алмамдыр керләрнең...

Яшим дип юл чыккач, кайдан бу өрәге? –
Килә дә баса ул аркылы юлыма.
Юатчы, заманым, өмет ул алда, дип,
Бер яхшы сүздән дә йөрәгем жылына...

---

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА (1960) – *шагыйрә, прозаик; ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һ.Такташ, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Толымлы ай», «Җирбизәк», «Хикәяләр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Туган телем кебек

Калкынмакчы булам – көчем җитми.
Башка суккан саен егылам.
Бу дөньяның кеме дәшә дисәм,
Туган телем икән: «Тор, олан!»

Атлап китмәк булам – сукмак тайгак,
Аякларда җегәр калмаган.
Мин көрәшче булып туган идем,
Җиңелгәнмен бу таш каладан.

Монда ятим телем Тукай сыман
Нидер әйтер өчен тырмаша.
Бер могҗиза бирер сыман Раббым
Киләчәктән – безгә чор аша.

Учак ялкыннары төшә кебек,
Тояк очкыннары көнемә...
Туган телем һаман кисәтә күк:
«Җебемәче, берүк, эремә!

Син егылма, олан!» – Газиз аһәң...
Бик белсәм дә кемнәр җәлләрен,
Ушларымны җыя алмый торам,
Туган телем кебек хәлләрем...

## Мин – дәвам

Мин бик зур авылда туганмын,
Һәркемне бетермим танып та.
Күршемдә яшидер шикелле
Сусылу һәм Түләк, Алып та...

Юлларым тигез үк түгелдер,
Тарихым үткәндер иләктән.
Телемне йотарга куштылар,
Әйттеләр: «Кечкенә милләттән...»

Авылым зур минем! Үзем дә
Шунда дәү күренәм нигәдер.
Туган җир кадерле баласын,
Белмим, ул кемнәргә тиядер?!

Тарихын хәтерли авылым,
Кем әйтә: «Син бик вак милләттән...»
Телем бит үзе бер хәзинә –
Ни генә чыкмас ул келәттән!

Үз йортым – кояшка караган!
Мин һич тә кол түгел, хуҗамын!
Чит җирдә табалмам шикелле
Мондагы бәхтемнең учламын.

Һәр кеше – кунагы, түр әзер,
Булса да ул кайсы милләттән.
Мунчасы ягылыр, мул сые
Табылыр – торачак теләктән.

Кай якта дисезме? Һәр яктан
Карасаң – ул җирнең үзәге.
Киң кырлар, басулар иле ул,
Тауларның юк хәтта сөзәге.

Яшемме? Белмимен – мин дәвам, –
Ниләрдер югалган, табылган...
Мин «Йосыф кыйссасы» сыенган
Сусылу-Түләкле авылдан!

## Агып барам

Бер йомычка сыман агып барам:
«Дөнья матур, – димен, – иркен дә!»
Су бөтерсә бөтерелеп алам
Ашкындыргыч гомер иркендә.

Бозлы упкыннарда батмас өчен
Сүз дәшмимен – телем өшегән.
«Нәкъ бүтәннәр кебек уйлау кирәк –
Сүзләр бер үк бөтен кешегә...» –

Ишетелә өстән. Ә мин – аста, –
Бер йомычка агымсуларда.
Бөтереләм, өшим, әмма агам,
Яз һавасын телим суларга.

Нәкъ үземчә итеп, тик үземчә!
Ташкын көчле: тынны буарлык.
Агымсулар эзне генә түгел,
Ярларымның үзен юарлык.

Бөтерелеп аккан йомычканың
Сарылары судан уңадыр.
Астан өскә карыйм. (Астан – өскә!)
Бер Аллаһым өстә – шуңадыр...

## Бер очкын...

Кемнәрдер учакны яккан да
Сүндерми киткәннәр көлләрен.
Җил искән уңайга кузлардан
Ялкыны чыгара телләрен.

Ялмый ут, ялмый ут дөньяның
Итәге янамы, күлмәге?..
Югыйсә (кем уйлар?) нибары
Бер очкын! Сүнмәгән, көлдәге...

## Уйлану

Җил дә көзгә килеп кергән, йолкый да өзә генә.
Гомерем тавыннан карыйм язмышым үзәненә.
Алмалар коела, диеп, җилкәй, син, утка салма!
Вакыт җитми өзелмәс ул тупырдап торган алма.

...Тәгәрәде алма микән – офыкның аръягына?
Кояш микән? – Күктә иде әле кай ара гына.
Үткәнем эзләп борылсам – йөрәктә яра гына...

***

Ни барлыйм юлларда? Хәтерем бүленә икегә.
Өзелгән, җуелган кайчакта талчыбык күк бөгә.

Ә Вакыт төшергән арага ак калын пәрдәсен.
Каерам пәрдәне: манзара! Кем әрли – әрләсен.

Үзеңнән бер карыш китсәңме – ябыла юллары.
Күперләр янганда ялкынны сүндергән мин бары.

Җил белән җилешәм һаман да, гүя ки көчем күп.
Җиде юл – салават күпере тик минем өчен күк...

## Улыма

Кулларың кулымнан аерылган, улкаем,
Бәйләнгән җепләрне саклыйм күк мин генә.
Мин синле гомремне яратып кичәмен,
Зур бәхет тауларын күтәреп иңемә.

Беренче елмаю... «Әннә» дип әйтүең,
Һәм тәпи китүең – бу бәхет минеке!
Шул көннән керфеккә сөрмәләр тидермим,
Күзгемнең каршыннан алганмын иннекне.

Әнинең куллары җылы һәм йомшактыр,
Әни ул матурдан-матурдыр болай да.
Әнинең күңленнән ургылган яктылык
Башкача табылмас һичкайчан, һичкайда.

Газабы, әрнүе сиңа ят булсын, дип,
Юлларың торсын дип яктырып тоташтан,
Ул нечкә җепләргә мин җил дә тидермәм,
Алар бит догага, йөрәккә тоташкан...

## И кышым...

И кышым, син язны көтәсең,
Ташуга әверелеп юлыңда
Ниләрне кыйратмак итәсең?..

И кышым, ашкынма әле син,
Болай да бу дөнья куркыныч,
Син тыныч чагында мин тыныч.

И кышым, язларны көтмимен,
Хәвефе-хәтәре тетрәткән
Ни калыр әрнүле йөрәктән?

И кышым, син язны көтәсең.
Ә минем ташусыз таңнарда
Килә тын сукмактан үтәсем...

## Без бәхетле идек

Без бәхетле идек. Ул бәхетне
Бөтен дөнья тоеп торырлык.
Хан кызы күк тормыш кичмәсәк тә,
Булганына шөкер кылырлык.

Кулда үргән сетка, – без авылдан
Киткән көнне искә алырлык!
Ә бит аның эре тишегеннән
Төшәрдәе төшеп калырлык...

Күлмәге дә, яулыгы да шунда,
Ни сыйганы – безгә шул җитте.
Ә күңелдән без хан кызы идек,
Куркытмады хәтта җир чите.

Юллар үтеп, еллар үткәнбез бит,
Нидер табып, нидер югалтып.
Бөтенесен бер сеткага салдык,
Берни калдырмадык чүпкә атып.

Тапканыбыз безгә хезмәт итте,
Ярлы булмадык без һәм бай да.
Хан кызыдай яшәп ятуыбыз
Үзебез корган рухи сарайда.

Хан кызлары көнләшерлек күңел...
Ул хыяллар һаман исертә.
Тик көзгегә, әйдә, карама, дип,
Вакыт кына нидер искәртә...

## Яшисе!..

Киләсе бу җиргә, китәсе...
Китәсе! – Нихәлләр итәсе?!.
Кургаштай күңелне эретәсе,
Аннары дөньяны көтәсе,
Гел алга, гел үргә этәсе,
Бәхетне куыплар җитәсе.
Юлымны яктырта көмеш ай
Ташлаган нурларның көлтәсе.
Билгеле, дөньяның мине дә
Каккалый-суккалый биртәсе.

Шуңа да кап-кара төненә
Килсә дә кайчак ут төртәсе,
Сүндерәм шырпымны, өрәм дә, –
Юлымны, дим, дәвам итәсе!
Дөньяны яктыга этәсе,
Көтсә дә алда мең киртәсе,
Тәкъдиргә язылган булса да,
Барыбер бер көнне китәсе –
Яшисе! – Нихәлләр итәсе...

***

Дәрәҗә ул – сүзең үткән мәлдә!
Тик бер караш, бер ым җиткән мәлдә
Кеше белән кеше дус кебек.
Бөтенесе көчкә буйсынадыр,
Кемдер горур, кемдер бик җебек...

Дәрәҗәңне көнең яулап алса,
Урындыгың китсә шуышып,
Кеше белән кеше дус булалмый,
Сүзләр үтми башлый, тупаслана,
Яктылыгы тормый елышып.

Ә көч җитмәвенә килешалмый
Бер ярсыган күңел, бер тынган.
Кеше белән кеше дошманлашса,
Бу дөньяның имән ишегенең
Тоткасы да какшый – тотынган...

## Сүзләргә теләк

Теләк өчен дә түлисе икән безләргә.
Рәхим-шәфкать бирче, Раббым, кайчак сүзләргә!

Утырасы килгән чакта заман түрендә,
Ни хәлләргә төшә алар кеше телендә!

Сүзләр... Сүзләр... Буталган чор яман, изгесе.
Сүзләр... Сүзләр – һәрвакытта дәвер көзгесе.



Нәбирә Гыйматдинова

# ИКЕ РӘССАМ

ПОВЕСТЬ

**1**

«Һай, көйдерәсең дә соң җанны, бәндә баласы! Таң атканда, тәрәзә төбендә ник шыңшыйсың икән син?! Бүтән җыр беткәнмени дөньясында!»

Әй суык, суык, өшетмә мине,
Өшетмә мине, өшетмә атымны,
Өшетмә мине, өшетмә атымны...

Тып-тын җәй иртәсе, шәһәр әле йокысыннан айнырга өлгермәгән, төн карасыннан әкрен генә араланып маташкан кояш, кызыл нурларын кершән итеп, офык читенә сөртә.

Бакый балкон тәрәзәсеннән башын тыгып, аска карады. Сорау билгесе сыман кәкрәйгән берәү нәкъ аларның фатир турысына басып «моңлана».

– Ой мороз, мороз...

Тротуардан шалдыр-шолдыр кул арбасы тартып килгән урам себерүче Низам аңа акырды:

– Нәстә таң тишегеннән улыйсың! Ничәнче көн пудрәт! Ну-ка, ычкын моннан! Себерке белән сыртыңны каезласам, сразы морозлан җылынырсың!

«Сорау билгесе» әз генә дә гәүдәсен турайтмыйча каршыдагы балалар мәйданчыгына борылды. Таныш кебек иде ул... Җырлавы да Бакый өчен бит! Аның йөрәген яралыйм дип җырлый. Адресны ничек тапкан! Һи, сермени ул бу заманда. Бакый Уразов – билгеле рәссам, мактануы түгел, ярты Казан аны таный. Әгәр рәссамнар берлегенә шалтыратсалар, ничәнче йортта, ничәнче фатирда яшәгәнеңә хәтле әйтеп бирәләр.

Ул киенеп, «җырчы» артыннан бармакчы иде, сак йокылы хатыны уянгач, җәлт кенә кәчтүмен урындык башына элде. Мәдинә хәзер:

---

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА (1956) – *Татарстанның халык язучысы; «Мәхәббәттә гөнаһ бар», «Икебезгә дә авыр», «Үзем генә беләм» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

– Ашамый-нитми кая чабасың? – дип сукраначак.

Әгәр мышкылдамаса, аягын сөйрәтеп кенә атлаган «сорау билгесе»н җиле белән дә куып җитәр иде. Хәер, икесе дә бер чама бугай, Бакыйның да тез буыннары ватык гармун сыман шыгырдый, җитмешнең кибәнен очлагач, бик сикертми икән шул.

– Чәең кайнаган арада һава сулап керәм әле, – диде ул. «Һава» сәбәп кенә, чын дөресе эчен пошырган «табышмак» иде, ә аның җавабы теге җырчыда. Кем син, атсыз-исемсез бәндә баласы? Нишләп син ничәнче көн рәттән аларның тәрәзә каршысында түләүсез концерт куясың? Җырың белән бәгырьне телгәләп, йа?

Ул урам себерүче Низамны кул күтәреп кенә сәламләде. Туктасаң – харап, ир үзен йорттагы бөтен халыкның якын дусты саный, санаса гына икән, очрадың исә зыр-зыр тел тегермәне ташын әйләндерә, ир-атмы, хатын-кызмы, бала-чагамы – аңа барыбер, сөйләш кенә, чур, сөйләшмә дә, тыңлап кына тор!

– Бакый әфәнде! – Себеркесенә атланып очтымыни, Низам килеп тә җитте. – Бу йортта бердәнбер кеше – Бакый гына «әфәнде» статусына ия иде. – Сез укыдыгызмы гәҗиттән, японнар нишләтә, ә? – Ир кесәсеннән кәгазь кисәге тартып чыгарды. – Менә-менә, фамилиясен дә яздым, Юсуха Марита дигән галим картлар белән көрәшмәкче. Алар, ди, яшьләргә комачауламасын өчен үз-үзләрен үтерергә тиеш. Аларга пенсия түләп, ил күтәрәмгә кала, ди. Бу хакта ни уйлыйсыз, Бакый әфәнде?

Кешенең ни уйлаганын сабыр гына көтәмени, «тегермән ташы» бар куәтенә әйләнә:

– Алдынгы милләт дибез инде Японияне, вәт сиңа мә! Хәерче Африка илләрендә дә болай кыланмыйлар. Аллаһ кына тудыра, Аллаһ кына үлем сәгатен билгели, шулаймы, Бакый әфәнде? Моныңише мөртәт галимне бездә черек бау белән асарлар ие, шулаймы? Бездә картларга почёт, яшьләргә ачык юл!

Бакыйда җәядән атып чебен борынына тидергән мәргән күзе иде, ул яртылаш аска бөгелеп таганда атынган ир-атны шәйләп:

– Чү әле, чү, шыпырт, агай-эне, – диде. – Турыга кара! Таганда тирбәлгән кеше синең танышыңмы әллә?

– Ә-ә, тегеме? Бер адашкан сәрхуш кисәге! Иямәште тәки минем территориямә. – Урам себерүче гайрәтләнде. – Йокыгыздан уятып, тагын уласа, суктым-ектым себерке белән! Җыры да үзе төсле өтек-төтек.

– Җыры әйбәт аның. – Карт рәссам үзалдына йөткерде. Хәерсез, дулкынласа, муен тамыры бүрткәндәй, тамак төбе төерләнә. Танышыңмы, имеш! Ул бәндәне Низамга гына сылар идең дә, юк шул, бәндә синең чакырылмаган кунагың бугай. Инде тәмам инанам дисәң – үзеннән сора!

– Себеркеңне бир әле, агай-эне.

– Сәрхушне кыйныйсызмы, Бакый әфәнде?

– Иптәшкә!

Бу аның «чире» иде. Кулда һәрвакыт нәрсәдер булырга тиеш! Кул буш тормасын. Әфган тауларыннан башланды ул «чир». Алар йоклаганда да, автоматын ычкындырмады. Аксап-туксап йөрмәсә дә (хәер, соңгы елларда

уңга-сулга авыштыра), ишек катында алмаш-тилмәшкә ике «аяк» сөялгән. Урамда – таяк, остаханәдә – кылкаләм... Шундый-шундый хәлләр!

– Мәгез, Бакый әфәнде, түлке очын сындырмагыз, фчүтеки хөкүмәт әйберсе.

«Мондый Низамнар белән ил беркайчан да хәерчеләнмәс. Йа, көлмә, картлач, үз хәлеңне бел!»

Ул якынлашкач, адәм аягына басып, таганын очыртып җибәрде. Баганадан сирпелгән ут яктысында аның йөзе ап-ачык күренә һәм бу йөз җыерчыклар белән «бизәлсә» дә, аның иясен миллионнар арасыннан танырга мөмкин иде. Күңеленең бер чите белән сизенде югыйсә Бакый.

– Синме, Алик?

– Точно мин, Баки дәдә.

– Нишләп болай сакал-мыек үстерден? Ник синең өстең-башың пычрак? Ник син салмыш? Соңгы сорау: син Себердә идең, ник безнең тирәдә чуаласың?

Сәрхуш ыржайды:

– Сине сагынып кайттым, Баки дәдә!

– Сагынуың шул хәтле көчле, тәрәзә төбендә тамак ертасың. Әтиеңнең рухын рәнҗетеп җырлама әле ул җырны! – Бакыйның ачуы кузгалды. Кузгалыр да, төннәр буе хатирәләрең кузгатып ят та! – Ул җыр синең ише исерекбашка төс түгел.

– Җырлама дип, авызыма сук, давай.

– Сугып, ни файда! Бүтән җырлама!

«Сорау билгесе» тураерга маташып, таган чылбырына тотынган иде, тотрыгын югалтып, йөзтүбән егылды. Аяк астында кеше аунатасыңмыни, Бакый аны беләгеннән тартып торгызмакчы иде, сәрхуш ирнең күлмәк җиңе умырылды. Черек! Сәләмә!

– Кузгалма, мин хәзер, – диде ул, хәле китеп.

Иште ишәк чумарын! Исерек кешенең гәүдәсе икеләтә-өчләтә авырая, болай да зәгыйфь кулбашының сөяге чатнагандай сызларга тотынды. Пычак белән кисәләрмени! Элеккеге яралар үзенә, картлык үзенә сиздерә.

Хатыны аш бүлмәсендә иртәнге тәгам әзерли, ул ишетмәсен өчен Бакый әкрен генә шкафтан озын җиңле күлмәк белән свитер, тартмадан акча алды һәм ачкычны чыкырдатмыйча гына борып, тыштан ишекне япты. Подъезддан чыгу белән Низам аның каршысына йөгерде:

– Бакый әфәнде, себерке кая, себерке?! Хөкүмәт әйберсен миннән түләттерәләр.

– Тузса дамы?

Бу елаткан да, көлдергән дә иртә иде.

– Тузса, списәйт иттерәм.

Кояш инде табак битен балкытып елмая, халык уянып, инде эшкә ашыга, ә Бакый кинәт кенә өстенә боз яудырган соры болыттан ничек котылырга белмичә угалана. Рәссамнар берлеге рәисе Рамил: «Сигезгә остаханәңә киләм», – дигән иде, ул буш йомыш белән йөрмәс, соңармыйсы иде. Бу җәфадан тизрәк котылсаң гына. Җәфа... Нишләдең син, Минәхмәт малае, бүгенге каты бәгырьле заман сине дә үзгәрттеме әллә? Комда аунаган бу бәндә чит кеше баласымы? Авылдашың Роман абыйның улы бит ул.

Сине Газраилдән саклаган командирның нәсел дәвамы! Өеңә чакырып, юындырып-киендереп, тамагын туйдырсаң, дәүләтең кимер идеме?! Дөрес, син Романга биргән вәгъдәңне арттырып үтәдең. «Аллага шөкер», – дип тынычлап яшәгәндә генә, менә сиңа мә, сюрприз! Димәк, нәрсәдер эшләнеп бетмәгән. Бөкрене кабер генә төзәтә, диләр, ә рухи бөкрене нәрсә белән төзәтәсе? Тел беләнме? Монда ата каешы кирәк шул, ата каешы! Ә Бакый бу адәм баласының матди ягын кайгырткан химаяче сыйфатында гына иде.

Җилкәсе үтереп авыртса да, карт «чакырылмаган кунак»ны (хәсрәт «кунак»ны!) сөйрәп диярлек тәбәнәк эскәмиягә китереп сөягәч, комга буялган өс-башын каккалап:

– Төсмерләп кенә танырлык сине, утыз елда шайтанга әйләнгәнсең, – диде.

– Җырлыйммы, Баки дәдә? Ой мороз, мороз... ха-ха, нервыңа тия, да, картлач? Әти үлгән, син исән. Ник алай? Не морозь меня, моего коня... Татарчасын да ятлаттырган идең, картлач. Әй, суык, суык, өшетмә мине, өшетмә мине, өшетмә атымны...

Себерке белән авызына ямаргамы әллә? Чү, сабыр ит, Бакый, кызма.

– Болай итәбез, энем. Менә сиңа чиста күлмәк. Башта гомуммунчада юын, сакал-мыегыңны кырдыр, менә сабын-мунчалага акча. Монысы... – Карт конвертны бөкләп, ирнең чалбар кесәсенә тыкты. – ...билетка. Бүген үк Себергә кайтып кит. Хатының янына.

– Ха-ха, катын үтүт! Өченчегә үләнгән ием, аерылыштык без. Квартирдан куды катын. Афган герое малае – бомж! Җырлыйммы, дәдә? Ой мороз, мороз... – Сәрхушнең сәдәф төймәсе хәтле генә күзеннән зәһәр очкыннар чәчрәде. Айныды! – Квартираңны алыштырып, эз күммәкче идеңме, дәдә? Таптым мин сине, дәдә! Атаклы художникның адресы белешмәләр бюросында бар. Баш эшли герой малаеның!

Себеркесен кочаклаган Низам:

– Ярдәм кирәкме, Бакый әфәнде? – диде. – Сезгә бәйләнсә, суктым-ектым моны!

– Тимә, хәзер китә ул, агай-эне. Мин дә өйгә керәм.

Сүз куертуның мәгънәсе юк иде. Ләкин сәрхуш тигәнәк сыман йөрәккә үк ябышты.

– Стоп, дәдә! Мин сәвсимгә малай янына кайттым. Күрештер аның белән!

Низам колагын шомрайтты:

– Ниткән малай турында әйтә ул, Бакый әфәнде?

– Җә, агай-эне, себерәсен себер син. – Монда шаһитлар артык иде. – Саташа җегет.

Алик ертык күлмәген салып ыргытты:

– Саташмыйм, минем Серго исемле малаем бар! Аның белән күрештерәсең, дәдә!

Бакый аны якасыннан тотып селкетердәй булды:

– Юк синең малаең! Юк!

«Кадерсез кунак» чалбар кесәсеннән конвертны ертып, акчасын санагач тел шартлатты:

– Ого, юмарт син, дәдә! Себерләре себерелсен, Казанда малай белән

яшим! Мин аңа тугач та кәтүк кушаматы тактым. Аңа утыз бер яшь бүген. Дөресме? Очрашу хөрмәтенә кәтүкне ресторанда коньяк белән сыйлыйм. Давай, адресын яз!

«Дәдә» эчтән генә үзен әрләде. «Кем белән сүз көрәштерәсең, сантый? Сусыз чиләк белән янгын сүндермиләр. Анықы түгел, синең улың ни дияр бит әле. Әгәр ул: «Нишләп минем өчен хәл итәсең, дисә?»

– Син, дәдә, кәтүкне урладың, син карак! Прокурорга жалу язам, төрмәдә черетәм мин сине. – Сәрхуш тәмам канатланды. – Тугыз айлык баланы яшердең бездән!

– Карале, күке ата, – Бакый хәсрәт «кош»ның янбызына төртте. – Иртәгә Толстой бакчасына кил, шунда минем улым белән күрешерсең! – «Минем» дигәндә, аның тавышы калай кебек чыңлады. – Мәгәр исереп килсәң, мин сине әнә теге урам себерүченең «кыйммәтле» себеркесе белән чүплеккә себереп түгәм! Шылдымы?

Аягына тимер божра таккандай, карт рәссам өенә керсә, хатыны киенгән-ясанган, мәктәпкә җыена иде.

– Аллам, озак! Казанның бөтен сөремле һавасын синнән генә сулаталар, ахры, – диде Мәдинәсе. – Боткаң суына, җылы килеш аша. Төнлә бик боргаландың, тагын кулың сызладымы?

– Сызлар да туктар. – Карт рәссам иртәнге мәхшәр турында сөйләп, хәләленең кәефен бозмады. – Алда үзгәрешләр көтелмәгәе әле, – дип кенә куйды.

– И Аллаһның рәхмәте, ниһаять, өйдә генә эшләргә ниятлисеңме, әтисе? Фатир иркен, өч бүлмә, рәхәтлән! Картаймыш көнеңдә нәрсәгә ул остаханә!

– Ә сиңа мәктәп нәрсәгә, Мәдинә?

– Анда минем укучыларым. Ярар, бәхәсләшмик, хәерле эш сәгатьләре сиңа! Ишекне бикләргә онытма, Бакый!

Һәркемнең үзенеке: укытучыга – мәктәп, ә рәссамга остаханә кадерле. Чөнки яшәткән-дәртләндергән, гомерен озынайткан иҗат рухы белән дөнья бәһасе дуслары шунда. Бу «визитёр» бер ритмга салынган тормышын бутап ташлагач, ботка ашалмады, чәй эчелмәде, аннан да хәтәррәге – күңелдә бер генә дә яңартырга теләмәгән хатирәләр уянды. Рамил Зәйнулла төгәл кеше, сигездә диган икән, сигездә килер, тик Бакый аны каршы алырга җитешмәс, соңарыр. Картлачның йөрәге түтенсез яна! Телефоннан гына ни-нәрсә аңлатасың, аңа кичекмәстән улы белән күзгә-күз карап сөйләшергә иде.

...Хастаханә ишеге төбендәге сакчы хатын аның юлын бүлде:

– Абзый, бездә карантин! Эчкә узарга ярамый. Нинди йомыш сезнең?

– Баш табибның әтисе без. – Бакыйның тавышына хәтле зәгыйфь иде.

– Ой, гафу итегез! Хәзер, сәркатибенә шалтыратам. – Сакчы кулындагы трубкасының төймәсенә басты. – Солтан Бакиевич үзендәме? Обходтамыни? Ой, әнә ул!

Артыннан көтүе белән фәрештәләр ияртеәнмени, коридор башында Солтан күренде. Кул селкегән Бакыйны күргәч, егет ак халатлар төркеменнән аерылып, аңа табан атлады.

– Әти?! Чирләдеңме әллә? Кулың сызлыймы? Ятып дәвалан дидем мин сиңа, әти!

– Юк өчен борчылма, улым. Рәссамнарның һөнәри чире ул, йөрәктән алда кул бетә.

– Әти, син бүген ике ат җиккәнсең!

Бакый шунда гына абайлады, ике таягын да тоткан икән. Өченчесен култыгына кыстырасы гына калган. Тәмам зиһенен чуалтты теге бәндә.

– Пар ат белән тизрәк юыртасың бит, – дип шаяртты ул.

Сакчы хатын читкәрәк китеп басса да, карт пышылдап кына:

– Сүз бар, улым, – диде. – Утыз елдан соң су төбеннән Алик калыкты.

– Кем, кем, әти?

– Синең атаң, улым.

– Мин андый кешене белмим, әти. Минеке – каршымда. – Солтан табиблар көтүенә ымлады. – Мине көтәләр, бүген өч операция. Кич хәбәрләшербез, әти.

– Улым, иртәгә Толстой бакчасында икегезне... – Җөмләнең койрыгы өзелде. – ...очраштырырмын дигән идем.

**2**

Кыр кәҗәсе кебек агач баскычтан ике генә сикерде Авзал. Артында шыгырдап, урам ишеге ябылды. Бакый Уразов! Очлы таягын идән тактасына кадый-кадый, икенче катка менә. Егет борылып исәнләшмәде, картлач та яшь коллегасын күреп өлгермәгәндер. Нишләп бу бабай халкы (алар өчәү иде) олыгайгач та, эшем кешеләре кебек көн дә остаханә юлын таптый икән? Гомеребезне очлаганда да, шедевр тудырабыз дип хыялланалар, ахры. Чынбарлыкка хилафлык китермичә реалистик әсәрләр сырлый-сырлый, бармаклары кәкрәйгән абзыйларга алмашка яшьләр үсте, бүген рәсем сәнгатенә алар хуҗа! Ике-өч буын арасында күк белән җир аермасы: дөньяны бүтән төрле итеп күргән, бүтән төрле уйлаган, бүтән төрле фикерләгән Авзаллар тиздән карт-корының искелек исе аңкыган картиналарын күргәзмә залларыннан кысрыклап чыгарып, заманга яраклаштырган абстракт сурәтләр тезәчәк. Малевичның йөз еллык «Кара квадраты» әнә нишләтә: кемдер аны бөек иҗат ди, ә кемдер «пүчтәк» дип яманлый, ә үзе сихерләнгәндәй, шуннан күзен алмый.

Авзалның эчен пошырган икенче бер нәрсә: бүлмәсе иде. Кечкенә, тар һәм ямьсез! Анысы да әрсезлек белән генә яуланды. Мөнир Садриев атлы рәссамның вафатыннан соң егет гариза язып, берлек рәисенә керде. Бакый Уразов хуҗа янында утыра иде, нәкъ менә ул тәгәрмәчкә таяк тыгып маташты:

– Мәрхүмнәрнең җаны кырык көн каңгырап йөрер, ди. Мөнир яшьти остаханәсен ярата иде. Куна-төнә эшләгән чаклары булды, кайтса – бүлмәсенә кайтыр. Аның әле анда картиналары шактый, кызы җыештырсын башта.

Рәис тә, картны җөпләп, баш какты.

– Сабыр ит, Авзал. Син безнең өметле рәссам. Идарәдә иң күп макталганы – син. Шулаймы, Бакый ага?

Ага көлемсерәде.

– Соңгы вакытта утырышлар Авзал Сәлимов исеме белән башлана, Авзал Сәлимов исеме белән тәмамлана. Егетне чамасыз мактап бозмыйк тагы.

Берлек җитәкчесе:

– Бүлмә мәсьәләсендә Мөнир абыйның туганнары әйберләрен алгач уйлашырбыз, – дигәч, егет тиз-тиз башындагы компьютерын «кабызды». Көт һавадагы торна очып, учыңа кунганын! Ул сәләмәләр кайчак алына да, болар кайчан уйлаша! Өч айданмы, ярты елданмы, бер елданмы? Юк, абзыйлар, калган эшкә кар яудырмагыз әле сез. «Изге ялган»ны кулланырга, мөгаен.

– Фатир хуҗасы куа. Эскизларымны вокзалдагы саклау камерасына илтәм инде.

Ялганын көчәйтеп, борынын да мышкылдаткач, аны җәлләгәннәр иде.

– Ачкычы миндә, – дип, Бакый Уразов аны үзе белән ияртеп китте. Бүлмә бик кечкенә иде, ул бер күрүдә үк Авзалга ошамады. Әмма ни диярсең, өлешеңә тигән – көмешең. Танылган рәссам Садриев абзый шушы куышка сыйдымы икән? Әйтәләр шул: өлкән буынның бөтен «хәсрәте» – сугыш уты кабынмасын. Ачлы-туклы тормышка да риза алар. Ә егет кыска гына гомерендә кысанда кысылып, тарлыкта тараеп яшәргә теләми!

– Энем, без күршеләр синең белән, мәрхүмнең әйберләрен миңа күчерик. – Карт рәссам аңа чүпрәккә таккан ачкыч бирде. – Бүген үк картиналарыңны ташы.

Күршесе иң майлы калҗаны эләктергән: аның ике тәрәзәле бүлмәсе фатир хәтле иде. Уң почмакта тәбәнәк суыткыч, түрдә үк өстәл, дивар буенда йомшак диван. Арысаң – сузылып ятып ял ит! Кышкы суыкларда йоклап та кал! Беркем дә якты дөньяларга мәңгелеккә килмәгән, Бакый Уразов та картаеп хәлсезләнгәч, остаханәсенә йөрмәс. Менә шул чакта Авзал берлек хуҗасыннан рөхсәт сорап вакланмыйча «хан сарае»на күченер. Тик абзый картаерга ашыкмады, инде ун елда бөредәге өмет яфрак та ярмыйча саргаеп кипте. Бүлмә һаман бушамады. Бакый карт кынамы, аның ике дусты – Гомәр Гаязов белән Бәшир Хисамовлар да кендеге белән остаханәгә береккән. Бу өчәү азау ярган урман бүреләре кебек иде. «Өер башлыгы», әлбәттә, Уразов, дуслар аңарда җыела, өчесе дә идарә әгъзасы, күп кенә проблемалар «берлек»кә кадәр, шушында хәл ителә бугай.

Бакый абзый «сине дә оямa сыйдырам» дидеме, беркөнне аны панорамалы картинасын бәяләргә чакырды. Сабантуй күренеше иде ул. Халык ураткан мәйдан уртасында ирләр көрәшә, ә арткы планда бүрәнә өстендә ике егет капчык белән сугыша. Икесенең дә баш түбәсендә кәләпүш. Биленә таянган Авзал:

– Яшь егетләргә ник түбәтәй кигездегез? – диде. – Түбәтәй татарның мескенлеген күрсәтә. Ул сәләмәдән котылырга безгә. Төркия патшасы Ататөрек беләсезме нишләгән? Кара баулы калпакны тыеп, Аурупа үрнәгендә киң кырлы эшләпә, костюм-чалбар кияргә дигән закон бастырткан.

«Өч бүре» тешләрен шакылдатып, аңа ташланырга тиеш иде. Чәйнәп өзсәләр дә, сүз юк, ул бит татарның иң изге әйберенә кизәнде! Ләкин абзыйлар аның тәнкыйтен уен-көлкегә генә борды.

Бәшир Хисамов Бакыйның башындагы яшел түбәтәен сыпырды:

– Менә кем ул, искелек калдыгы! Сал каз ояңны!

– Ки салам эшләпә! – диде Гомәр Гаязов, кеткелдәп.

Алдында көлештеләр, ә артында тиргәделәр. Ачык ишектән барысы да ишетелде: Бәшир белән Гомәрнең чыбыркысы каты шартлады:

– Яшь тай ничек тибенә!

– Мокытлар үсә!

– Таш тишкән әрсез чүп үләне!

– Әдәпсез!

Гәрчә, Авзал нәкъ менә Бакый Уразовның маңгаена чиртсә дә, гаҗәп, ул егетне яклады:

– Яшь чакта без дә калай әтәчләр идек. Койма биек, тавыш – гайрәтле. Без талант, өлкән рәссамнар уртакул дип төкерек чәчтек. Дөнья бабай үз җае белән урыныңа утырта, коймаңны тәбәнәйтә, кикригеңне шиңдерә. Авзал безнең кебек беркатлы авыл малае, читкә тибәрмик без аны, яшьтиләр.

Авзалга көлке иде. Улмы беркатлы?! Юк, ул кәбестә кебек катлы-катлы. Егет биш былтыр ук җаныннан туган авылын тамчысына хәтле сыгып чыгарды. Яшь рәссам хәтта шәһәрнеке дә түгел, Авзалның ватаны – Җир шары! Ул – космополит! «Өчлек» белән нинди уртаклык булсын ди, егет үзе алардан читләште. Аның каруы Тәүфыйк Зыятдин белән «ботка пеште». Кайчан карама кәҗә сакалын бармагы белән тарый-тарый, коридорда киләп сарып йөргән рәссам иҗат дип пошынмый, аның ярты ел элек башлаган эше нибарысы өч сызыктан гына гыйбарәт, зары да һаман бертөрле иде:

– Уч тутырып гонорар түләсәләр, маңгай тиреңне агызып эшләр идең. Безнең хезмәт шалкан бәясеннән дә җүнрәк. Ник чиләнергә ди!

Аны сәүдәгәр малае ашата, имеш. Дан-шөһрәтләргә ирешмичә тамак өчен генә яшә инде, ә! Тәүфыйк абзыйның да бүлмәсе ат биетерлек зур.

– Алайса нишләп үз көегезне генә көйләп, өегездә ятмыйсыз? – диде Авзал шелтәләгән төсле. «Шундый остаханә биләп», – димәкче иде дә, яхшысынмады.

– Минем монда көем көйләнгән. – Рәссам Бакый ишегенә ымлады. – Яшьтиләр белән күңеллерәк миңа.

– Сез дуслармыни?

– Ни дус, ни дошман, урталыкта без. – Тәүфыйк Зыятдин тагын «өер башлыгы»ның ишегенә ишарәләде: – Син, кара мыек, кара каш, миннән гайре берсеннән дә фикердәш эзләмә! Алар сиңа көндәшләр, аңыштыңмы?

– Рәхмәт, – диде Авзал, бу агач йортта аңа дус та, фикердәш тә кирәкми, Тәүфыйк абзый белән берлектәге яңалыкларны белеп тору өчен генә аралаша иде. Ул «урман бүреләре» кебек идарә әгъзасы икән, кайда күргәзмә оештырыла, кемгә мактаулы исемнәр бирелә, кем ял йортына юллама белән бүләкләнә – барысын да түкми-чәчми минуты-сәгате белән кайтарып аудара.

Ә бүгенге «хәбәр»не берлек җитәкчесе үз аягы белән китерде. Ярты ай элек кенә сайланган Рамил Зәйнулла иде ул. Корылтайда өч төркемгә бүленгән рәссамнар һәркайсы үз намзәте өчен «көрәште». Тәнәфестә кандидатларның икесе Авзалны да «эшкәртеп» маташты.

Беренчесе:

– Мине сайласаң, картиналарыңнан төсле альбом эшләттерәм, – дисә, икенчесе вак-төяк вәгъдәләр белән чикләнмәде:

– Фамилиямне тамгаласаң, киләсе елда Тукай премиясе кесәмдә дип сана!

«Фикердәш» Тәүфыйк Зыятдин терсәккә орынып:

– Өчесен дә шытырдатып сыз! Өчесе дә файдасыз зат, – диде.

Рамил Зәйнуллинны сызмады ул, аның программасы кызык, анда яшьләр өчен (ә Авзал яшь!) нинди генә проектлар каралмаган, һәммәсе дә аңа аталган кебек иде. Әрсез көндәшләр чатыр чабып «тавыш» җыйганда, Зәйнулла: «Җәмәгать, мин иңнәремдә дөнья йөген күтәрдем, миңа бәрелмәгез!» – дигән кыяфәт белән бу тамашаны гел читтән генә күзәтте. Мөгаен, ул җиңәчәгенә ышана иде. Корылтай аны сайлады. Моңарчы төрле чараларда очрашсалар да, кул биреп исәнләшерлек дәрәҗәдә танышлык юк, чөнки Рамил, ил-көндә танылса да, гади рәссам гына иде, ә бүген ул берлек хуҗасы! Элеккеге рәис Авзалга хәерхаһлы иде, премиясен кызганмады, һәрдаим күргәзмәләрдә картиналарын элдерде, грантлар бирдерде. Ә монысына якынаер өчен бер адым атламасаң, бөтенесеннән дә мәхрүм калуың ихтимал. Кайчакта, башыңны иеп, ата казны да сәламләрсең! Ялагайлар яңа рәисне сырып алырга өлгергәндер инде. Әллә күршесенең кулы белән «алтын балык» эләктерергәме? Рамил картлач янына еш килә, һәм аңа «остаз» дип эндәшә. Якын итә, димәк. Училищеда укыганда, Авзалга «гений» диләр иде, инде син гений башың белән йөз суыңны түгеп: «Бакый ага, безне берлек җитәкчесе белән әйбәтләп таныштыр», – диярсеңме? Горурлыкның җиде кабыргасы берьюлы сыначак бит!

Зәйнулла каршысына атылып чыкмады егет. Бакый Уразовның ишеге гадәттәгечә шар ачык, ул аның кырыеннан: «Сездә эшем юк» кыяфәте белән үтеп китмәкче иде, карт аны үзе «эләктерде»:

– Авзал, кер әле, кер!

Рәис җиңел генә урыныннан кубып, Авзалга кулын сузды:

– Ни хәл, дус?!

Әкәмәт, моңа бер дә түрәлек чире йокмаган. Урындыгыннан кузгалмыйча гына сәламләсә дә, гаепләмәс идең. Хуҗа бит! Костюм-күлмәк киеп, галстук тагасы кеше футболка белән джинсы чалбардан! Ә баш түбәсендә... яшел кәләпүш!

– Син дә тыңлап бак әле, Авзал. – Бакый карт аны түргә әйдәде. – Рамил безнең идеяләр казаны, көн дә яңалык аңарда.

– Иске яңалыкларны яңартырга исәп. Рәссамнарда ярыш дәрте уятасы иде. – Рамил Зәйнулла һәр җөмләсеннән соң пауза ясады. Яңалык икән, ул тиз-тиз әйтелсен! Авзал, мәсәлән, өтерсез-ноктасыз бер сулыштан сөйләп ыргытыр иде.

– Татарлар тормышын сурәтләгән оригиналь әсәрләргә конкурс дип күзаллыйм мин аны. Шул хакта синең белән киңәшмәкче идем, Остаз.

– Безнең җыр җырланган инде, шәкерт. Син менә боларга... – Бакый карт Авзалга күрсәтте. – ...яшьләргә таян, аларның фикерен бел.

– Аксакалларның хәер-фатихасы белән башланган эш уңа, диләр, Остаз. Дөресме, Авзал?

Егет аяк очы белән идән тактасын «казыды», ул берничек тә рәискә «әйе» дияргә тиеш түгел, бүгенге заман дилбегәсе Авзаллар кулында, алар рәсем сәнгатен тамырдан үзгәрткәндә, өлкән буын койрыгын кыссын!

Бусага төбендә карт «бүреләр» өелешкән иде. Диварның колагы бар, ахрысы, тычкан кыштырдаса да, ишетә. Хәер, Остаз белән шәкерт микрофоннан сөйлимени, тавышлары бөтен коридорга яңгырый.

Бәшир Хисамов:

– Шәп нәрсә уйлагансың, Рамил энем, – диде. – Җиңнәрне сызганыгыз, җегетләр! Алга, җиңүләргә!

– Остаз гына безнең җыр җырланган, ди. – Рәис нигәдер боеккан Бакый абзыйның җилкәсеннән шапылдатты. – Син күпме шәкертләр үстереп очырдың. Питерда – синекеләр, Лондонда – синекеләр... Даны миңа димәдең, аларга дидең... Хәтерлисеңме, берсендә бармагыма суккан идең?

Бакый картның сагышлы йөзенә елмаю җәелде.

– Буяуларны буташтырдың син, малай!

Барысы да дәррәү көлешкәндә, Авзал кармагын күлнең уртасына ук чөйде. «Шаяртыгыз, шаярт! Алтын балык берегезгә дә тәтеми, ул – минеке!»

– Бәйге турында белдерү эләрбез, – диде Рамил Зәйнулла. – Олыгыз-кечегез катнашасыз! Син дә, Остаз! Әле җырың җырланмаган!

– Хәлсез карт бүре аудан, һич югы, аксак куян булса да тотып кайта, яшьти.

Гомәр Гаязовның мәзәген тыңлап бетермәде егет, халык гөрләшкәндә, куышына сызды. Ул шедеврга тиң абстракт картинасын күз йомган килеш тә күрде: татарлар тормышыннан, дисезме? Рәхим итегез, менә сезгә милләтнең иң чибәр кызы – Сафия туташ. Хәзер аны ничек тә натурщица роленә күндерәсе. Киреләнмәс, чөнки туганнан бирле Авзалны үзенә өйләндерергә хыяллана.

**3**

...Җаныңнан тынычлык югалса, иҗат куыгының филтәсе пылт итеп сүнә. Бакыйга таныш бу халәт. Кул эшкә бармый, үтереп эч поша. Аңарда аксак куян тотарлык кынамы, аю ботарларлык көч-гайрәт бар. Үз гомерендә ул дүрт йөздән артык бала тудырды. Ир-ат бала тудырамыни, вәт сантый карт, диярләр. Юк, акылы таралмады Бакыйның, күз нурын түгеп, газап кичереп тудырган картиналарын ул «газиз балаларым» дип атый. Гарипме алар, сау-сәламәтме, аермыйча, һәммәсен тигез яратты рәссам. Соңгысы – иң төпчек сабые күңел бишегендә тирбәлә. Шуңа керешәм дип канатланганда гына, Алланың рәхмәте, бәйге игълан итте шәкерт. И син, җете төсләрең белән хәтергә сеңгән балачак: кыр-басуларда ашлык урылып сuктырылган, авыл халкының ярлырагы «уфалла», хәллерәге ат арбасына төяп, тегермәнгә капчык-капчык бодай илтә. Ә буа кырыендагы тегермән хуҗасы – әтисе Минәхмәт. Әүвәл ул җиңел кулдан үзенең өлешен тарттыра. Чөнки ерак бабаларыннан ук күчкән «багышлау» йоласын башкарасы. Сәер йола, билгеле, ир баланы чирәмгә бастырып, баштанаяк он тузаны белән «коендыралар». Бабасы шулай «багышланган», әтисе шулай... Инде чиратта – Бакый, әтисе кеше инде аңа кушучлап он сибә... Чәч ап-ак, керфек ап-ак, авыз-борын ап-ак... Гүя күктән кар ява. Нәсел дәвамы «багышланды», үскәч, ул әтисен алыштырачак. Кем тегермәнгә хуҗа? – Бакый хуҗа! Әнисе Бибизәйнәбнең исә мәшәкате икенчерәк, ул «әпәй туе»на әзерләнә: былтыр ук әрәмәлектән җыеп киптергән колмак алкаларыннан табигый чүпрә

әчетә. Мич башындагы савыт «чыш-пыш» авазлары чыгарса – әчеткеч җитешкән! Аны кисмәккә бушатып, он белән изәсе дә төнгелеккә «кунарга» калдырасы. Ә иртән могҗиза: пырдымсыз камыр күпереп ташый. Мич инде ягылган, күмере тартылган, әнисе җитез генә онда әвәләнгән йомры кисәкләрне калай табакларга салып, кызу таш өстенә тезә... Ә исе! Ызбада нинди ярык-тишек бар, шуннан һуштан яздырып, урамга ипекәй исе тарала. Бу үзенә күрә «сигнал»: әһә, Бибизәйнәб «гатавый». Әби-апаларның кайсы кәнфит-прәннек, кайсы әҗмуха чәен кыстырып (юклык заманы!), тегермән мәйданына агыла. Җиз самавыр кайнагач, чирәмгә ашъяулык җәелә... Әтисе күкрәк турысына куеп, әпәй кисә һәм күрше авылдагы умартачыдан даруга гына дип сораган балын телемнәргә ягып, балаларга өләшә. (Бакый үскәндә, бал дефицит иде. Бүген генә ул кибеттә – «бал», базарда – «бал». Хуҗасы аңа шикәр комы кушамы, манный ярмасымы яки крахмалмы – үзе дә белмидер.) Чәйләр эчеп, догалар кылынгач, яшьрәк хатын-кызлар Бибизәйнәб апалары тирәсенә сырыша. Ул авылда калфак-кәләпүш чигү остасы, аңа Ташкенттагы сеңлесе посылка белән бәрхет тукымалар, тишегенә черки мыегы калынлыгында гына энә сыярлык вак-вак пыяла ташлар, мүлин җепләре җибәрә. Әнисе «әпәй туе»на шуларны да алып килгән, бичәләргә һөнәрен күрсәтмәкче. Оста барда телеңне генә түгел, кулыңны да тый икән:

– И, бу җиңел ич. Мин дә чигәм, каяле, Бибизәйнәб түти! – дип очынган күрше килене, бармагын энә белән чәнчеп, үрле-кырлы «сикерә».

Баллы ипи ашап, тамагын туйдырган малайлар, тегермән тынган арада чумып-чумып, буада йөзә...

Әби-апаларның моңлы җыры, яңгыр тамчыларыдай, су өстенә чәчри...

Акмаган суның дулкыны
Чи утынның ялкыны.
Дәрман бетте, дәртем дә юк,
Сүнде йөрәк ялкыны...

Киндердән моң ишетелми, син аны ничек сурәтләрсең икән, диярләр. Әтисенең күз карашында чагылыр ул... Бакый аның өметен үтмәс кайчы белән кисте. Кисте генәме, нәсел йоласының тамырын корытып, Казанга – сәнгать училищесына укырга китте. Качып китте. Колхозның бәрәңге төягән йөк машинасы Чистайга бара иде, егет шофёрга сиздермичә генә капчыклар артына посты. Чистайдан Кама елгасын көймәдә йөзәсең дә атлы кеше очраса – атта, трактор очраса – тракторда башкалага юл тотасың. Кесәдә нибарысы карандаш белән шакмаклы дәфтәргә сызгалаган рәсемнәр генә, ә имтихан алдыннан дуслашкан Бәшир, Гомәр, Мөнир, Тәүфыйкларның дүртесендә дә төсле альбом. Тәүфыйк исемлесе шунда ук аны тәнкыйтьләп атты:

– Фу, пүчтәк бит болар! Бәдрәф кәгазенә яраса гына.

Гарьләнде онда әвәләнгән тегермәнче малае. Ул дәфтәрен ертмакчы гына иде, Бәшир кулыннан йолкып:

– Нишлисең, акылсыз! – диде. – Шәп синең рәсемнәрең! Тәүфыйкныкыннан ун тапкыр әйбәтрәк алар. Хыялыңны үтермә! Мин әле үзбәк кышлагыннан ук килдем Казанга. Безне кире борырлар мужыт, сине – юк!

Бормадылар, хәтта «сәләтле» дип мактадылар. Әтисен рәнҗетеп качкан егетнең ашау ягы каты-коты, кечкенә генә стипендия «әпипә» генә биетә, Тәүфыйкны санамаганда (ул колхоз рәисе малае), дүртәү – Бакый, Бәшир, Гомәр, Мөнир кичләрен шәһәр мәдәният сараенда плакат эше нәрсәләр «иҗат» итеп, диварлар буяп, тиеннәр «сукты». Саран җитәкчеләрдән әллә ни таммаса да, ипи-тозлык акча иде ул. Укулар тәмамланганда, инде шактый көрәйгән егетләргә училище директоры Камил Кәримов юллама тоттырды:

– Мәскәү художество академиясенә барасыз! Сезне Татарстан үз хисабыннан укыта. Стипендиясе мулдан, кисәтәм: анда да диварлар буяп йөрсәгез, талантыгыз җилгә очачак, малайлар!

Бакый бу тәкъдимне өнәмәде.

– Башта без армиядә солдат шулпасы чөмермәкче идек, Камил абый.

Дуслар белән киләчәккә табан сызган юлга директор «бүрәнә» тәгәрәтте.

– Өлгерерсез! Солдат каешы буарга билегез нечкәрәк әле.!

«Бишлек»кә Тәүфыйк Зыятдин кермәгән иде. Ул өйләнә икән.

Академиядән соң егетләрнең шактый гына калынайган биленә солдат каешы таман иде инде. Язмыш дүртесен дүрт тарафка таратты: Бакый Әфган дулкынына эләкте. Хикмәти Хода, полк командиры – аның авылдашы Роман Казаков! Якташлар рәхәтләнеп татарча аралашты. Камышлыкны икегә бүлеп аккан Аксу елгасының уң ярында – татарлар, сул ярында руслар яши, ә дәүләт теле – татар теле иде. Роман «кайнар нокта»да өченче ел икән. «Энем, иң хәтәре – таулар, алар өстә, без – аста, уяу бул», – ди. Атышлар тынса, командир әкрен генә җыр көйләр иде.

Ой, мороз, мороз, не морозь меня,
Не морозь меня, моего коня...

Хәтта ул аны татарчага да тәрҗемә иткән.

Әй, суык, суык, өшетмә мине,
Өшетмә мине, минем атымны...

«Их, үзебезнең салкын кышлар сагындыра, карда ятып, бер аунар идем», – дигән авылдаш абыйга андый кышлар насыйп булмады шул. Засадага эләкте алар, атыша-атыша чигенгәндә, гәүдәсе белән Бакыйны ышыклаган командирның яраланган корсагыннан эчәкләре тишелеп акты... Акылдан шашкан егет аларны ике кулы белән кире тутырды... Авылдашның соңгы сүзләре томан эченнән генә ишетелә иде:

– Хатыным Матуркай... улым... ташлама... Әй, суык, суык...

Әле уң, әле сул битенә суккалап кына, Бакый солдатны аңына китерделәр. Әлеге коточкыч күренеш гомере буе аның күз алдында эленеп торачак иде. Соңра, үзенең дә иңбашын ядрә чәрдәкләгән егетне, илгә озаттылар. Ташкент хәрби госпиталендә дәваланганнан соң ул туп-туры авылга кайтса да, туган нигезен читләтеп, башта Казаковларга сугылды. Балачакта ерак шомырт урманына барганда, гел алар турыннан узалар, гадәттә, ызба алдындагы эскәмиядә хатыннар черт-черт көнбагыш чиертер иде, бүген исә кайчандыр төп кебек утырган таза йорт танымаслык хәлдә ямьсезләнеп җиргә янтайган, ни коймасы, ни капкасы юк иде. «Матуркай

Рязань балалар йортында үскән дөмә ятимә, улым белән икесен вакытлыча Камышлыга кайтардым. Апагыз эшкә батыр түгел, әти-әни мәрхүм, үзләре генә ничек көн күрерләр?» – дигән иде Роман командир. Урам белән тоташкан ишегалдында миләш агачына сарган чыпчыкларга рогаткасын төзәгән сары чәчле малай Бакыйдан куркып, тупсасы каерылган ишектән шылды. Куркырсың да! Егет нәкъ йонлач урман шүрәлесе, йөзен сакалмыек баскан. Менә башына кара яулык бөркәнгән ябык кына бер хатын чыкты. Монда сүз артык иде. Юатып кына җиңеләйтерлек хәсрәтмени! Тол хатын, ятим бала һәм җимерек йорт... Күкрәкне утлы кисәү өтте. Исәнләшим дисә – тел әйләнмәде, күрешим дисә – бармаклар катты.

Хәбәр алгач та, өйдәгеләр аны көтә, әнисенең ашы пешкән, әтисе, олы кунак төшергәндәй, йорт тирәсен җыештырган, мунчасын ягып, мәтрүшкәле каен себеркесен парлаган. Бакый юынып-кырынып, адәм кыяфәте керткәч, тегермәнче Минәхмәт ничәмә еллар саклаган үпкә-сүрүен «тиште»:

– Ата-баба малын ишәйтәсе урынга ташкалага качтың. Укып – мулла, чукып карга булмадың! Буяучы ир-ат һөнәреме?

– Рәссам мин, әти!

– Миңа димәгәе! Бүтән китмә, кал! Тегермән аякта, аның хуҗасы – син. Сиңа багышланган дәүләт ул.

– Әгәр берәрсенә сатсаң, әти?

Әтисенә тегермән җене ияләшкән, ахрысы, туздыдулады:

– Әйттерерсең әйтмәгәнне, малай актыгы! Нәстә ди, йа?! Череп ауса аусын, сатмыйм!

– Акча кирәк миңа, әти.

Бакый «акча» дигәч тә, әтисе шкаф тартмасындагы симез генә төргәкне өстәлгә куйды.

– Мә!

– Әҗәткә, әти!

– Сиңа атап җыйган акчаны бурычка бирергә кем дип белдең безне!

– Әти, әни, тыңлагыз әле, кабат сөйләмәмдер. – Якыннарыннан яшерәсе юк иде. – Хатларны ачып укыйлар дигәч, мин сезгә чын дөресен язмадым. Әфганда идем мин. Яраланып, госпитальдә яттым. Әгәр командирым ышыкламаса, якты дөньялар белән хушлаша иде улыгыз. Рус очындагы Казаков ул, кулымда үлде.

– Андук күңелем сизде, төшемдә бил тиңентен кара кирза итек киеп, пычрак ерасың. – Әнисе яулык очын бөгәрләп еласа, әтисе башын чайкап ухылдады.

– Әти, миндә мәңгелек бурыч. Роман абый гаиләсенә булышасы иде. Аларның йорты сәләмә. Монысын сүтеп, яңаны төзеттерәм. Акчаны шуңа соравым сездән.

– Яхшы, улым, яхшы. Әгәр әфган җирләрендә үлеп калсаң, ул акчаларның ни хаҗәте безгә. Фәрхулла абзаңның нараттан сатлык бурасы бар. Шуны белешәм хәзер.

Картайдым дисә дә, атасы җиңел сөякле йөремсәк иде, балта остасы белән хак-бәясен килешкән. Оста идән-түшәмен җәеп, ишек-тәрәзәсен үзе уеп бирә икән. Иң авыры – Бакыйда иде. Әле бит ул тол хатын белән

сөйләшмәде. Дөрес, кайгылы хәбәрне аңа әллә ничә ай элек җиткергәннәр. Юатырлык сүзләр дә тапканнардыр, ә егет ни дияр? «Батырларча һәлак булды?..» Бу сүз белән батыры да, куркагы да тигезләнә түгелме соң? Сугышта төрлесен күрәсең. Әнә берәү җанын саклар өчен тау куышына яшеренде, ә «тегеләр» эчкә граната гына томырды.

Матуркай белән Алик чәй эчә, өстәлдә бердәнбер тәгам – сынык клиндер. Бакый әнисе җибәргән таба ашларын хатынга сузды:

– Сезгә күчтәнәч, апай.

Хатын, кашын җыерып, усал гына:

– Кичә баланы куркыткан кеше син идеңме? Сиңа бездән нәрсә кирәк? – диде.

– Сезнең ирегез командирым иде.

– Тегендәме?

– Тегендә.

– Ничек үлде ул?

Кыска гына бер җөмлә белән котыл югыйсә: «Батырларча һәлак булды».

Вөждан кушмады...

– Каты яраланды. Гәүдәсе белән мине капламаса, яшисе иде Роман абый. Сезне ташламам, апай.

Ир югалту кайгысыннан елый-елый күз яше кипкәнме, әллә сабыр савыты тирәнме? – Хатын аһ-ваһ итмәде. «Сезгә яңа йорт тергезербез», – дигән хәбәргә дә битараф иде Матуркай. Малайны исә кичәге «урман шүрәлесе» өркетми, ул төенчекне чишеп, бармагын ялый-ялый, майлы бәлеш сыпырта иде.

Өмә белән йортны тиз өлгерттеләр. Искесе утынга туралды. Кыш көннәрендә койма ягып чиләнгән хуҗабикә монысына әзрәк шатланды кебек. Алик белән дә дуслашты Бакый, малайның киләчәге турында да ул кайгыртачак, укыту, киендерү аның бурычы иде. Командирның яраткан җырын көч-хәл белән ятлаттырды менә. Иренә малай. Ялкаулык белән мәнсезлек, мөгаен, аңа әнисеннән күчкәндер. Чистай базарында энәдән-җептән киендергәч тә, Алик рәхмәт әйтмәде. Хәер, алардан рәхмәт ишетер өчен булышамыни Бакый! Гомер – тауар түгел, ул – бәһасез! Аллаһы Тәгалә аны авылдашының кулы белән озынайтты, димәк, аның һәр мизгеле өчен егет соңгы сулышына хәтле түләргә тиеш.

Камышлыда тагын күпме торыр иде, авыл советына училище директоры Камил Кәримов: «Уразов срочно Казанга килсен», – дип, өч тапкыр шалтыраткан. Бакый үзе дә рәсем дөньясында кайнаган җан дусларын сагынды. Утын кисеп, такта ышкылап тупасланган бармакларын нәфис кылкаләм дә ятсыныр, мөгаен.

Казанга аяк басу белән бер-бер артлы әтисеннән хатлар «яуды»: «Матуркай ирләр җыеп эчә...» «Малае фифирус пыскыта...» «Төнлә тәрәзәсен ватып, кибеттән аракы урлаган... Кибетче милисәгә җәвит итәм ди...»

Тиз генә хата төзәтергә кесә телефоны юк заман шул, егет сөйләшү пунктына йөгерде:

– Әти, зинһар, шешәләр өчен акчасын бир!

Соңгы хат күптән уйланылган карарга этәрде. «Улым, күсәк малай

өйалдына ут төрткән, күршеләр сүндермәсә – йорт янасы икән». Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, ике катлы тарихи бина бушагач, шәһәр җитәкчесе аны берлеккә тапшырган. Идарәдә өлкәннәр: «Яшьләр җүнле эш күрсәтмәде әле, очындырмыйк», – диләр, урта буын, шул исәптән мин дә, арканны сезнең якка тарттым. Дусларың белән чүп-чарны чистартып, җәлт кенә урнашыгыз! Бүген үк, хәзер үк! Аба-чаба йөрсәгез, остаханәдән колак кагасыз! – дип, Бакыйны чабышкы атыдай куалаган училище директорына авыл хәлләрен сөйләсә – вакыт кына сузылачак, бергә әфган таулары тузанын иснәгән Казан егете Илфат белән адреслар алышкан иде, служагы сәүдә базасыннан йөк машинасы яллады. Аның карамагында ярты гына көн иде.

...Өйалды янган өйнең ишеген ачкан хатын күзен тондырып, аңа карады. Инде кара яулыксыз, чәч-баш тузган...

– Акча китердеңме? – диде ул, мәче төсле иренен ялап. Акчада каймак тәме бар шул.

– Ник эчәсез, апай?! – Бакый аны элеп алып, селкеп салырдай булды.

– Эчәм! Мин иректе! Акча давай, махмыр миндә!

– Малаеңны юлдан яздырасың бит, апай!

– Акыл сатма, акча давай! Бездә поминка!

– Көн дәме? Аликны алып китәм. Казанда укыр.

Хатын биш бармагын бөкләде:

– Тот! Алик, килче бирегә!

Апын-төпен атлаган малайның күз кабагы шешенгән, ул сөт кенә эчмәгән иде.

– Нәрсә, анай?

Матуркай улын Бакыйга таба этәрде:

– Исеңдә тот, атаңның үлемендә ул гаепле!

**4**

Берлек рәисе бая ук китсә дә, Тәүфыйк Зыятдин һаман коридорда аяк табаны шомартты. Аны тыңламаска кирәк, паркта Сафия көтә. Әмма абзаң кырмыска кебек кадалып, баскычтан ук озатты.

– Ашыгасың ашыгуын, энекәш. Тыңла әле мине. Рәсем белән җенләнгән малай-шалай училищеда Уразов түгәрәгенә йөрде. Берсе – Рамил Зәйнулла иде. Остазым, имеш. Кемнең кулында – шуның авызында: бәйгедә Бакыйны җиңдерәчәк шәкерте. Сиңа-миңа үтүт беренче урын!

Егет авызын кыйшайтты:

– Уразовта супер идеяләр юк! Сезнең берегездә дә юк, дөресрәге. Сез үткән заман калдыклары! Бакый ага әнә бала-чага уены уйный, ватман кәгазенә акай хәрефләр ясаган, шуларны төрле төсләргә буйый. Чүп аның иҗаты!

– Маладис, туры бәрәсең, энекәш! – дип ыржайган «кырмавык»ны җиңеннән тотып туктатты Авзал:

– Минеке туры, ә сезнеке нигәдер гел кыек. Нишләп сез яшьтәшләрегезне яратмыйсыз?

– Һы, хатын-кызмыни алар яратырга?

– Ә нишләп алар сезне араларына сыйдырмый?

– Көнләшәләр чөнки.

– Нәрсәдән?

– Талантымнан, энекәш.

– Көлдердегез! Иң шәп мәзәк бу! Бүлмәгездәге картиналарны абзарга элсәң – сыерларның сөте кими бит, Тәүфыйк абзый. Сезнең тирегез калын, үпкәләмәссез, шәт, – диде егет. – Гафу, мин чынлап та ашыгам.

Иңнәренә үзе үстергән хыял канатларын җилпи-җилпи «очкан» Авзал килә-килешкә үк Сафияне биленнән эләктереп, зыр-зыр әйләндергәч, эскәмиягә утыртты:

– Сәлам, асыл кошым! Сиңа бер тәкъдимем бар. Әйтимме?

– Мин риза! Риза! – диде кыз, кулын чәбәкләп.

Авзал сагайды.

– Нәрсәгә «риза?»

– Тиле, син миңа кияүгә чык, дисең лә! Тәкъдимеңне кабул итәм: риза!

– Син ул тиленең тилесе, кызый. Кем өйләнәм ди?! Җәренгә уйлашырбыз бәлки.

Сафия аягын күтәреп, тезен кочаклады.

– Ә мин тагы... Утызны тутырыйм дидең – тутырдың. Үземнең фатирым дидең – анысына да тиендең. Син ничә ел попугай төсле җәренгә дә җәренгә дип кабатлыйсың. Андый «җәренгә»ләрдән туйдым мин!

– Җә, пырылдама, асыл кошым. – Авзал кызның җилкәсеннән сыйпады. – Вәгъдә, җәренгә!

– Шулай өметләндерә-өметләндерә ташларсың әле, атка атланган рәссам! Әниләреңне ташлаганны, мине бигрәк тә. Өч ел Кушнаратка кайтмыйсың, этиең: «Безнеке ат дагалыймы анда?» – ди. Мин дә синнән ким эшләмим, ләкин авыл сукмагын онытмыйм.

Бүтән чакта ул бу асыл кошны иңенә кундырып, болай сайратмас, кагып кына төшерер иде, бүген ярамый, бүген түзәсе...

– Мәхәббәтебез хакына ызгышмыйк, Сафия, яме? – диде Авзал, елмаерга тырышып.

– Нинди мәхәббәт турында әйтәсең син?! Бер генә яклы мәхәббәт бит ул, минеке генә! – Кыз бәйдән ычкынды. – Үзеңне генә яратасың, нарцисс син!

– Бездә конкуренция көчле, асыл кошым, һәркем үзен даһи саный. Әз генә өскә үрмәләсәң – аягыңнан аска сөйриләр.

«Асыл кош» чыркылдады:

– Синең белән кем булашсын, бөегем! Яшь-яшь башыңнан ничәмә шәхси күргәзмәңне оештырдылар, гәзитләрдә күкләргә чөеп мактадың. Сине колагыңнан тартып үстерәләр кебек әле миңа. Ун тапкыр талантлырак коллегаларың күләгәдә калмыймы икән? Авзал Сәлимов күләгәсендә!

«Моңа өйләнсәң, иртә-кич кырык биш минутлык дәрес тыңларсың, укытучы хатыннардан Аллам сакласын», дип уйлады егет.

Ярсудан бит алмасы алсуланган Сафия кинәт кенә басылды.

– Йа, нәрсә төтенсез яна? Нәрсә сүндерәсе, бөегем?

Әһә, кытыгы кытыклана!

Кулын кесәсенә тыккан Авзал кыз каршысында таптанды:

– Ничек башлыйм икән, асыл кошым?

– Азагыннан башла!

Илһамланган егет һавага аркылы-торкылы сызыклар «сызды».

– Син хатын-кызларның абстракт сурәтен күргәнең бармы? Француз рәссамы Паскаль Пратт – аның чын остасы. Аны беләсеңме, асыл кошым?

– Кая инде безгә Праттларны белү! Безнең өчен иң мәшһүре – Авзал Сәлимов!

Сафиянең чәнечкеле ирониясенә кадалсаң, тагын сүз атышу башланачак иде, егет ишетмәмешкә салышып дәвам итте:

– Беренче карашка хатын-кыз күренми дә, абстракционизмның бөтен сере шунда. Әсәрне анализлап булмый, аны хис-кичерешләр аша гына тоясың. Яңа конкурска мин сине ясыйм, асыл кошым.

Кыз күңелсез генә:

– Яса соң, – диде. – Шул киндердә калсам гына инде.

Авзал Сафияне күтәреп, җиргә бастырды:

– Алай димә, син минем йөрәгемдә, асыл кошым! Без синең белән бәйсез һәм азат татар кызы образын сурәтләрбез, ул татар хорына кигән балитәкле ак күлмәгең белән калфагыңны ыргыт, сиңа кием кирәкми, ялангач, синең сылу буй-сыныңнан кылкаләм көнләшәчәк!

– Бәй, нишләп мин ялангач соң ул? – диде кыз, гаҗәпләнеп.

– Образ таләбе, асыл кошым. Син – заман кызы! Аннары мин синең гәүдәңне чуар төсләр белән бизим.

Нәфрәтеннән пыялаланып, күз алмасы чатнаган кыз аның яңагына кундырды:

– Бозык!

Остаханә ишеге төбендә тәмәке көйрәткән Тәүфыйк Зыятдин янында дәшмичә генә үтмәкче иде Авзал, «кырмавык» тагын аңа иярде. Яңак һаман әчетеп сызлый, эчтә ачу өермәсе бөтерелә, мондый чакта аның күзенә чалынмавың хәерлерәк.

– Сез бер дә басылып утырмыйсыз, ахры, Тәүфыйк абый. – Менә шушы өермәне кемгәдер күчерәсе килә иде, җае чыкты! – Картиналарыгыз сатылмагач, эшләдең ни, эшләмәдең ни! Ник сез рәсем белән мавыктыгыз икән? Сезнең берлеккә керү турындагы гаризагызны өч тапкыр борганнар, ә яшьтәшләрегезне идарәдән җырлап уздырганнар, ди.

Тәүфыйк Зыятдин җиңел генә егетнең ачуын «йотып»:

– Син дошманнар гайбәтен тыңлама! – диде. – Бакый кабул итү комиссиясе рәисе иде. Әллә кем инде! Дипломатлар модада чагы, мин шуңа кыйммәтле коньяк, кәнфит салып, алдан ук күчтәнәч илттем. Киредән фатирыма китергән. Сатылмый, имеш! Миңа конкурслар ниемә! Зур гына түрәнең туган көненә портретын ясатмакчылар, коттеджында. Бәясе – ярты миллион! Вәт каерам акча!

Авзал өчен дан белән акча бер-берсенә ябышкан сиам игезәкләр иде. Күкрәкне шатор-шотыр «мәче» тырнады. Коенасы иде ул данга да, акчага да, тәкәббер Сафия киреләнде.

...Бакый Уразовның, гадәттәгечә, ишеге ачык иде. Аның «кырмыска оясы» тыныч, шуны таяк белән бутасаң, бәлки ачуым кимер дип, егет юри аягын кыштырдатып атлады. Диванга аркасын терәгән карт рәссам уйга баткан иде. Монысы Тәүфыйк белән бер чыбыктан сөрелмәгән, монысы «өер башлыгы», монысының урманында муртайган бүреләрдән

тыш, Рамил Зәйнулла кебек яшьләр дә ауга йөри. Болар аксак куян гына эләктермәс сиңа!

– Исәнмесез, Бакый ага?

– Без бүген күрештек бугай, Авзал. Әллә мин көпә-көндез йоклап китеп таң аттырамны?

– Йокымсыраган идегез шикелле. Уятыйм дип исәнләштем. Бер нәрсә сорасам ярыймы?

Бакый карт, диваннан калкынып:

– Берне сора, икене сора, – диде.

– Кабул итү комиссиясе рәисе булгансыз икән. Нишләп Тәүфыйк Зыятдиновка өч тапкыр аяк чалдыгыз?

Гаҗәп, карт әйләндермәде-тулгандырмады:

– Чалдым, әйе, – диде.

– Талантыннан көнләштегезме?

Менә бу сораудан соң түмгәктәге «кырмыскалар» дәррәү кузгалып, тешләшергә тиеш иде. Ә карт – сабырлык үрнәге!

– Тәүфыйк уртакул, ул моны үзе дә белә. Аның ишеләрне без дистәләп алдык берлеккә. Аларның да яшәргә хакы бар. Тәүфыйк сукыр атасын картлар йортына илтте, безнең мондый миһербансыз иптәшне үзебезнең сафларда күрәсебез килмәгән иде.

– Көн дә күрәсез! – Авзал һаман күршесен җенләндермәкче иде.

– Мин күрмим, ул үзе күренә! – Болытлы көннәрдә дә йөзе көләч карт нигәдер боек иде. – Сорауларың тәмаммы, Авзал? Тәмам икән, эшлә, трай тибеп йөрмә!

– Эшлә дисез... – Ачуын шушы картка бушатырга кергән егетнең кисәк кенә борыны юешләнде. Балачакта шулай иде: урамда малайлар кыерсытса, Авзал борынын мышкылдатып, этисенә әләкләргә йөгерер иде. Менә хәзер Бакый аның этисе кебек. – ...Объект кәҗәләнә. Бәйгегә чибәр генә туташның сурәтен ясамакчы идем.

– Ояламы?

«Чишенми», – дисә, бу борынгы заман кешесе аңламас.

– Кыргый зат.

Сүлпәнәйгән күршесе җанланды. Гүя икәү урыннарны алмашты: Авзал карт, ә Бакый яшь рәссам иде.

– Энем, тормышның үзен чагылдырабыз дип көчәнмә! Син әүвәл образыңны хыялыңда тудырып, бизәкләргә төр. Кылкаләмеңне табигатьтәге буяуларга ман. Салават күперендә җиде генә төс, диләр, юк, Аллаһының беребез дә кабатлый алмаган «күпер»ендә күбрәк алар, күңел күзебез сукыр, шуңа җиде саны белән генә чикләнәбез. Тап син аның сигезенчесен, тугызынчысын, энем.

Әкиятләрдә генә карт-корыны Әбелхаят суы бөркеп яшәртәләр шул, хәлсезләнгән күршесе йөрәген учлады.

– Уф, атым чыгымлый. Син бар, эшлә, Авзал, эшлә!

Бакый Уразов хаклы иде. Ундүртенче гасырның даһи рәссамы Леонардо да Винчи ефәк сатучы сәүдәгәр Джоконданың хатынын бер үзгәрешсез киндергә төшердеме икән? Мона Лизага серлелек асылда хыял ярдәмендә өстәлгәндер бәлки. Рәсем сәнгатендә андый мисаллар бихисап. Италия

мәшһүре Сандро Боттичеллиның Венерасында борынгы грек алласы Афродита образы. Сандро бу картинаны ясаганда, «алласы» әллә аның каршында торганмы?

Ул мольбертын тәрәзә янына күчерде. Хыялындагы кыз Сафиядән ун тапкыр чибәррәк булачак. Егет күлмәк җиңен сызганып, җиңел кулдан, серле алиһәсенең силуэтын сызды.

...Остаханә идәнендә бөгәрләнеп йоклаган Авзал уянганда, кояш күкнең иң югары ноктасыннан яктырта иде. Кич – төнгә, төн – таңга ялганган. Эшләп түгел, уйлап арылды. Мөгаен, ике атнадан портрет төгәлләнер. Диңгез, комлы яр буе... Төсләр нурына коенган шәрә алиһә... Һа, «асыл кош» көндәшеннән көнләшеп үләчәк! Әгәр Авзал киндердәге кызга гашыйк булса? Ул бит чынбарлыкта юк, ул хыялда гына! Хисләнгән яшь рәссам күз карашы белән генә алиһәсен иркәләмәкче, дисә, кан тамырлары бозланып катты. Киндердән аңа Сафия карап тора иде...

**5**

«Атаңның үлемендә ул гаепле...» Коточкыч сүзләр! Әйе, Бакый «гаепле»: исән калды һәм гомере буе шул гаебен «юды»: мәрхүм авылдашының гаиләсен асрады.Тик акчасы бәрәкәтсез, үзе тир түгеп тапмагач, Матуркай аны уңга-сулга сипте. Ник сипмәскә: юмарт болыт – Бакый ай саен «алтын тәңкәләр» яудыртты. Шешәдәшләре белән аракы лыкынган анасына улы да «булышты». Рәссамга җигелеп эшлисе дә эшлисе иде. Аллаһның кодрәте киң: Гомәр, Мөнир, Бәширләр белән дүртәү иске бай йортын чистарткач, остаханәгә тиендерде. (Тәүфыйк Зыятдин соңрак әзергә-бәзер урнашты.) Бүлмәләр төрле зурлыкта иде, Бакый:

– Әйдәгез, шобага салабыз, – дигәч, өч яшьти аны күтәреп, ике тәрәзәле «оҗмах оясы»на кертеп бастырды:

– Рәхәтен күр, Уразов!

Камышлыда «боз» кузгалып маташа, Матуркай ниндидер бер ир кисәге белән бөтенләйгә Себергә китмәкче икән, фатирга шактый гына күләмдә акча сорады. Сорады дип йомшарта Бакый, теге «гаеп»не кабатлап таләп итте! Нишләсен егет, банктан кредит алды. Өйләнеп, алты гына ел иркен сулап яшәгәндә, беркөнне аңа телеграмма тапшырдылар. Эчтәлеге кыска иде: «Фәлән сәгатьтә, фәлән поездддан каршыла. Алик.»

– Бакый, син алардан өзел! – дип ялварды барысыннан да хәбәрдар хатыны Мәдинә. – Ни туганың, ни дустың, вакытында күп ярдәм иткәнсең, җитәр!

– Аның атасы мине газраилдән саклады. Мин аның баласына тиеш!

«Кунаклар» өчәү иде.

– Өйләндем, дәдә, – диде буйга тартылып ябыккан Алик. – Таныш, хатыным Алисә белән улым Серго.

Керләнгән юрганга ураган сабый тугыз айлык кына иде. Мәдинә аны юындырып, чиста чүпрәккә төрде. Табындагы ризыкны хапыр-хопыр йоткач, йөреп керәбез дип киткән яшьләр ярты төндә генә кайтты. Икесе дә шыр исерек иде. Әле ярый тамагы ачып елаган орчыкка Мәдинә даруханәдәге катнашманы суга болгатып эчертте. Иртәгесен йокыдан уяну белән Алик аракы таптырды:

– Баш чатный, төзәттер, дәдә!

– Бездә «шайтан суы» юк. Хатының торсын, баласын имезсен! Юыныгыз да чәй эчегез, айнырсыз, шәт.

– Саран син, дәдә!

Берәр әмәл кылмасаң, болар хәмергә чумачак иде.

– Сез бездә ничә көн кунасыз, егет?

– Өч, дәдә, өч. Аннары авылга!

– Димәк, өч көн урамга аяк та атламыйсыз. Өстегездән биклим, ачкыч Мәдинә апаң белән миндә генә. Ашарга бар, яшәгез!

Их син, беркатлы рәссам! Аракы дигәндә, айдан сикерә сәрхуш! Алик сикереп, аягын сындырмаган анысы, хуҗаларны гына «чишендергән»: Мәдинәнең кеш тунын, алтын-йөзек-алкаларын, өрфия яулыгын, Бакыйның өр-яңа костюм-чалбарын, түфлиләрен, кул сәгатен һәм яшьтиләре белән бакча-дача төзисе акчасын урлаган. Йозак тишегенә кадак яратып ачкан, хәерсез. Анлык башы эшләгән. Аның каруы караватта тибенә-тибенә биләүсәсе чишелгән нарасый ята!

– Әнекәем! – Мәдинә шуңа ташланды. – Әнекәем, орчыкны онытканнар!

Бакый өстәлдәге туу турындагы таныклыкны кат-кат укып:

– Онытмаганнар, – диде. – Синең белән миңа бүләк калдырганнар. Әллә ни ерак качмаслар, хәзер милициягә шалтыратам.

– Зинһар, шалтыратма, көтик! – Мәдинә баланы кулында тирбәтте. – Бигрәк җиңел, орчык! Еларлык та хәле юк, ач. Хәзер ашатабыз, бәләкәчем.

«Малаебызны бирегез!» – дип, менә-менә ишеккә тибәрләр кебек иде. Кич җитте, килмәделәр. Орчыкны күтәргән хатыны шунда:

– Тунсыз, алтыннарсыз да яшәрбез, дөнья малы – дуңгыз каны, безнең иң зур байлыгыбыз – улыбыз бар, – димәсенме!

Саташа бичәсе! Кем аларга чит кеше баласын тоттырсын!

– Бакый, син иҗат ит, мин бөтенесен дә җайлыйм. Мәгариф өлкәсендә таныш-белешләрем күп, орчыкны уллыкка алабыз. Аллаһы Тәгалә итәгемә салган бәхетемне беркемгә дә бирмим, – дип әсәренгән Мәдинәнең, мөгаен, шакымаган ишеге, кермәгән тишеге калмагандыр, сабыйга документлар җыйган яңа әти-әни фатирларын алыштырды. Ата күке белән ана күке малайны эзләп килсәләр, эз яшерәләр, янәсе. Орчыкның теле ачылганда әйткән беренче «әттә-әннә»сенә ничек шатланды алар. Икәүнең күңел җылысына төренеп үскән малай ун яшендә үк үзенең нинди ояда канат ярганын белә иде. Паспорт өстәленнән ул сөенче белән кайтты.

– Әти-әни! Мине котлагыз, исемемне үзгәрттем, бүгеннән мин Уразов Солтан Бакиевич!

Медицина университетын да: «Сине үзем дәваламын», – дип, әтисен кайгыртып сайлады Солтан. «И улым, улым, тән ярасы ни ул, җанны биләгән борчулары хәтәр аның. «Ата күке» синең җилкәңә менеп атланмакчы».

Көш, күке, көш! Малайның сиңа бурычы юк. Әнә Солтан: «Мин андый кешене хәтерләмим, минеке – каршымда», – дип, кырт кисте. Ул да, Бакый сыңары, ике сөйләшми. Ләкин «күке» ерткыч кош төсле тырнагын тирән батырмакчы. Ничек улын аңардан араларга соң? Яшьтиләр белән киңәшергә кирәк. Гомәр белән Бәширдән ул гаилә хәлләрен яшермәде. Элек алар бер йодрыкка тупланган дүрт дус иде, кызганыч, Мөнир Садриев бик иртә китте.

Адәм баласы бит, типкәләмик дип, Тәүфыйкны да якынайтканнар иде. Мөнир авырып, Шатко хастаханәсендә ятканда, ул да передачалар илтте. Мәрхүмнең гәүдәсен дә бергә алып чыктылар. Дөньяның асты өскә, өсте аска әйләнеп каплангач, шәһәрдәге тарихи биналарны йә иштеләр, йә тиеннәргә саттылар. Акчалылар диварларына күпме сырхауның бәгырь җепселләре тартышканда ыңгырашкан авазын сеңдергән хастаханәне иплэп-сиплэп, маңгаена яңгыравык исем чәпәп, ресторан ачкач, Зыятдин оныгы: «Мин сезне юбилеема чакырам, олы малай бизнесмен, чүл дөясе хәтле машинасы белән сезне иң шәп җиргә ташыр», – дигәч, «бүреләр», бүләк әзерләп, бәйрәмгә җыенды. Тик «чүл дөясе» челтәрле тимер капка төбенә туктагач, бәйрәм рухыннан җилләр исте: элеккеге Шатко! Монда кадерле дуслары Мөнир дөньядан узган иде. Мәрмәр баскычтан Тәүфыйк төшеп:

– Хуш киләсез! Күрәсезме, абзагыз сезне нинди ресторанда сыйлый! – дип мактана башлагач, Бакый, әз генә таягы белән аңа кизәнмәде. Бәлки кизәнер дә иде, кулындагы ак розаларга күбәләк кунды. Мөнирнең җаны иде бугай ул...

Өчәү дәшмичә генә кире борылды. Уйласаң – уеласың, валлаһи!

Кыл уникедә Бәшир белән Гомәр чәй эчәргә керә, һәм бу тәртип бик сирәк бозыла иде. Карт рәссам табын көйләде. Шөкер, Солтан атна саен «файдалы» дип, суыткычка әллә ниләр тутыра, умыртып ашарга яшь чакмыни, чемченә «бүреләр». Мәдинәнең майлы боткасы гына тамактан тиз шуа. Аның иң рәхәте: бергә җыелу, бергә! Аллаһ шушы ике тугры дустан аермасын! Аларның өчесендә өч төрле холык иде. Гомәр ут йомгагы, сүтелсә – көйдерә-яндыра, ләкин иҗатта артык тыйнак, гәрчә тәнкыйтьчеләр талантын бәяләсә дә, «мин» дип шапырынмас, ә Бәшир басынкы һәм күндәм, «өчлек»тә ул чын матур ир-ат, бөдрә чәч, җыерчыксыз тип-тигез маңгай, олыгайгач та тоныкланмаган чем-кара күз, төп-төз борын... Әмма табигать йөзенең аскы өлешенә җиткәч арыган, ахрысы: күпертмәле ирен урынына колакка кадәр ике сызык кына сызып җибәргән. Нәкъ бака авызы! «Матур бака» кушаматы чат ябышты аңа. Берсендә Бәшир күңеле нечкәреп зарланды:

– Үзбәкстанда туып үссәм дә, Казан – минем ватаным. Безнең күршедә үзбәк агае картайган ишәген дүрт ягың кыйбла, дигәндәй, урамга куды. Хуҗасына хезмәт итә-итә бетерешкән хайванны җәлләдем. Хәзер үзем дә ишәк ише: эшләттеләр-эшләттеләр, ни даным, ни саным. Бу куллар дистәләгән мәдәният йортларын бизәде, су буе плакатлар язды. Кемгәдер пачка-пачка премия өләшкәндә, мине һаман артка чигерделәр. Бер генә исемем дә юк бит, җегетләр!

– Бар синең исемнәрең, алар хәтта икәү, – дигән иде Бакый, шаяртып.

Ә хисләнгән дусты аңламады.

– Ничек икәү?

– Берсе мулла укып колагыңа өргән Бәшир исеме, икенчесен без куштык: син – «Матур бака».

Тәгәрәп көлгән иде Бәшир. Бүген исә дусларга дигән чәй суынды. Кая ул «ата күке» мәсьәләсендә киңәш-табыш итү, Гомәр кичке поезд белән Алтайга – кызына китәм, чемодан тутырам, ди. Бәширне каядыр зар-интизар булып көтәләр икән. Икесе дә бер авыздан:

– Без бәйгенең кызыксыну премиясенә дә риза, син беренчегә тырыш! – дип теләк теләп саубуллашты, бәгырь кисәкләре. Бакыйга башта Мәдинәнең заказын төгәллисе әле. Хатыны башлангыч сыйныфларда татар теле укыта иде, кыскарту шаукымыннан тетрәнеп кайтты елады, кайтты елады.

– Бакый, татар телен мәктәпләрдән сөрделәр! Кемгә зыяны тигән минем телемнең! Нишлим, Бакый, нишлим? Директор: «Бездә дворник штаты буш», – ди. Татар башы белән шул сүзнең татарчасын белми. Урам себерүче ул, мәйтәм. Сез минем телемне урамга себердегез дә, мин аны җыеп чүп савытына түгимме, мәйтәм.

Җаны балаларга береккән укытучы юаныч тапты: таныш мәктәп директоры аңа түгәрәк бирде. Түләүсез! И, Мәдинәнең сөенүләре! Менә ул иреннән «Әлифба» дигән түгәрәгенә төсле татар хәрефләре ясаттыра. Авырсынмый, Бакый, ясый. Кинәнсен хатын! Ә тегермән... Борынгы «он патшалыгы» әтисе белән әнисе артыннан ук җимерелде. Хуҗа булып, иңбашын терәп сакламады аны Минәхмәт малае, сакламады, корылмалар да, кеше сыман, кирәксез икәнен тойса, тиз бетерешә икән ул. Хәзер аны киндердә генә терелтәсе, анысын да хыялда гына яңартасы. Мөлдерәмә тулы буасы да кипте. «Һәр кешенең бер дәрте, тегермәнчедә су дәрте», – дияр иде мәрхүм әтисе.

Кич белән Солтан килде. Аерым яшәгән егет һәркөнне аларга сугыла, улы да койрыксыз дөнья куа, әнә, ике айга Италиягә тәҗрибә тупларга җибәрәләр, ди. Солтан кәгазь битенә телефон номерын язды.

– Бу минем урынбасар – Нәкыйп Каштанов, чирләсәгез, сразу аңа шалтыратыгыз! Ишеттеңме, әни, ишеттеңме, әти?

Бакый егетне поездда озатканда:

– Теге атаң белән нишлибез соң, улым? – диде.

Солтан аның изүен каптырды:

– Урамда салкын җил исә. Бала ике атадан тумый, минем әти – син, чепуха белән башыңны катырма! Сау бул, күрешкәнгә кадәр, әти!

– Исән-сау гына йөр, улым. – Бакыйның керфек очы яшьләнде. Картлар күңеле пыяла, биш кисәккә уала шул. Җитмәсә, остаханәдәге җансызлык ямансулата, гүя тормыш арбасының дүрт тәгәрмәче дә сынган, ул бүтән тәгәрәми. Монда һәркем үзенең барлыгын сиздереп «яшәде»: Тәүфыйк тычкан сагалаган мәче кебек шыпырт кына коридорда йөренә, ике яшьти, «без бар» дип, сигнал биргәндәй, берьюлы тамак кыра, Авзал дивар «ишеп», музыка акырта... Гомәр – сәяхәттә, Бәшир ниндидер йомышта, ә яшь күршесе кайда?

Йа, моңсуланма, карт! Сез икәү, синең башыңда миеңне тишеп «ата күке» кукылдый. Аңа ни диярсең кич белән, уйла! «Ул исемен үзгәртте, ул хәзер Солтан Уразов», – дип сереңне ачарсыңмы? Әйдә, ач, бу бәндә аның канын эчсен!

...Парктагы эскәмиягә сузылган сәрхуш Бакыйга ябырылды.

– Ник үзең генә?! Малаем кая?

– Синекен белмим, минеке чит кешеләр белән күрешмим, ди.

– Сездә минем малай!

Бакый кулын канат итеп кагынган «кош»ны җиңелчә генә этәреп, урынына «кадаклады»:

– Җилләнмә, җилең зәхмәтле! Малай дисеңме? Сез аны Мәдинә апагызның тунына төреп, безнең фатирдан алып чыкканда, юлда төшереп калдырмадыгызмы икән?

Ир: «Урламадым», – дип акланмады. Карт аны кызганып та куйды. Аллаһ аны сөеп яраткандыр, кәкре һәм туры юл күрсәткәндер, кайсысын сайлый – ихтыяры.

– Әйдә, мин сине картлар йортына урнаштырам, – диде Бакый. – Өстең – бөтен, тамагың тук булыр.

«Ата күке» күзен шарландырды:

– «Картлар йорты»на?! Үзең урнаш! Мин улымда торам! Адресны бир!

– Юк синең улың, җәфа!

Карт «юк» белән әүвәл үзен ышандыра иде. Ә сәрхуш һаман турыны кәкрегә бөкте:

– Шыттырма, дәдә! Сергоның атасы – мин! Поездда төрмә албастысы белән таныштым, аның дачасында шашлык кыздырып ял итәм. Малайның колагына киртлә! Ул мине закон нигезендә тәрбияләргә тиеш. Сезгә бер ай срок, кушканны үтәмәсәгез, бандит иптәш белән арт сабагыгызны укытабыз!

Яна, куркыт, бәндә баласы, бу очрашу соңгысы! Газиз баласының дөньясын синең караңа буятмас өчен җанын фида кылачак Уразов әти!

...Карт рәссам баскычтан җырлый-җырлый менде.

Ишегалдым мамыктыр,
Басмыйк, дуслар, языктыр.
Ормыйк башны, түкмик яшьне,
Ходай шулай языптыр.

Тавышын ишеткәч, яшьтиләр: «Һай, моңлы да җырлыйсың!» – дип, шап та шоп кул чабар кебек. Чапмадылар, остаханәдә тынлык иде. Ул тынлыкта күңел төшенкелеге тагын да көчәйде. Коткарса, хыянәтсез дусты – кылкаләм коткарыр... Иҗат төпсез диңгез, баш-аягың белән чум, Бакый. Жәлләмә, үзеңне камчылый-камчылый эшләт! Атна дәвамында көч һәм дәрт-дәрман күкрәктән суырылып, киндергә күчте. Бу – рәссам өчен бәхет иде. Аяк очына гына басып, бүлмәсенә табан теркелдәгән Бәширне, гәрчә ишеккә арты белән утырса да, «күрде» ул.

– Әй, син, кайларда йөрисең, Матур бака? Әллә берәр күлгә иләштеңме?

Урлаганда тотылган гөнаһсыз каракмыни, Бәшир комач кызарды.

– Сәлам! Буяуларга килешем, тизгә генә. О, синең тегермән полный ход бодай тарттыра, ахры. Балачак хатирәләрен кузгаттыңмы? Бәйгегә шәп картина өлгертәсең, Алла бирсә, яшьти.

– Рәхмәт, Алла кушып өлгертермен, шәт. Ә син? Дөресен әйт!

Өер башлыгыннан яшерерсең, ди! «Матур бака» муенын сузып, тирән итеп сулады.

– Дөресеме? Дөресе шул: Тәүфыйк бер түрәнең портретын ясарга алынган да, иптәш эшен гел бракка чыгарып бара икән! Зыятдин туганыбыз ярдәм ит дигәч, нишлим инде, кызгандым. Күз яше белән ялвара. Хатын-кызның, ничектер, елавы табигый. Ә моныкы... Ир-ат белән хайваннарның яше йөрәкне тишә минем, яшьти.

– Ай-яй, Бәшир, ай-яй! Нинди зур бәйгедә катнашасы рәссамга түрә чырае кадерлерәкме?

– Биздем мин андый ярышлардан, яшьти. Мисаллар китеримме? Берсендә авыл хуҗалыгы идарәсе кыр-басу күренешләрен туплап, зиннәтле кәгазьдә альбом бастырмакчы икән. Җаваплы мөхәррире миңа: «Бәшир абый, алыныгыз, сез – осталарның остасы» – дип, салпы якка салам кыстыргач, өч ай буе Арча басуларында илһамланып яттым. Яттым дип, көн-төн эшләдем. Арыш арасындагы зәңгәр чәчәкләрнең таҗына хәтле яратып ясадым. Мөхәррир егет: «Болар чын сәнгать әсәре, альбом – сезнеке!» – диде. Ә идарә башлыгы минекеләрне хурлап, берәүнең плакатлардан күчергән трактор-машиналарын сайлаган. Син ябык конкурсны хәтерлисеңме? Конвертлар алдан ук ачылып, төкерек белән ябыштырылган иде, бишенче рәис, мин аны сан белән генә атыйм, үзенең ялагайларын «җиңдерде». Шуннан соң күңел сынды минем. Без бит – үзбәк кояшында иркәләнеп үскән йомшак халык, сезне генә ул зәмһәрир суыклар чыныктырган.

– Быелгысы гадел. Рамил Зәйнулла хәрәмләшмәс.

– Анысына шикләнмим, чөнки синең шәкерт. Тәүфыйкны, мәйтәм, бөтенләй үк бетереп атмыйк, яшьти. Алай ук начар кеше түгел ул. Чүт кенә мәнсез, димме шунда.

– Аллаһ шулай ялалткан инде аны, без төзәтәлмәслек итеп, – диде Бакый, ишеккә карап. Йөрсен иде әле Зыятдин коридорда үзалдына мыгырданып. Күршесе дә даңгыр-доңгыр музыкасын кабызсын, югыйсә бу тынлык изәсыта иде.

– Карале, яшьти, сүз башы бит шүрәле дигәндәй, безнең яшь таебыз бармакларын сындырган. – Бәшир кул чугын селкеде. – Унысын да. Энесеннән Тәүфыйкка шалтыраттырды. Яшьләр әллә ниткән шайтан уеннары уйный, таудан мотоцикл белән мәтәлгән. Егетебез абстракт картинасы белән шаккатырмакчы иде, финишка җитәлмәс. Сиңа көндәшләр кими, яшьти.

– Син дә Тәүфыйк сыңары, мәнсез!

– Гафу, яшьти. Мин – мәнсезнең шаяртуы да мәнсез. Китим әле.

Кичкырын аркасына биштәр аскан Авзал аның ишек төбенә килеп басты. Умыртып эшләр чагында кул сындыру – рәссам өчен фаҗига. Бакый бүген-иртәгә егетнең өенә барырга җыенган иде, әнә, түзмәгән балакай, үзе киләсе иткән.

Нәрсә дип юатасың? Кисәсе – киселгән, тегәсе – тегелгән. Ахыры хәерле тәмамлансын.

Егет һәр сүзен теш арасыннан сытып кына исәнләшкәч, карт рәссам:

– Ак бияләйләр кигәнсең икән. Яшь сөяк, тиз төзәлер. Шөкер, башың исән, – диде.

– Баш дисез... Сезгә әйтергә җиңел шул! – Салам өеменә шырпы сызып ыргыттылармыни, яшь күршесе гөлт итеп кабынды: – Сез, әнә, конкурска дип җан тырмашасыз, сез минем гариплеккә шат! Сезгә җиңәргә кирәк! Сез һаман мактаулардан туймыйсыз! Бөек әсәрегездән ярты гына минутка арынып, миңа бүлмәмне ачсагыз иде. Ачкыч чалбар кесәсендә. Өстәлемдәге телефон зарядныгы белән колакчаны рюкзакка аткарып, йөгемне җилкәмә атландырсагыз һәм дә артымнан ишекне бикләсәгез, рәхмәт диярмен.

Утың да, суың да синең үзеңдә, яшьлек! Бакый ишектән керү белән тәрәзә кырыендагы мольбертка текәлгәч «кибән» капылт сүнде.

– Бәйгегә шедевр өлгертә идем, бармаклар имгәнмәсә...

Икенче тапкыр сурәткә карарга оялды карт рәссам, чын мәгәр, оялды.

– Ник ул ялангач, энем?

– Абстракт рәсем сәнгате турында ишеткәнегез бармы? Ишетмәсәгез, миңа вәгазь укымагыз! Әбинең әкиятләреннән дә туйган. Авылга кайтсам: «Улым, кеше сурәтләре ясама, ахырзаманда синнән җан сорарлар», – дип бәйләнә кортка.

– Әкият түгел ул, энем, тегендә баргач, һәр гамәлебез өчен җавап тотасы. Төзәт хатаңны, кыз баланы сызык-бизәкләр белән генә чуарлама, башаяктан ук киендер!

Егет кагына-кагына, җилкәсендәге йөген идәнгә шудырды.

– Сез сукырмыни, Бакый ага?! Күрмисезмени, җәйге айларда урамдагы шәрә хатын-кызларны?! Өсләрендә бер генә каптырмалы чүпрәк!

– Без хәзер аларның шул чүпрәкләрен дә салдырып, күргәзмә залларына эликме инде, энем?

– Мин иҗатымны төрле ысуллар белән төрләндерәм. – Авзал рюкзагын типкәләде. – Сезнең кебек социалистик реализм баткаклыгында гына чупырдасаң, дөнья күләмендә мәңге танылмассың! Сез яңалык дошманы, Бакый ага!

Карт рәссамның күптән, бик күптән «кибәннәре» яндырылган, сызам дисә, шырпы кабы да буш иде, ул иелеп, тыныч кына рюкзакны алды, тыныч кына шуңа өстәлдәге әйберләрне тутырып, Авзалның аркасына асты. Егетнең чәнечкеле сүзләренә рәнҗемәде. Әйе, әдәпсез-әхлаксыз «яңалыклар»ны өнәмәгән Бакыйлар буыны «искелек калдыгы», ахрысы. Әйе, заманы да алар заманыннан үзгәрәк, ахрысы. Яшь чакта алар ни хәтле генә «даһилар» чире йоктырса да, өлкән кылкаләмдәшләрен тәнкыйтьләргә базмас, кая ул тәнкыйтьләү, җыелышларда рөхсәтсез кырыйларына да утырмас иде.

Ишеген дә бикләмичә киткән егет аңа борчу калдырды... Балачакның якты хатирәсе – тегермән күренешен түгәрәклисе рәссам көнозын музейларда сакланган киемнәрне карап әйләнде. Мода салоннарына, зәркән кибетенә сугылды. Әмма эзләгән нәрсәсе табылмады. Бакчадагы агач күләгәсендә хәл җыйганда, бер кыз бала кыяр-кыймас кына эскәмия читенә елышты. Бакый урамдагы һәр сылуга каш сикертер яшьтән узган иде инде, ә туташ, рәссамны таныды бугай, елмайды. Йа Хода, күктән иңгән фәрештәгә ничек сокланмыйсың, ди! Яңа гына шыткан яшел чирәм төсендәге күз, болыт итәгеннән кисеп теккәннәрмени, өстендә балитәкле ап-ак күлмәк, муенында вак алмалар сыман шул аклыкка тәгәрәшкән төймәләр, энҗемәрҗән чигелгән калфак, икегә аерып үргән чәч толымнарының очында көмеш чулпы! Аның зиһене чуалды. Йөз чалымнары таныш... Кайда күрде соң бу гүзәл затны, кайда?

Ул:

– Кызым, син ни атлы? – димәкче иде, парк сукмагында өчәү кул изәде:

– Сафия, хорга соңарабыз, әйдә!

Көтмәгәндә тап булган аклыкка тузан бөртеге дә кундырмыйча алып

кайтырга кирәк иде, Бакый остаханәгә ашыкты. Вакыт белән исәпләшмичә, дөньясын онытып, өч атна күрше бүлмәдә эшләгән карт рәссам картинага соңгы нокта төрткәндә суырылып тәмам бетәште. «Сурәтләр җан сорар, ди...» Исән чагында ук микәнни? Тынлык томандай таралган, баш гүелди, кайнар дулкын аяктан өскә табан үрмәли дә, суынып, янә табанга төшә иде, хәлсезләнгән Бакый диванга ауды. «Һи, сиңа бер ай срок дидеме? Улым Солтанның тормышына чәнти бармагыңны да тыктырмыйм, ата күке! Синең малаең юк. Моннан ары мин дә юк...»

Йөрәк комлы ярдагы балык кебек өч кенә тапкыр сикерде.

... – Кил, улым, – диде атасы.

– Тукта, әти, мин әле тегермән күренешен төгәлләмәдем!

– Борчылма, улым, адәм баласының җирдә өч көнлек эше кала. Әле генә бодай тарттырдым, кил.

Тегермәнче әтисе аның чәченә учлап-учлап он сипте. Тирә-як агарды, агарды, агарды.

Мәңгелеккә юл бик кыска иде...

Урам ишеге төбенең гомерлек «сакчысы» Тәүфыйк Зыятдин аны әрләп каршы алды:

– Югалдың син, туганкай, югалдың! Дүртенче ай күренмисең. Җансыздыр син, билләһи! Шөкер, кулың төзәлгән!

– Энем Алтайда яшәтте. Тынычта тау һавасы сулатып. Анда элемтә өзек. Бүген кайттым. Ишеттем дә... – Күңел касәсе тулган егет тешен кысып, көчкә түзде.

– Тынычта алайса, ә бездә менә күңелсез. Их, яшьти ишеген ачып куеп җырласын иде өздереп! Сагынырбыз без аны, сагынырбыз. Бәйгедә син беренче, шулай сөйләнә халык. Чын мәгәр, кыз сурәтең шаккаткыч! Маладис!

– Нинди «беренче»?! Нинди «кыз сурәте»?! – дип ачынып кычкырган Авзалны беләгеннән чеметте Тәүфыйк Зыятдин:

– Хәтерсез, бүлмәдәге иҗат җимешең турында әйтәм! Карале, сиңа әрсезлектән тыш тыйнаклык та килешә икән үзе.

...Яшь рәссамның идәнгә тезләнгәч кенә хәтере «уянды». Ак күлмәгенә бик килешле ак калфак кигән Сафия искиткеч гүзәл иде.

«Касә» ташып түгелде. Тыелалмыйча үксегән егет:

– Кичер, оста, син ул – җиңүче, – диде һәм нечкә кылкаләм белән киндер кырыена тамга салды: «Бакый Уразов».



Гөлназ
Гарипова-Дениз

# КҮКЛӘРНЕ ТУЗ ДИП БЕЛДЕМ ЛӘ...

## Бер күрүдә

Бу җиһанның һәр почмагы таныш,
Җиһан – миңа, мин җиһанга туган.
Бер күрүдән таныйм Мәхәббәтне –
Бар дөньямны кинәт югалтудан...

Илче булып алдан җырым бара,
Юллар салып хисләр арасыннан.
Бер күрүдән таныйм мәхәббәтне –
Сызлап куйган йөрәк авазыннан.

Күңел офыклары алсу-алсу....
Күз ачып йомганчы кояш чыккан.
Бер үбүдән таныйм мәхәббәтне –
Тәнгә түгел, җанга капкан уттан.

Газабыннан, сагышыннан таныйм,
Ярсуыннан таныйм, шашынудан...
Елмаешып аккан күз яшеннән,
Сулуларым кабып ашыгудан...

Кирәк-кирәксезгә дә көлүдән,
Канатсыз да очасы килүдән.
Кош тоткандай сөенеп йөрүдән –
Бер күрүдән...

---

Гөлназ ГАРИПОВА-ДЕНИЗ (1980) – *шагыйрә. Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлаган. «Чулпы чыңы», «Бер толым яктылык» исемле шигырь китаплары авторы. Төркиядә яши.*

***

Йөрәк тәрәзләрен шигырь чиртә –
Төн һавасын сулыйм йотлыгып.
Керфекләре йолдызларны сыйпый –
Бу – минем Болыт...

Төш пәрдәсен ярып җилләр иссә,
Йолдыз йокысыннан уяныр.
Һәр тамчысы – бер җыр булып төшәр –
Бу – минем Яңгыр...

Сөенечләр рәт-рәт тезелеп тора –
Кайгылар чигенә куркудан.
Сагышлары шау чәчәктә әле –
Бу – минем Урам...

Бәхетемнән күккә ашар өчен
Күп тә түгел, бары Син кирәк.
Мәхәббәтне баш таҗыдай үргән
Бу – минем Йөрәк.

Дөнья үзе яратудан тора,
Һәр мәл – бер могҗиза, бер тылсым.
Йөрәгемә кушылып бер Җан тибә –
Бу – минем Улым...

## Бер...

Бер сызланса йөрәк, чүлләр елар,
Елгаларның күз яшьләре кибәр.
Ябылуны белмәс иске ярам
Яңа яраларга бәхет теләр...

Бер елмайса йөрәк, җир-күк кавышыр,
Гашыйк диңгез ярларыннан ташар.
Айдан качкан парсыз йолдызкайлар
Кояшына сарылып күккә ашар!

Бер яратса йөрәк, онытылыр,
Мөлдерәмә бәхет белән тулыр...
Офыклардан тик Ул карап торыр,
Бу ярату барын оныттырыр...

Бер онытса йөрәк, хәтерләмәс,
Күзләреңә карар – тик күрәлмәс.
Килгән-киткән эзләрең табалмас...
Сүнгән йөрәк башка кабыналмас...

## Елама...

Күңел сазың сөю көен уйнаганда
Кыллар елый диеп уйлама.
Кар эремәс борын гөлләр көлми,
Бу да үтәр, үтәр, елама...

Көйнең уртасында күк күкрәсә,
Бәхетсезлек диеп юрама.
Яшеннең дә ялтыравы матур,
Бу да үтәр, үтәр, елама...

Берәм-берәм кыллар өзелсә дә,
Сабырыңның төбен сынама.
Үч саклама адаштырганнарга,
Бу да үтәр, үтәр, елама...

...Көй тукталып, кыллар тутыккач та,
Саз түренә сыенып уй кала...
Хатирәләр бәйләмен кочканда
Елмаерсың үткән елларга...

## Хат

Тузларны төннән сорадым,
Сүзләрне күңел тезде.
Яшеннәрдәй шашкын хисләр
Каләм кылларын өзде...

Үксеп еларга кыймадым,
Яңгырлар күптән бездә.
Күңелдә күкләр күкрәде,
Күзләрдә – чүлләр эзе...

Барын яхшыга юрадым –
Төнне, каләмне, эзне...
Сабырлар саеккач кыен –
Язлар куалмый көзне...

Күкләрне туз дип белдем лә...
Сүзләрне күңел тезде...
Йолдызлардан хатлар яздым –
Күктән укыгыз безне...

## Ябалдашлар кебек...

Яфрак йөзләреннән шигырь укыйм –
Кояш нуры язып калдырган.
Туган якның бөдрә каеннары
Минем җырларымны сагынган...

Ябалдашлар кебек зәңгәр күккә үрелеп,
Акчарлактан сәлам алыйммы?
Канат җилләренә йөзем куеп,
Артларыннан карап калыйммы?

Яфрак йөзләренә хатлар сырлыйм –
Җилләр туган якка илтсеннәр.
Бик сагынган сезне, дисеннәр.
Кунак булып кайтам, көтсеннәр.

## Туган өйгә

Яфракларның алкышыннан колак шаулый,
Күк гөмбәзе яңгыр вәгъдә итә –
Тәгәрмәчләр сагыну көен җырлап
Мине кабат туган якка илтә...

Сөенечкә уртак – коя яңгыр,
Яшеннәре – дуамал яшьлек күк.
Яңгыр белән мине сәламләве –
Гөмбәзләрне ярып күкри бу Күк.

Бу чакрымнар аңа берни түгел –
Күңел күптән инде туган өйдә –
Бу кавышу – яңадан туу күк,
Гел кайтасы, бик кайтасы килә...

## Ярый әле

Күз күрмәстәй кыллар киерелгән –
Күңелләрнең мөлдерәмә мәле...
Тәрәз каксам, һич борып чыгармый –
Сер сөйләргә таң бар... Ярый әле...

Сагышларны сары суырып үпкән,
Сагынуның үзәк өзгән мәле...
Туган басулардан сәлам булып
Аҗаганнар уйный... Ярый әле...

Яңакларда – таңнар сөрткән аллык,
Үзәннәрдә – учак күмерләре...
Йөрәк атлы йортка нигез булып
Хатирәләр яши, ярый әле...

## Улыма

Төннәргә әманәт күз нурым –
Ай белән серләшә сулышы.
Мин генә аңларлык моң тулы –
Улымның җыр кебек йокысы...

Бер керфек очында – мең кояш –
Яп-якты төннәрем-кичләрем.
Күңелемә бөртекләп тутырам
Улымның сер тулы төшләрен...

Һәр мәлгә «шөкер»ләр сыенган –
Учымда – нәп-нәни куллары.
Рәхәтнең рәхәте, бәхетнең бәхете –
Улыма бәллүләр җырлавы...

## Күз яше

Күбәләк-керфекләр тетрәнеп куялар
Күзләрдән бер бөртек яшь төшсә.
Күз яше – йөрәкнең туктамас яңгыры,
Күз яше – күңелдә бер чишмә...

Сөенсә, моңайса, яратса өзелеп,
Күңелләр түгелми чыдармы?
Яңгырлар – күкләрнең бүләге җиһанга,
Чишмәләр – Җир-ана җырлары.

Сөенә, моңая, ярата белмәгән
Җаннардан күз яше коелмас.
Яңгырлар яумаса, чүл булыр йөрәкләр,
Чишмәсез күңелдә җыр тумас.

Йөрәкнең гөлләре еламый, елмая,
Күзләрдән бер бөртек яшь төшсә.
Күз яше – йөрәкнең туктамас яңгыры,
Күз яше – күңелдә бер чишмә...

## Әти дигән күпер

Тагын дәште әти: «Кызым» – диеп,
Төш тә түгел иде, өн кебек.
Күзгә тулган яшьне көчкә тыеп,
Тәрәзәгә килдем йөгереп…

Тәрәзәләр кәрнизенә карыйм –
Әти сәлам язып калдырган…
Бүген тагын мамык кебек җилләр исә
Әти киткән юллар ягыннан.

Юксынуларыма ял булсын дип,
Пышылдап булса да дәштеңме?
Ишегалды тулы синең эзең –
Яшьләремне алар яшерде...

...Киткәч кайтмый торган йорт капкасы,
Ачылмыйча торсаң ни булган?
Ике дөнья чиген тоташтырып,
«Әти» дигән күпер сузылган…

***

Алданып арыган өметне
Кабызыр чаралар юк, дисәм,
Көлдәге бер калдык чаткыдан
Ут булыр кисәү дә бар икән...

Көзләргә авышкан йөрәктә
Сулышлы тамырлар аз, дисәм,
Көзләрнең элпәсе астында
Шау чәчәк келәме – Яз икән...

Тормышның типкесе астында
Алынган гыйбрәтләр бар, дисәм,
Күкрәктә һаман шул беркатлы
Алданып туймаслык җан икән...

***

Елмаясың, елмаясың – елмаеп туеп булмый,
Гел очасы килеп тора – канатны җыеп булмый,
Моннан да олырак бәхет сорарга кыеп булмый.

Йөгерәсең, йөгерәсең – йөгереп арып булмый,
Аның тавышын ишетми йокыга талып булмый,
Теләсәң дә, бу халәтне шигырьгә салып булмый.

Сокланасың, сокланасың – сокланып туеп булмый,
Бу матурлыкның эченә кайвакыт сыеп булмый,
Мөлдерәмә тулган хисләр, түгелсә – тыеп булмый.

Көн күңеле, төн теләге – барысы бәхет юрый.
Мин генә түгел, күге дә Ул диеп кенә сулый –
Йөрәккә уелса бер зат, этәреп куеп булмый:

Яратасың, яратасың – яратып туеп булмый...

***

Борынгылар:
Җиде кат үлчә, бер кат кис....
…Кайчы гына түгел, сүз дә кисә ич.
Сизрәп-сизрәп беткән йөрәк ямауларын
Типчеп кенә торам иртә-кич.
Җиде кат үлчә...
Уйлар озын юллар кичә,
Бер уй аклый бара никтер икенчесен –
Вак һәм эре үпкәләрдән таулар үсә...
Газапка тиң яшәүләре кичермичә...
Бер генә кис –
Кирәгеннән җаваплырак бүген бу хис.
Юлларыңа үлчәү-тамга сала-сала
Ялгыш адым ясалмыйча кала...
Борылып кара –
Акыл ярмыйча калдырган
Тәүге яра...

## Көткәндә

Күзләрем юлларда... Көтәләр.
Күзләрем юлларны үбәләр.
Ул мизгел җитүен күрмичә калмыйк дип,
Керфекләр ябылмый түзәләр...

Урамнан кешеләр үтәләр,
Сабырлар вакытны сүтәләр...
Ярату, кадерләү һәм бәхет эчендә
Минутлар тиз эреп бетәләр.

Җир шары яратып әйләнә,
Күзләрем юлларны үпкәндә.
Күңелдә чәчәкләр яшәрә,
Кадерле кешеңне көткәндә.

***

Чәчләрем сибелми җилләрдә...
Уйларым чәчелми илләргә.
Чәчелгән һәр шәйгә – бар тозак.
Язмышның сабагы – зур йозак.

Күз нурым түгелми һәркемгә,
Сокланмыйм җетеле һәр гөлгә.
Түгелгән – бөртекләп җыела,
Ялгышсаң, яңадан коела...

Сүзләрем манчылмый шикәргә,
Эзләрем кушылмый читләргә.
Читләшәм «алдану» затыннан,
Билгесез юлларның чатыннан.

Ачысын йоттыра, камчысын суктыра,
Алдымда – тормышның рәтләре.
Сыйныфым – билгесез,
гомерлек урыным –
Язмышның мәҗбүри мәктәбе.

*«Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» әдәби конкурсы*



Асия
Юнысова

# СЫЛУКАЙ

БӘЯН

*«Эх, бер балкып калсын әле яктым! –*
*Балта сабын салдым учакка».*
Саҗидә Сөләйманова

Мин «лаеклы ял» дигән сөргендә. Мәгариф, «Белем дөньясы» дигән локомотив, бихисап мөгаллимнәрен, шәкертләрен төягән вагоннарны сөйрәп, алга – киләчәккә таба хәзер миннән башка гына ыргыла. Минем дә кырык елдан артык гомерем шулар белән бергә алга таба омтылып узды. Януларым, ярсуларым, өметләрем, алдануларым, уңышларым, ялгышларым төялгән состав иде ул. Хәзер инде миннән башка гына... Шагыйрь Такташ әйткәндәй, «...хәзер инде яшьләр яратсыннар, хәзер инде яшьләр сөйсеннәр!..» Ә минем өлешкә очсыз-кырыйсыз уйлар йомгагын сүтәр өчен төннәр калды. Төннәр шундый озын икән ул. Янып эшләп йөргәндә, миңа гел вакыт җитмәде. Ә хәзер вакытым бик күп минем. Ирем дә, балаларым да, көн дә йөдәтә торган туган-тумачам да юк. Мине җылы канат ышыгында иркәләп-назлап үстергән, алсу төсләрдән генә торган якты дөньяга бер тәҗрибәсез кызын очырган әнкәем дә күптән инде фани дөнья кешесе түгел. Минем юлдашларым, тугры сердәшләрем – уйларым, хатирәләрем. Элек китаплар иде.

Кеше гомерен шаулап торган ябалдашлы, мәгъруранә күкрәп үскән агачка охшатам мин. Агач та бит, нәни бер үсентедән шулай күтәрелә, күккә үрли, яшел яфракларга, кайсыларыдыр чәчәкләргә төренеп, яшьлеген

---

Асия ЮНЫСОВА (1947) – *шагыйрә, журналист; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистларының Х.Ямашев, язучыларның С.Сөләйманова исемендәге премияләре лауреаты. «Үскән кыз», «Мин кышны яратам», «Айлы юл» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

үткәрә. Табигать биргән куәтенә карап, җимешләрен ил табынына өеп куя. Аннары, гомер сәгате суккач, корый башлый. Аңарчы кинәнеп яшәп кала әле ул. Гасырлар гына түгел, меңәр ел яшәгән агачлар барын беләм. Әйе, белеп була аны. Агачларның кәүсә кисемендә гомер елъязмасы язып барыла. Шул «язмаларга» карап, Җир планетасының кайчан, нинди казаларга тарыганын укый белүче ботаник галимнәр бар. Табигатьтә серләр бетәрме? Ул серләрне ачарга тырышучылар да һәр заманда да табыла.

Мин көндәлекләр язмадым. Яза башлаган идем дә, авызым пеште. Мин бер хакыйкатьне балачакта ук аңладым: кешеләрнең яшерен эч серләре чит күзләрне гомергә кызыктыра. «Ярамый» дип уйлаучыларга караганда, әрсез күзле кешеләр күбрәк. Фаш булган серләр шул серләр иясенә каршы төбәлгән ядрә ул! Димәк, чит-ятлар каршында күңелеңне шәрәләндерергә ярамый. Я-ра-мый! Укытучының көндәлекләре – мәктәпне тәмамлауга ил-көнгә сибелгән шәкертләре инде ул! Алар остазлары хакында нинди хатирәләр алып китәләр, алар күңелендә син нинди буяулар белән сеңеп каласың – шулар инде укытучының җанлы көндәлекләре.

Корыган агачны утынга турыйлар. Елгыр балта җыйнак яркаларга ваклаган, инде хәзер утын булган агачны матур итеп әрдәнәләргә өеп куялар да ипләп кенә, берәмтекләп кенә мичкә яга башлыйлар – ялкын биюенә карап сокланалар, җылыналар. Учак каршында утырырга мин дә яратам. Янган утка карап, кем туйган?!

Янган утын көлгә әйләнә.

Көл – ашламага!

Шуларны күз алдына китереп, укытучы гомере турында уйланам!

## Йокысыз төннәрдән репортаж

Журналист булырга да хыялланган идем мин. Вакыты җиткән икән бит. Көннәремне төннәр учагына ягып яшәп яткан җирдән үземнең көн дә бер репортаж язганымны абайлап алдым. Элек мәктәпләрдә «Радио-газета» дигән тапшырулар оештыра торган идек. Ягъни язмыйча, сөйләп кенә гамәлгә ашырыла торган журналистика. Минеке – уйлап кына. Менә кайда икән ул иркенлек. Кәгазь кытлыгы да юк. Вакыт чикләве дә... Хәер, вакытны таң чикли. Төнне йокысыз үткәргәч, иртәнгә уйлар сүлпәнләнә. Бәдән йончый. Төне буе бимазалаган уй-хатирәләр дә төссезләнә, кирәксезгә әйләнә. Көн яктысы кешене ятактан кубарып Кояш күзенә дәшә. Ярый әле, барлык тереклек иясенә тигез карый торган Кояш бар. Ул аермый, араламый, кимсетми! Төнге уйлар иркендә, дөресрәге, әсирлегендә ташлап калдырмый. Кояш кына мәңге балкысын!

Әйе, мәңге балкысын! Бәлки әле кешеләр дә, бәгъзе агачлар кебек, меңәр ел кинәнеп яшәүгә ирешерләр. Кеше – Тереклекнең таҗы, патшасы, диләр бит. Патша булгач, ни өчен соң кеше ташбака яки козгын гомерен дә яши алмый? Сәер, бик сәер сер бу! Ә бит озын-озак яшисе килә адәм баласының. Ниятләрен дә әле озак яшәрмен дигән уй белән кора. Өйләр сала, балалар үстерә, оныкларын күрә, туруннарын да күрергә хыяллана. Ә югарыда Кодрәт иясе елмаеп кына куя. Карарбыз, янәсе...

Хатирәләрем ничә төнгә җитәр икән? Ничә репортажлык яшәлде икән?

**Беренче төн**

Кеше гомерен балачагы балкыта. «Сугара» дип әйтәсем килеп китте. Чөнки кеше Балачак дигән чыганактан һаман-һаман су ала. Саекмас кое ул – Балачак! Шул коедан бер йотым су эчеп куюга, хәтердә әле бер сурәт, әле икенчесе терелә.

Март аенда «Кошлар көне» дигән бәйрәм бар. Аны мәктәпләр белә дә, бала-чага белә. Кошлар туган ягына кайтып җиткән көннәргә әзер булсын өчен сыерчык оялары ясый торган идек. Оялар, кошлы җырлар, кар сулары, якты нурлар... Талчыбык куначада сайраган елтыр томшыклы сыерчыклар... Менә шул була инде ул безнең өчен Җир йөзенә Яз килү!

Мин баланы ни өчен сыерчыклар өчен генә оялар хәстәрләү кадәресе гел аптырата торган иде. Әзер ояга кайткан сыерчык – ул һәрвакыт «безнең сыерчык» – оя эргәсенә кунаклауга сайрап та җибәрә торган иде. Өздереп-өздереп сайраулары аның! Күңелләргә бәйрәм инде менә. Аңа нәрсә – оя үреп азапланасы юк. Бөтен эшен ташлап, үзенә оя корып куйган хуҗаларына рәхмәт җырларын түгә. Безнең өчен дә кадерле, тансык концерт ул. Сыерчык сайрап торсын өчен куйдык бит инде ул матур ояларны.

Тургайлар да бик матур сайрый. Кеше күзе ирешә алмаслык биеклеккә – зәңгәр гөмбәзнең «төбенә» үк, биниһая югарылыкка ук менеп җитәләр. Күзгә күренмиләр, ә җырлары килеп ирешә. Алар кайда оя кора икән?

Әзер ояга кайтып керсә, карлыгач та сайрар иде микән? Нинди күркәм кош лабаса. Ә ул әнә кайтып җитүгә – карлыгач та бер дә ялгышмыйча, үз кыегына турылый – томшыгы белән кызыл балчык ташый, салам юнәтә. Аңа яңа ояда күкәйләр салып, балалар чыгарып, кошчыкларын очарга өйрәтеп өлгерәсе бар. Аннары янәдән диңгез-таулар аша ерак юлга! Бусы да бер могҗиза. Бала чыгарыр өчен ник туган илләренә кайталар икән алар? Югыйсә газаплы очышларда ничәмә-ничә кош җаннары кыела. Ә алар шул юлны һаман-һаман кабатлый. Океаннар аша очып үткәндә, канатлары бик тә тала торгандыр. Туктап ял итәргә юлларында кораблар очраса, ярый ла бит... Ә алар кайталар. Безне сөендерергә, безгә яз ясарга дип кайталар. Аңлап, төшенеп бетереп булмый торган фидакарьлек. Минем яраткан шагыйрәм Саҗидә Сөләйманова «кешеләр кошлар нәселеннән» дип язган иде бит әле. Ә минем «укытучылар кошлар нәселеннән» дип тәгаенлисем килә. Фидакарьлек җәһәтеннән! Әйе, укытучылар да кошлар затыннан!

**Икенче төн**

Оя, өй дигәннән... Минем әти дә укытучы булган. Фидакарьләр затыннан. Сала башлаган өебезнең түбәсен ябарга өлгермичә сугышка чыгып киткән. Түбәсе ябылмаган өй, хуҗасы кайтканчыга кадәр дип төреп, киштәгә куелган ипи кыерчыгы кебек көткән этине. Түбә ябылган анысы. Ә менә болдырга күтәрелә торган басмаларны кагып куючы табылмаган. Дөресрәге, кителгән күңелнең «кулы җитмәгән». Без бала чакта иптәш кызлар белән кемнең идәне ап-ак итеп, кырып-иләкләп юылган икән дип, бер-беребезнең уңганлыгын карап йөри торган идек. Шундый комиссия иде менә.

Зәнияләргә керәсең, капкадан өйалдына кадәр илтә торган ак яссы ташларга кадәр ялт иткән. Өйалды басмалары күзнең явын алырлык.

Идән сайгаклары ак кәгазьдәй. Без бәләкәй чакларда идән буяу дигәнне белмиләр иде әле.

Ә безнең болдыр басмалары юк. Туры өйалдына керәсең. Бер көнне ишегалдында карап-карап йөрдем дә лапас эргәсендә ике бүрәнә башы тәгәрәп ятканын абайладым. Шуларны болдыр каршына тәгәрәтеп китердем. Лапаска сөяп куелган такталарны алып килеп, шул бүрәнәләр өстенә салдым. Кадаклар таптым, чүкеч алдым... Әти төзеп бетермәгән өйне төгәлләп куймакчымын. Кешенеке кебек өй кирәк иде миңа.

Икенче юлы – инде мәктәпне төгәлләп киләм – өебезне кышка әзерләү хәстәренә керештем. Мин институтка китәрмен. Әнигә өй җылы калсын әле. Кышын бүрәнә ярыкларыннан җил өрә торган иде. Әни белән икәү балчык бастык. Ярыкларны сылап куйдык. Мин сыладым. Әни исе китеп карап торды... «Булдырасың икән, кызым. Мәктәпне бетергәч, авылда каласыңмы әллә?» Калмасымны белә. Әни – башлангыч сыйныфлар укытучысы. Мин дә укытучы булачакман. Һичшиксез! Авылда укытучыдан да дәрәҗәле кеше юк. Мин шулай уйлыйм. Әнинең бүрәнә ярыгын сыларга моңарчы тотынмавы да эштән курыкканнан түгел. «Кызым, Хөсния апаңа әйтермен. Син бүтән болай азапланма. Бераз әҗерен бирсәк, бик риза була ул. Укытучының куллары матур, чиста булырга тиеш. Күңеле кебек үк. Бала-чага укытучы апаны энә күзеннән үткәрә ул – шуны онытма. Пөхтә йөр, дәрәҗәле йөр. Бөтен эшне дә үзең эшләп бетереп булмый ул. Укытучының иң олы эше – мәктәп!»

Әни сүзе керә торган иде миңа. Ачуланып әйтсә, карышыр да идең. Ул чын педагог булгандыр инде, бер үгет сүзен дә баласына кырыслык аша сеңдерергә тырышмады. Иплә кенә, җайлап кына. Әмма мин бу юлы күңелдә йөрткән, инде онытылып бетәргә тиешле кинә сүзен әйтеп куйдым:

– Әйе менә, Хөсния апаны чакырырсың син. Минем тагын берәр кадерле әйберемне аның елак кызына биреп җибәрерсең. – Бик озак кызыгып йөргәннән соң сатып алынган, әмма миңа насыйп булмаган кызыл туфлиләрем искә төшкән иде.

– И кызым, кызым, кимәс борын бәләкәйләнгән иде бит инде ул туфлиләр. – Тәнәфестә Хөсния апа кызы йөгереп үткәндә, аның аягындагы искиткеч матур туфлиләрдән күземне ала алмыйча нәүмизләнеп кала торган идем. Үз аягымда резин галошлар гына иде.

– Мин өченче сыйныфта укыганда, мәктәп ятим балага ярдәм йөзеннән биргән киез итекләрне Шәйхи малаена биргәнеңне дә онытмадым әле мин.

– Аларда җиде бала иде. Шәйхи абыең – сугыштан аяксыз кайткан инвалид! Ә син минем берүземә берәү. Итек сиңа тиеш түгел иде. Гадел бирелмәде ул. Юкны уйлап, җаныңны ваклама, балам. Алда бәхетең күп булсын. Акылың зур, кибәкне бөртектән аера белерсең. Укытучы иң гадел кеше булырга тиеш ул. Укытучы дигән олы исемгә тиенгәч, иншалла, син бик гадел булырсың!

**Өченче төн**

– Казан ерак, Алабугага гына барырсың. Анда укыганнардан әйбәт укытучылар чыга, – диде әни.

Сүзен тоттым. Үзем дә бик еракка китмәм, әни янына ешрак кайтып йөри алырмын дип ниятләп куйган идем. Ялгыз кала бит. Җитмәсә, дөнья

көтү фәнен минем кадәр дә белми. Укыган елларда үз көнемне көтү әмәлен дә таптым. Хастаханәдә төнге кизүдә торып, акча эшләдем. Кизү торуның студент өчен уңай яклары бар. Төнлә авырулар бик борчымыйлар. Уяу төн чыгуның яшь чакта бер авырлыгы да юк. Филологларга әдәбиятны күп укыйсы. Эшең дә бара, китаплар да укыла. Сүзлекләр ятларга да җай бар. Чит телләр һәм рус теле укытучысы булырга әзерләнәм бит. Яхшы укыдым. Мохтаҗлык күрмәдем. Өс-башымны рәтләдем. Буем зифа. Чибәр дә, диләр. Әмма егетләрем юк. Алар кайда да юк инде. Укырга бик ашкынмыйлар иде бит элек егет затлары. Бигрәк тә безнеке кебек кызлар укый торган факультетта. Алай да ике егетебез бар иде әле безнең. Шуларның берсе – без Мокамай дип йөрткәне – миңа биш ел буе тагылып йөрде. Чын исеме Мөкатдис иде инде аның. Зыяны тимәгәч, ияреп йөргәненә алай ачуым чыкмый торган иде. Нигә дигәндә, кайгыртучан иде ул. Авылга кайтасы булганда, сумкамны күтәрешеп, вокзалга озата төшә. Кичкырын берәр яры барасы йомышым булса, озатып куя. Санчо Панса инде менә! Яратып йөргән егетем булмагач, көнләшеп торасы да юк. Җайлы бит – үзе бар, үзе юк!

Укып бетергән елны шул Мокамай барыбызны да шаккатырып куйды. Үзе теләп, хәрби хезмәткә китте бу. Флотка! Шуны алганнар бит! Буе бар иде инде анысы. Тик су асты көймәсендә йөзәргә озын буй комачауламый микәнни соң? Танкистлар җыйнак гәүдәле булырга тиеш дип ишеткәнем бар иде. Флотта буй кадәресе, күрәсең, мөһимдер. Әнә бит сугыш күренешләре булган кинофильмнарда буй-буй тельняшкалы, олы йодрыклы матрослар «полундра!» дип сөрән салып, кул сугышына ташланалар. Безнең Мокамай да диңгез бүресе булып кайтып төшәр микән? Чур мине! Ул кайткан төштә без Алабугада булмабыз инде.

Безнең төркем эшкә билгеләнү ыгы-зыгысында кайный. Кемгәдер туган төбәгенә кайту кирәк. Кемнеңдер ераккарак китәсе килә. Парлашучылар юк хөкемендә. Ә мин әйтәм: кайда укытучыларны торак белән тәэмин итәләр, шул авылга гына барам, дим.

– Гөлирәм! Нефть ягына кит син, – ди кураторыбыз. – Анда зур төзелешләр бара. Яхшы юллар салына. Ул якта электр кермәгән авыллар юк. Шәһәрләр якын. Гомумән, андагы авыллар шәһәрчә яшәргә өйрәнеп килә.

Кураторыбыз Госман Абдулычның бу тәкъдиме миңа ошый.

– Нефть төбәгеннән чакыру булса, мине истә тотарсыз әле, – дип, «кишәрлеккә» казык кагып куям.

– Гөлирәм, берәр бурильщик егеткә кабасың инде син анда. Һәр кичең нефтькә баткан эш киемнәре юып үтмәгәе әле синең.

Бусы – көнче ахирәтләр сүзе. Чөнки кураторыбызның да, деканатның да отличник студентның, ягъни минем үтенечне аяк астына салмасын чамалыйлар.

Шулай булып чыкты да. Мин Баулы районына җибәреләм.

Киткәнче төркемебез белән карар кабул итәбез. Бик тә мөһим карар бу. Үзе бик тә романтик. Дөрес, Ангара ягына китү түгел максатыбыз. Зур елгаларда ГЭСлар корып кую да түгел. Югыйсә Себергә, тайгага чакырган дәртле, яшьлек куәте ташып торган романтик җырлар безнең йөрәкләрне дә алгысыта.

Нинди Ангара, ди, әле ул монда! Үзебезнең Чулман буенда яңа шәһәр калкачак. Зу-у-ур химкомбинат салыначак. Бөтенсоюз комсомол төзелеше игълан ителгән иде инде. Шәһәрнең инде исеме дә тәгаенләнгән – Түбән Кама дип аталачак ул кала! Төрле төбәкләрдән зур төзелешкә дип килгән яшьләр корып куелачак химия комбинатының нигезенә субай кага башлаганнар. Тулай тораклар бар икән инде. Без бит – укытучылар. Мәктәпләр төзеп куелуга җыелырбыз Түбән Камада. Биш еллап гомер үтеп китәрдер инде. Үтә бирсен. Аңа кадәр билгеләнгән эш урыннарында белем бирә торырбыз. Ул арада үзебезнең дә кавырсыннар ныгыр.

Шулай килештек. Димәк, биш елдан барыбыз да кабаттан бергә булабыз. Югыйсә мәҗбүрият буенча, билгеләнгән урында өч ел эшләү дә җитә. Очрашу ихтималы булгач, аерылышу да авыр түгел икән. Хәбәрләшеп торырбыз дип, яңа адресларыбызны алмашабыз.

Хыялга бай син, Яшьлек!

**Дүртенче төн**

Юллар, чыннан да, шома икән. Башта – Әлмәткә, аннары Баулыга илтте мине ул юллар. Олы куллар һавага күтәргән кызыл чәчкәләргә охшаган факел букетлар юл буе озата барды. «Айсыз булса да, бик якты шул Баулы төннәрендә» дип җырлана торган җыр радиодан көн дә яңгырап тора. Хак икән, төннәр монда якты икән.

Мин РОНОдан әмер алып килеп төшкән Таллыяр авылы урамында кукраеп утырган нефть скважинасын күргәч, бөтән дөньяга килеп эләккәнемне тәмам аңладым. Яшәп күрсәтәселәребез бар икән әле болай булгач.

Сигезьеллык мәктәп директоры Гаязов абый кабинетына килеп кергәч, тагын бер хәйран калдым: минем капризым-гозерем үземнән дә алда килеп җиткән икән. Директор – сыңар куллы. Димәк, фронтовик. Сүзләре тәвәккәл, әмма кырыслыгы шаянлык, юмор белән өретелгән. Ишек шакып, керергә рөхсәт алган идем үзе. Директор янында кеше бар икән. Яшьрәк бер кыз, укытучы бугай, уку елы башланганчы өч көнгә туган авылына кайтып килергә рөхсәт сорый. Гаязов абый: «Һичшиксез рөхсәт, сеңлем. Тик син менә бу графиндагы суны эчеп бетерергә тиеш. Шунсыз җибәрә алмыйм», – ди. Мин бу сүзләрдәге мантыйкны аңламыйча шаккатып торам. Нигә инде әниең янына кайтып килү өчен тик торганнан ике литр су эчәргә кирәк икән? Минем дә бит әле танышу өчен генә килүем. Аннары өйгә кайтып, әйберләрне, бәлки әле әнине дә алып киләсе булыр. Мин катып торам. Ә теге бичара стакан арты стакан су эчә. Юк, мин бу кадәрле суны берьюлы эчә алмам.

Гаязов абый миңа таба борылып, күз кысып куйды:

– Синең белән, чибәр туташ, торачак өеңне бергәләп карап кайтырбыз. Мәхдүмәне авылына озатып җибәрик тә... Сиңа бит өй кирәк, диделәр. Шулаймы?

– Шулай. Әллә өй бармы? – дип сорадым. Өйле булу ихтималына сөенеп.

– Безнең мәктәп каршында укытучылар өчен салынган берничә торак бар. Яшәп тору өчен яраклы алар. Сиңа дигәне өр-яңа. Сөяктәй сөяннән өеп куелган. Килмәгән җирен китереп, чөен кагып яши башларсың. Син әниеңне дә алып киләсең икән бит әле?

– Әйе. Сез ул хакта каян беләсез? Берәүгә дә әйтмәгән идем.

– Чибәр икәнсең бит, сеңлем. Әниең берүзе калганын, әтиеңнең сугыштан кайтмаганын беләм. Безнең якта егетләр гаярь. Озак ялгыз йөртмәсләр. Ятим ананы еракта тилмертү дә дөрес гамәл түгел. Сагынуга дәва таба алганнары юк әле. Дөрес әйтәмме?

Дөрес әйтә иде директор абый. Кем сөйләде икән аңа минем хәлләрне? Гаҗәбенә ниләр диярсең. Әни әле картаймаган. Тик миннән аеры яшәүне күтәрә алмас ул. Алып килермендер. Икебез ике җирдә дөнья көтү яраган эш түгел. Башлы-күзле булырга җыенганым да юк бит әле.

Өйне карадык. Яшәрлек икән дип таптым. Беркатлы булганмын. Ниргәләре басылмаган, урынына утырмаган бүрәнә өем кыш буе минем белән салкыннарда усал итеп шартлап, җилле төннәрдә сызгырып сөйләшәчәк әле. Беренче кышны түзәрмен; икенче кышка кергәндә, мүкләсен мүкләп, кагасын кагып, туфраксасын сылап, җылы тотарлык хәлгә китерермен сине, өйкәем! Яңа булгач, һавасы рәхәт, диварлары якты, искелек тузаны коелмый. Әлегә директор абыйга җавабым: «Ошаттым!» – булды.

– Ошатсаң, менә шул. Авылны караштыр. Ык буйларыннан ура. Кайткач, әниеңә сөйләрсең. Бүгенгә өч укытучы яшәп ята торган өйгә кереп кунарсың. Сине әйбәтләп кунак итсеннәр. Хәер, сине алар янына үзем кертеп калдырырмын. Сез танышмаган бит әле. Иртәгә әниең янына кайтып китәрсең. Күченү хәлләрен сөйләшерсез. Август киңәшмәсенә матур күлмәкләреңне киеп килеп утырган бул. «Безгә менә нинди кыз килде!» – дип мактанырлык булсын директор абыеңа.

– Миңа да су эчәсеме соң?

Бу җөмләмне ишеткәч, Гаязов абый урамны яңгыратып көлде:

– Юк, сине җырлатырбыз гына. Җырлый белә дигәннәр иде. Мин үзем – гармунчы.

Сыңар кул белән ничек гармун уйный ала икән дип аптырап калдым. Аннары гына директор абыйның шаян кеше икәнлеге башыма барып җитте.

Авыл зур икән. Урамның берсен генә йөреп килергә өлгердем. Капкалар саен диярлек иске йортлар каршында буралар күтәрелгән. Сугыштан таланып чыккан авыл бөтәеп маташа. Әтиләренә алмашка калыккан малайлар-курпылар нефть эшенә кереп, акча эшли башлаганнар, күрәсең. Киләчәк тормышның матур булырына өмет бар Таллыярда.

Тыкрыктан гына Ык буена төшәм. Әрәмәләр, әрәмәләрдән ары тезмә таулар... Гүзәллек монда яши икән. Яратырмын мин бу авылны. Инде хәзер үк яратам бугай. Озаклап хозурланып йөрергә вакыт ягы тар. Директор абый мине мәктәптә көтеп тора торгандыр. Урнаштырып китәрмен дигән иде бит. Ашыгыйм әле мин. Яшәп калсам, Ык буйларын бер түгел, мең урармын әле. Өйдән биш минутлык арада гына ага бит ул минем сердәшем булачак елга. Әнә бит, өянкеләр дә: «Көтәбез. Кил, яме. Күрше булып яшәрбез», – дип калдылар.

Бөтен вөҗүдемне ниндидер бер ашкыну биләп алды. Мәктәпкә таба йөгердем генә.

**Бишенче төн**

Якты төннәремә килеп кердем. Татарстан буйлап август киңәшмәләре гөрләп узды. Мин дә Таллыяр мәктәбенең бер лаеклы вәкиле сыйфатында

ике көн җыелыш-утырышларда йөрдем. Коллегаларым матур-матур күлмәкләр тектереп кигәннәр. Бер-берләрен кызыксынып күзәтәләр. Миңа да игътибар итүчеләр бар. Гаязов абый әйтмешли, «Күлмәк бәйрәме» генә түгел икән әле бу җыелышу. Җитди сөйләшүләр дә булды. Министрлыктан килгән вәкилләр укытучы халкы арасында йөри башлаган хәбәрләрнең имеш-мимеш кенә түгеллеген раслады. Сигезьеллык мәктәпләрнең тиздән урта мәктәпкә әйләнү ихтималы бар икән. Ул «тиздән» дигәннәре кайчанрак булыр икән?

Таллыяр мәктәбендә балалар саны ишле. Икешәр булган сыйныфлар да бар. Димәк, урта мәктәп бу авылга тиеш тә тиеш инде. Укытучылар укырга атлыгып торган укучыларының тугызынчыга район мәктәбенә китүләрен белеп-күреп торалар. Көн дә йөреп укырга мәҗбүр икән инде болар. Ярый әле, бу авылдан нефтькә йөреп эшләүчеләр күп булганга күрә, транспорт мәсьәләсе бик тә уңайлы итеп хәл ителгән. Сәгать саен «школа» автобуслары йөреп кенә тора. Кайбер сәгатьләрдә автобуслар икешәр дә килә. Авыл халкы районга бару-кайту җәһәтеннән кинәнеп яши. Автобусларның кондукторлары бала-чагага бәйләнмиләр. «Кая барасың?» «Ипигә», «Китапка». Бара бир. Шундый зур автобуска берничә бала йөкмени! Таллыяр кешесе булып киткәч, бу рәхәтлек – авылның зур юл буенда урнашуы – минем дә офыкларымны киңәйтте. Вакытың мөмкинлек бирә икән, Баулысына гына түгел, Октябрьский каласына да, Бөгелмәгә, Урыссуга да тиз генә барып кайта торган идек. Кесәгә акча керә башлаган яшь чакта кием-салымны да кешедә югын эзлисең бит ул. Ә мин, гомергә белем алуга хирыс кеше, китаплар да төяп кайта торган идем.

Баштагы мәлдә мәктәптә сыйныфларның эреле-ваклы булуына аптырабрак калган идем. Ничек инде ул «дүртенчеләр» берәү дә «бишенчеләр», «алтынчылар», «җиденчеләр» икешәр! «Сигезенчеләр» тагын берәү генә кала. Гаязов абый күземне ачты. «Игътибар ит, бала! Бишенчегә зур авылның бистәләреннән аз санлы мәктәпләрдә «дүртенчене» тәмамлаган балалар килеп кушыла. Хәтта Ык аръягындагы Башкортстан авылларыннан да киләләр. Мәктәп кан яңарта. Зур сыйныфларны урталай бүлми чара юк. «Җиденче»дән соң – имтихан! Сыйныф тагын кимеп кала. Техникумнарга, СПТУларга китәләр – бушлай туклану, бушлай кием кию кызыктыра юксыл халык балаларын. «Сигезенче»дә укыту өчен тыеп калырга тырышмыйбыз. Монда инде соңгы сүзне ата-аналар әйтә. Ә кайчагында шундый өметле, башлы балалар адашып куя шикелле. Урта мәктәп булсын иде ул! «Җиденче»ләреңнән алдагы сыйныфларда өч ел рәттән класслар ярым буш булды. Чөнки сугыш елларында балалар тумады.

Ил язмышы балалар санына сукмый каламы соң инде?!

Әйе. «Җиденче»ләр минеке итеп тәгаенләнгән иде. Моңа кадәр аларның сыйныф җитәкчеләре булган Рәсимә Хәеровна, тиң ярын табып, башка мәктәпкә күченгән. Сыйныф кызларының елый-елый аны озатып калуларына шаһит булдым. Балалар мине кабул итәр микән, диебрәк, пошаманда торам. Яраттырасы килә!

Мине «җиденчеләр» белән директорның укыту эшләре буенча урынбасары Җәүһәрия Камаловна таныштырды. «Менә мәктәпнең иң яшь, иң акыллы, иң белемле укытучысын сезгә сыйныф җитәкчесе итеп алып

кердем. Рәсимә апагызны сагынып елап утырмагыз. Минем әле башка сыйныфларга да кереп, аларны да яңа уку елы белән тәбрикләп чыгасым бар. Госсамов! Тәртип өчен син җаваплы каласың. Сынатсаң, атаң янына үзем барам!» – диде дә, Җәүһәрия Камаловна күмер сыман күзләренең утлы карашы белән укучыларны шым итеп, ашыгып чыгып та китте.

Тәлинкә кадәрле зәңгәр күзләрен миңа төбәп, Госсамов елмаеп җибәрде. Мин дә елмайдым. Завучның кинаясеннән бу таза беләкле үсмердән сагаерга кирәклеген чамалап калган идем инде. Йә ярый, мин мәктәп күрмәгән кеше түгел. Үскәндә, әнигә ияреп, мәктәпкә күп йөрелде. Авылда балалар бакчасы ише әйбер юк иде бит элек. Иң арткы партада утырасың шыпырт кына. Кырыс укытучының өйдәге ягымлы әниең икәнлеген онытып торасың. Дәрес вакытында кече йомышка кысталып, чыгып керәсе булганда, кул күтәреп: «Апа, чыгып керергә ярыймы?» – дип сорый торган идем.

Җәүһәрия Камаловна чыгып киткәч, сыйныф-оркестр каршына дирижёр булып, мин килеп бастым.

– Минем исемем Закирова Гөлирәм Гәрәевна. Ә сезнең белән сыйныф журналындагы исемлеккә карап таныша барырмын:

– Абдуллина...

– Галиуллина...

– Инсапов...

– Нуретдинов...

– Хәмитова...

– Шәйхетдинов...

– Шиһапова...

22 фамилияне санап, Шакирҗановка төшеп җиткәнче тыныч кына барган танышу сеансы мәкерле елмаюга җитеп төртелеп калды. Фамилияләре әйтелгән балалар итагать белән генә торып басалар иде. Ә менә 23 нчесе – Шакирҗанов торып басмады. Партага гәүдәсен кыйшайтып яткан рәвештә калды. Мин бу циркка игътибар итмәдем. Беренче көннән үк тәмсезләнү кирәкми иде миңа.

– Хәзер инде сезнең сорауларга җавап бирермен.

– Апа, апа!

– Мин апа түгел, Гөлирәм Гәрәевна! Килештекме?

– Апа, әй кем әле, Гөлирәм Гәрәевна! Безнең андый исемне ишеткәнебез юк иде. Нәрсә соң ул «ирәм», гөлме, чәчкәме?

Инсапов бу. Шук, әмма яхшы күңелле малай булырга тиеш...

– Мин аны үзем дә күптән түгел генә белдем. Әбием кушкан исем ул Гөлирәм. «Ирәм багы» Бөек Моголлар мәмләкәтендәге (Моголларны каян белсен инде алар!) бостан – бакча булган. Бәлки әкияти берәр җирдер инде ул. Бик матур урын булган дип язалар аның турында. Хәзер дә бар микән ул? Барып күрсәң ярар иде ул. Мин бик тә матурлык яратам, сәяхәтләр яратам. Сезне дә матур, кызыксынучан кешеләр булып үсәрсез дип ышанам. Без моңа бергәләп ирешербез. Мин бит бүгеннән – сезнең сыйныф җитәкчесе.

– Аңынчы безгә чыдап каласыгыз бар әле.

Бусы мәкерле елмаю иясеннән кисәтү. Исеме нефтьягы өчен бик тә ярашлы икән тук кыяфәтле бу иркә малайның – Факел!

– Факел, куркытма әле син мине. Без әле синең белән дуслар булырбыз.

– Факел түгел мин, Факил! Дуслашып тормабыз, «сигезенчегә» калмыйм мин.

– Әле ул көнгә кадәр бер ел вакыт бар.

– Апасы, бер елга куян тиресе дә чыдамый, ди минем инәй.

Безнең шундыйрак рәвеш алган әңгәмәне кыңгырау чыңы коткарды. Рәхмәт кыңгырауга.

– Сылукай!

Чыгып барган мизгелдә мине куып тоткан өннең иясе Гөлнәзирә иде. Гел соңгы партада утыра торган, дәрестә аз сүзле кызның елына бер, әмма берәгәйле әйтеп куя торган гадәте бар, диләр. Шул сыңар сүз бик тә гомерле булып китә икән. Биология дәресендә Мичуринны үткәндә, урынсыз әйткән «Хәстәрчән американнар» дигән җөмләсе халык авыз иҗатына бер мисал сыман йөргәнен ишеткәч, үземнең дә фольклорга кереп каласымны сизгән идем аны. «Сылукай!» димәк.

Гөлнәзирәнең шушы бер өненә сыйныфның минем хактагы тәүге фикере сыйган иде. «Сылукай!» – әллә нишләтте мине шушы бер сүз. Шул могҗизаи өне белән миңа канат куйган латыш кызлары сыман җитен чәчле, озын буйлы кызыкай үзе бөтен бите белән кызарды. Чөнки сыйныф дәррәү көлеп җибәрде. Чөнки сыйныфка позитив кирәк иде. Ә кыз балага бу көлү позитивмы соң? Әнә бит ничек кызарып, башын түбән иде. Ул минем белән ихлас соклануының касәфәтен күреп, тагын да йомылып калмас микән? Мин аңа терәк булу җаен табармын. Ачылыр әле бу оялчан гөл!

Тәнәфескә омтылган балаларым белән бер дулкында мин дә мәктәп шау-гөренә кушылдым.

Гаязов абый мине кабинетына чакырып алды. «Җиденче»ләрем белән танышудан алган тәэсирләр кызыксындыра дип уйлаган идем. Директор абыйның җитди сүзе бар икән.

– Гөлирәм сеңлем! Син безгә бик кирәк вакытта килеп төштең. Рус теле һәм әдәбияты укытучысы Екатерина Алексеевна ялга китәр кебек сөйләнә. Рус кешесе бер киткәчтен кире әйләнеп кайтмый инде ул татар авылына. Димәк, аның рус теле сәгатьләре дә сиңа күчәр. Немец теле сәгатьләре җиткелекле анысы. Тагын бер рус теле укытучысы сорамыйча булмас. Август киңәшмәсендә ишеттегез бит инде – Таллыяр мәктәбен урта мәктәп итүләре бик ихтимал. Таллыяр мәктәбе дә урта мәктәп булмаса тагын... Укытучы апаларың һәммәсе дә югары белем алырга тырыша. Казан юлыннан кайтып кермиләр. Читтән торып укучылар саны ишәйде. Сезнең инде диплом кесәдә. Сессияләргә китеп югаласыгыз юк. Мәктәптә куна-төнә эшләрлегегез бар. Җиң сызганып торыгыз. Әниегезне алып килдегезме әле?

– Әни кышка кергәндә генә килергә ниятли. Йорт-җирне бетерү тиз түгел бит. Хәзер менә бәрәңгеләрне аласы бар дип тора. Аннары тавыкларын, казларын урнаштырып йөрер. Мин урнашкан өйне дә кыш чыгарлык итеп караштырасы бар икән бит әле. Әйбәтләп мүклисе...

– Ярый, сеңлем. Тәнәфес узып бара. Иркенләп сөйләшер өчен педсовет бар. Анысы шушы араларда булыр. Хәзергә синең «җиденче»ләрдә рус теле дәресе. Екатерина Алексеевнага ияреп кер. Сыйныфыңны арткы партадан

күзәтә тор. Бер атналап шулай йөрерсең. Балаларны төс-кыяфәтләреннән таный башларсың. Холык-фигыльләрен абайла. Үзең дәрес биргәндә бөтенесен дә игътибарга алу кыен ул.

Арткы партада утырганда, бер нәрсәгә шаккаттым. Укучылар рус теле укытучысы белән татарча аралашалар икән. Югыйсә Екатерина Алексеевна – коеп куйган рус кешесе. Балаларга рус телендә мөрәҗәгать итә. Ә тегеләр татарча әйттерәләр генә: «Катя апа, Катя апа!» Уңнан да ишетәм шуны, сулдан да... Ни хәл бу? Димәк, вакытында тыеп калучы булмаган. «Катя апа»лары да Инсаповларның «Мин, апа, незналяң», «мин, апа, не понимай»ларын елмаеп кына тыңлап тора. Сүзләрен, шуклануларын аңлап тора. Ун ел татар авылында эшләү дәверендә татарчаны да тәмам өйрәнеп бетергән инде ул. Әмма бер сүз дә татарча кайтарып әйтми. Укучыларның рус телен үзләштерү кадәресе дә, укыту кысаларында алганда, начар дип әйтерлек түгел. Әйбәт кенә өлгереп баралар кебек. Әнә бит, Левитанның «Алтын көз» картинасына карап, матур гына хикәя яздылар.

Аннары тагын бер гайре табигыйлеккә аптырадым. Татар апаларына, русларда урнашкан кануннар нигезендә, атасының исемен дә кушып мөрәҗәгать итү тәртибе урнашкан мәктәптә рус милләтеннән булган укытучыны «апа» дип йөдәтәләр. Екатерина Алексеевна моны үзе шулай теләгәнме, әллә шаян малайлар җиңеп чыкканмы? Рус телле укытучының мәктәптән китәргә теләвенең сәбәбе дә шул түгел микән әле?

Екатерина Алексеевна исә – сабырлык мисалы. Шук башлар бик азынып киткәндә генә «усалланып ала»: калын пыялалы күзлек эленгән йөзенә кырыслык рәвеше чыгара да шелтәләп алгандай итә: «Чего улыбаешься как майская роза! Вот возьму за ушко да посажу на солнышко!» Аның бу гыйбарәсен Таллыяр мәктәбендә ул елларда укыган кешеләр гомер буе онытмый. Екатерина Алексеевнаны искә төшергәндә, шушы җөмләдән соң һәрвакыт тагын бер җөмлә әйтелә: «Булса да булыр икән киң күңелле, ягымлы кеше!» Аның белән бер генә атна таныш булып калдым. Гомер буе онытмадым. Ә ул безнең мәктәптән декрет ялына китте дә кабат әйләнеп кайтмады.

**Алтынчы төн**

Бер атнадан колхозның бәрәңге басуына чыгабыз икән. «Коммунизмга» колхозы бала-чага ярдәменнән башка гына уңышны җыеп ала алмаячак. Гомумән, авылның бөтен эше бала-чага хезмәтен файдалануга корылган. Кырда эшләтү балаларга хезмәт тәрбиясе бирү дип атала. Алдагы көнне узган педсоветта Гаязов абый бурычларыбызны бәйнә-бәйнә аңлатты. Хәер, ул аны ел да аңлата торгандыр инде. Тир түгеп эшләгәннең әҗере интернатта торып укучы балаларның өстәлендә булачак. Базардагы үзбәк агайлары әйтмешли: «Хуп мәйле!» Эшләрбез дә, эшләтербез дә. Алай гына түгел икән шул әле. Бәрәңге басуы тәрбия кыры да булачак. Гаязов абый безнең бала-чага белән җил-яңгырда җилләвебезнең гаҗәп уңай якларын күрә: «Укытучы – балаларның гына түгел, бәлки бөтен авылның тәрбиячесе ул. Авыл абыстае, авыл агае үз өендәге тишек борыннарын тәрбияләүне мәктәпкә тапшырган. Имеш, әнә, яхшы укысаң, Гөлирәм апаң кебек гыйлемле кыз булып, биек үкчә, чиста кием киеп, дәрәҗәле булып йөрерсең, ди ул кызына. Миргалим абыең кебек фотоаппарат асып, авыл

хәбәрләрен район газетасына язып торырлык абруйлы адәм булырсың, ди улына. Улын-кызын чиста эштә итеп күрә авыл кешесе. Хөкүмәтебез исә укытучыдан бала-чаганы бәрәңге алудан, көтү көтүдән тәм таба торган бик тә белемле, зыялы кешеләр итеп тәрбияләп бирүне көтә. Безгә ни эшләргә кала, җәмәгать? Ни эшләргәме? Бала-чаганы бәрәңге басуына ашкынып барырлык итеп кызыктыру әмәлен эзлибез! Эшләсен дә ул, космонавт булырга да хыяллансын! Әхтәм Харисовичның Иптәшләр суды каршына килеп басмаслык юньле кеше дә булсын! Шулай бит, Әхтәм Харисович?

– Бик шулай.

– Димәк, ысулларын эзлибез! Кайсыгыз новатор булыр икән? Мин монда сыңар кулым белән сезне алкышлап, җиңүле адымнарга рухландырып, мәктәптә калып торырмын. Сез бер ун көнләп кырда тир түккәннән соң, күмер чапкан шахтёрлар кебек баеп кайтып төшәрсез. Ә без монда тылда калганнар белән мәктәп янындагы гүзәл бакчабызны кышка әзерләү хәстәренә керешербез. Очрашуга килгәч, юкә аллеяларында култыклашып йөргәндә, безләрне сагынып искә алырлык бакча калдырасы иде бит! Чәчәк түтәлләренә, җимеш куакларына күмелгән, биек-биек агачлары белән авылны ямьләп тора торган бакча! Багана башларындагы динамиклардан музыка яңгырап торыр. Эх, ямьле көннәр киләчәк әле. Шул көннәр хакына сугыштык лабаса!

Күмәк хезмәтнең хикмәтле тылсымын кем белми! Директор абый укытучыларга балчыкта казынырга кушмады. «Сез – рух бирүчеләр. Дәрәҗәгезне белеп кенә йөрегез, сүзегезне уйлап кына сөйләгез. Сез – үрнәк! Авызыгыздан хикмәтле сүз генә чыксын. Академиклар да, мактаулы табиблар да компасларын беренче укытучыларына турылап яшиләр. Барлык белемнәрнең башы – укытучыда. Фәлән-фәлән апа әйткән иде, фәлән-фәлән абый сабагымны өйрәткән иде, диярләр алар. Шулай бит, Әхтәм Харисович? Теге малай, Равилме әле ул, тәмәкесе авызы янында шартлаганын кешегә сөйләп йөрүен йөрмәде, әмма ул сабакны тәмәкегә үрелгән малайларның барысы да, мөгаен, белә. Тәвәккәл инде үзең дә? Кирәк бит – яшергән урынын табарга, тәмәке вагы арасына пистон куярга. Мин моны белмәдем, яме! Әмма дә ләкин мондый экспериментлар кабатланмасын! Саграк кыланыгыз. Әхтәм абыйларының кичәге шахтёр, бүген бүре сугып ала торган мылтыклы сунарчы булуын хәтердә тотканга күрә генә, эчтән тынды алар.

– Пистон кую тәмәке белән кем шаярганын ачыклау максатыннан булды инде ул. Чамасын белеп кенә бит... Радикаль чара димәктән. Туктадылар бит.

Бәрәңге басуы авылга якын гына. Малайларның байтагы велосипедка атланып килгән. Басу башында ташлап калдырганнар. Югалыр дип куркасы юк авыл җирендә. Малайлар – көрәк, кызлар чиләк ала килгән. Авыл баласына эш рәтен өйрәтәсе юк. Малайлар, буразналар алып, казый да башлады. Кызлар чүплиләр. Тулган чиләкләр башта күчкә бушатыла. Самосвал килеп җиткәч, машина әрҗәсенә төйиләр. «Егет кеше» оста гына айкап салуга кара туфрак өстенә эре-эре бәрәңгеләр тәгәрәп китә:

– Аh кызый, бәхетең мулдан икән! Гел эре бәрәңге генә чыга сиңа!

Кыз җитез генә «бәхетен» җыештырып ала. Кемгә авыррак икән соң

– малайларгамы, кызларгамы? Казу эше дә җиңел түгел, гел түбән иелеп чүпләү дә.

Менә минем эшем җиңел. Күз күреме иркенлекне күзәтәм. Кай тарафка карасам да, ерак офыкта таулар шәйләнә. Таулар... Таулар ымсындыра ул! Ашъяулык япкандай тип-тигез, ямь-яшел уҗым кырлары иркенлеккә өнди! Күрше басуда бодай уралар. Анда да Таллыяр укучылары комбайнчы ярдәмчеләре булып эшли. Кайдадыр ерак көтүлекләрдә озын чыбыркы сөйрәгән малайлар колхоз көтүен көтә. Басу-кырларга җиңелчә төтен исе, төтен сыман томан таралган. Җир исе, бәрәңге сабагы исе миңа да балачактан якын, таныш. Кайда да авыл хезмәте бала-чагадан башка гына булмый. Ил-көн белән тырмашалар. Сабанда сайрашалар, ындырда ыңгырашалар. Әллә нинди гыйбарәләр беләм икән бит. Балаларым янына барыйм әле мин дә. «Балаларым»нан, күп булса, ун яшькә өлкәнрәктермен инде. Ә үземне нindидер күпне күргән, зирәк кеше сыман тоям.

Бәрәңге басуында төшкә кадәр эшлибез. Арада туктап-туктап ял ясап алабыз. Мин «җиденче»ләремә укыган китапларымны сөйлим. Шәһрезадәгә әйләндем инде тәмам. Фраерманның «Кыргый эт Динго»сын өч көн рәттән сөйләдем. Кызыклы урында туктыйм да икенче көнне дәвам итәм. Җәүһәрия Камаловна латыш язучысы Вилис Лацисның «Җир тозы» әсәрен сөйли икән. Исләрем китте. Химия укытучысы шундый, үзе калын, үзе җитди китапны укып чыгарга ничек вакыт тапты икән? Югыйсә ул да читтән торып институтта укып йөри бит әле. Әле үзенең сөйләм теле дә бик ятышлы. «Сигезенчеләр» аны, вакыйгалар уртасына чумып, онытылып тыңлыйлар.

Китап арты кинолар сөйләү башланды. Кичке сеансларга мәктәп укучылары кертелмәүнең бер файдалы ягы бу. Укучылар, укытучылар караган фильмнарны күрми калганга күрә, безнең арсеналда кинолар бар. Иң җайлысы – һинд фильмнары. Иң җайсызы да шулар. Чөнки авылга һинд киносы килгәндә, олысы-кечесе клубка килеп тула. Тыеп кала торган түгел бала-чаганы да. Клубка үтеп керер тишекне табалар алар. Ата-аналары да һинд киносына «биш» тиеннәрен жәлләми.

Фәхрия Хәлиловна мәдәни программаны укыту программасына җайлаган: фольклор монда. «Алчәчәк» әкиятен (Аксаков язган аны, фольклор дисәм дә) «бишенчеләр» генә түгел, мин дә авыз ачып тыңладым.

Миргалим абый Шәрипов кыр эшләрен ямьләүнең ирләрчә ысулын тапкан. Минем сыйныф малайлары да шунда урала. Бер чиләк сап-сары бәрәңгене салам белән күмеп, тансык сый әзерләмәкчеләр. Кырдагы аш болай да тәмле тоела бит ул. Мондый экзотик ысул белән әзерләнгәне бигрәк тә телне йотарлык була. Студент чагында без дә колхозга йөрдек. Без дә чиләк каплап бәрәңге пешерә торган идек.

Бәрәңгенең тәмле исенә дә алданмыйча, һаман Нәкыя Гыймаевна тирәсендә – бәрәңге чүпләп, чиләккә җыйнап кайнашкан балаларым янына китәм. Боларны, эш дәртеннән бигрәк, Җирнең шушы ноктасында купкан глобаль бәхәс тота икән. Биредәгеләрне әкиятләрнең өр-яңасы – коммунизм мавыктырган.

– Апа-апа (рәсми эндәшү формасын читкә куеп торган икән болар), менә безнең буын коммунизмда яшәр дип әйтәсез сез. Егерме ел гына көтәсе.

Миңа анда 32 яшь кенә була. «Һәркемгә хажәтенчә!» булыр дип сөйлиләр. Бүген җитмәгән хажәт егерме елдан ничек җитәр икән соң?

– Менә, Инсапов, син бу бәрәңге төбен казып киттең инде. Бер төптән өч бәрәңге чыгардың. Ә мин чокып карасам, тагын икене табам. Менә таптым да. Димәк, намуслы хезмәт белән муллыкка ирешеп була. Әле бит фән-техника алга китәчәк дип торабыз. Җитештерү өч тапкырга үсәчәк әле ул. Менә күрегез дә торыгыз.

– Апа-апа, коммунизм булгач, күп һөнәрләрнең кирәге калмаячак икән... Ә минем юрист буласым килгән иде. Җинаять кылучылар беткәч, юристлар да кирәкмәячәк бит инде.

– Син, Идрисов, алдан ук кайгырмый тор. Сиңа дигән шөгыль табылыр. – Инде сөйләшүгә мин килеп кушылам. – Исемең ничек әле синең?

– Мөдәррис.

– Менә ничек. Синең кем буласыңны маңгаеңа язып куйганнар икән бит инде. Мөдәррис – укытучы дигән сүз бит инде ул. Мөгаллим сүзенә бик тә аваздаш. Укытучы һөнәре бервакытта да юкка чыкмаячак. Борынгы Грециядә безнең гасырга кадәр үк яшәгән Платон дигән философ әйткән бу сүзләрне. Үзенең остазы Сократны шулай зурларга теләгән ул.

– Ә ул Стократ рус кешесе булганмыни? Исеме гел русча сыман...

– Стократ түгел. – Мин рәхәтләнеп көләм. Бу малайлар әле, үсеп җитеп, белем ягыннан меңне бәреп егарлар. Хәзергә аларның самимилекләре үзе бер кызык. – Сократ ул. С-о-к-р-а-т! Борынгы дәвернең мәшһүр акыл иясе. Борынгы Греция фәннәр, сәнгать үсеше җәһәтеннән әле һаман да үрнәк. Бу дәүләттә – Элладада белемле булу иң зур дәрәҗә саналган. Димәк, кулдан авыр физик эш төшкәч, акылны җигеп, дөньяны алгарышка илтү өчен мөмкинлекләр күбәячәк. Кешеләр сәламәт яшәүне максат итәчәк. «Сәламәт тәндә – сәламәт акыл – тормыш зирәклеге менә шунда!» – дип әйтә торган булганнар алар. Эллиннар тән һәм акыл сафлыгын кайгыртуны алга куйганнар. Эллада дәүләтендә сәнгать, фән, театр, әдәбият алга киткән чорны Алтын дәвер, икенче төрле әйткәндә, Перикл патша гасыры дип йөрткәннәр. Ул дәвердән безнең дәвергә кадәр килеп җиткән мәрмәр сыннар әле хәзер дә сәнгати камиллек үрнәге санала. Алар уйнаган спорт төрләре безнең чорга Олимпия уеннары рәвешендә килеп җиткән.

– Ул Перикл гасырында да кара эшләрне мәктәп укучыларына йөкләгәннәрме?

– Юкны сөйләмә инде, ахир. Роботлар булгандыр...

– Әйе, коллар дигән роботлар булган, ди...

Сөйләшү ялгышрак тарафка китеп бара түгелме соң? Мин тагын бер акыл гимнастикасы ясап алам:

– Альберт Эйнштейн дигән галим турында берәр вакыт белми калмассыз. Шул галим менә ничек дигән: «Һичшиксез шундый көн килер ки, фәнни алгарыш кешеләр арасындагы гади аралашуны кысрыклап чыгарыр. Аралашудан мәхрүм калганнарның балалары дивана булып үсәр». Бер-берегезнең кадерен белегез. Ялгызлык – иң зур җәза ул. Ялгыз дивана... Уйларга да куркыныч.

Бәрәңге мастерлары, берара тын калып, мин әйткән сүзләр хакында уйланалар. Әлбәттә, бу тиклем зирәк сүзләр алар башында ягылып

кала алмый. Коммунизм исә менә генә – якын киләчәк сыман! Ул аңлаешлы! Әллә кайсы гасырда онытылып калган Перикл гасыры түгел инде ул синңа. Коммунизм кыры кул сузымында гына! Партиянең XXII корылтаеннан соң телдән-кулдан төшми торган ялтыравык уенчык ул – коммунизм.

Бәхәскә Нәкыя Гыймаевна нокта куйды:

– Инсапов, Идрисов, бу хакта алга таба да сөйләшербез әле. Учак янында безне генә көтәләр бугай. Әлегә «Һәркемгә – хезмәтенчә!» дигән лозунг – социализм шигаре гамәлдә.

– «Эшләмәгән – ашамый!» була инде ул безнеңчә. Минем бабай шулай ди...

– Барыбызның да бабайлары шулай ди...

Учак янына җыелышабыз.

– Абый, абый, иртәгә дә бәрәңгене чиләк каплап пешерик әле. Бүгенгесе бөтен кешегә дә җитми калды.

– Аның каравы, өйдәгесе – әниләрегез пешергәне тәмлерәк булыр. Иртәгәгә бәрәңге басуында сезгә эш бетә бугай инде. Мәктәпкә кайтабыз.

Шулай итеп, «эшкә өйрәтү декадасы» тәмам. Шәһәр мәктәпләрендә укучы балалар рәсем, музыка мәктәпләренә, төрле түгәрәкләргә йөреп, сәләтләрен шомарткан, төрле паркларда көзге алтын яфракларны ерып, туп типкән, эшсезлектән йөдәп йөргән арада авыл балалары «эшкә өйрәнде». Югыйсә авыл баласының йорт тирәсендә дә хезмәт куяр, эшкә өйрәнер урыннары күп. Мал-туарын караша, утын яра, мич яга, суга бара, үз бәрәңгеләрен ала.... Әле тагын макулатура җыю, көл җыю, ярдәмчесез калган ялгызларга барып, аларның эшләрен эшләшү. Күрше әбиләргә су китерү. Кыш буе мәктәп мичләренә ягар өчен кайтарып аударылган карт агачларны утынга яру. Бетә торган түгел инде авыл баласының мәшәкате! Кая ди инде ул дәрес әзерләп, өйгә бирелгән эшне уйлап утырулар! Шул килештән дә начар укымыйлар бит үзләре.

Бала-чаганы көзен – бәрәңге, җәен чөгендер басуында кәҗә майларын чыгарганчы эшләтү авылда калу хакындагы изге хыялларның тамырына балта чапмый иде микән ул?! Соңрак баш калкыткан, кызларны фермаларга сыер саварга төшереп, ничек итеп булса да, авылны яшәртү хакындагы хыял да яшь йөрәкләрдә таяныч тапмады.

Басудагы тырыш хезмәт әҗерле иде. Октябрь башында узган «Уңыш бәйрәме»ндә колхоз идарәсе мәктәпкә мандолиналар һәм баян бүләк итте. Интернатта яшәүче балаларны кыш буена тәэмин итәрлек яшелчә базга төшерелде. Әйбәт бит инде.

«Уңыш бәйрәме» уңаеннан укытучылар көче белән концерт куйдык. Мин өр-яңа алсу күлмәгемне киеп, сәхнәгә чыгып баскач, тамашачылар – укучыларның ата-аналары күпчелек иде – утырган озын эскәмияләр тарафыннан дулкын йөгереп узды: «Сылукай!» Минем яңа исемем авылга таралып өлгергән икән. Мин җырладым. Бу арада үзалдыма гел көйләп йөри торган җыр иде ул.

Бик еракта дусты, бик еракта,
Син дә шулай ерак дисеңме...

Эскәмияләр тагын пышылдашып алды: егете еракта икән моның. Сагына икән. Бик сылу, озак сагышланып йөрергә юл калдырмаслар... Шаулатып кул чаптылар үзе. Алдагы рәттә Гаязов абый утыра икән. Кул чапмады. Аннары гына барып җитте мин тиленең башына: сул кулы юк бит аның. Елмайды! Күңел күтәрер өчен безгә елмаю да җиткән.

**Җиденче төн**

Октябрь бәйрәме алдыннан педсовет буласы икән. Беренче чиреккә йомгак ясау инде ул җыелыш. Юньләп укыту булмады. Беренче чирек программасын йөгертеп кенә үттек. Күбрәк язма эшләр нигезендә чирек билгеләре куелды.

Гаязов абый өлгереш мәсьәләсенә артык тукталасы итмәде.

– Иптәшләр, үзебезнең корылтай белән тәбрик итәм сезне. Мәскәүләр үрнәгендә Президиум сайларбыз. Сылукай, син яңа кеше. Коллективка кереп китү өчен файдасы тияр: беркетмә язып барырсың. Синең грамота зур бит. Апаларың әле диплом юнәтү ниятеннән укып кына йөриләр.

– Ярар соң. Тик Сез миңа Гөлирәм Гәрәевна дип дәшсәгез, күркәмрәк булмасмы?

– Яшьләр көйле булыр инде ул. Мәшһүр химик Менделеев хатынына beләсезме ни дигән? Мин төзегән җәдвәлдә беренче урында хатын түгел, водород тора дигән. Мин җитәкләгән мәктәптә беренче урында кем торырга тиеш?

– Сез, Гаязов абый, Сез! – куштан тавыш иясен танырга тырышмадым. Яши-яши бөтен битлекләр дә ачылып бетәр әле.

– Булды. Шутить не будем. Көн тәртибенә ике мәсьәлә чыгарам. Беренчесе болай. Мин бүгеннән, иптәш Никита Сергеевич үрнәгендә, волюнтарист.

– Төшенмәдек.

– Төшенерсез, Әхтәм Харисович. Мин РОНО мөдиренә гариза яздым. Укытучыларны мәктәптән мәктәпкә күчереп йөртүләрне туктатуны үтендем. Ул үз чиратында югарыга язган. Уңай җавап бар. Димәк, көченнән килгән укытучылар, җир кишәрлеге алып, нигез сала башлый алалар. Утрак тормышка күчәсез. Таллыяр авылын яратып бетермәгән кешеләрне тотмабыз анысы. Тик мондый матур табигатьле авыл дөньясында бүтән юк. Берлинга кадәр барып җиткән карт солдатка ышаныгыз. Җир сораучыларның исемлеген төзүне дә сиңа тапшырабыз, Сылукай. Беренче итеп үзеңне язып куй. Башлы-күзле булганчы торып тор исемлектә. Аннары карарсың. Өй урыннарын үзегез караштырыгыз. Юллау мәшәкатьләрен үз өстемә алам. Колхоз рәисенең дә, авыл советы рәисенең дә мәктәпкә мәхәббәтләре артып киткән көннәр. Файдаланып калыйк.

Җыелыштагылар өй урыны сайларга хәзер үк чыгып йөгерергә әзер бер халәткә кергәннәр иде.

– Тынычландык, җәмәгать. Көн тәртибендәге икенче мәсьәлә уңаеннан сөйләшү төн уртасына кадәр җиткелекле. Бала-чагаларыгызны ашатып киткән идегезме? Мал-туарыгызны димим. Алары юк бит сездә. Өе булгач, каралтысы да, курасы да булыр. Хәзергә тавык, каз, умарта белән чикләнеп торырга киңәш итәм. Сөт-катыкка күршегә керерсез. Сыер җитәкләп, мал духтырына йөрүне хөкүмәт килештерми. Укытучыны вагайта, ди.

Мин дә килештермим. Укытучы кәртинкә кебек йөрергә тиеш ул. Әнә, Гүзәл Садриевна көзге пычракта да мәктәпкә ак резин итекләрдән килә. Вертолёты бар, ахры. Аңардан калышып тормагыз.

«Башмагым» спектаклендәге сыман, «тфү чорт ялгыштым», ягъни читкә киттем. Икенче мәсьәлә болай. Урта мәктәп дип хыяллануны дәвам итәбез. Әмма паровоздан алда йөгерә торабыз. Ур-ра, җәмәгать – Таллыяр мәктәбендә кичке мәктәп ачыла. «Сигезенче», «тугызынчы», «унынчы» сыйныфлар ачарбыз. Баштагы елны «җиденче» дә булыр. Тормыш хәле сәбәпле укуларын ташлаган бәгъзеләр өчен. Андыйлар бардыр дип уйлыйм.

– Бар, бар!

– Аннары... Тайт итеп кенә, «тугызынчы», «унынчы» сыйныфларны каян аласың әле аны. «Сигезенче»гә килгәннәре адымлап барыр алга таба. Ну, җәмәгать, дәрес сәгатьләрегез ишәя инде. Өй салырга акча кирә башлый үзегезгә. Эш көнегез дә төнге унбергә кадәр сузылмагае. Сез ризамы шундый шартларга? Юк икән, төп фәннәр буенча бер-ике укытучы сорыйсы булыр. Көчегез җитәрме? Булдырам мин аны дип алгысып, математика белән тарихны, география белән химияне алырга карамагыз. Бу номер узмас. Үз фәнегезне кичке мәктәпне тәмамлаганнар институтларга барып керерлек итеп укытсагыз, рәхмәт диярбез. Баулыга йөреп эшләүче шәп егетләр бар авылда. Хәзерендә Баулы урта мәктәбендә укып йөрүчеләрдән дә берничәсенең авылга кайту ихтималы бар. Өй артында гына укып йөреп булганда, акыллы кеше көн дә районга китәрме? Укытып чыгарсаң, әллә кем булырлыклар. Үстерик әле авылны. Таллыяр мәктәбен «Академгородок» ясыйк. Новосибирскидагы ише.

Җыелыш җанланды. Ничә кеше табып булырын уйлашалар. Төрле фикерләр әйтелде. Егетләр килер ул. Ә кызлар, гаиләле, балалы булып өлгергән, заманында җидеелык мәктәпне бик яхшы укып төгәлләгән кыз-хатыннар бар бит әле. Бәлки алары да укып, табиб булсаң иде ул дип хыялланып яшидер. Кыз баланың иң олы бирнәсе – диплом дип әйтә торган иде бит минем әни дә. Ире хатынын, хатыны ирен кичке мәктәпкә җибәрмәскә мөмкин. Клубка альтернатива була бит инде ул кичке мәктәп – яшьләр җыелган урын.

Кичке мәктәп мәсьәләсе алдан ук уйланылган, хәстәре күрелгән булган икән. Ноябрь башыннан эшләп тә китте. Авыл өчен мәгарифтә инкыйлаб кебек булды бу. Радиоузел аша көн дә хәбәрләр ирешеп тора. Исемлектә кемнәр теркәлгәне игълан ителә. Галиәсгар Камалның «Беренче театр»ындагы кебек «Вәли җизниләр баргач, без дә барабыз» рухы өйләргә үтеп керде. «Җиденче»гә алты-җиде кеше – элек көтү көтеп, мәктәпне ташлаганнар килде. «Сигезенче»ләр, гомумән дә, класс тутырып утыралар. Элегрәк мәктәп җидееллык кына булган бит.

Эшләп киттек шулай. Мәктәп көр авазлардан яңгырап тора. Өлкәннәр белән тәртип хакында да, белем алуның кирәкле шәй икәнлеге турында да сүз куертып торасы юк. Алар күбрәк киләчәккә хыяллар белән яшиләр. Өлгергәнлек аттестаты ачачак мөмкинлекләр хакында сөйләшәләр. Бер-берләренә ярдәмләшәләр. Иртәнге биштән буровойларга барып эшләүчеләр бит алар. Бурлаклар кебек түзәләр. Гомумән, ул елларда Таллыярда уку дәрте бик көчле иде.

Беренчеләрдән булып аттестат алганнарның барысы да диярлек вузларга барып керделәр. Уку йортларында да стаж белән килгән студентлар хөрмәтле иде. Инженерлар, юристлар да чыкты Таллыярдан. Без – укытучылар, аларның уңышын үзебезнең уңыш кебек күрдек. Алар белән бергә без дә көнне төнгә ялгап эшләдек. Мәктәптән кайтып кермәдек. Читтән торып укып йөргән апа-абыйларыбыз да дипломнарын алды. Берсе дә ташламады. Таллыярдагы кебек белемгә сусауны бүтән күрмәдем мин.

Минем белем эстәп, Казан юлында йөрисем юк-югын, әмма сәхнә бар. Авыл укытучысы «атказанган артист» та бит әле ул. Авыл яшьләре белән дуслашып алдым. Концертлар, спектакльләр куябыз. Шул ыгы-зыгыда уку елы узып та китә.

Җәйге каникулны Алабугада укыган елларда да көтеп ала торган идем. Каникул ул минем кебек ярым ятим кыз өчен ел буе мохтаҗлык күрми яшәрлек мая туплап, өс-башны юнәтеп кала торган вакыт. Берәр поезд маршрутына проводник булып урнашам. (Бу сүзнең төрки телдә «кылавыз» дигән алмашы да бар.) Дәрескә кергәч, сыйныфтагы кыз-кыркын энә күзеннән үткәрә торган матур киемнәрем шул елларда алынды. Маршрутлар Урта Азия ягына да, Кырымга да, башкалага да була торган иде. Мәшәкатьле дә, маҗаралы да. Берьюлы шулай Симферопольгә барабыз. Кара диңгез буеннан барганда, состав техник тукталыш ясап алды. И-и, шатлана-шатлана диңгезгә йөгердек. Әнә генә бит. Өлгерәбез. Безнең суга чумганны гына көткәндәй, состав тартылып куйды, кузгала да башлады. Сарафаннарны кочаклап, поезд артыннан чабабыз гына. Ә поезд туктап, безне көтеп алырга уйламый да. Соңгы вагон ишегенә эленеп өлгердек. Башсыз инде үзебез дә. Ялангач килеш диңгез ярында басып калсак, ни эшләгән булыр идек инде, йә?

**Сигезенче төн**

Төннәрнең аргамагы шундый инде аның. Бер төрле уйның чанасына утырсаң, әллә кайларга ала да китә. Әле кичке мәктәптә дәресләр башланмаган, ә мин инде аларны озатып та куйганмын.

Минем бит әле Гаязов абыйның волюнтаризмына бәйләнәсем килеп тора иде. Сәбәбе дә җитди. Көзге каникулга туктадык бит инде. Иртәгәсен йокы туйдырып, аннары юлга җыенырмын, әни янына кайтып килермен дип тора идем. Пионервожатый Фәния белән ишектән әни кереп килә. Минем фатирны Фәния күрсәткән. «Килеп чыгармын», – дип тә язмаган иде бит югыйсә. Мин үзем кайтып килермен дип сөйләшкән идек. Әнине җыендырып, алып китәргә кайтасы идем.

– Нишләп болай, әни? Ул-бу юктыр бит?

– Юк ла, кызым. Тукта әле, кая барып егыласымны үзем барып күрим әле дидем. Нигез бетерү уен-муен эш түгел ул. Торырлыкмы өең, җылымы икән, дидем. Карт сөяк җылы ярата ул!

– Тукта, ашыкма әле син. Башта синең күчтәнәчләрең белән минем чәемне эчеп алыйк. Фәния, син дә чишен. Әнинең кәрчә-мәрчәләре тәмле була аның. Тулай торак кызлары көтеп ала торганнар иде.

– Бар-бар. Кәрчә-мәрчәләрем дә, син алмый киткән җиләк кайнатмасы да миңа ияреп килде. Сез, яшьләр, күтәрергә яратмыйсыз бит. Без әниләргә сезне сөендерергә генә булсын. Аллап-артлап асабыз. Килгәч тә утырып

ашарбыз дип, өчпочмагын да тыккан идем. Мичеңә ягып җибәрүең әйбәт булган әле. Кая соң, плитәңә куеп җылытып алабызмы? Мич алдына куеп кынамы...

– Әни, башта үзең җылын әле. Итекләреңне салып, минем өйдә, корыда торган киез итекләремне киеп куй. Өем җылы дип мактана алмыйм. И әни, синең дә, минем дә җылы өйдән бәхет булмады инде ул.

– Мин торган фатир бик җылы. Әллә шунда күчәсеңме, Гөлирәм Гәрәевна? Минем әни кузгалып килә торган түгел. Эшлим әле мин дип карышты.

Әни Фәниягә кызыксынып карап алды:

– Әниең нинди эштә соң, балам? Син бит әле минем кызымнан да яшьрәк күренәсең.

– Ие шул. Мин мәктәпне генә бетереп килгән идем Таллыярга. Минем үземнән кече ике энем бар. Әнигә ярдәм итә башлыйм дип ризалаштым пионервожатыйлыкка. Күнегеп киләм инде. Әнием башлангыч сыйныфлар укытучысы минем.

– Синең әниең дә минем шикелле нәниләрне укыта икән ләбаса. Тагын ике энең булгач, эшләми хәле юк инде аның. Атагыз юкмыни?

Фәния аның сорауларын җавапсыз калдыргач, әни үзен минем янга китергән сүзләренә күчте.

– Әни, туктап тор. Кунакны сыйлап озаткач, иркенләбрәк сөйләшербез. Өчпочмагың тансык. Сүзне аны тук карынга сөйләшсәң рәхәтрәк. Җәелеп утырып сөйләшербез. Син үзең килгәч, хәзер минем дә ашыгасы җирем юк бит инде.

– Ә мин менә ашыгырмын, кызым. Алай да юл чынлыгы хакына икене кунармын. Сыйлан, кызым, Фәния. Без әле иркенләрбез. Гөлирәм, балам, мичеңә иртә-кич ягасыңмы? Мич каршына көйләнгән караватың миңадыр инде. Үзеңә тәрәзә буендагысымы? Салкын өрмиме соң тәрәзәдән? Мин киткәчтен, мич каршындагысына күчәрсең. Мин сине күреп кайтырга дип кенә килдем. Мәктәпкә кабат чакыралар. Илле яшьтән пенсиягә чыкмам бит инде. Ризалашырмын. Минем беренчеләремне алып калган Раушанияне күрше авыл егете урлап алып киткән. Вәйт заман! Берәү анда Галәмгә оча, икенче бер шундый ук егет, сарык бәрәнен урлагандай, кызлар урлый. Укытучы кызны бит әле! Ушларың китмәле.

– Ай Аллам икән, мин кайтып китим әле. Яхшы чагында. Йә минем юлыма да каршы чыгучы табылыр.

– Кисәтеп куючылар юктыр бит, Фәния балам?

– Бар бугай. Шуңа күрә кич клубка да чыгып йөрмим. Шаярып кына әйтүем. Исән-сау булып тор, Хәтирә апа. Күрешербез әле.

Фәния киткәч, әни төп сүзен йомгаклагандай итеп куйды:

– Кызым, мәктәпкә төшәргә ризалаштым инде мин. Икенче чиректән алып китәрмен. «Дүртенче»не бетерткәнче ташламам. Аннары сезне дә бит өч елга җибәрделәр мәктәпләргә. Торып каласыңмы, китеп барасыңмы – белгән юк. Түбән Каманы сала башладылар. Чит-ят килеп тулган, диләр. Шунда җыелышмакчы идегез бит.

– Әни, җир кишәрлеге алып, өй салып яшәү белән кызыктырмакчылар. Мин кызыкмыйм.

– Өй салу өчен тигезлек кирәк. Ялгыз күтәрә торган йөк булмас ул. Атыгызны шул Түбән Кама тарафына турыласагыз, дөресрәк булыр. Миңа киңәш итүең яхшы. Киңәшле эш таркалмас. Акыллы дуслар тап. Өлкәннәр сүзен тыңлый торган бул. Сиңа адресланган хатларны алып килдем. Ачып укымадым. Иркенләп укырсың әле. Бу торган өеңнең урыны әйбәт икән анысы. Торып калсаң, каз-үрдәк асрап яшәргә кызыга торган. Әмма өең, күршебез Зәйтүнә апаң әйтмешли, полуфабрикат кына икән. Бер көннән калмый җылыту хәстәренә кереш. Шундый зур мәктәпнең завхозы бардыр. Укытучының эше – укыту! Директор абыең белән сөйләш. Тик ипләп сөйләш. Җитәкчеләр янында тәртә җимермиләр. Аңлатып сөйләш! Югары белем кесәдәге диплом гына түгел әле ул. Диплом – акыл, дәрәҗә билгесе! Күзгә карап әйтеп булганда әйтәм инде, кызым. Ялан-ялан очрашып булмас. И-и, берәр миһербанлы бәндәгә юлыксаң иде дә соң, балам. Ул чагында акыл биреп йөдәтмәс идем. Үзем сезнең акыл белән яшәр идем.

Икенче чирек аеруча тиз үтеп китте. Чөнки елның иң күркәм бәйрәме алда тора. Яңа елга әзерлек ыгы-зыгысы рәхәт тә соң ул! Яңа ел бәйрәме үзе дә чыршыга эленгән ялтыравык пыяла уенчык сыман елык-елык килеп ымсындыра, мавыктыра, кызыктыра, әллә ниләр вәгъдә итә.

Вәгъдә итүчеләр арасында, әлбәттә, укытучылар иң алда тора. Беребез – Кыш бабай, икенчебез Кар кызы булып, әдәбият укытучысы белән немец теле укытучысы матур кәрҗиннәрдән тәмле күчтәнәчләрне дә, хыялый вәгъдәләрне дә күп сиптек. Чыршы тирәли сикереп тә йөрдек, сикерттек тә. Үзең катнашкан уеннар аеруча күңелле була бит ул. Мин – яшь кеше. Миңа сикерү берни түгел. Ә Фәхрия Хәлиловна ничек бишкә төрләнеп өлгерә икән соң? Кыш бабай тунын салуга сәхнәгә Шүрәле булып, озын бармаклар киеп чыкты. Ә үзенең бит иртәгә юлга чыгасы, Казанга сессиягә китәсе бар.

– Ничек шулай булдыра аласыз? Бер дә үзегезне аямыйсыз! – дип сорадым аңардан кышкы каникуллардан соң, – февраль аенда инде бу – «Аҗаган» уены вакытында балалар белән беррәттән түше белән кар ерып шуышып барган Фәхрия Хәлиловна янына «позициягә» килеп яткач.

– Агач мылтыклардан ата идек без сугыш елларында. Ул чагында уен кебек түгел, чын сугышка әзерлек сыман иде. Хәзер уйныйбыз гына бит. Үзе бер рәхәт. Әнә, үзеңә кара – ничек итеп битләрең алланып чыккан. Чын Кар кызы булгансың. Безнең шулай ихластан уйнавыбыз балаларга да бер кызык. Аннары ни бит, сеңлем, укытучы беркайчан да үзе өчен яшәми. Дөресрәге, укытучы укучыларында эреп бетә. Син үзең дә шундый ла. Үзеңне читтән күрмисең генә. Менә абайларсың әле: без бүгенге «Аҗаган» уеныннан мәктәпкә бүтән кешеләр булып кайтып керербез. Безнеке кебек шәп профессия юк ул. Күр әле, безне никадәр самими йөзләр, самими куаныч төреп алган. Бу самимилекне алдарга ярамый. Адәм баласы мунчада шәпләп юынганнан соң да чиста су белән тәнен йөгертеп ала. Ә без – укытучылар, шул сафлыкның уртасында кайныйбыз. Бездән бик күп нәрсә тора. Саф күңелле баланың ышанычын җуймас өчен укытучы үзе дә ихлас булырга тиеш. Булдыра алган кадәренчә...

**Тугызынчы төн**

«Аҗаган» уеныннан соң Ык аръягындагы карга төренгән әрәмә, аклык,

сафлык дөньясы гел үзенә тартып торды. Математика укытучысы Нәкыя Гыймаевнаның бертуган сеңлесе Сәрия белән танышкан идем. Яшьләребез бер тирә. Ул да туган авылын сагынып яши икән. Баулыга йөреп эшли. Экономист белгечлеге булганга күрә нефть идарәсенә урнашкан. Минем белән уртак яклары да байтак. Сәяхәтләр яратам, ди. Мин дә сәяхәтче бит. Иптәш табылганга сөенеп торам әле. Әрәмәдә чаңгы шуып, кып-кызыл гөлҗимешләр белән сыйланып йөргәндә, серләр дә килеште. Бер фатирда яшәсәк иде ул диештек. Сәриягә дә апа-җизни янында читенрәк, ахрысы.

– И, Гөлирәм, җае табылырга тора ла аның. Алар яңа өйгә күчкәч, син алар яшәгән йортка күчеп калсаң, ару булыр иде. Директор белән алдан сөйләшеп куясыңмы әллә? Безнең җизни алтын куллы кеше бит ул. Өйләре каралган. Тишек-тошык та, ишелгән урын да юк. Күршеләре җайлы кешеләр. Мунчалары яхшы ...

– Шул мунча ягы чыннан да кызыктыра. Өй борынча мунча белешеп йөрү оялдыра. Баулыга барып, шәһәр мунчасында юынып кайтам.

Әгәр Сәрия белән бергә шул өйдә торып калсак, дип хыялланып алам. Бер-беребезне кайгыртып яши алыр идек әле. Икебезнең беребез башлы-күзле булганчы... Әни килмәскә уйлады бит инде.

Укытучы профессия генә түгел шул. Ул – диагноз! Минем әнием дә шул диагноз белән яши. Кызы янына күченеп килергә ашыкмады. Кышкы каникулда, Гаязов абыйдан рөхсәт сорап, үзем аның янына кайтып килдем. Хатлар җыелган икән. Берсен дә ачмыйча Таллыярга ала килдем.

**Унынчы төн**

Әнинең Тәүгилдедән китәсе килмәгәне ачыклангач, директор янына кереп, фатир хәлен тагын бер кат уртага салып сөйләштем.

– Гаязов абый, мине әрсезләнә дип уйлый күрмәгез. Анысы түзәргә була ла ул. Мин Сезнең кебек тәҗрибәле кешегә акыл бирерлек яшьтә дә түгелмен. Сез минем патша сараен кыш мәлендә бер күреп китәсезме әллә? Мин юлламада каралган өч елны юрганга төренеп тә түзәрмен. Йорт үзе табигать сынауларына бирешер дип куркам. Мин әле иң мөһим хәбәремне әйтми тордым. Сәрия апасы белән җизнәсенең яңа йорт җиткереп мәшәкатьләнүләре, аларга үзенең дә матди яктан ярдәмләшүе хакында әйтеп алган иде бит инде. Мин бу серне ачарга тиеш идемме икән, юк микән? Хәер, авылда өй бетерү кебек олы хәбәр сер булып кала димени инде! Сәрия дә, мине сертотмас үрдәк дип гаепләмәс. Үзе бит директорыңа кереп сөйләшеп куй дип киңәш бирде. Ә ул, апасы Нәкыя Гыймаевна кебек үк башлы кыз. Уйламаган сүз әйтә торган түгел. Тәвәккәл таш яра, ваемсыз баш яра, ди торган иде әни. Ә мин, әни сүзе белән йөри торган, тыңлаучан бала идем.

– Алай дисең инде, Сылукай. Минем сине үз кызым кебек күреп, якын итүемнән файдаланасың. Кабинетымның ишек тоткасын шомартып бетердең.

– Икенче генә керүем. Гафу итә күрегез. Алай еш бимазаламам.

– Хуп мәйле... Шушы арада завхоз абыең белән кереп, гүрнәчәңне карап чыгарбыз. Өркетеп тә куйгачтын инде... Мәсьәләгә җитдирәк карарбыз. Нәрсә, бүгеннән үк өч кенә ел эшләрмен дип торуыңмы? Сылукай, өч ел узган җирдә, җиде елы да узып китә аның. Теге мәзәктә ничегрәк әле: кияүгә

чыгасы кыз чыкмаган, үләсе карчык үлмәгән! Оясын яратмаган каз кебек кыланып йөрүеңне ошатмыйм. Конкрет тәкъдимең тагын да бар идеме?

– Менә бит, үзегез үк минем буразнага төштегез. Минем өч елым – конкрет. Без сабакташлар белән өч елдан соң Түбән Камада җыелышырга килешеп таралыштык. Әле бүгеннән үк бу хакта сүз башларга уемда юк иде. Теге педсоветта волюнтарист булырга ниятләвегез өметләндереп куйган иде.

– Шуннан ни? Волюнтаристларга мөнәсәбәтең әйбәт түгелмени синең?

– Мин озын колактан Әхтәм Харисовичларның Аргы урамда өй җиткереп килүләрен ишеттем. Нәкыя Гыймаевнадан, дөресрәге, аның сеңлесеннән белештем. Ул хәбәр хак икән. Ул гаилә яңа өйгә күчә калса, алар хәзер яшәп ята торган өйгә мин күчәр идем.

– Ул яшәгән өйгә кем дә күчәр иде. Әнә бит, минем волюнтарист булып китүемне дә көтмичә өй салып ята. Бу сүзең – хак! Син әле ул абыеңның узган кыш бүре сугып кайтканын күрмәдең. Малай-шалайлар белән низаг чыга калса, Әхтәм абыеңа гына сиздер.

– Сылукай үзе дә җебегән кыз түгел...

Директор кабинетында тагын бер кеше барлыгын абайламаганмын икән.

– Мин Сылукай түгел. Гөлирәм Гәрәевна, дип эндәшегез миңа, Зәһәрия Камаловна!

– Менә каптың, Сылукай! – директор абый сыңар кулы белән бот чабып көлә иде. – Ул да бит Зәһәрия түгел. Җәүһәрия – Бриллиант булыр бу апаң.

– Ай, кичерә күрегез, Җәүһәрия Камаловна! Мин икесе дә Сезнең исем дип торам.

Сыйныфны указка очында гына тотып тора торган, дәрес вакытында тын да алдырмый торган, күзләре утлы күмер сыман янып торган Җәүһәрия апа белән пычакка пычак килү! Юк, кирәкми иде миңа мәктәп коллективында мондый көчле дошман.

– Зәһәр натр исемә төште Сезне күргәч. Үзеннән-үзе телемнән ычкынды. Балалар чире йогышлы бит ул. Менә күрәсезме, мин чыннан да «Сылукай» дигән матур кушаматка лаек түгел.

– Ярар сана, бала булма. Җәүһәрия апаң кебек киң күңелле кеше дөньясында юк. Онытты инде ул аны. Кушаматның бер ишесе дәрәҗәне генә арттыра аның. Сезнекеләр шундый.

Бер көнне өемне карарга комиссия килде. Юри чатнама суык, мәктәпләрдә укулар булмаган көнне сайлаганнар, күрәсең. Мичем шарт-шарт янып тора. Өйнең ниргәләре бәсләнгән иде. Мичкә каршы дивардан тамчылар тама. Өйгә урамнан туры килеп керешле. Болдыр ише корылма юк. Ишекнең аскы ягын интернаттан иске одеяллар алып кайтып тыгызлаган идем. Көч-хәл белән ачып керделәр.

– Синең монда блиндаж кебек икән, – диде артиллерист Гаязов абый. Аннары: – Яшь кеше өшимени ул, – дигән булып, үз сүзен куәтләде.

Завхоз Ильяс абый – бик акыллы кеше. Актан-күктән бер сүз әйтми караштырып утырды да киткәндә генә: «Гаязов абый, җәйгә чыккач һәммәсен рәткә китерербез. Яңа хуҗалар зарланырлык булмас. Гөлирәмне җылыга чыгарыйк инде без. Сезнең теге тәкъдимегез әйбәт тәкъдим ул», – дип, ишек тирәсен кагыштырып алды.

– Чамалап як. Янгын фәлән чыга күрмәсен. Утының җитәрлектер бит? Кирәк икән, китертербез, – диештеләр. – Әниеңне кузгатмый торуың да дөрес булган. Хуҗалары бик мактагач, мәктәп әйбәт кенә өйгә тиенде дип калган идек тә. Әле бит беренче елын гына кышлый. Бүрәнәләре начар түгел, урыны да әйбәт. Кеше кызыгырлык йорт итәбез әле аны. Килер бер көн. Илебез тәмам тернәкләнеп җитәр. Укытучыларга дипломы белән бергә өр-яңа фатир ачкычы бирә башларлар. Укытучы – илдәге иң дәрәҗәле, иң мөһим профессия икәнен аңларлар.

Мин өй сорап, бүтән аптыратмам дигән уйда калдым. Тиздән көннәр дә җылыныр. Яз, яз арты җәй җитәр. Яшәрбез әле!

Май башында Әхтәм Харисовичлар яңа өйләренә күченделәр. Сәрия белән мин алар өендә торып калдык. Йорт җиһазларының да байтагы безгә калды. Икебезгә алты почмаклы зур фатирыбыз бар. Матурлап бизәп куйдык. Чәчәкле пәрдәләр элдек. Китап шкафыбыз өйнең төп бизәге булды. Нәрсә-нәрсә, китап байлыгы бар инде бездә! Китап – укытучының иң ышанычлы, иң зур коралы!

**Унберенче төн**

Рәхәткә тиендек.

Яңа торагыбыз мәктәпкә дә, клубка да якын гына. Тормыш уртасында кайныйбыз. «Җиденчеләр» дә еш кына кереп чыгалар. Стена газеталары чыгарасымы, концертка әзерләнәсеме – мәктәптә буш класс бүлмәсе эзләп йөрмибез. Үзебезнең өйдә генә җыелышабыз. Атнаның бер көнендә кызларны мандолинада уйнарга өйрәтәм.

«Май ае җиткәчтен» дигән җөмләнең дә сере ачылды. Тик әле хәзергә җиһанда март хөкем сөрә.

Безнең сыерчык мине эзләп тапкан бит! Әлбәттә, ул түгел. Безнеке әнием янындагы оясын җыештырып йөри торгандыр әле. Безнең өй кыегындагы колгага кунып, очынып-очынып сайрыйдыр. Кара атлас киемнәрен төзәткәләп куядыр. Өй нигезенә кояшта кызынырга дип чыгып яткан песиебез аңа карап ымсынып-ымсынып аладыр да, үз мөмкинлеген дөрес чамалап, тыелып кала торгандыр. Сыерчык кайда да, ул кайда! Бәлки әле песикәйгә дә сыерчык җыры бик тә ошыйдыр. Бәлки әле ул да безнең сыерчыкны таныйдыр. Ә мин аларның икесен дә сагынам. Яз килде бит, яз!

Таллыярда яз Ялпы тавы ягыннан кар сулары булып агып төшә. «Камышлы Каран ярган!» дигән өн булып килә ул. Кичке тынлыкта болдыр баскычына чыгып басып, колагыңны сагайтсаң, яз тавышын – Камышлы Каранның тыенкы гөрелдәвен ишетәсең. Кар сулары Ыкка төшеп кушылырга ашыга. Кар сулары зур елганы кышкы йокысыннан уята!

Менә бер көнне мәктәптә ыгы-зыгы купты:

– Ташу китә!

Дәрес бара иде. Класста бер бала калмады. Ташу китә икән бит! Елга бер генә була торган иң бөек тамаша. Хәтта укытучылар да резин итекләрен киеп, Ык ярына ашыкты. Авылның бөтен халкы шунда, диярсең... Зур сулар янында яшәгән кешеләр генә мондый ашкынуны аңлый торгандыр. Иделдә дә ташу тынычрак китә. Чөнки анда бозларның куәтле ташкынын тыю чаралары алдан күрелә.

Ык буена мин дә төштем. Тыкрык башыннан карап торучылар янына

бик якын бармыйча гына күзәтәм. Таллыяр халкының мәҗүси бәйрәмен манзара кылам. Бала-чаганы тыеп, боз өстенә менмәскә өндәп кисәтүләрне санамаганда, нигездә, бу галибанә күренешне өлкәннәр сабыр гына күзәтә. Ел да кабатлана торган манзара бит инде югыйсә. Юк, кешеләр күңелендә барыбер табигатьнең дәртенә, буйсынмас кодрәтенә табыну, хәтта ки соклану яши! Әнә бит кемнәрнеңдер утын өемнәрен, яр кашында гомер бакый үскән өянкеләрне җиңел генә иңнәренә салып, бозлар Агыйдел тарафына алып китә. Агыйдел аларны Чулманга илтеп тапшырыр. Чулман Иделгә, Идел Каспий диңгезенә. Таллыяр малайлары боз өстендә яккан учаклар да шунда китәр.

Мин үзалдыма әкрен генә көйлим:

Кар сулары, кар сулары!
Үтәрме ярсуларым.
Сөйләсәм дә аңлашылмас
Серләрем бар шул әле...

– Гармун белән төшүем дөрес булган икән. Гөлирәм Гәрәевна булган җирдә җыр булмый калмый инде ул!

Кичке мәктәпкә сигезенчегә килгән Фасил бу. Гармунда өздереп уйный. Шуңа мин аны гармунчы егет дип хәтерләп калдым. Бу егет быел армиягә китәсе бугай. Тик укуын бүлмәс өчен сәбәпләр бар. Беренче сәбәп – армиягә каралучыларның саны кирәгеннән артык икән. Шуңа күрә белемгә омтылган яшьләр калып тора. Фасил башка егетләрдән җитдилеге, ниндидер нәселдән килә торган зыялылыгы белән аерылып тора. Нишләптер, җиденчедән соң укуы бүленеп калган. Югыйсә аның иптәшләре Баулыга йөреп тә, алга таба укып киткән бит.

– Фасил, син клубка гына түгел, ташу карарга да гармун белән йөрисең икән. Минем җырлавыма игътибар итүеңә рәхмәт. Бәлки әле концерт-фәлән әзерләгән вакытларда даими аккомпаниаторым булып китәрсең. Зәкинур абыегызны эләктереп калу кыен.

– Мин риза булыр идем анысы. Сез минем уйнавымны килештерсәгез, – диде ул, кыенсына төшеп. – Их, баян булсын иде ул!

– Мәктәпкә Уңыш бәйрәменә бүләк ителгән баян тик тора бит. Гаязов абый белән сөйләшеп карарбыз. Мәктәп мәнфәгатен дә искәртсәк, каршы килмәс ул. Сугышка кадәр гармунда уйный торган идем дип әйткәне дә булды. Җәй узганчы баян серләренә төшенеп бетәрсең бит. Көзен бәйрәмнәр күбәя. Бәйрәм җырсыз, гармунсыз узмый. Мәктәптә сөйләшеп бетерербез. Мин китәм әле, мәктәпкә кайтам. Бала-чаганы бүген укытып булмаска охшаган.

– Сау булыгыз. Сез бик матур җырлыйсыз. Нинди яңа җыр иде соң ул?

– «Кар сулары!» Ташу киткән көн өчен әле генә иҗат ителгән җыр. Үзешчән сәнгать әсәре!

Ташулар да китте. Апрель дә үтте. Ак чәчәкләргә төренгән май ае да җитте. Укучыларым май килгәнгә сөенгән әрәмәдән миңа ландышлар, шомырт чәчәкләре китерә. Минем «җиденче»ләрем имтиханга әзерләнәләр. Әрәмәгә чыгып, какы, кузгалак хәлләрен белеп кайтырга да иренмиләр. «Сигезенче»гә ничәсе калыр икән? Ике сыйныфны кушарлармы, юкмы икән, дип уйлап йөрим.

Башкисәр Факил «сигезенче»гә калмый да калмый инде. Аның гаебе белән ЧП булды бит. Бик теләсә дә, дөресрәге, анасы бик теләсә дә, калдыра торган түгел. Оркыя Зәкиевна дәресендә пәке белән уйнап утыра икән малай актыгы. Оркыя Зәкиевна моңа әллә ничә тапкыр кисәтү ясаган. Факил бармакларын парта өстенә җәеп салган икән дә, бармак араларына турылап, пәке ыргыта икән. Кулы төгәл каһәрнең – бармакларын җәрәхәтләмәгән. Аның бу кыланышына озак чыдаган Оркыя Зәкиевна, аннары малайның пәкесен тартып алган да, үз бармакларына кадаган. Ул «канлы» вакыйга мәктәпне дер селкетте. Эш зурга китүдән барыбыз да курыктык. Оркыя Зәкиевнаның нилектән андый хәлгә төшкәне аңлашыла. Үзен тотып кала алмавы гына аңлашылмый. Ярамый укытучыга алай ычкынып китү! Бернинди тикшерү, төпченүләр булмады. Оркыя Зәкиевна мәктәпкә бүтән килмәде. Әлбәттә инде, Факил дә китәргә тиеш. Сыйныфташлары аңа бойкот игълан итте.

Бу очракта шундый чишелеш дөрестер дип уйлыйм. Һәр вакыйгага да резонанс бирергә ярамый.

**Уникенче төн**

Мәктәптә күңелсез хәлләргә караганда күңеллесе күбрәк. «Май ае житкәч»нең сере ачылды. Сәяхәтләр чире белән чирле иде мәктәп. Һәр сыйныф үз көченә күрә маршрут сайлый. Маршрутлар берничә. Башлангычлар шешәгә сөтле чәй салып, бер телем икмәк кыстырып, Имәнлек тавына менеп төшә. «Бишенче»ләр аръякка чыгып, какы-кузгалак җыеп кайта. Асылмалы күпер аша Ыкның аръягына исән-имин чыгу бала-чагадан бигрәк, укытучы апалары өчен имтихан.

Минем «җиденче»ләр дә походка җыена. «Җиденче»ләр икесе бергә кузгала. Башкортстан ягындагы Турай авылына кадәр барачакбыз. Барабыз да, Турай урта мәктәбендә кунып, икенче көнне өйгә кайтабыз. Бернинди максат юк инде бу сәяхәттә. Шулай дип уйлаган идем дә. Максатның нindiлеге походка әзерлек барышында ук ачыкланды.

Мин бит студент чактагы сәфәрләремдә гел затлы урыннарга йөреп, «бозылып» беткән идем. Абхазиядәге күңелеңне мәңгегә үзенә әсир итә торган Рица күле генә дә ни тора! Чемоданыңны тутырасың да, поездга утырасың да – китәсең! Бер мәшәкате дә юк. Син кояш назлаган затлы урыннарның иркә кунагы!

Монда нindiдер Турай авылы. Шул авылга барып җитү өчен биштәр хәстәрлисе бар икән. Авылда кемдә рюкзак, кемдә көтүче букчасы барлыгын, юл биштәрен ничек әмәллисен ата-аналар белә. Балаларын шунда йөгертәләр. Сәрия миңа да җизнәсенең рюкзагын алып торган. Сугыш күргән абзыйлар биштәрне оста итеп тутырырга өйрәтәләр. Арка яклап одеял түшәп куела. Кружка-кашык ише әйберләр шалтырап йөдәтмәслек итеп урнаштырыла. Алмаш оекбаш, җылы кием куелгач, юлга аласы өч-дүрт күкәй, ярты ипигә, балык консервасына урын табыла. Кем нинди ризык юнәтә инде... Ыкның аръягына чыгуга ук бер утырып ашап алалар икән. Җәяүлеләр төркеменең сукмагы гаҗәеп гүзәл җирләрдән үтә. Адым саен сөзәк тау битеннән тибеп чыккан чишмәләрдәге суның тәмлелеге! Менә ни өчен шешәгә тутырып, су алып азапланмаганнар икән! Кружкалар бар, кушучлар бар. Көмеш суны, тешеңне сындырырлык татлы

суны эчеп кинән генә. Ул суларның тәме гомергә тел төбендә кала торган. Җәяү атлый-атлый янып-пешкән аяклардан чүәкләрне салып ташлап, яланаяк салкын чишмәләргә кереп китүләр... Анысы да онытылмас. Гомер буе аяк сызлап азаплауның бер сәбәбе шул башсызлык касәфәте түгел микән әле? Кисәтә идек югыйсә. Тик бала-чага тыңлыймыни ул олы кеше сүзен?

Тыңламыйлар шул, тыңламыйлар. Бер мәлне бер төркем малай-кыз юлда машина тәгәрмәченә юлыктылар. Йә, нигә кирәк икән инде ул аларга? Кирәк икән шул. Бу турыда тау сырты да текә генә күренә. Шул сыртка тәгәрәтеп алып киттеләр бит болар тәгәрмәчне. Инде ни эшләрләр икән дип, Җәүһәрия Камаловна белән хәйраннар калып карап торабыз. Балаларның «акылдан язмаган» өлешенең дә күзләре тау сыртына үрмәләүчеләрдә. Кайсыдыр шаккаткан, кайсыдыр көч биреп тора.

– Ташлагыз! – Монысын Җәүһәрия Камаловна белән мин кычкырабыз.

– Тәгәрәтеп җибәрегез! –Тамаша teләүчеләр авазы бусы.

Өч малай, ике кыз, бер тәгәрмәч иң биек ноктадан безгә җиңүле карап торалар. Инде нишләрләр? Шунда яткырып кына калдырсыннар иде дә бит. Юк шул – тәгәрәтеп җибәрделәр. Нинди олы афәт ихтималын соң мизгелдә генә абайлап алабыз. Юл белән параллель электр чыбыклары тарттырылган баганалар тезелеп бара икән ләбаса! Әгәренки тизлек алган тәгәрмәч чыбык өстенә менсә, чыбыклар өзеләчәк. Анда исә зур көчәнешле ток агымы! Барыбыз да бетәбез.

Беттек!!!

Чытырдатып күзне йомам. Ачам. Тәгәрмәч, ниндидер бер могҗиза белән чыбыклар өстеннән сикереп үтә дә Ыкка төшеп чума.

Юк, мин бу балалар белән походка чыкмыйм бүтән!

Тукран тәүбәсе. Икенче елны Кандра Күлгә кадәр өч көнлек походка бардык. Анда инде еланнар белән сугыштык. Юлы исә тагын да маҗаралырак булды. Палаткалар куярга өйрәндек. Учакта казан асарга да туры килде. Таллыяр балаларын походлардан тыя торган түгел иде шул. Туган якны танып-белүнең бик тә үтемле чарасы ул сәяхәтләр. Шунысы кызык: сәяхәтләр вакытында балалар ачылып китәләр. Бик миһербанлыга әйләнәләр. Дәрестә өлгереше түбән булган малайларның тормышта бик тә булдыклы, тапкыр булуларын күреп сокланасың. Фәхрия Хәлиловна әйткән иде аны: «Юл йөргәндә балалар сынала. Кемгә таянып була икәнен күрәсең», – дип. Кешелек сыйфатлары, бәлки, көндәлектәге билгеләрдән мөһимрәктер дә әле ул. Юл йөргәндә биштәремне миннән күтәртмәделәр. Төн кунганда мине палатка авызына яткырмадылар. Яшь кенә булсалар да, кайгырта беләләр иде.

Походтан кайткач, Гаязов абый сәер генә сорап куйды:

– Йә, Гөлирәм Гәрәевна, арыслан читлегенә керергә әзерме инде син?

– Сез һаман шаярасыз. Ни дигән сүз булды инде бу, Гаязов абый? Елмаюыгызга караганда хикмәтле сүз бугай.

– Хикмәтле, Сылукай, хикмәтле. Мәзәге бар аның. Бер цирк директоры янына бәләкәй генә буйлы, кызганыч кыяфәтле, җил иссә, очып китәрдәй хатынкай эш сорап килгән икән: «Юлбарыслар өйрәтә алам», – ди икән бу. Директор да аны-моны сиздермәгән: «Күрәсезме, читлектәге юлбарыслар борчылалар. Бер-берләре белән тынышмыйлар, читлек чыбыкларына

ташланалар. Барыгыз, менә шул җанварларны тынычландырып карагыз», – дигән, ди. Хатынкай, берни булмагандай, дәү читлек эченә кереп китә. Шундук акырырга да тотына:

– Тынычландыкмы, дуңгызлар! Урыннарыгызга барып баскан булыгыз! Кемгә әйтәм мин!

Арысланнар көтмәгәндә ябырылган бу афәттән куркышып, койрыкларын кысалар. Аннары үз почмакларына барып утырышалар. Таң калган директор: «Акылга сыймаслык хәл бит бу. Сез моңа кадәр нинди җанварлар белән эшләгән идегез?» – дип сорый. «Мәктәптә 7 «б» сыйныфы белән», – дигән ди хатынкай. Сине дә читлеккә – арысланнар янына кертергә була хәзер. Походтан исән кайткач, дим».

– Бу мәктәптә арыслан тотардай ханымнар мин генә түгел бугай.

**Унөченче төн**

Уку елы тәмамланган көннәр – мәктәптә иң күңелле чак. Соңгы кыңгырау чыңлаган. Имтиханнар тәмамланган. Сыйныфлар саны ачыкланган. Укытучыларга дигән шомырт, сирень чәчәкләренең хуш исеннән күңелләр алгысынган. Көннәр ямьле. Йөзләр көләч. Гомер алда. Кайгы-хәсрәт тә юк кебек. Алда торган җәй айларына матур-матур ниятләр корылган. Җәйге отпуск акчалары мул гына чыга. Тормышлы укытучылар бу акчаларын дөнья мәшәкатьләре өчен тәгаенләп куя торгандыр инде. Читтән торып укучылар бар бит әле. Алар инде Казан сәфәреннән монда булмаган кирәк-ярагын акча санамый гына юнәтеп кайтырмын дип сөенә. Мин дә сөенәм.

Сәриянең дә ялы җиткән. Ленинград ягыннан урап кайтырга ниятлибез. Укытучы күпне күрергә, күпне белергә тиеш. Ленинградны барып күрмәгән укытучының дәрәҗәсе юк икән Таллыяр мәктәбендә. Сугыш елларында Ленинград балалары Таллыярга эвакуацияләнгән булганга күрә микән әллә? Бу авылда Ленинград белән ниндидер рухи бәйләнеш бар сыман. Югыйсә ниндидер хатирәләр сөйләгәннәрен дә ишеткәнем юк. Хәер, Баулыда әле дә Ленинград табиблары яши икән. Халык шуларның аеруча белекле булуларына ышана. Берәр табибның Ленинградка кайтып киткәнен ишетсәләр, моны район өчен зур югалтуга саныйлар.

Сәрия белән серләребез килешү икебезгә дә рәхәт. Ул да минем кебек мәгънәле яшәргә тырыша. Нефть идарәсендә эшләгәнгә күрә, Сәрия акчалы. Өч тиенеңне санап, юлда йөрү рәхәт түгел лә ул. Матур гына йөреп кайттык. Әйбәт хатирәләр калды. Гомергә җитәрлек затлы белем запасы тупланды. Без урнашкан кунакханәдә төрле тарафлардан килгән туристлар бар иде. Шулар белән таныштык. Ригадан килгән «сигезенче» сыйныф балаларының безнекеләр белән чагыштырганда тук чырайлы, гәүдәле булуларына игътибар иттек. Боларда тормыш мул бугай дигән нәтиҗә ясадык.

Азәрбайҗаннан килгән хатын-кызлар белән танышып киттек. Сөйләмдә аерма бар барын. Әмма бик теләгәндә, бик дикъкать белән тыңлаганда аңлашырга була. Сәрия бер көнне ашханәдән чыгып барганда, минем кисәк кенә беләгемнән тотып алды:

– Карале, Гөлирәм, әнә теге кызга, гел син бит ул. Киеме бүтәнчә булмаса, син дип уйлар идем. Чак кына җитәкләп алмадым шуны.

– Кай җире мин инде аның?

– Буе-сыны, биленә төшкән озын толымы, синеке кебек серле күзләре.

Синдәгедәй күзләр – озын керфекләр арасыннан тонык зөбәрҗәттәй сирпеп карый торган күзләр!..

– Син бит минем әнинең яшь чагын тасвирладың. Әллә үзе качып кына безгә ияреп килгәнме?

– Шаярма әле. Чынлап сөйлим мин. Әллә яннарына барып карыйбызмы? Кич белән танышу кичәсе була, дигәннәр иде. Шунда инде.

– Ә беләсеңме, Сәрия, минем бабай – әнинең этисе – Бакуга кадәр барып җиткән бит тегү машинасын күтәреп. Аның юл сандыгының капкачына йөргән юлларының картасы сызылган. Ул чагында бабай өйләнмәгән егет булган әле. Туган ягына кайткач уналты яшьлек әнине күреп кенә утырак тормышта калган. Белмәссең...

– Һәр кешенең бу дөньяда игезәге бар икән... Шулай диләр.

– Ярар, кичен кармак салып карарбыз ул гүзәлгә. Бәлки, бабайның гөнаһына юлыгырбыз.

Петергоф фонтаннарын күрергә киткән җирдән кичке очрашуга кайтып җитә алмадык. Хәерле булсын инде. Чибәр кызны аулап йөрүләр егетләргә генә килешә ул.

Без сәяхәттән урап кайтуга әни үзе Таллыярга килеп төште.

– Тәүгилдегә үзем кайтып килмәкче идем бит, әни. Ул тирәдә урнашып калган сабакташларны бергә җыеп сөйләшәсем дә килә. Ел буена да хәбәрләшә алмадык. Син җыйнап китергән хатлар, күченеп йөргәндә, адреслары белән бергә югалган. Кәгазь-фәләнне, чүпкә санап, мичкә яккан идек. Шунда кереп киткәннәр, ахрысы.

– Яңа фатирыңны үз күзләрем белән күрәсем килде. Ошаттым. Монда да Ык якын гына икән.

– Авыл бит яр кашына сиенып, буйдан буйга сузылган. Кешеләре авылның кайсы очында да бер сыман инде – ягымлылар, ярдәмчелләр. Әйдә, Ык буена төшеп килик соң. Ашыгыр җиребез юк. Иркенләп йөреп кайтырбыз. Иртәгә Имәнлек урманына менеп төшәрбез. Бәлки, җир җиләге коелып бетмәгәндер әле. Кеше монда җиләкне чиләкләп җыя. Без Сәрия белән җиләк вакытына соңардык. Кызыл бөрлегән дә, шомырт та күп, диләр. Алары соңрак өлгерә икән.

Тыкрык башында көянтә-чиләген иңнәренә элгән Гөлҗәннәт апага юлыктык. Кер чайкап кайтып килә икән. Бу авылда шулай – керне бәләкли-бәләкли, Ыкта чайкыйлар.

– Гөли-и-рә-ә-ә-рәм! Әниең килгән икән. Чат үзең төсле, әниеңдер бит инде?

– Әнием-әнием. Менә Ык буйларын күрсәтергә алып төшеп киләм әле.

– Күрсәт шул. Әрәмәгә дә алып чык... Безнең Җәннәт бакчасы бит ул әрәмә. Минем оныклар абыстай әбидән сораганнар икән: «Әбекәй, оҗмах нинди була ул?» – дип. – «Әрәмә төсле була ул», – дип әйткән, ди. Ә нигә, җимеш урынында җимеше, төнбоеклы күлләре бар. Андагыдай дару үләннәре бүтән беркайда юк. Мин үзем бөтен кышлыгына җитәрлекне җыеп куям. Улым әйтә: «кара каен дигән агач безнең әрәмәдә генә үсә. Бүтән җирләрдә каен ак кына була», – ди. Дару үләннәрен унҗиде сәгать сукканчы җыеп калалар инде аны. Син, күрше, исемең Хәтирәме әле, быелга соңардың. Бөтенләйгә килүеңме, кунакка гынамы? Гөлирәмгә дигән

дару үләннәре минем чормага эленгән инде. Белеп торыгыз. И-и, безнеке печәннән кайтып килә икән лә! – Су өсләтеп бу ярга таба йөзеп килгән печән чүмәләсе Шәйхенур абзый икән.

Әйе, әрәмә җиләк-җимеш, үлән-сәлән генә түгел, печән дә, мичкә кыш буе ягарга җитәрлек чыбык-чатыр да икән әле. Оҗмах та шундый микәнни?

Менә шулай үз итте безне авыл. Тик әни бүтән төрле уй корып йөри икән. Исәбе Таллыярга күченү түгел. Әле үзебезнең өйдән дә күрше авылга күчеп китү ихтималы бар икән. Яшьлегендә артыннан йөргән бер егет шахтадан туган ягында яшәп картаерга дип кайткан. Буйдак икән. Акчалы. Өй салмакчы. Әни аңа иптәш булырга ризалашса, әни янына үзе күчеп килмәсме...

Менә ничек икән хәлләр. Мин монда зифа буема бер яр таба алмый йөрим, әни инде берәүне каратып та куйган. Каршы килмәдем. Гомере тол хатын гомере булды. Яшь бит әле ул. Инде хәзер парлы булу бәхетен кичереп карасын.

Август киңәшмәләре алдыннан туган йортыма кайтып килдем. Сабакташым Гөлсәрия Ташлыда – күрше авылда урнашып калган. Инде кияүдә. Алай да мине күрергә дип килеп җитте. Икенче шимбәгә Сания белән Энҗене дә чакырдык та Гөлсәрияләрдә җыелыштык. Иренең гаиләсе нык нигезле икән. Өч кызны кунак иттеләр. Яңа бал белән сыйладылар. Мунча да якканнар. Яшь пиннек белән сихәтләнгәч, озак кына кич утырдык. Сөйләшеп, сүзләр бетмәле түгел. Безнең Мокамай кызларның һәммәсенә дә хатлар язып чыккан. Бердәнбер егетебез булу ләззәтен кичерә, каһәр. Чынлыкта беребез дә аны егеткә санамый. Алай да үзенә матрос тельняшкасы килешә икән. «Һо-һо! Егет булып килә бит бу!» – дип көлештек, Гөлсәриягә килгән фотосурәтен караганда.

– Ә без аны, Гөлирәм, синең егет инде бу дип юрап йөри идек, – диде Сания.

Аның үзенең егете авылда агроном иде. Без укыган биш ел буе Саниягә бәрәңгесен, тегесен-бусын ташып, кайгыртып торды. Энҗе кырагай иде. Укып бетереп, өч ел эшләми торып, кияүгә чыгасым юк дип, кырт кисеп куйды. Шулай итеп Мокамайга кәләшлеккә мин калганмын инде.

– Сез аны нигә миңа юраган идегез соң? Мине арурак егет таба алмас дидегезмени?

– Юк ла инде. Син генә аны шулай иптәш итә белә идең бит. Матур итеп сөйләштерә, юк-бар мәзәкләренә көлгән була идең. Ул бичарага синең игътибар канат куя торган иде.

– Ә менә миңа аның бер хаты да килмәде.

– Барыбер аңа тимәсеңне аңларлык акыл кергәндер инде Мокамайга да.

– Мокамай калып торсын әле. Кызлар, бер ел укыттык бит инде. Кем ничек сыйныф җитәкчесе сыйфатында балаларын кулга ала алды? Үзебезчә август киңәшмәсе ясап алыйк әле. – Мин кызларга Гаязов абыйның арысланнар турындагы кыйссасын сөйләп күрсәттем.

– Булды-булды, андый арысланнар бездә дә булды. Иң гаярь арыслан буласы малайны староста итеп куйдым да ел буе бер кыенлык күрмәдем «сигезенче»ләремдә. Бөтен сыйныфны бөтереп кенә алды. Малайның

миңа күзе төшкәнен сизеп алган идем. Андый хәлләр була икән. Өлкән укытучыларның дә сөйләгәннәре булды.

– Ә мин менә елап җиңдем. Махсус түгел. «Бишенче»ләргә керәм. Дәрестә бер малай тыңламый гына бит. Үзе дә тыңламый, башкаларның да игътибарын тотып тора. Әллә ничә мәртәбә кисәтеп карадым. Ыжламый да. Тәмам нервыма тиде бу малай. Аның янына килдем дә кулымдагы китап белән бар көчемә партага суктым. Аннары үзем, укытучы өстәленә ятып, үсеп-үксеп еладым. Сыйныф тып-тын калды. Арадан берсе директорга кереп сөйләгән. Теге башкисәргә бик каты эләккән, күрәсең. Бүтән андый хәл кабатланмады.

– Безнең физика укытучысы бик псих. Ачуы чыкса, эреле-ваклы герләрен тота да ыргыта. Балалар өйрәнгән инде – тайпылып, иелеп калалар.

– Килеп тисә, үтерә бит инде!

– Үтерә инде, үтерә. Тик ул аны уйлап торамыни...

– Тыңлату җәһәтеннән ир-ат укытучыларга җиңелрәк инде анысы. Ираттан шүрлиләр бит. Әхтәм Харисовичның пистоны хакында да сөйләп алдым.

Кемдер тәртипсез малайлар янына үзе килеп утырып, карта уйнап җиңгән егет кыйссасы хакында сөйләп көлдерде. Тупласаң, менә дигән «Тәртипсезлек энциклопедиясе» язарга мөмкин икән. Энҗе менә химия укытучысының тәртипсез малайларны дәрестән чыгарып җибәрүенә аптырый икән: «Чыксыннар. Саф һавада йөрсеннәр. Миңа белем алырга теләгән балалар класста калса, җитә», – ди бит ул.

– Ничек инде алай, укытучы һәр баланы белемле итәргә омтылырга тиеш. Безнең Таллыяр мәктәбендә Нәкыя Гыймаевнаның геометрия дәресендә сыйныф гөж итеп тора. Бер бала да чыгып китми. Ярыштан мәсьәлә чишәләр. «Апа, минеке дөресме?», «Апа, минекен тикшерегез әле», «Апа, дөрес чишелешне мин беренче булып таптым!» Сыйныф кайнап тора. Дәрес азагына һәр баланың билгесе бар. И-и, ярата лар инде шул Нәкыя апаларын! Укучыларны эшләтә белергә кирәк икән ул!

Биш, юк, җиде, ун елдан без дә иң зирәк укытучылар булып җитешербез әле. Безне дә яратырлар, сагынырлар! Минем әни әйтә: «Балаларның «икеле»гә укыганнары тормышта аеруча рәхмәтле була. Шулары истә кала да, – ди. Бәлки, күп игътибар, күп тырышлык куелганга күрәдер инде бу. Без бит алар арбадан төшеп калмасыннар, үз урыннарын тапсыннар өчен көч куябыз. Бала-чага шуны аңламый бит дип уйласак та, аңлыйлар, бәялиләр икән. Соңлап килгән аңлауның әҗере дә кайта. «Бишле»гә укыган бала ул: «Мин үзем тырышам, мин үзем башлы!» дип уйлый. Һавалырак була.

**Ундүртенче төн**

Яңа уку елына мин инде тәҗрибә белән киләм. Мәктәп тормышын эчтәлекле итү җәһәтеннән уйлап куйган ниятләрем дә бар. Чит тел укытучысы сыйфатында, дәрес бирүдән кала, берни дә эшләмим икән бит мин. Югыйсә безнең күп милләтле илебездә дә төрле милләт балаларын дуслаштыру, аралаштыру өчен әллә нинди ысуллар табарга мөмкин. Мин үзем институтта укыганда, ГДР балалары белән хат алышып караганым булды. Хәтта Тельманның кызы Ирмадан да хат килде бервакыт. Нигә соң әле мин бу багланышлар җебен Таллыяр мәктәбенә дә сузмыйм.

Авыл балалары Европа илендә яшәүче яшьтәшләре белән аралашырга тартынырлар дип уйлыйммы? Юк, белемнәре, тел белү згы җитешмәс дип уйлыйм. Ә бит бу җәһәттән кимлек, ул минем – немец теле укытучысының кимчелеге. Без бу хат алышуларны аерым ике баланың кара-каршы хат алышуы гына итеп калдырмабыз. Мәктәп белән мәктәп, сыйныф белән сыйныф хат алышканда, белем кимлеге беленмәс. Хатларны күмәкләп язарбыз. Менә кайда ул минем үземә дә үсәр өчен мәйдан.

Алман телендә, сирәк булса да, китаплар очраштыра. Һәрберсен сатып алып барам. Җайлаштырып тәрҗемә ителгән русча китапларны да алам. Сөйләм телендә ныгып урнашкан гыйбарәләрдән башка бер телне дә өйрәнеп булмый. Шуңа күрә чагыштырып уку кирәк. Ул телдә болай диләр икән, ә бездә ничек соң әле ул, дип ныгытып бикләп барам. Шул рәвешле сөйләмемне камилләштерсәм, шаять, өченче чиректә адреслар юнәтү хәстәренә керешермен. Балаларга бу идея ошар дип уйлыйм. Беренче космонавт яшәгән ил дөньяда бик популяр. Юрий Гагарин дөньяга ишекләрне киереп ачты. Чит тел белү киләчәктә бик макталыр дип уйлыйм. Һәр яңа тел – тагын бер хәзинә сандыгы бит ул! Унтугызынчы гасырда яшәгән асылзатлар хәтта үз ана телләрен онытырлык кимәлдә чит телләр белгәннәр. Алай ук та ярамый, әлбәттә. Сандугач булам дип уйлап, үз телен оныткан әтәч кебек. Безгә ул көнгә кадәр ерак әле. Телләр өйрәнү хәтерне дә яхшырта.

**Унбишенче төн**

Минекеләр быел «җиденче»не тәмамлады. Ике «җиденче»не кушкач, бер «сигезенче» калды. Киткәннәр икән шул. Кимегәннәр. Ә «сигезенчеләр» барысы да «тугызынчы»га килгәннәр. Хәзер безнең мәктәп «Таллыяр урта мәктәбе» дип атала. Шәп яңгырый бит. Кечке мәктәптә укып йөрүче балигъларыбыз урта белем турындагы «Өлгергәнлек аттестаты»н кич утырып алып бетерерләр инде. Акыл утырткан кешеләрне укыту бик рәхәт икән ул. Тәртип турында сөйләшәсе юк. Сөйләшсәк тә, алга таба нинди уку йортына бару турында гына. Хыяллары зурдан аларның. Берсе авыл хуҗалыгы институты, ди. Икенчесе университетның география факультеты, ди. Өченчесе шул ук вузның юрфагына ниятләп тора. Икәве төзелеш инженерлары институтына, берсе химия-технология институтына китмәкчеләр. Таллыяр мәктәбеннән никадәр югары белемле кешеләр чыгачак!

Барысы да – егетләр. Карасана, аттестат алу, белемгә омтылу гади бер авыл балаларына бөркет канатлары куя икән ләбаса. Һәм ул канатларны, Җәүһәрия Камаловна, Нәкыя Гыймаевна, Әхтәм Харисович, Роза Гариповна, Галимә Хәмитовна кебек, үзләре дә читтән торып белем алып йөргән фидакарь укытучылар куя. Чөнки аларның үрнәге күтәрелеп килүче бөркетләргә егәр бирә. Афәрин! Мин санаган укытучылар – сугыш елларында, фронтка киткән укытучылар урынына җиденче сыйныфтан соң ук килеп баскан балалар бит. Беренче укучыларын китапсыз, дәфтәрсез көе дә белемле итүгә ирешкән, киләчәкнең матур булачагына инандырган комсомоллар. Кирәк тирәкне ега, дигән сүз дөрес икән. Аннары шул тирәкнең тамырлары ябалдашлары күккә терәлердәй карагайларга да куәт бирә!

Димәк, теге гармун тоткан егеткә нота грамотасы өйрәтеп карарга иде дигән уем дөрес ният булып чыга. Искитмәле сәләтле бит ул егет. Укуында

тукталып калган. Хәзер кичке мәктәпкә йөри. Дәресләргә кадәр аның белән шөгыльләнә алыр идем. Безне Алабугада нота танырга өйрәттеләр. Берәр музыка коралында уйный белү мәҗбүри иде. Миннән башка нота таный белүче юк, ахры, дисәм, Галимә Хәмитовна кыз балалардан мандолинада уйнаучылар ансамбле оештырды. «Тик ул бу егет белән шөгыльләнергә вакыт таба алмас шул», дип уйлыйм. Бик мәшәкатьле тормышта яши.

Әгәр мин үз белгәнемне Фасилгә тапшыра алсам, ул да башка егетләр кебек, Казанга барып, вузга, консерваториягә булмаса да, педагогика институтының музыка факультетына керә алыр иде.

Таллыяр яшьләренең киләчәге хакында уйлап, үз яшьлегем узып барганын абайламыйм икән. Тәүгилдедән киткәндә әнием дә бик борчылып калды: «Ялгыз аккош күлләрдә генә ул. Ялгыз кала күрмә. Тиңеңне тап. Сайланма, димим. Сайлан. Гомер юлын бергә узасы кешене сайларга кирәк аны. Син хәзер зур белемле кеше. Ярың да ярашлы булырга тиеш».

– И әни, авыл яшьләре иртә башлы-күзле була. Мин алар өчен апа да бит әле. Ул авылда бөтен укытучыга да «апа» дип эндәшәләр. Син үзең бит мине бик тыйнак, кырыс итеп тәрбияләдең. Якын килергә куркалар миңа. Югыйсә, бөтенесе белән дә аралашам. Якын итәләр, бергәләп концертлар, спектакльләр куябыз. Сәхнәдә уйнаганда минем парым булып япь-яшь Хәлилләр чыга.

«Япь-яшь Зөфәрләр» дигәнен әйтми торган идем әле. Илдар Юзеев поэмасы буенча «Таныш моңнар» дигән спектакль куярга йөрибез. Зөфәрем Фасил булачак. Аның кебек гармунчыны табуы кыен. Баянның да серенә төшенеп килә. Каһәрең, үзе бик тә чибәр дә әле ул егет. Авылда берничә кызның йөрәген яндыра, диләр. Булса да булыр. Аның кыланышлары да зыялы. Ниндидер бер морза баласы, диярсең. Үзәге өзелгән кызларның хәлен аңлыйм мин. Гармунчылар һәр авылда да егет күрке санала. Мин үзем гармунчы яры булмас идем. Синеке генә булырга тиешле берәүгә әллә ничә кызның кызыгып каравына түзмәс идем. Минем өчен эчке бер тынычлык халәте мөһим. Бимазаланып яшәү кирәк түгел миңа. Мин тын-тыныч бәхет тансыклыйм.

Ноталар өйрәнеп утыруыбызга игътибар итүчеләр бар бугай. «Таныш моңнар» ны әзерли башлагач, көнләшеп караучылар да өстәлде.

– Ул Гөлирәм Гәрәевна Фасилнең йөргән кызы бар икәнен белми микәнни? Яшьләр арасына ник керә икән ул? – дигән сүзләр колагыма килеп ирешкәч, нота дәресләрен дә, спектакльгә әзерлекне дә туктатырга уйлаган идем.

Гайбәт сүзләрен соңгы вакытта шактый дуслашып киткән, көнчелеген юк-юкта да сиздереп ала торган клуб мөдире Хәлимә аша ишеткәнгә күрә тыелып калдым: «Беткә үч итеп, туныңны утка якма, Гөлирәм. Син бит бу авылга якты, җылы нур өстәргә килдең. Добролюбов әйткәндәй, халыкка мәңгелеккә җитәчәк игелек орлыклары тарату бит синең вазифаң. Ә син вак сүзләргә колак саласың. Яше узып бара торган клуб мөдире ни әйтмәс?! Ничек дияр иде икән әни: «Кеше булган кешедә мең кешенең эше бар. Кеше булмаган кешедә кемнең ни эше бар?» – дипме?

Димәк, вакланмыйм. Сөйли бирсеннәр.

Спектакльне без Таллыяр егетләрен армиягә озату көненә турылап әзерлибез. «Озату кичәсе»нә авыл да озак әзерләнде. Бу авылда шундый йола бар икән: армиягә китәсе егеткә ядкарь итеп кызлар кулъяулык

чигәләр. Яратып йөргән кызы гына түгел. Кемнең күңеле җитә – шул чигә. Кулъяулыклары иң күп җыелган егет кукраеп йөри инде. Һәр кеше үзенекен мактандырасы килгәнгә, кулъяулыклар күп җыела. Берсеннән-берсе матур чигелешле ядкарьләрне егетләр бер-берләренә ялгап, билләренә урап куялар. Әниләре соңыннан ул төеннәрне чишеп, яулыкларны юып, үтүкләп, улының юл чемодагына тутыра. Матур йола.

Ә без спектакль уйныйбыз бит инде. Әйткәнемчә, «Таныш моңнар». Мин – Резидәкәй, Фасил – Зөфәр. Фасил армиягә китүче егетләр арасында түгел. Югыйсә яше җиткән. Ни сәбәпле калып торадыр, әйтә алмыйм.

Тамаша залындагы алгысу, ашкыну безгә дә күчкән. Ничәмә-ничә яшь йөрәк бүген озату-аерылышу халәтендә яши. Мәңге шулай булган. Кешеләрнең иң үзәк өзгеч хис-тойгылары аерылу, сагыну хисләре белән өретелгән. Була шундый көннәр-мизгелләр – кешеләрнең айлар-еллар дәвамында яшереп саклаган серләре, озак вакыт тын торган янартаулар кебек бернигә дә карамый иреккә ыргыла. Ишетсеннәр, күрсеннәр, белсеннәр! Яратам булгач, яратам!

Сәхнәгә гармун тотып җырлап чыккан Фасилне күргәч сискәнеп киттем. Репетицияләр вакытында җырның язмасын гына ялгый идек. Бу юлы үзе җырлый. Мин аны җырлый дип белми идем дә бит.

Резидәкәй,
Зәңгәр күлмәгеңне
Кайсы елгаларда чайкадың?
.............................................

Пәрдә, тәрәз пәрдәсе артындагы Резидә, ягъни мин, сулык-сулык өзгәләнәм. Егет җырын дәва итә:

Резидәкәй,
Белсә идең шуны:
Синдә генә минем уйларым.
Резидәкәй бәгърем, ник дәшмисең,
Кайда синең зифа буйларың?

Пәрдә ярыгыннан залны күзәтәм. Хатын-кызлар пышын-пышын серләшәләр. «Дөрес икән бит, балакаем...» Фасил җырлап җибәрерлек булгач соң инде. «Чибәр бит, каһәр, тегесе дә. Иманыңны оныттырырлык». Егет яшь бит. Яхшы түгел бит». «Туктап тор. Хәзер егет китә дә, тегесе чыга».

Колак янында гына ишетелеп торган «соңгы хәбәрләр» аркасында сүзләремне онытып җибәрдем. Гармун икенче мәртәбә көйне искәртте.

Шул егетне,
Гармун тоткан килеш,
Төшләремдә күреп уянам,–

дип үксеп-үксеп елыйм, үксеп-үксеп җырлыйм. Мин бит аны чыннан да төшләремдә күрә башлаган идем. Гармун тоткан килеш. Бу, бәлки, образга керү генә булгандыр. Чынында, башымны югалтканым юк бит әле

минем. Мин Фасилне укучым итеп кенә күрәм. Музыка алфавитын яхшы гына үзләштерде. Мин аңа барган җирләремнән ноталары язылган җыр буклетлары алып кайтып бирәм. Тырышып-тырышып өйрәнә ул шуларны. Аттестат алуга музфак ягына китсә, һичшиксез, укырга керә алыр дип уйлыйм. Авылдан килгән, өстәвенә хезмәт стажы белән килгән яшьләргә вузларда игътибар зур хәзер. Егет француз егетләре сыман ак йөзле, кара чәчле, чибәр. Буе да бар. Күңел төбендә посып яткан шайтан баласы: «Казанга бер китсә, монда кире кайтмый инде ул. Сиңа булмый инде ул», – дип пышылдый. Әллә чыннан да шайтанның минем күңелдәгесе: «Яшь аермагыз әллә ни түгел инде. Унар яшь аерма белән дә кавышучылар, сайрашып яшәүчеләр бар. Сезнең нибарысы дүрт яшь инде арагыз», – дип котыртып ята.

Колак янындагылар канәгать калдылар: «Дөрестер, балакаем. Үзен җырлый бит бу. Төшкә керә, ди бит! Тегесенең аның кызлары әллә ничәү!»

– Беләбез! – дип әйтәсем килә генә бит тегеләргә. Ярамый. Мин сәхнәдә. Рольдә. Аннары, «вакланмыйм!» бит әле мин.

Яшьләр вечер ясап кала. Мин кайтырга чыгам. Октябрь ахыры. Сукмак – кайда баткак, кайда каткак. Җитмәсә, урам да караңгы. Энә күзедәй яңгыр сибәли. Ярый әле, өем клубка якын гына.

– Гөлирәм! – Фасил тавышы. Кара син аны, ничек гади генә эндәшә. «Гәрәевна» дип тә тормый. Сәхнәдә тиң ярлар булгач, шулай да ярый дип уйлый. – Әйдә әле, Ык буеннан кайтыйк. Яшьләр гел шуннан йөри. Анда үлән һаман яшел. Аяк киемең дә чиста калыр. Мин менә баянны куеп, гармунны алып чыктым. Әкрен генә җырлашып кайтыйк әле. Ташу караган көннән бирле шул турыда хыялланып яшим. Теге җырыңны бүтән беркемнән дә ишеткәнем юк. Үзеңнән отып каласым килә. Исемең белән генә эндәшүем әрсезлектән түгел. Якын иткәннән генә!

– Бар әле, гармуныңны да калдырып чык. Уен коралы дым тидергәнне яратмый ул.

– Ярый алайса. Тик син китми тор. Мин тиз булам.

Ул гармунын кертеп чыга.

– Нинди җыр иде соң әле ул? Үзем генә көйләп йөргән, сүзләре дә оешып бетмәгән җыр иде бит ул.

– Бигрәк әйбәт икән. Сүзләрен менә хәзер, бергәләп уйлап табарбыз.

– Минем колакка кергәч, авторы бардыр инде. Мин сиңа үзем хәтерләп калган сүзләрен генә әйтә алам:

Канат какты гомер,
Җилкендерә җанны
Язның бозлары да,
Язның сулары да...

Гөрләгәндә сулар,
Шаулаганда шулар
Безнең ярсу җырлар
Нигә онытылмый...

Шул сүзләрен генә беләм. Анда да бутыймдыр әле. Шагыйренә ишетелсә, безне гафу итмәс. Ә кушымтасы болай:

Язгы ташу,
Су тавышы –
Моң агышы:
Әллә кавышу,
Әллә аерылышу?!

– Отып алырга җайлы икән. Әйдәле, бергә җырлап карыйк әле.

Шактый йөрелде. Күз карасында тынып калган Ыкның да хәлен белдек. Бүтән җырларны да искә төшердек. Яңгыр сибәләсә дә, тәмам үзәккә үтеп чылатырлык түгел.

– Җырлашып йөреп, минем өй турын узып китмик. Бу турыда ярлар бик текә икән. Үргә сукмак бармы соң монда?

– Безнең авылда һәр өйгә Ык буеннан сукмак менә. Чыннан да, синең турың икән бу. Әйдә, җитәклим әле. Таеп китәрсең. Җырлашып йөрисең килми инде синең авыл малае белән...

– Йөрдек бит инде. Җитәр. Сиңа ярый ул. Мин бит – укытучы. Спектакль барганда, минем колак янында ниләр сөйләгәннәрен син дә ишеткән булсаң, укытучы апаңны урабрак үтәр идең.

– Ишетәсем килми минем, яратасым гына килә. Сине иркәлисем, кочасым, үбәсем килә. Менә ничек итеп! Эчтән генә уйлыйм: «Әллә минем яратасым килми дисеңме? Ярамый бит! Назлар миңа да тансык ла ул – ярамый бит!»

– Җитте, егет. Тезгенеңне ныграк тот. Үсә төшкәч сөйләшербез. Минем флотта хезмәт итә торган егетем бар. Вәгъдәләшкән егетем... – Мин Фасилнең кочагында икәнмен бит. Җәһәт кенә аннан ычкынам да: «Тыңла әле, мин сиңа үзем яраткан бер шагыйрәнең шигырен укып күрсәтәм, – дим. – Үзең нәтиҗә ясарсың:

...Кермим кеше биләмәләренә,
Чикләр аша яулык болгама.
Ике ярдан икәү карап йөрик
Ташып-шашып аккан елгага.
Кермим кеше биләмәләренә,
Үз җиремдә ташка таш өям,
Мәһабәт тау түбәсенә басып,
Мәхәббәткә шуннан баш иям.

– Аңладыңмы? Шул шагыйрәнең тагын бер шигыре бар. Анысын да укыйммы?

Үзем сөяр идем, берәү сине
Өзелеп яратканын белмәсәм.
Тагын берәү сине шулай сөйсә,
Бәхетең артык булыр – көнләшәм.

Ут йотсам да, салкын су эчәрмен,
Сиңа кабынмасын ялкыным.
Ярсуларым тулып ургылсын да
Җырга күчсен!
Көтмим артыгын.

– Синдә барысы да китаптагыча икән, Гөлирәм! Ә мин сине барыбер яратам! Менә кайтып җиттең. Ут йотып яңгыр астында калган Зөфәреңне төшеңдә күр, яме. Хуш иттек!

Башкача «свиданиеләр» булмады безнең. Авыл да тынычланды.

Фасил тагын ике елдан, кулына аттестат алып, Казанга укырга китте. «Язгы ташу» җыры (Сүзләре Рәдиф Гаташныкы икән аның) җырланмыйча калды. Гармунчы егетнең Таллыярдагы кызлары да коелып калды. Казанда тиң ярын бик тиз тапкан, диделәр. Ә минем матур итеп яратасым килә иде.

Авылга бер кайтуында Фасил минем янга мәктәпкә кереп рәхмәт әйтеп чыкты. Казанга барып укырга керә алуында минем өлешем зур булуын аңлый иде ул. Шул ук көннең төнендә үзәгемне өзеп, безнең турдан җырлап узды:

Тик бер генә көлеп дәшкән идең,
Истәлеге калды озакка.
Онытканнар инде онытсыннар,
Ә мин риза татлы газапка.

Сагышлы моң тулы көннәремдә
Елмаюың синең таң иде.
«Оныт», димә, зинһар, «оныт», димә –
Җырым булып кына кал инде.

**Унбишенче төн**

Их дөньясы! Бәхеткә тиенәсе, яратуга тиенәсе гомерем сагышланып, моңланып уза. Сәрия кияү тапты үзенә. Клуб мөдире Хәлимә дә башлы-күзле булды. Дәртләнеп, кичке мәктәптә укып йөргән егетләрнең һәммәсе дә теләгән вузларына барып укырга керделәр. Бер мин генә, ташу китеп беткәч, ярда ятып калган боз кебек.

Әни газизе Нургазизе белән тату гына яшәп ята. Пенсионер шахтёр әни янына күченде. Анысы әйбәт әле – туган нигездән мәхрүм калмадым. Абзый нык иде әле. Өйне рәткә китерде. Мунча да җиткерде. Бакча да тергезде. Кайтып ял итеп китәрлек урын ул хәзер минем өчен. Каникулларда еш кайтам. Сәяхәтләрдә күп йөрелде. Артык кызыкмыйм хәзер.

Әни минем ялгызлыгым өчен борчыла. «Төс ташлаганчы үз ишеңне табып кал. Яшь чакта кавышкан белән олыгайгач парлашкан бер булмый ул», – ди. Ул беләдер инде, хаклыдыр. Эчем тулы сагышны, эчем тулы моңны кая куярга соң? Нидер җитмидер кебек күңелгә. Ул нидернең ни икәнен беләм лә мин. Җылы җитми, наз җитми миңа. Тәмам сусадым минназга. Яратасым, яратыласым килә минем. Әнигә күңелдәгесен сөйләп булмый бит инде.

Төннәрен йоклый алмый ятам. Бигрәк тә айлы төннәрдә әсәрләнәм. Мин генә микән ул шулай. Айдан сузылган могҗизаи көмеш нурлар тәмам сихерли. Айның Җирнең иярчене генә икәнен белсәк тә, шул җисемгә бер хикмәт итеп карыйбыз.

Үзеннән-үзе шигырь юллары тезелә:

Түп-түгәрәк булып тулгансың да
Тәрәзәмә тагын килгәнсең.

Йокысыз төн, тәнем гасаблы.
Нигә кирәк сиңа, Тулган Аем,
Гасаблыны тагын азаплау?

Миллиард күзләр сине күзли, Аем,
Син шуларга сердәш булсаң соң...
Ә син мине эзләп киләсең дә,
Йөрәгемне минем иләс итеп,
Кулларыңны миңа сузасың.

Көмеш юлың адаштыра синең,
Саташтыра сынап каравың.
Синең уйны беләм, серле Җисем,
Көмеш нурдан сихри ятьмә үреп,
Ялгыз җаннар шулай аулавың.

Зөһрә кыздай бер ятимме мин дә,
Миңа да соң синме ахирәт?
Йокым түгел, серем алдың, инде,
Ялгыз яшәү хәлен син өйрәт!

Бала-чага белән мыжлап торган мәктәп дөньясында яшәп тә болай өзгәләнүләрем үземне дә борчый башлады. Юньле хәл түгел бу. Югыйсә мәктәптә көләч, актив, хәтта матур да укытучы Гөлирәм Гәрәевна мин. Һаман да Сылукай әле мин. Ә менә өемдә үзем генә калганда, еш кына күзләрем яшьләнә. Еш кына үзалдыма җырлар көйләп йөрим. Кич чыгып йөрүләр ниндидер җәмәгать эшләре булганда гына. Урта мәктәп гөрләп эшләп киткәч, кичке мәктәптә укучылар калмады. Анысы бер җиңеллек инде үзе. Әмма гаиләле кешеләр өчен генә ул шулай. Хәер, тел укытучысының дәфтәр тикшерүләре дә ярты гомерне ала. Дәресләрем күп бит. Немец теле генә түгел, рус теле дәресләренең дә яртысы миндә. Дәртеңне басарга җитә торган «нагрузка» инде бу. Шулаен шулай да бит. Күңел бар бит әле. Укытучылар бүлмәсендә гаилә, бала-чага хәлләре турында сөйләшә башласалар, мин сүзсез калам. Үземне чит дөнья кешесе кебек итеп тоям. Коллегаларым: «И-и синең рәхәт, ичмасам. Ир кайгыртып көенәсең дә, балаң өчен ут йотасың да юк», – дигән булалар. Әллә мине юатулары, әллә, чыннан да, гаилә тормышыннан арып китәләр.

Укытучыларның балаларын кызганам. Аларга таләп тиешеннән артык. Үзара низаглары чыкса, баладан үч алалар. Бер көнне укытучылар бүлмәсендәге өстәлгә кар йомарламы килеп төште. «Кем дә кем?» диешәләр. Гаепле бик тиз ачыкланды. Фәхрия Хәлиловнаның «бишенче»дә укып йөрүче улы икән. Кайсыдыр класс тәрәзәсенә төбәгән кар йомарламы укытучылар өстәленә килеп төшкән. «Бу бала моны юри эшләгән. Тәртипсез икән улың, Фәхрия Хәлиловна!» – дигән сүзләр тагын да куера башлаганчы, малай Баулыга – рус мәктәбенә күченде. Гомумән, укытучы балаларының мәктәптә бер-ике генә булуын абайлаган идем инде мин. Имәндә икән чикләвек. Тышкы итагать ышыгында укытучылар дөньясында да барыбер көнләшү кебек нәрсә яши. Көнләшү дә түгел бу. Бер-береңнең ялгыш басып куюына сөенү. Шул хәлгә төшә күрмәсәм иде.

Яңа уку елы алдыннан уйга калдым. Мин бит әле һаман ватык сәгать кебек. Үземнең психик халәтемне мин үзем кайгыртырга тиеш. РОНОга берәр санаторийга юллама сорап бардым.

– Уку елына аякка баскандамы? – диләр.

– Бәрәңге басуына быел чыкмый калырмын. Көзге, кышкы каникулларда эштә булырмын, – дигән хәйләләр таптым.

Юллама булды. Әле мин моңа кадәр барып җитә алмаган урынга булгач, сөенеп тә куйдым. Карабах дигән җирне картада табып кына белә идем. Азәрбайҗанның бер төбәге икән. Кара Бакча була инде ул безнеңчә. Азәрбайҗан дигән төшенчә Ленинградка барган чактан күңелгә кереп калган иде. Йә ярый, барып күрим әле мин ул Кара Бакчаны, андагы кешеләрне. Кай ягым белән аларны хәтерләтәм икән мин? Зөбәрҗәт күзләрем беләнме, кара бөдрә толымнарым беләнме?

Санаторий минем кебек йокысызлыктан йөдәгәннәр өчен икән. Имеш, мондагы тау һавасы Европадагы иң чиста һава икән. «Шуша» исемле бәләкәй генә шәһәр икән бу санаторий урнашкан урын. Шуша ул шешә, ягъни пыяла дигән сүз. Димәк, һава пыяла кебек үтә күренмәле. Чыннан да үтә күренмәледер. Тау араларында үз уен коралларында уйнап, җырлап көтү көтеп йөргән чабаннарның җырулары, ниндидер тар дигән уен коралында уйнаулары, тау сыртларын кичеп, санаторийга кадәр ишетелеп тора. Иртә таңнан яңгырап уята торган азәрбайҗан мәкамнәре көне буена да тынмый. Бик тә үзенчәлекле җырлыйлар болар. Тавыш дулкынын ничектер тибрәтеп, дулкынлы авазлар чыгаралар. Бу халыкның иркенләп, тарсынмыйча үз моңнарына, мәдәниятләренә коенып яшәүләренә кызыктым. Хөрлек билгесе бит бу! Безнең татарыбыз да шундый бәйсезлеккә берәр вакыт тиенә алыр микән?!

Татарларны яраталар монда. Хөрмәт итәләр.

Килеп җиткән көнне унике сәгать йокладым. Уянмыйча! Иртән табиб янына киттем. Ишек янында ук Чаллы кызы Римма белән танышып киттек. Бик кыю күренә. Үземнең укытучы икәнемне әйтеп тормадым. Китапханәче дидем. Римма мине шефка алды. Мин ияреп йөрергә күнгән рәвештә йөрдем. Бу кызыкай ит комбинаты директорының секретаре икән. Үз дәрәҗәсен бик белеп, һәр ишектән кыю үтеп керә. Үзләрендә шулай өйрәнгән. Безне ул массажга да, башка төрле дәвалау процедураларына да яздырды. Кәҗә сукмагыннан гына шифалы су эчәргә барып кайттык. Дәвалау чараларын тиз генә үтеп чыктык. Аннары таш калага – Шушага төшеп киттек. Базарга! Юк бәягә виноград, анар, помидор төяп кайтып кердек.

Таш каланы күрүдән алган тәэсирләр чамасыз иде. Чыннан да таштан өеп ясалган өйләрнең берсенең генә дә тәрәзәсе урамга чыкмый. Һәрдаим дошман явы килеп керү ихтималыннан сагайган таш шәһәрләр шулай яши торгандыр инде ул. Хатын-кызлары ишегалдыннан битәр ачыклык күрми инде боларның. Гаҗәбенә ниләр диярсең: һәрдаим сугыш көткән Шуша каласы бер шагыйранә хәяттә гомер кичерә. Урамнарда сулары бездәге фонтаннар кебек таш түгәрәкләрдән бәреп чыккан коелар очрый. Һәммә җирдә – таш диварлар. Диварларга борынгы шагыйрьләрнең – Нәсими, Ганҗәви, Низамиларның газәлләре, робагыйлары, нәзыйрәләре чокып

язылган. Иң гаҗәбе: җирле халык борынгы заманнардан калган ул мәдәни мирас ядкарьләрен без «Туган тел»не белгән кебек яттан белә.

Дару үләннәре белән сәүдә итә торган даруханәләрдә Әбүгалисина файдаланган илачларны (даруларны), мадәтләрне тәкъдим итәргә мөмкиннәр. Әй борынгы дәверләрнең үзе фәлсәфи, үзе шагыйранә, үзе самими багланыш, аралашу, гомер сөрү рәвешләре! Күңелне әллә нинди зур, кадерле нәрсәне югалту ачысы сызландыра. Шушы өммәт белән барышып, аңлашып, сайрашып яшисе иде лә безгә. Яшибез шунда көтүеннән аерылган, кемлеген оныткан томана җәнлекләр кебек. Үткәннәр сагындыра дигән гыйбарәнең асылы зиһенемне сызып уза.

Базарга көнаралаш йөрдек. Чөнки Шәрык базарының үзгә бер тәмле исләрен тансыклыйбыз. Санаторий янындагы рәйхан кушып пешерелгән тәмле чәйгә ияләштек. Якындагы авыллардан ял итүче гади агайлар капчык-капчык анар алып киләләр. Күчтәнәч итеп кенә. Ишегалдында ук әстерхан чикләвеге үсеп утыра. Чикләвек өлгермәгән әле. Яшел чикләвек әллә ниткән чирләрдән дәва икән. Яшь чакта андый хикмәтләрне беләсеңмени. Җыймадык.

Иртән йөгерергә чыгам. Сөт сыман ак, куе томан. Берни күренми. Көн яктысында хәтерләп калган сукмактан үргә каршы йөгерәм. Шул чагында курка белмәгәнемә хәзер аптырыйм. Югыйсә, бирегә тауларда яшәүче кыргый җанварлар да килеп чыккалый икән. Нигәдер, шундый хозурлык дөньясында явыз җанварлар да, начар ниятле адәмнәр дә яшәми дип уйланылгандыр инде. Берьюлысы йөгереп кайтып килгәндә томан эченнән тавыш килде: «Физкультура, да?» Бүтән ялгызым гына йөгереп йөрмәскә булдым. Дөньяныкын белмәссең! Тавыш иясе танылган композитор Поженян булып чыкы. Берничә көннән шул могътәбәр кешене, юк кына сылтау табып, санаторийдан куып җибәрүләрен ишеттем. Ике халыкның үзара киеренке мөнәсәбәтләре әнә кая барып җиткән икән ләбаса! Нинди генә дошмани хисләр уянса да, кеше кеше булып калсын икән ул! Югыйсә, Поженян җырларын Мөслим Магомаев та җырлый.

Йокы туйдыргач, дәва сеанслары да ала башлагач, минем йөрәгемә кереп оялаган төшенкелек үрмәкүче кармавычларын беркадәр йомшатты. Миндә тирә-юнь белән кызыксыну галәмәтләре беленә башлады.

Өченчебез Барнаулдан килгән алман кызы Лиза. Петр I заманында Рәсәйгә күченгән алманнардан ул. Тик сугыш елларында бу халыкка карата кырын карау булганнанмы, үзенең холкы шундыймы – безнең белән аралашасы урынга, күбрәк йоклау ягын карый. Югыйсә немецчамны бераз шомартырга җай чыкканга сөенгән идем. Ә без Чаллы кызы Римма белән кинога баргалый башладык әле. Көнаралаш тансылар да була. Рәсәйнең ерак төбәкләреннән саулык эзләп килгән кешеләрнең байтагы астма чиреннән дәвалана. Тау һавасы килешергә тиеш икән. Саулык барыбызга да кирәк.

Без әле Шуша базарыннан алып кайткан бармак буе виноградны урабыз. Аннары гына кибетләргә дә кергәли башладык. Римма мал таный торган кыз булып чыкты. Әллә каян гына затлы мохер шарфларны, парчалы шәлләрне күреп ала. Арзан гына үзләре!

Бер көнне мунчага төшеп юынып аласы иттек. Душ кабиналары куелган мунча эчтән бикле. Узып баручы бер хатын: «Юынып бетмичә ачмас инде

алар. Азәрбайҗан кызлары кереп киткән иде», –дигәч, шакып карыйсы иттек. «Ачсагыз иде. Без мөселманнар!» Шулай шакый торгач ачтылар болар. Икәү икән: «Мөселманмы, чын әйтәсезме?»

Телләр кардәш бит. Аңлаштык. Ышандылар. Эчке киемнәрен салмыйча гына юынгач, аларга кем булса да ярый торгандыр да бит. Күрәсең, берберләреннән дә оялалар. Мунчалаларын сабынлап, тәннәрен күлмәк аша гына юалар. Бүтән көннәрдә дә бергәләп юындык. Безне таный башладылар болар. Ә безгә көн дә юынырга булсын!

Газеталар сатып ала торган киоскның сатучысы Висалә белән сөйләшеп йөри башлаган идем. Бер көнне аңардан сорыйсы иттем: «Әйтче, миңа гына шулай тоеламы – азәрбайҗан ханымнары Рәсәй хатыннарын өнәмиләр кебек?» – дидем.

– Өнәмибез. Рәсәйдән ялга килгәннәр безнең ир-атларыбызны station аздыралар. Йә, безнең кайсы ягыбыз сездән ким?

– Ким түгел, хәтта артык та әле. Синеке кебек ялкындай күпереп торган куе чәчләр бездә юк. Йөзләрең шәфталу кебек нәфис. Бакуга килеп төшүгә үк исем киткән иде матур кызларның күплегенә...

Висалә көлеп җибәрә:

– Минем сүзләрем шәхсән сиңа кагылышлы түгел. Син кайсы халык баласы, татармы? Син бит үзең дә дөньядагы бер чибәр. Син безнекеләрне алып китүчеләрдән түгел. Үзеңне алып калмагайлары. Мин монда күзәтеп утырам. Син үтеп киткәндә егылып калалар. Чәчеңне безнең кебек гел дә гел хынага буяп йөрсәң, синең чәчең минекеннән биш тапкыр куерак буласы! Ә буй-сының! Мин сиңа көнләшеп карыйм. Тансыларга йөрмә син. Безнекеләр матурлыкны бәяли беләләр. Алып калырлар.

Ә без бүген Чаллы кызы белән тансыга җыена идек. Нишләргә икән соң? Мин урлана торган яшьтән узган инде. Дөньяны да күргән кеше.

Клубка матур киенеп килдек. Шунда ук игътибар үзәгендә калдык. Монда Таллыяр түгел, мине кем дә белми. Җитди укытучы битлеге киеп йөрисе дә юк. Туйганчы биисем килә минем. Иркенләп. Миндә кемнең ни эше бар! Мин бит, психологлар теле белән әйткәндә, махсус релаксация үтәр өчен килдем. Сагыштан диваналанмас өчен. Ялгызлык тутыгыннан таркала башлаган җанымны терелтү өчен!

Алай да шунда ук биючеләр арасына кермим әле. Күзәтим. Монда гадәтләр нindirәк икән? Мөнәсәбәтләр ни рәвешле? Әле, килештермәсәм, кайтып китүем дә бар. Утыргычларның да алдагы рәтенә түгел, кешеләрнең аркалары ышыклаганына кереп утырам. Бию залындагы сүрән яктылыкта югалам. Ишектән атлап кергән мәлдә төреп алган кызыксыну дулкыны да мине югалта. Чаллы кызы бии! Ул кайда да үзен кыю тота торганнардан. Һәммә кешегә дә югарыдан карап өйрәнгән. Сүзне сайлап тормый. Мөселман кызы икәнен дә бик тиз оныта. Аның шул хаясызлыгы мине куркыта. Бергә йөргәч, мине дә шундый дип уйлыйлар бит инде. Башка иптәш каян табыйм соң инде. Булганы белән.

Әрмән җырлары белән азәрбайҗан җырлары аралаша. Музыкантлар шәп. Мин, кинәнеп, матур музыка тыңлыйм. Егетләр ялгыз чыгып та бииләр икән. Анысы үзе бер соклангыч тамаша. Итәк тотып биюләр генә түгел инде бу. Бөркетләрчә очынып, үкчәләрен уйнатып, әмма гаҗәп нәфис хәрәкәтләр

белән бииләр. Ходаем, биюгә чакыра күрмәсеннәр тагын. Минем тирәли бөркет кагынганда, аккош кебек йөзә белмәм мин. Көлкегә калырмын.

Ул кичне тамашачы булып утырып кына уздырдым. Икенче юлы ипле биюләргә дә чыктым. Өченче көнне, әле биюләр башланганчы ук берәү нәкъ миңа төбәп килде генә бит. Таныйм да кебек.

– Менә таптым бит, юлдашым! Вагонда китабыгызны онытып калдырган идегез бит. Исемегезне сорамаганмын. Юлыгыз Шушага – санаторийга икәнен белгән идем инде. Көн дә диярлек килеп йөрдем дә, чарасызлыктан, үземә дә юллама сатып алдым. Санаторий сукмакларында тапмый калмам әле дип уйладым. Менә беренче көндә үк таптым да.

– Әйе, мин дә сезне таныдым. Әтиегез белән идегез бит. Рәхмәт инде, китап зур югалту булмас иде. Күпме борчу тудырганмын сезгә...

– Китаптамыни хикмәт. Сезне кабаттан очрату – үзе зур табыш. Сез алып бирмәсәгез, ул көнне поездга утыра алмый кала идек бит. Шимбә вагоннары бик тыгын була. Утыра алу бәхет эше.

– Ә миңа, чыннан да, бәхет елмайган иде. Мин үзем дә билет ала алмасам, вокзалда кунып калам бит инде дип борчылып тора идем. Мин сөялгән касса тәрәзәсе ачылды да китте...

– Шунда мин сезгә таба кулымны суздым: ике генә билет, янәсе... Әйдәгез, биибез. Кич безнеке бүген. Тагын да сөйләшербез. Мин сезне бүтән берәү белән дә биетмим! Ризамы?

– Риза! – Мин бу гидрогеолог егеткә каршы килә алмый идем. Кыяфәте-килбәте, төсе-бите, киенү-сөйләшү рәвеше, юлда ук чамаланган зыялылык-белем кимәле нәкъ минем хыялымда йөргән егетнеке иде. Аның белән дә биергә чыкмасаң, Гөлирәм!

Биедек тә биедек. Һай, беттем! Мин куркып торган бию җиткән икән. Мин уртада. Каһарман, егетнең исеме шулай иде, бөркет булып бөтерелә. Миңа нишләргә? Зифа буемны тулгандыргандай итенәм. Ике беләгемне Кавказ кызларыча дулкынлатып карыйм. Юк инде. Бию түгел инде бу. Барлык күзләр бездә. Егетем мине кулларына алып бөтереп әйләндерә... Ярый, шуның белән минем биеп азаплануларым туктала. Югыйсә мәктәп кызларына әллә нинди кадрильләр, молдаван биюләрен өйрәткән Гөлирәм бит мин. Егетемнең осталыгы, егәре, энергетикасы алдында коелып калдым. Магнетизм тылсымы бу. Егетнең харизмасы гаепле моңа.

Икенче көнне безнең тәрәзәгә ниндидер кызыл җимеш килеп тиде. Карыйбыз. Авызын ерып, Каһарман басып тора.

– Чык әйдә! Алыча җыярга барабыз!

Йөгереп чыгам. Тау аралыгына алып китә. Ә анда челтерәп, чишмә агып ята икән. Алыча куаклары бу урында иркенләп җәелеп аккан инешнең аргы ягында. Кызыл җимешләре белән еракган кызыктырып торалар. Инеш өслэтеп, бер күперчек сыман нәрсә бар. Тик аңа үрмәләп менәрлек түгел.

– Йә, ничек чыгабыз инде? – дим.

Каһарман мине җайлы гына итеп учына утырта да шул күперчеккә бастырып та куя. Үзе, әлбәттә, эһ дигәнче сикереп тә менә. Мине болай күтәреп йөрткәннәре юк иде әле. Рәхәт булып китә. Менә мин дә иркәләнергә өйрәнәм.

Иркәләнәселәр бар икән әле. Ул кичне клубта миңа сюрприз әзерләнгән

булып чыкты. Бер заман музыка тынып калды да, диджей Татарстаннан килгән Гөлирәм өчен җыр игълан итте. Каһарман, мәшһүр Мәхмүт Әсәмбаевны туздырып, ут уйнатып, минем каршыма биергә төште. Мин кичәнең йолдызына әверелдем. Бию соклангыч иде. Болай да биеп була икән! Халык аһ итте. Бию тәмамлангач, без залда калмадык. Безгә инде тамашачылар кирәк түгел иде.

Төн буе сайрашканнан соң, таң алдыннан ул тагын ишек шакыды. Томанлы сукмактан икәү йөгерергә чыктык. Аннары кочаклашып, кояш чыкканчы үбештек.

– Унсигез яшемә кайттым, Гөлирәм! Кабындым мин! Мин сине яратып туя алмыйм. Ярый әле, таптым. Без икебез бер яшьтә икәнбез. Минем дусларым килә бүген. Мине югалтма. Без базардан бәрән ите алып кайтырбыз. Аннары, синең бүлмәдәшләреңне дә чакырып, тау итәгенә шашлыкка барырбыз. Син ризамы?

Риза, әлбәттә, риза. Кызлар да ничек кенә риза булырлар. Аларга мондый кадерне кем күрсәткән әле?

Егетләр җәһәт-җәһәт ит турыйлар. Помидор, суган белән яшь итне тал чыбыгына аралаштырып тезәләр. Бернинди маринадлау юк. Бик тәмле буласы бу сый. Лиза безгә иярмәде. Римма белән икәүләп табын хәстәрлибез. Каһарман, ничек күреп ала торгандыр, мине үргә каршы күтәреп кенә менә, күтәреп кенә төшерә. Бер адым атлатмый. Аңа мине шулай кулда йөртү бер ләззәт сыман. Рәйхан оетылган чәй белән сыйны түгәрәкләп куябыз. Безгә шундый хөрмәт күрсәткәннәре өчен рәхмәт егетләргә! Римма да телен тыя белде. Аңа да рәхмәт.

Алда әле ун көнебез бар иде. Шул ун көндә югарыда йөзгән ак болытлар безне күреп, юлларын онытып туктап калды. Егетемә куш учымнан су эчергәндә көмеш сулы чишмәләрдә бәхетле йөзләребез чагылып калды. Шуша урамнарындагы шигъри аятьләрне берәм-берәм икәү укып чыктык. Аш вакытларын белмәдек. Йөгереп арымадык. Тау кәҗәсе кебек таудан тауга атылдык. Томаннар таралганчы үбештек. Мин аның йолдыз күзләрен күреп туя алмадым. Ул минем җырларымны тыңлап хәйраннар булды. Бер-беребездән гомер буйларына да бизмәс төсле идек. Мәхәббәт дастаннары иле Кавказ шаукымы бу!

Китәсе бар! Аерыласы...

Китәсе көн якынлашкан саен безнең мөнәсәбәтләр якыная гына бара. Аерылышу көненнән куркып торабыз. Ул миңа: «Кал!» – дип әйтә алмый. Мин аңа: «Китик икәү!» – димим. Ялган хисләрдә янабызмы әллә?

Хушлашыр көн барыбер килде. Миңа килгәндәгедән дә ямансурак. Каһарман: «Мин сине барыбер табам!» – дип әйтүен әйтә дә бит ул. Ә мин югаласымны беләм.

Поездга кадәр озата килде. Поезд кузгалып киткәндә, вагон баскычына кабат-кабат сикереп менде. Үбә дә үбә. Шашып-шашып...

Калды! Калды! Калды! Йөрәгемне алып калды...

– Тап, яме, яме!

Очкыч мине Казаныма алып китә. Ә минем йөрәгем Баку аэропортының шәмәхә төнендә кала.

Үзем адресымны да бирмәдем. Чөнки үзгәрәчәк ул. Таллыярда – минем

өчен бушап калган авылда, мин бүтән яши алмамдыр инде... Чөнки вузларга киткән укучыларым, кияүгә киткән дус кызларым минем яшьлегемне урладылар. Мин хәзер бушап калган өемә, гармун чыңы тынган классларга бүтән керә алмыйм.

**Уналтынчы төн**

Тора-бара ярсуым басылды. Могҗизага ышанып яшәвемне дәвам иттем. Дөньяда Каһарман, аның кебек мәхәббәт тәмен аңлаган, сөю ләззәтен татыган, кадерен белгән кеше барында мин боегырга тиеш түгел. Ул бит мине бер тапкыр тапкан иде инде. Димәк, тагын да табачак. Исән генә булсын!

Бу уку елын Таллыярда төгәлләрмен. Чөнки миннән башка немец телен укытыр кеше юк. Чит телдән аттестатта билге булырга тиеш.

Эшлим дисәң, йөрәкне басарлык шөгыльләр табыла ул. «Дуслык клубы» ачып җибәрергә дигән ниятем бар иде бит. Китәм бит инде. Башлап тормаска булдым. Алга таба укырга ниятләгән укучылар белән тирәнтен шөгыльләнә башладым. Минем фәннән баллары түбән булып, күңелләре кителерлек булмасын. Узган уку елында бер кызга диктанттан «дүртле» куйганнар. Үзем барып, эшен тикшерттем. Бер хатасы да юк иде. Төзәттеләр. Кыз медицина училищесында укып йөри... Һәммәсе белән дә йөреп бетереп булмас. Белемнәре үзләре белән булсын, дим.

Май ае җитте. Соңгы кыңгырауга бер атна кала «Пионер көне» дигән бәйрәм бар. Бу бәйрәмне беркайда да Таллыярдагы кебек күңелле итеп бәйрәм итә белмиләрдер. Авылның табигате дә бик ярашлы. Саф-саф тезелгән ал галстуклы пионер отрядлары барабаннар кагып, быргылар кычкыртып, Кылы күле буена төшәләр. Биш чатлы йолдыз сыман зур учак урыны әзерләнгән. Менә кайчан шук малайларның дәрәҗәсе арта. Йолдызның һәр чатында салют булуга, учакны дөрләтеп җибәрү өчен шулар сакта тора. Кемнең чаты яктырак янар! Аннары ул чатлар бергә кушылып, зәңгәр күккә таба ургылыр. Алтын очкыннар чәчрәр. Пионер җырлары җырланыр. Төнлә булса, бу күренеш тагын тантаналырак булыр иде дә. Без төнгә калдырмыйбыз. Әле отрядларның рапорт бирәселәре дә, ярыштан уеннар уйныйсылары да бар. Пионер учагы тирәсендә бер генә тыңлаусыз, тәртипсез бала күрмәссең. Фәкать шатлыклы, бәхетле йөзләр генә!

Учак тирәсендә укытучылар да спорт киеменнән йөри. Егетлек исе керә башлаган малайлар күзе төшкән кызларын велосипед рамасына утыртып йөртеп киләләр. Әле берсен, әле икенчесен. Кайсыдыр кызлар кулында сап-сары казаяк чәчкәләре күренә. Тәүге саф хисләрнең нәфис бөреләрен күрмәгәнгә салышабыз.

Учак янганны, янгын телләре биегәнне күзәтергә мин дә яратам. Күзләрем талганчы утка карыйм. «Гөлирәм Гәрәевна, бик якын бармагыз. Чәчегезгә очкын чәчрәр», – дип кисәткән булалар минем яшь джентльменнарым, учакка чыбык-чабык өсти-өсти. Минем дә ут иясенә ясак бирәсем килә. Бер арурак агачны алам да ялкын уртасына ыргытам.

– Аһ, Гөлирәм Гәрәевна, балта сабын салдыгыз бит утка. Алып та булмый инде аны хәзер.

– Берни түгел! Яңа сап ясарсыз, – дим мин, гаярьләнеп. Ут иясенә

миннән бүләк булсын. Ә сезгә миннән бер якты калсын! Яктыны аны кире кайтарып алмыйлар.

**Унҗиденче төн**

Мин җәйне әни янында уздырдым. Әни минем, ниһаять, аңа якынрак урнашырга теләвемә бик сөенде. Ул инде хәзер укытудан туктаган. Бабаен гына кадерләп яши. Әни ялгыз дип кайгырасы юк. Түбән Камага август башында кайтып төштем.

– Исәнме, Яшьлек каласы!

Кемдә тукталыйм икән? Сабакташларның миннән алдарак килеп төпләнгәннәре бардыр бит инде. Шулар ишеген шакыйммы, әллә әүвәле РОНОга керимме?

РОНО ишеге төбендә үк Мокамай – минем Санчо Пансам белән маңгайга маңгай бәрелешәм.

– О-о! Сабакташ-җанаш ! Сине күрер көн дә бар икән. Югалттык без сине, югалттык. – Ничек иркен сөйләшә бу минем белән.

– Кыюлангансың син.

– Ничек инде «кыюланган?!» Морской волк абзаң! Син, матурым, бөтенләйгәме? Эш белешәбезме? Әллә инде алдан белешеп куйган идеңме? Кадрлар күп хәзер. Эш булмаска да мөмкин. Ну, синең юлыңда мин очрадым. Бер проблемам да юк дип уйла.

– Мөкатдис, ашыкма әле. Үз хәлләреңне сөйлә. Син үзең ни эш бетереп йөрисең монда? Яңалыкларың кай тирәдә?

– Кай тирәдә, дип. Баштан башлыйммы? Флотта сәүдә корабына эләктем мин. Кочегар булып хезмәт иттем. Биш ел! Акча белән кайттым. Өч бүлмәле кооператив фатир сатып алдым. Бер өйләндем – аерылдым. Икенче өйләндем – аерылдым. Шулай итә торгач, өч бүлмәле фатирым бер бүлмәлегә калды. Бүтән өйләнмим. Бүләр фатирым калмады.

– Ну минем Бишендедә мәктәп салып биргән өем бар. Укытудан китсәм, аны алалар инде. Син ул авылны белә торгансыңдыр. Түбән Камага якын гына ул. Ә без сезләр әйләнеп кайтуга шәһәрне ару гына төзеп куйдык.

– Шәп төзегәнсез. Матур гына, җыйнак кына шәһәр килеп чыккан. Миңа да почмак табылыр бит. Шушында яшәп калырга уйлап торам.

– Ни, син, Гөлирәм балакаем, кияүдә түгелме?

– Юк шул, атакаем, кайгыртуың өчен рәхмәт. Хатыннан хатынга йөргәндә, кесәң тулы акча булганда, мине исеңә төшермәдеңме бер дә?

– Сез бит безнең төркемдә күбәү идегез. Кайсыгызны гына уйлап бетерәсең анда.

– Ярар, хәзер чынлап сөйләшик инде. Мин эш сорарга дип килдем бирегә.

– Бар Бишендегә. Минем урын бушый анда. Әле үзләре белмиләр. Мин җәмәгать эшенә күчәм. Миңа киңлек кирәк. Алга таба депутатлыкка үрмәләргә исәп бар. Белмәгән кешесе, ачмаган ишеге юк, диләр минем турыда. Хак та шулай.

– Кешесенә юлыкканмын икән...

– Озакка сузмыйбыз. Керәбез дә хәл итәбез. Аннары мин сине Бишендегә илтеп тә куям.

– Бәлки әле мине бүтән урынга билгеләрләр...

– Методист урыннары бар. Ризалашма. Шәһәрдә тиз генә фатир булмас. Ә минеке әзер тора.

Мокамай әйткәнчә булып чыкты. Методистка ризалашмадым. Бишендегә килдек. Мокамайның өе яшәмәслек түгел. Караган бу өен. Депутат буласы кеше авылда торып кала алмый бит инде. Өй, әлеге дә баягы, мәктәпнеке.

– Гөлирәм, монда кара әле. Бакчы, минем бакчада һәммә нәрсә күкрәп уңа. Бала-чага тырышты. Минем җирдән аерыласым килми. Бергәләп үстерербез инде алга таба да. Киртә буенда чәчәк түтәлләре. Алары синеке булыр. Тик менә күршеләр начар монда. Тавыклары бакчага керә. Түтәлләрдә тибенә. Минем өйдә тормаудан файдаланалар. Үзем өйдә чагында киртә аша болгап кына атам мин аларны. Чалып, шулпа пешереп ашамаганга куансыннар.

– Алай кылансаң, күрше начар була инде ул!

– Кыланмасаң, башыңнан йөриләр. Тора башлагач, үзең дә аңларсың әле. Мин килгәләп йөрермен. Сине минем хатын дип уйласалар, акланып торма. Миннән шөллиләр алар. Йорт җиһазын әлегә калдырып торырмын. Бәлки әле бөтенләй дә алып китмәм. Син әйберсез генә, ахры.

– Әйе шул. Кием-салымнан башка мөлкәтем юк. Кирәге чыккан саен алгалармын әле. Укытучылар гидай булырга тиеш дип өйрәттеләр бит безне. Синең дә әнә мал-туарың юк бугай.

– Мал-туар кирәкми дә ул. Укытучы пролетариат кебек яшәргә тиеш. Бәйсез булып. Мин максатымны яңа җәмгыять төзүдә күрәм. Шуңа күрә кулларымны богаусыз калдырам – милексез, баласыз, хатынсыз.

– Алай күңелсез була торгандыр ул. Бишенде мәктәбендә укучылар җитешлеме? Әллә монда пролетариат кына яшиме?

– Бу кадәресен мәктәп патшалары белән сөйләшерсең инде. Мин киттем әле. Яшелчәләргә су сип, яме. Бу арада яңгырлар булмады.

***

«Патшалар»ның РОНОдагысы миңа җылы мөнәсәбәт күрсәтте. Иван Петрович атлы керәшен агае иде ул. Керәшеннәр кешелекле безнең якта. Бу агай да вак сүз сөйләп тормады. Иң эресеннән башлады:

– Яшьлектәге романтик хыял кайтарды, дисең инде туган якка. Укытучының шул инде аның. Чегән кебек күчеп йөри-йөри, тегендә биш елын, монда ун елын калдыра. Олыгайган көненә каккан казыгы да булмый. Мин сиңа атаң кебек кеше. Киңәшем дә атаң киңәше кебек булыр. Беренче көннән үк гариза язып калдыр фатир сорап. Кәгазь ашарга сорамас, ятсын шунда. Ни булмаска ярап торыр. Шәһәрдә фатирларны чутсыз төзиләр. Башлы-күзле булып куйсаң да, артыгы булмый әле фатирның.

Ә менә Бишенде мәктәбенә без сине рус теле укытучысы итеп җибәрәбез. Хәзер бит инглиз теленә күчтек. Ата-аналар да, заман да шуны сорый. Немец теле арткы планга күчә бара. Инглиз теле халыкара тел кимәлендә урнашып килә. Шулай да инде ул. Рус теле укытучыларының сәгатьләре дә күп була. Димәк, акчасы да. Алдан ук белеп бар, диюем. Синең тәҗрибәң бар бит инде рус теле укытудан? Сиңа Баулыдагы коллегаларым әйбәт характеристика сырлаганнар. Без аны «Мәгариф отличнигы» на тәкъдим иттек, дигәннәр. Насыйп булса, ул исем сине Бишендедә эзләп табар. Без

дә аяк чалмабыз. Теге сабакташың – правдоруб егет – авыл белән уртак тел таба алмады. Күп мәшәкать ясады безгә.

Алай икән. Бу ягы күңелсезрәк икән. Аның белән уртак ихата тотасыбыз бар бит әле. Араларыбыз уртак түгеллеген сиздереп куясы булыр авылдашларга.

Мәктәп директоры Рабига апа Җиһанова икән. Без укыган заманнарда ук данлыклы директор иде. Һаман эшли икән әле. Зур тәҗрибәле кеше инде ул. Бу җәһәттән күңелемдә өмет туды. Гадел булыр. Гадел җитәкче калкан кебек ул.

Дөрестән дә рус теле һәм әдәбияты дәресләрен өеп бирделәр. Сыйныф җитәкчесе урыны «сигезенчеләр»дә бушаган икән. Ничек тә уртак тел табарбыз. Уку елы башлангачны ата-аналарны йөреп чыктым. Укучыларымның да өйдә торганнары белән күрештем. Бернинди кытыршылыклар да булмады. Авыл да яратмаслык авыл түгел. Торыр җиремне үз көемә җайлап, җыештырындым. Мокамай атнага бер генә күренеп китә. Катык-сөт ала килергә күндердем әле аны. Акчасын да алдан биреп куйдым. Килүгә үк кружка тотып, күршегә кирәсе булмасын, дидем.

Уку елы ипле генә башланып китте. Ипле генә дәвам итте, ипле генә тәмамланды. Тормышымда истә калырлык вакыйгалар да юк. Сабакташлар да үз дөньяларына чумганнар. Очрашулар эзләп йөргән кеше юк. Күңелдә дәррәү ашкыну уянырмы яңа урында дип өметләнгән идем баштагы чорда. Ял көннәрендә Түбән Камадан урап кайтам. Шәһәрдә кеше арасы – юаныч.

Мәктәптәге юанычым – балалар белән эшләү. Рус телен яратучылар түгәрәге оештырып җибәрдем. Аны «Алтын ачкыч» дип атадык. Дәртләнеп-дәртләнеп, икенче ана телебезне яраттырам. «Нигә кирәк ул безгә рус теле?» дигән бала юк. Бусаганы атлап чыгуга рус теле кирәк. Хәер, рус теле үзе дә ишектән кусаң, тәрәзәдән керә хәзер өйләргә. Беренче дәресемне үк рус теле буенча зур белгеч булган Дитмар Розенталь турында мәгълүмат бирүдән башладым. Польшада туган яһүд кешесе рус теленең сүзлеген төзегән. Йөзләгән дәреслекләр язган. Үзе дә уникe тел белгән.

Икенче дәрестә тел байлыгы хакында сөйләштек. Шекспирның актив кулланган сүз байлыгы 15 мең сүздән торган. Пушкинныкы 21 мең сүздән. Толстойныкы 66 меңгә җиткән. Инглиз телендә 470 мең сүз бар икән. Рус телендә аннан да күбрәк санала. Бу мәгълүматларымны балалар белән уртаклаштым... Мин үзем өчен генә уйлап куям: шул байлыкның күп өлеше төрки телләрдән алынган сүзләр. Әгәр дистәләгән төрки телләрне сугарган сүзләрне бергә җыйнасаң, биниһая тел байлыгы тупланыр иде. Һич югы, татар теленең таралып яткан «балаларын» танырга өйрәнәсе иде. Ә без күрәләтә гадиләштереп сөйләшергә тырышабыз. Имеш, надан кеше дә аңларлык булсын. Үз байлыгыбыздан үзебез оялабыз.

«Алтын ачкыч» түгәрәгендә балаларның тагын бер яраткан шөгыле – русчадан татарчага тәрҗемә итү. Әйтик, мин аларга А.С.Пушкинның бер шигырен бирәм дә алар шуны, һәр бала үзенчә, тәрҗемә итеп карый. Кызык кына килеп чыга.

«Я помню чудное мгновенье,
Передо мной явилась ты,
Как мимолетное виденье,
Как гений чистой красоты».

Инде булган тәрҗемәсен укып күрсәтмим әле. Шигырь ритмын тоярга өйрәнсеннәр. Бу шигырьне яшүсмерләрнең һәммәсе дә диярлек яттан белә.

Һәркайсы үз кичерешләре аша яңа шигырь иҗат итә. Үртәшмиләр. Кәгазь кыштырдаталар. Һәр вариантны укып карыйбыз. Кемнеке икәнен дә әйтмим. Ирен кыйшайтуларга урын калдырмыйм. Иң ахырдан профессиональ тәрҗемәченең иҗат җимешен укып күрсәтәм:

«Хәтерлим мин гүзәл бер мизгелне:
Әйтерсең лә күктән иңдең син.
Кинәт күрдем алларымда сине,
Саф матурлык күрке идең син».

Шул рәвешле Пушкин иҗатын да яраттыра алдым дип уйлыйм. Барлык халыклар да яраткан шагыйрьләр күп түгел. Таллыяр мәктәбендә Екатерина Алексеевна һәр дәресен Пушкинның гомер даталарын кабатлатудан башлап җибәрә торган булган. Түгәрәктәге күнекмәләр кайбер балаларда шигырь утын кабызып җибәрде. Язып киттеләр.

Берничә еллар күңелдә йөргән «Дуслык клубы»на да өлгереп җиттем. «Пионер» журналы аша социализм лагере илләрендә яшәүче балаларның адресларын сорап алдым. Болгария, Алмания, Польша, Куба балалары рус телен мәктәпләрдә өйрәнәләр иде. Аралашу рус теле ярдәмендә барды. «Сыйныф журналындагы фамилиясе «Г» хәрефенә башланган балага» дип адреслана беренче хат. Бу бер мисал гына. Теләсә кайсы хәреф булырга мөмкин. Шуннан китә инде... Бүләкләр, курчаклар... Кунакка чакырулар. Без мәктәптә бүләкләрдән музей да бизәп куйдык. «Чит ил»нең тылсымы зур иде. Таныш түгел дөньяга тылсымлы тәрәзә иде ул хат алышулар. Мин үзем студент вакытта Эрнст Тельманның кызы Ирма белән хат алышканымны сөйләдем бугай инде. Алман телен яхшырак өйрәнү өчен әйбәт тәҗрибә булган иде ул.

**Унсигезенче төн**

Хатлар килми. Кемнән килсен инде ул? Адресымны бирми киттем. Үзем гаепле. Каһарманның: «Мин сине барыбер табам», – дигән вәгъдәсенә ышанып яшәлде. Тапмады. Табылмадым. Яңа танышлар да эзләмәдем. Мокамайның минем белән уртак ихата биләве, күрәсең, безнең исемнәрнең кушылып сөйләнелүенә сәбәп булгандыр. Югыйсә бернинди якынлык юк. РОНО мөдире әйткәндәй, ул «Правдоруб»ның файдасыннан зыяны күбрәк. Бишендегә килеп киткән саен район газетасында берәр тәнкыйть мәкаләсе чыгара. Әле менә дәүләт заданиесенә кибеттән сатып алган майны тапшыралар дип язган. Авыл Советына тикшерү килде. Бу хәбәрне Мокамайга мин сөйләгәнмен дип уйлыйлар икән. Янәсе, калада яшәгән Мокамай аны каян белсен? Ә мин авылда – халык арасында яшим. Аратирә йомышка кергәли торган күршеләрем сөт бирмәс булды.

Ул гына җитмәгән, Мокамай үзенеке санаган бакчага умарта оялары

кайтарып куйды. Умарта кортлары кеше кушканча түгел, үзләре урнаштырган кагыйдәләр нигезендә яши. Күршеләрнең дә үз кагыйдәләре бар. «Умарта тотасыз икән, кимендә ике метрлы биеклектәге койма коегыз!» – диләр. Мокамаймы соң инде койма тотучы! Күч аерганда, кортлар тынгысызлана. Күршеләрнең оныгын чаккан бит берсе. Китте елаш, китте ызгыш. Мин үзем дә корт чагуыннан куркам. Бер гаебем дә юк. Тоттым да бик кыйммәтле юллама алып, Һиндстанга киттем. Ул вакытта чит илгә чыгу җиз иләк аша уза алсаң гына мөмкин иде. Ә миңа бу мөмкинлек «Мәгариф отличнигы» дигән исемгә алмашка бирелде. Безне ныклап әзерләделәр. Сәяси тотрыклылык ягын сынадылар. Төркемебездә безнең аяк атлавыбызны күзәтеп торучы да бар иде. Булса соң... Мин ярты адым да кыек басарга җыенмыйм.

Һиндстан – хыял бит ул. Һинд фильмнарыннан күңелгә оялап калган хыял. Бу хыял хакына әллә ниләрдән баш тартырсың. Берничә һинд җырын өйрәнеп куйдым. Фильмнардан кереп калган җырлар бар бит. Сувенирлар җыйдым алмашка. Берничә татар яулыгы – көмеш җеп белән чиккән батист яулыклар әзерләдем.

Ничек барганны, ничек урнашканны инде онытып та бетергәнмен. Алары мөһим дә түгел. Ә менә Һиндстан үзе! Тәэсирләр! Сөйли башласаң, мең төнгә җитә торган. Йокларга ятканда, минем белән түшәккә башын куя торган ике серем, ике шатлыгым, ике юанычым бар. Икесе дә – мәхәббәткә һәйкәл. Берсе – Каһарман. Мәңгелек мәхәббәтем. Аның хакында сөйләдем инде. Икенчесе – Агра шәһәрендәге мәрмәр сарай! Таҗ Мәхәл сарае. Ул да мәхәббәт һәйкәле. Җаһан шах Джамна елгасы ярында вакытсыз дөнья куйган сөекле хатыны Мөмтаз Мәхәл ядкаре итеп, моннан дүрт йөз еллап элек ак мәрмәрдән салдырган, асылташлар белән бизәлгән сарай бу. Бер-берсен үлеп яраткан бу икәүнең мәхәббәтенә һәйкәл. Мөмтаз ханымның язмышына кызыгам. Ярата да, яраттыра да белгән. Җаһан шахка сокланам – яратуын бөтен дөнья көнләшерлек рәвештә чагылдыра алган. Бу мәхәббәт алдында фәкать баш ияргә генә кала. Җир йөзеннән әнә нинди мәхәббәтләр эз калдырып кичкән. Ә минем яшен кебек йөрәгемне телеп үткән мәхәббәттән хәтта бер хат та калмады. Кайда ди инде ул безгә сарайлар! Почмаксыз торып калуыңны да уйлаучы юк.

Таҗ Мәхәлгә илтә торган баскычта озаклап утырам. Мине делегация җитәкчебез эзләп таба. «Закирова, Сез бит Татарстаннан? Илчелектә бүген безнең хөрмәткә кабул итү мәҗлесе. «Татарстаннан вәкил бармы?» дип кызыксындылар. Берәр хикмәте булуы мөмкин. Берәр җыр өйрәнеп барыгыз әле. Җырлыйсыз бит сез. Ишетеп йөрим. Берәр юньлерәк сувенирыгыз калмадымы әле анда?»

Илчелектә чибәр генә егетләр каршылады. Биредә берничә тел белгән, күркәм кыяфәтле, буй-сынлы егетләр – МГИМОны тәмамлаган дипломатлар туплана. Араларында татар егетләре дә бар микән әллә?

Шулай дип уйларга да өлгермәдем, миңа эндәштеләр:

– Сылукай!

– ?

– Танымый торасызмы? Мин бит сезнең укучыгыз. Таллыяр мәктәбеннән.

Гобәев мин, Фидаил. Кочаклап алмавыма гаҗәпләнмәгез. Дипломатларның үз-үзләрен тоту кагыйдәләре кушмый. Алман телен шәп өйрәткәнсез. Урта мәктәптән соң квота белән МГИМОга эләктем. Шундый разнарядка бар иде элек. Аз санлы халык балаларын, авыллардан сайлап алып, күтәреп җибәрергә дигән. Жирәбә миңа чыккан. Алтын медальгә тәмамладым бит мин мәктәпне. Сәләтем ачылды, укып киттем. Әдәпкә өйрәттеләр. Башта Азәрбайҗанда вәкиллектә эшләдем. Анда сезне белгән бер егет белән танышып киттем. Ә ул миннән сезне эзләтте. Бик тиз табарга кирәк иде аңа сезне. Гафу итегез, сезне яраткан бугай ул. Мин озаклап сөйләшеп тора алмыйм. Ярамый. Сезнең җитәкчегез игътибар итте инде. Кисәтү алмагаегыз. Тиз генә адресыгызны әйтегез әле. Мин хәтерләрмен. Хәтер ягы шомартылган безнең.

Мин әйттем. Ул «хәтерләдем» диде. Аннары мәҗлес башланды. Мин сәер дә, серле дә дулкында йөздем. Шәбәеп киттем. Осталыкны күрсәтү халәтенә керде мәҗлестәгеләр. Мин тоттым да «Йөрәк сере»н җырладым. Акапелла гына.

«Аның йөрәге дә юксынудан
Сызланадыр кебек уемда.
Ара ераклашты, тик нигәдер
Кавышырбыз кебек тоела...»

Болай матур җырлаганым юк иде. Барлык хисләремне түктем генә. Җаһан хан мәхәббәтен дөнья каршына бастырып куйган бит әле. Нигә миңа да түгелмәскә! Безнең делегациядә миннән башка татарлар юк иде. Әмма минем йөрәк серемне тын да алмый тыңладылар. Илчелек вәкиле иңнәремә һиндларның ефәк шәлен китереп салды.

Түбән Камага кайтып төшкәндә, шул шәлдән дә купшырак, зиннәтлерәк мөлкәтем юк иде. Юраганым да юш килгән. Мокамай өе урынында мине учак урыны каршылады. Янганмын. Фаҗига төнлә булган. Яшен сукты, диделәр. Мин күренмәгәч, мине дә ут эчендә калган дип уйлаганнар. Янмыйбыз әле.

Икенче көнне РОНОга киттем. Иван Петрович бу юлы да ачык чырай белән каршы алды. «Менә, Закирова, бик вакытлы килдең. Синең хәлне уйлаша идек әле. Гаризаң булган икән. Фатир чиратың килеп җиткән. Кил әле тәрәзә янынарак. Йортыңны күрсәтәм. Фатирыңны карап кайт. Янгын сәбәпле матди ярдәм дә булыр бераз. Урын-җир, тәлинкә-кашык сатып алырлык».

Могҗизалар кырына килеп чыктыммы әллә?

Ошады фатир. Яз башында әни вафат булган иде бит минем. Шахтёры бер ел алданрак китте. Туган авылга кайтып, иске өебезне сатып килдем. Йорт җиһазы алырлык акча чыкты. Хәзер инде Бишендегә йөреп эшлим. Мокамайны Казанга күченгән, диделәр. «Юридик белеме булган пенсионер теләсә нинди оешманы төп башына утыртырга сәләтле. Бәясе дә кыйммәт түгел», – дигән имеш. Яшьләр әйтмешли: кулына әләм алсын, муенына барабан элсен сәнә!

Яңа ел алдыннан биш сургучлы хат килеп төште. РОНОга килгән. Хат Каһарманнан иде. «Саумы, гүзәлем. Саумы, онытылмас ярым! Озак


эзләргә бирмәделәр миңа сине. Шушада танышканда, мин МГИМО студенты идем бит. Гидрогеолог булуым да ялган түгел иде. Эшләп йөргән җирдән эләктем мин ул даирәгә. Минем атам Советлар Союзы Герое иде. Андый кешеләрнең балаларына хөкүмәтебез игътибарлы булды. Мине дә укыттылар. Укып бетергәч, Ирандагы Тебриз каласына – анда азәрбайҗаннар тупланып яши – вәкиллеккә юлладылар. Шарты шундый иде: өйләнеп китәсе! Мин сине генә хатыным итеп күрә идем. Эзләп карадым. Хәтта синең бер укучыңа да тап булдым. Аның белән хат язып карадык. «Күчеп китте» дигән җавап килде. Ә мине кысалар: тиз кирәк! Күрше кызын алдым да киттем. Айнура белән ике бала үстерәбез. Тебризда мөселман кануннары буенча яшиләр. Шыгый мөселманнар. Сез сөнниләр бит. Аны-моны белдермәбез. Мин сине кайтып алам. Икенче хатыным булырга ризалашсаң, Үзәккә мөрәҗәгать язам. Каршы килмә, бәгърем. Икенче булсаң да, Беренче булырсың. Фидаил миңа синең Консуллыктагы кабул итү мәҗлесендә җырлаган җырыңның сүзләрен язып җибәргән. Иншалла, бергә булырбыз.

P.S. Намаз укырга өйрәнә башла! Биредә хатын-кызларга яулык бөркәнеп йөрисе. Анысына да алдан укияләшә тор!

Яратам сине!»

Мин бик нык уйлана калдым. Тормышым бер эзгә төште дигәндә генә, мондый да кискен вираж ясый алмамдыр мин. Кеше яккан учакларда күмер актарып гомер итүне дә йөрәгем кабул итми.

Тәвәккәллек җитмәде миңа. Мәктәптә укытып калдым. Һаман-һаман авылга йөреп укыту ардыргач, РОНОга методист булып күчендем. Пенсиягә ашыктырып озатмаган булсалар, эшли идем әле мин. Мөмкинлек бирмәделәр шул. Бишенде мәктәбенә ике елда унбер яшь укытучы килде. Чаллыда да вуз ачылды. Кадрларны алар да бирә. Яшьләргә сәгатьләр җитми. Юктан да тарткалаш китә. Укытучыга без яшь чактагыча олы итеп карау, юл кую юк хәзер. Менә мин үзем башлап юл куйдым. Пенсия дигән сөргенгә ризалаштым... Югыйсә мәктәптән дә якын, мәктәптән дә кадерле бернәрсәм дә юк иде.



Фәнәвис
Дәүләтбаев

# КОЯШЫ БАР КҮҢЕЛ ӨМЕТЛЕ УЛ…

## Шигырь чыга

Уйлау җитә – шигырь килеп чыга,
Җен чыккандай чүлмәк эченнән.
–Үзең читләшмәсәң беркайчан да
Аерылмам, – ди ул, – мин синнән.

Синдә калды, эшем бетте диеп,
Чыккач ятмый алай сузылып.
Сайрап торыр тылсымлы кош сыман,
Әверелә матур сүз булып.

Шигырь чыга ургып, чишмә булып –
Сусаганнар кат-кат эчсенгә.
Күңел сусауларын басар өчен
Татлы йотым бит ул кешегә.

Шигырь чыга җирдән, судан, күктән.
Шигырь чыга айдан, болыттан.
Шигырь чыга урман, елгалардан,
Шигырь чыга алсу офыктан.

Шигырь чыга уйдан, хыяллардан…
Җитеп торсын, башка өстәмим.
Теләсә каян таба ала аны
Күңеле бай булган хискә, дим.

Күңелемнең тылсымчысы булу
Килә әле, килә көчемнән.
Уйлау җитә – шигырь килеп чыга,
Җен чыккандай чүлмәк эченнән.

Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ (1951) – *шагыйрь; «Суз җырыңны, былбылым!», «Карурман чишмәсе», «Таныш халәт» һ.б. китаплар авторы. Актанышта яши.*

## Бер мосафир...

Мин һаман да, мин һаман да әле
Бер мосафир гомер юлында.
«Бирешмәсме, түзәлерме?!» диеп
Кат-кат сыный икән бу дөнья.

Тормыш йөген иңнәремә салып,
Үргә таба менеп барышым.
Барган саен, тукталмыйча гына,
Күзәтүем кояш баешын.

Күнегелгән, һич тә сыктамыймын
Иңнәремдә йөгем авырга.
Язсын иде әле озак шулай
Туктамыйча алга барырга.

Бер Аллаһка гына билгеледер
Алда әлениләр көткәне.
Кайсы яклап кына карасаң да
Хурланырлык түгел үткәне.

Яшәгәчтен, кеше исеменә
Кирәктер лә лаек булырга.
Мин һаман да, мин һаман да әле
Бер мосафир гомер юлында.

## Син көтүдә икән...

Син көтүдә икән, шуны аңла –
Арттагыга аңа тынгы юк.
Чыбыркы еш төшә сыртка чыжлап,
Яшәү язган аңа куылып.

Син көтүдә икән, хәйләкәр бул –
Сөзешмәскә һәрчак җаен тап.
Уртада да тыныч булыр, димә,
Күпкә кулайрак алгы саф.

Син көтүдә икән, башкаларга
Гайрәтеңне өлгер күрсәтеп!
Сиңа тигән үз җәзасын табар –
Кичекмәстән яса кисәтү!

Син көтүдә икән, һич онытма –
Юаш булу монда – мескенлек.
Юаш шундук читкә этәрелә,
Тик көчлегә монда өстенлек.

...Көтү көтү инде. Күп чагында
Сәбәпче ул кадер бетүгә.
Үз көчеңә ышанасың икән –
Кирәк түгел, кермә көтүгә!

## Сөйгәнем бүләге

Чиккән кулъяулык – чәчәкләрнең дә
Иң матурлары кучкән йөрәктән.
Шатлану гына аздыр, аздыр ул
Күңелгә якын мондый бүләктән.

Чиккән кулъяулык – гомер аланы,
Кояшлы көндәй тоташ балкыштан.
Без түгел, гүя юллар ялгышкан,
Узмышлар юктыр, юктыр язмыштан.

Чиккән кулъяулык – синең истәлек,
Соңгы истәлек – мәңге сакларга.
Канатлы аттай калкып хыялдан
Алып китә ул егет чакларга.

Чиккән кулъяулык – яшьлек ядкаре,
Йөрәк түрендә аның урыны.
Тыңлап туймаслык моңга әйләнеп,
Ишеттерсен ул сиңа җырымны.

## Кирәк түгел

Кирәк түгел сине түбәнсеткән,
Тиң күрмәгән, сине кимсеткән.
Кирәк түгел кылтык, тәкәббер зат –
Үзен өстен итеп хис иткән.

Кирәк түгел тик үз җае өчен
Тыштан гына йөргән дус булып.
Кирәк түгел гайбәтеңне саткан,
Ачы теллеләргә кушылып.

Кирәк түгел, дуска саналып та,
Синең уңышлардан көнләшкән.
Кирәк түгел үзең юк чагында
Сине мыскыл итеп сөйләшкән.

Кирәк түгел ачу саклап йөргән,
Синең якка таба таш аткан.
Кирәк түгел, аңлашып та тормый
Ара өзгән – синнән баш тарткан.

Кирәк түгел, белештерми үзен,
Усал эттәй өскә сикергән.
Кирәк түгел мин-минлекле кеше –
Җанга борчу гына китергән.

## Өметем

Маяк итеп сине барыр юлымда,
Тормышның бар сынауларын мин үттем.
Ярты юлда туктап калмам, бирешмәм,
Җанда әле син булганда, өметем.

Туктатмадың, алга таба йөгерттең,
Тауларны да җиңел менәр үр иттең.
Тормышның юк яуламаслык үрләре
Күңелемдә син барында, өметем!

Тормышымда ышанычны арттырдың,
Күңелемнән шундук сине үз иттем.
Балкып тор син, күңелемнең кояшы,
Беркайчан да сүрелмәче, өметем!

Бер яклап та юк сынатыр исәбем,
Күңел белән әле егет кебек мин.
Син барында тау күчерер кебек мин,
Яшәүгә көч, дәрт өстисең, өметем!

## Кояшы бар күңел

Кояшы бар күңел өметле ул,
Караңгылык аны чолгамый.
Ваклыклардан өстен була белә,
Матур итеп күрә дөньяны.

Кояшы бар күңел сабырлыкны
Өлге итеп ала холкына.
Андый күңел яман уйны белми,
Яхшылыкка гына омтыла.

Кояшы бар күңел башкаларга
Үзе якты, җылы өләшә.
Аның алга куйган максаты да:
«Игелек, – ди, – кылып мең яшә!»

Кояшы бар күңел игелекне
Тиеш диеп эшли ул аны.
Кояшы бар күңел якты сирпеп,
Нурландырып яши дөньяны.

## Аңламыйммы әллә?

Бертуктаусыз дөнья үзгәрештә.
Аңламыйммы шуны әллә мин?
Киткәннәргә хәерле юл телим,
Көткәннәргә – кайнар сәламем!

Аңлаешсыз чуар дөньясында
Ак һәм кара бергә кушылган.
Гаҗәп, әмма кырыс чынбарлык шул –
Бүген дошман кичә дус булган.

Дөнья гына түгел, күңелдәге
Уйлар да шул тора үзгәреп.
Язмыш сынауларын кичкән чакта
Сабырлык бир, Раббым, түзәрлек!

Буталыплар беткән дөньясыдай
Уй очы да беткән чуалып.
Җанның тынычлыгын саклау мөһим –
Төшенелә шуңа соңарып.

Күңелдәге булган үзгәрешләр
Уйлар ташкынынннан башлана.
Түзәлмәслек авыр чакларда да
Ярдәмеңнән, Раббым, ташлама!

Уй-гамәлләр аша көйләнә шул
Яшәве дә Җирдә адәмнең.
Күңел матур булса – уйлар матур,
Аңламыйммы шуны әллә мин?!

## Ишет, кешем!

Ишет, кешем, намазга ул дәшә –
Илаһи моң – азан тавышы.
Ялган кыйммәтләрдән арынсын да
Бер Аллага бәндә табынсын!

Үз тәмугы өчен хәстәрләнә
Табынганнар акча-байлыкка.
Намаз укып, тәүбә кылып яши
Ышанганнар Алла барлыкка.

Илаһыга булган тугрылыкка
Бәндә кат-кат җирдә сынала.
Аңа тыңдәш күрмәү-эзләмәүдә
Ихлас иман, ихсан сорала.

Галәм падишаһы – Бөек Затка
Якыная бәндә дин аша.

Ерагая бәндә Илаһыдан
Йөрәгендә иман булмаса.

Ихлас җанлы, чын бәхетле кеше –
Үз бәхетен диннән табучы.
Ишет, кешем, намазга ул дәшә –
Илаһи моң – азан тавышы!

## Барыбыз да Алла бәндәләре

Барыбыз да – Алла бәндәләре –
Яшәү өчен Җиргә килгәнбез.
Галәм – гүя җил-давыллы диңгез,
Уртак – чайкалучы көймәбез.

Барыбыз да – Алла бәндәләре.
Иртә-соңмы җирдән китәрбез.
Нигә туганны да аңламыйча
Яшәүчеләр Җирдә күп лә без.

Барыбыз да – Алла бәндәләре –
Аның кодрәтеннән туганбыз.
Адәм белән Һава балалары –
Бер-беребезгә ерак туган без.

Барыбыз да – Алла бәндәләре,
Кунаклар без фани дөньяда.
Юкка түгел җирдә яшәвебез –
Иманыбыз кат-кат сынала.

Барыбыз да – Алла бәндәләре.
Түгел койрыклы, мөгезле.
Икегә бер атлам урын биреп
Куенына алыр җир безне.

## Кояш баешына таба юлым

Кояш баешына таба юлым,
Барган чагым артка карамый.
Һәр мизгеле гомер кимүенә –
Вакыт галиҗәнап аямый.

Ни калдырам, диеп уйлаган чак
Мизгелләрдән торган гомердә.
Үткәннәрен кайтарырлык түгел,
Тәкъдир язган ниләр күрергә?

Җыелалар гомер дисбесенә
Очып кына үткән бу көннәр.
Килә торсын! «Тормыш авыр!» – диеп
Елларымнан һич тә үкенмәм.

Кеше булып саналсам да үзем,
Тузан бөртеге тик галәмдә.
Көфер булыр сүзем, әйтә алмыйм
Гомер үтте диеп әрәмгә.

Җавап әзер күптән, сорасалар –
«Нидә бәхете?» дип адәмнең.
Чын бәхетем җирдә яшәвемдә,
Оныкларда күреп дәвамым.

Кайнап торган тормыш эчендә мин,
Сагышымны шатлык аралый.
Кояш баешына таба юлым,
Барган чагым артка карамый.



Рәис
Сафин

# ЯЗМЫШ СУКМАКЛАРЫ БУЙЛАП

ПОВЕСТЬ

## Кара болытлар куера

*Язмышлардан узмыш юктыр шул*

Баш очымда кара болытларның куерганын сизми дә калдым...

«Иртәгә сәгать унга судка килергә» диелгән чакыру кәгазе тоттырды миңа Киров районы милиция бүлегендә җинаять эшләре тикшерүчесе булып хезмәт иткән кече лейтенант Анастасия Фролова.

Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыгар, диләрме әле? Бик тырышканда бер гөнаһсыз кешенең дә гаебен табып була икән! Уйнап кына башланган эш уймак чыгарды да куйды. Уйламаган-көтмәгән җирдә килеп чыккан бу хәл мине өнсез калдырды, башка тимер таяк белән суккандай итте. Милиция бүлегеннән аңкы-миңке булып урамга чыктым һәм, кая барырга белмичә, аптырап калдым. Бераздан аяклар, ирексездән, Казанның Киров райкомына таба атлады. Баруын барам, ләкин нәрсә эшләргә кирәген белеп түгел. Күземә ак-кара күренми, акылым томан эчендә. Кем уйлаган диген? Хөкүмәтнең баштан ашкан планын үтәү уе, кешеләргә яхшылык эшләү нияте белән тотынган эшең өчен төрмәгә утыртырга җыенсыннар әле. Шул да буламы дөреслек?

Райкомның икенче секретаре Мачтаков Николай Васильевич мине берсүзсез кабул итте. Мәсьәләне бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Ул телефонын алып, милиция бүлегенә, аннары район суды рәисенә шалтыратты.

– Моңарчы нәрсә караган соң ул Сафин дигән бәндәгез? Әгәр алдан хәстәрен күргән булса, бу чүп безгә килеп тә җитмәгән булыр иде. Без дә мондый юк-бар эш белән баш катырып тормас идек. Ә хәзер нишләмәк кирәк? «Эш» теркәлгән, аны бер сәбәпсез кире алу һич мөмкин түгел.

Рәис САФИН (1935) – *шагыйрь һәм прозаик; «Йөрәк парчалары», «Бабайлар чуагы», «Көзге ажаган» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Тик суд карары нигезендә, кайбер мәсьәләләр тулысынча ачыкланмаган, төгәлсезлек бар, дигән сәбәпләрне күрсәтеп, тикшерүчегә кире кайтару мөмкин. Анда инде үзегез хәл итәрсез. Йә булмаса, район прокуроры «Эш»не бүген үк үзенә соратып алырга мөмкин, – дигән район суды рәисе.

Мачтаков елмаеп, урыныннан торды. Яныма килеп, кулын иңемә салды. «Борчылма, син бит үзебезнең кеше, берәр җаен табарбыз, – диде. – Һәрнәрсәнең башы һәм очы булган кебек чишелеше дә булырга тиеш. Һәм без аны табарга тырышырбыз. Ә хәзер, бернәрсә булмагандай, эшеңә бар. Хафалануыңны эт тә сизмәсен».

Әгәр берәр көтелмәгән хәл була калса дип, өй телефонын да бирде. Аның ихлас сүзләре эчемә бераз җылы йөгертеп, өмет чаткылары уятса да, мондый чакта борчылмый-хафаланмый калырга ничек мөмкин булсын, ди. Көнем томан эчендә, төнем мең төрле вәсвәсә-саташулар белән үтте. Җаным әрнеп сыкранды. Башымда очсыз-кырыйсыз чуалчык уйлар давылы уйнады. Нишләп болай, баш әйләндергеч хәл булып чыкты соң әле изге ният белән башланган бу эш? Кем уйлаган аның авыртмас башка тимер тарак буласын?! Бу инде чынлыкта: ит яхшылык, көт явызлык, дигән гыйбарәнең классик мисалы түгелме?

Хәер, аның нәкъ шулай булачагын ашханәнең тәҗрибәле җитештерү мөдире Наташа алдан ук чамалап: «Раис Абдуллович, борчылмагыз, үзебез ничек кирәк, шулай хәл итәрбез. Барысы да кирәгенчә булыр. Сезгә мондый хәтәр эшләрдән ерактарак булу хәерле», – диде бит югыйсә. Хәтта йөк төяүчеләр дә: «Сак булыгыз, безнең арада берәүләрнең йомышларын үтәп, акча эшләп йөрүчеләр дә булуы мөмкин. Каш ясыйм дип, күз чыгара күрмәгез», – дип кисәттеләр.

Бу дөньяда озын-озак гомер иткән әниемнең дә: «Алдыңны, артыңны карап йөр. Безнең нәсел – сәүдәгәрләр нәселе түгел. Без – мәгърифәтчеләр, китап әһелләре. Ә сәүдәгәр нәселе – үзенә бертөрле характердагы, акыл төзелешләре, фикер сөрешләре башкача булган затлар. Аларның холык-фигыльләре үзгә – сәүдәгәрләрчә булыр. Алар, теләсә-теләмәсәләр дә, сиңа елмаеп карый торганнардан. Һәр әйткән сүзләре ихластан кебек тоелса да, сәүдәгәрләрчә – барлык эшләрен үзләренең шәхси мәнфәгатьләрен күз алдында тотып, алдан ук керем-чыгымын исәп-хисапка алып эш иткән кешеләр. Ә сатучы кеше – шул ук, отышсыз эшкә керешмәгән сәүдәгәр ул. Менә син, балакаем, шулар белән эш итүче җитәкче буларак, һәр эшеңне башлаганчы, аның ни белән бетәсен уйлап тотын», – дип, киңәш-нәсихәт биреп торулары юкка булмаган икән.

Менә ул – башкаларның акыллы киңәшләренә, тормыш тәҗрибәләреннән чыгып әйткән эшлекле сүзләренә колак салмауның ачы җимеше. Юкса, башында мыскал кадәр акылы булган кеше күрә торып, заман таләбенә яраклашкан кануннарны бозар идеме? Үзенә карата һәрчак этлек эшләргә ашкынып, ялгышлык эшләвеңне эзләп, шуны түземсезлек белән көтеп торган бәндәләр бар икәнлеген белә торып, хата эшләгән кешене кем дияргә? Ашханә мөдире: «Сезгә мондый хәтәр эшләрдән ерактарак тору хәерлерәк булыр», – дип, юкка гына әйтмәгәндер. Димәк, бу хәерсез эшнең күңелсез хәлләргә китерү ихтималын мөдир дә, йөк төяүчеләр дә сизенгән.

Мондый очракларның борчулы мәшәкатен үз башлары аша кичергәннәр, күрәсең. Шуңа күрә минем шикелле үзбелдекле кешене бу шикле-шөбһәле эштән тыеп калмак булганнардыр. Ә мин – беркатлы бәндә, аларның изге теләкләрен аңламаганмын. Югыйсә берәүләрне куркытып, берәүләрне сатып алып, булмаган хәлләрне, эшләнмәгән эшләрне бар итеп, бер мәртәбә төп башына утырттылар бит инде үземне. Аңлаган кешегә гыйбрәт алырлык, дөрес нәтиҗә ясарлык иде кебек...

Ләкин башында аек аң-акылы, фикерләү сәләте булган затларны да, шул заманның котылгысыз тормыш шартлары, яшәешнең тискәре якларын чагылдырган, гамәлгә яраксыз, ләкин үтәргә тиеш булган кануннар да, хата-ялгышлар эшләүгә этәргеч булдылар шул. Хәтта җәмгыять файдасына җиң сызганып, ихластан намуслы хезмәт иткәннәрдән дә, ихтыярсыздан, шушы алдавыч капкынга эләгүчеләр аз булмады түгел.

Уң кулның нәрсә эшләгәнен сул кул белмәгән кебек, ил тормышындагы дистәләгән карарлар, күрсәтмәләр, әлеге дә баягы кануннар күпмедер дәрәҗәдә илдә барган алгарышны, тормыш таләп иткән яңарышларны тоткарласалар да, бу турыда җитәкче даирәләр хәбәрдар булсалар да, социализмның нигез ташларына әйләнгән юридик актлар яшәештә кала бирде. Киров район суды рәисе әйтмешли: чүп «Эш»ләр аркасында күпме кеше җинаятьчегә әверелеп, хаксызга төрмәләрдә, ГУЛАГ баракларында иза чигеп, коега төшкәндәй юкка чыкты.

Шул исәптән, мин үзем дә, акылсызлык корбаны булып, кайсыдыр төрмә камерасының «хуҗа»сына әверелеп китмәмме? Үземә карата әвәләнгән чүп «эш»кә һаман да нокта куярга ирек бирми контрольдә тоткан, аны хокук саклау органнарына әледән-әле искәртеп, бер бәндәнең мәкерле уй-планнары баш очымда Дамокл кылычыдай эленеп тора... Моның шулай икәнен, чүп «эш»не тикшерүче хезмәткәрнең онытылып беткән чакта, янә теге кемсәнең таләбен үтәп булса кирәк, мине милиция бүлегенә чакыртып, инде күптән ачыкланып беткән сорауларга кайта-кайта җавап алып, аларны чиста кәгазь битләренә язып-теркәп куюы дәлилли иде. Һәм әлеге билгесез әләкченең каядыр югары урында утыручыларның берсе икәнлеген дә абайларга мөмкин иде.

Баш очымда кара болытлар һаман куерды, күкләрне иңгә-буйга ярып очкан карчыгалар корбан эзләде...

## Кияүсез туй

*Чир китәр – гадәт китмәс...*
Халык мәкале

1969 елның 3 маенда – бәйрәм кичәсендә без гаиләбез белән циркка барып, тамаша кылмак булдык. Хәтеремдә: берничә минутка соңга калып, ашыга-ашыга, фойе аша узып барышлый, каршыбызга данлыклы цирк һәм кино артисты Юрий Никулин очрап, юлыбызны бүлде. Ул өч яшьлек Ирек улыбызны кочагына алып: «Без сезне көттек-көттек тә тамашаны башларга булдык. Син инде безгә үпкәләмә, яме», – дип шаяртып та алды әле.

Урыннарыбыз тамаша залындагы кыйгач-кыйгач менгән рәтләрнең иң соңгысында булгангамы, әллә залдагы бөркүлектәнме, тыным кысыла,

йөрәгем читлегеннән чыгардай булып тибә башлады. Шабыр тиргә батып, көч-хәл белән атлаганга, мине хатыным Самия цирк табибы бүлмәсенә озатып куйды. «Инфаркт миокарда» дигән куркыныч чир мине сырхауханә ятагына сузып салды. Ә бит әле миңа нибары 34 яшь!

Палата табибы Наил Салихов үз туганыдай күреп, бар мөмкинлекләрдән тиешенчә файдаланып, булган даруларның минем организмга яраклыларын сайлап, шифалы зәм-зәм суы кебек тылсымлы сүзләр әйтеп дәвалады. «Яхшы сүз – җан азыгы, яман сүз – баш казыгы», дип, юкка гына әйтмиләрдер шул. Мин аңа гомерем буе рәхмәт укыйм. Бар бит ул дөньяда изгелек кылучы игелекле затлар!

Инде хәйран сихәтләнеп, сырхауханәдән чыгар алдыннан Наил Салихов хатыным Самия белән икебезне үз бүлмәсенә чакырды. Ягымлы йомшак тавышы белән хәл-әхвәлләребезне сорашканнан соң:

– Дөресен әйтим, хәтәр чир белән авырыйсың син, Рәис энем, – дип, сүз башлады ул. – Ләкин бу әле, кулларны өскә күтәреп, өметсезлеккә бирелү дигән сүз түгел. Тәнеңдә җаның, күңелеңдә омтылышлы теләк, атлыгып торган ихтыяр көче булганда, «мин әле яшәргә тиеш» дип, көнкүрештәге кайбер кызыктыргыч әйберләрдән тыелып, табиб күрсәтмәләрен тайпылышсыз үтәгән очракта күкрәк киереп үк булмаса да, тыйнак тормыш үрнәгендә озак яшәргә мөмкин. Бу – табиб сүзе! – Аннары тагын да мул итеп киңәшләр бирүен дәвам итте: – Курыкмагыз. Бер ияләшкәч, бер дә кыен түгел ул. Тагы да өстәп, шуны әйтәсем килә: көн саен иртән ашыкмыйча гына, берәр сәгать җәяү йөрүне дә гадәткә кертү бик файдалы булыр. «Хәрәкәттә – бәрәкәт» дип, бик белеп әйтә безнең зирәк халкыбыз. Бу шөгыльләр йөрәк мускулларын ныгытырга, миокардны савыктыруга ярдәм итәчәк. Әлбәттә, боларның барысы да саф һава сулап, челтерәп аккан чишмәләрнең көмешкә бай суларын эчеп, тыныч тормыш шартларында хафаланмый гына, берничә ел авыл җирендә яшәп алу, һичшиксез, сәламәтлекне элеккеге хәленә кайтару өчен дәваларның иң үтемлесе, алыштыргысызы булыр иде.

– Наил абый, белеп сөйлисезме сез бу сүзләрне? Анда безне беркем дә колач җәеп көтеп тормый, – дип кабынып китте хатыным. – Хәтта, көтеп торган исәптә дә, гомерләре буе колхозда «таяк»ка эшләүче авыл халкы бездән бот чабып көләчәк. Анда кайтып, без кем булып эшләргә тиеш, ди?

– Мин авылга кайтыгыз, димәдем. Авыл җиренә, дидем. Алар бер үк җирлектә булсалар да, икесе ике рәвештә тормыш итүче берәмлекләр. Анда халыкка һәртөрле хезмәт күрсәтүче оешмалар, предприятиеләр эшли. Һәркем үзе булдыра алган эшне шул оешмаларның берсенә урнашып эшли ала. Анда да шул ук хастаханә, табиблар, шәфкать туташлары һәм дарулар. Менә шуларны күз уңында тотып әйтүем. Мин кайтыгыз димим, уйлап карауны тәкъдим итәм.

– Безнең өчен борчылып әйткән сүзләрегез өчен зур рәхмәт. Сез әйткән авыл җирендәге тормышны мин яхшы беләм. Үзем – кичәге авыл кызы. Андагы тормышның авырлыкларын мин үз җилкәмдә татыдым. Шуңа күрә кабат ул тормышка кайтырга һич риза түгел. Үзегез уйлап карагыз. Андагы мөмкинлекләр белән шәһәр мөмкинлекләре – җир белән күк арасы. Авыл

кешесе игенне үзе үстерсә дә, ипине шәһәрдән ташый бит. Тегесе, монысы кирәк саен юк акчасын бар итеп, шәһәр кибетенә барырга кирәк. Әйтик, шул ук кирәкле даруларны да шәһәр аптекаларында гына табып була.

Табибның җавабы кызыклы иде:

– Анысы шулай инде, Аллага шөкер, ач-ялангач булмасак та, кыенлыклар баштан ашкан. Халыкны мохтаҗлык баскан. Әле дә түзгән халкыбызга рәхмәт. Син әйткәнчә, авыл җирендә тормыш итүләре икеләтә авыр. Ләкин ул тормышның да, шәһәр белән чагыштырганда, уңай яклары аз түгел. Шул ук шомырт, чия, алма агачларының искиткеч хуш исләре белән тылсымланган саф һавасы – син әйткән җир белән күк арасы. Ә сихри моңнар көйләп аккан көмеш сулы чишмәләре, аллы-гөлле чәчәкләрен балкытып торган ямьле болыннары, тугайлары! Яфракларын инеш суларында чайкаган бөдрә таллар – боларның барысы да, безнең яшьлегебезнең онытылмас истәлекләре булып, авыл җиренең исебездән чыкмас алыштыргысыз хәзинәләре ләбаса. Анда көне-төне зыянлы исләр чыгарып утырган завод-фабрикалар, туктаусыз үкереп-кычкырып торган машиналар, поездлар юк. Бар җирдә матурлык, бар җирдә сөйкемле тынлык, гармония. Бар дөнья үзенең табигый халәтендә яши.

– Боларның барысы да шулай. Бер ияләнгәч, шәһәрнең шау-шуына, ыгы-зыгысына да түзеп була. Тик акчасыз торып булмый. Авылда да шулай. Ә шәһәрдә бигрәк тә. Ни әйтсәң дә, шул агулы исләр чыгарып утырган завод ирем Рәискә бүген уртача эш хакының 80 процент «больничныен» түли. Авыл җирендә кем аңа бу акчаны бирер иде икән? Ә безнең яшисе килә. Балаларны ашатып-эчертеп, тәрбияләп үстерәсе бар. Бу авыру ирне дә карыйсы бар. Даруы кирәк. Тегесе-монысы кирәк. Барысына акча кирәк. Аның бит башы авырудан чыкканы юк. Әле экзема, әле баш авыруы. Шуңа күрә ирлеге дә ташка үлчим генә. Менә шундый хәлләр әле бездә. Нишләргә дә белгән юк. Баш каткан, – диде хатыным Самия, җиде юл чатында калган кеше сыман уфтанып...

Әйе, хатыным Самия әйткән башымның авыру сәбәбе бала чагыма тоташкан. Аллаһы Тәгалә үзенең сөекле бәндәсен һәр төрле сырхаулар биреп сынар икән. Мин дә бала чагымнан ук шундый авыр сынауларга дучар ителгәнмен.

Дүрт яшемдә чакта башыма почтальон Галимҗан абыйның безнең өйдән ерак түгел генә булган тимерчелектә яңа гына дагалатып алган аты типкән. Ул аны капка баганасына бәйләп, үзе тирә-яктагы өй хуҗаларына почта таратырга киткән була. Ә без югары очтагы Әмир исемле телсез малай белән балта остасы әтием ясап биргән кечкенә чанага чиратлашып утырып, бер-беребезне тартып уйнап йөргәнбез.

Ул көнне һава тын һәм аяз була. Моннан ике көн элек кенә күз ачкысыз бураннар котырып, кар көртләре юлларны каплап киткән. Минем кайнар каным кояш нурларында энҗе-мәрҗәннәр кебек җемелдәп торган ап-ак кар бөртекләрен алсу төскә манган.

Әнием сөйләвенчә, элек мине Әмир тартып йөргән. Аннан соң мин аны тартып йөрергә тиеш булганмын. Әмир миннән ике яшькә олырак һәм олы гәүдәле дә булганга, минем көчем җитмәгән булса кирәк, мин чана бавын ат койрыгына бәйләп куймакчы булганмын. Тик ат минем

бу «акыллы» гамәлемне өнәп бетермәгән. «Мине юк-бар мәшәкатьләр белән борчып йөрмә әле», дигән кебек яңа дагалы аягы белән башыма тибеп җибәргән.

Баштанаяк канга батып яткан, ярымүле гәүдәмне күршебез Әминә апа күтәреп, өебезгә алып кергән. Көтелмәгән бу фаҗигане күргән әнием һуштан язып егылган. Авыруга сабышкан. Абыйларым өнсез калган. Ул арада, сүз иярә сүз чыкканда, ирләрчә горурлык белән телгә алырга яраткан сөекле улының һәлакәтле хәлгә тарыганлыгын ишеткән әтием дә бөтен эшен ташлап, әлсерәп өйгә кайтып кергән. Кан эчендә яткан гәүдәмне кочып, үкси-үкси елаган. Кайнар күз яшьләре канлы битемне юып аккан. Ул мине бөтен балаларына караганда да үтә яратып, миңа өмет баглаган булган. Соңгы елларда кызамык чиреннән бер-бер артлы үлеп барган балалардан соң туган тансык бала да бит әле мин.

Үзәк өзгеч бу шомлы хәбәр бөтен авылга таралып, өй эче халык белән тулган. Мине кызганудан елау, шыңшу башланган. «Акыллы бала» дип аталган кечкенә Рәиснең – минем бу хәлдә калуымны авылыбыз халкы да ачынып кичергән. Мине үләр дип уйлаганнар. Гомере булып, исән калса да, акылы зәгыйфь булыр, зур эшләр майтара алмас дип, фараз кылганнар.

Озак та көттерми, Фәрит абыем чакырырга барган, авыл халкы «ат духторы» дип атап йөрткән һәм чынлыкта колхозның корчаңгы атларын, зәһәр исе тамакларны ярып керә торган ниндидер сасы майлар сөртеп, саргылт сыекча сиптереп дәвалаучы Шәйхулла исемле авылдашыбыз, булган барлык даруларын букчасына төяп килеп тә җитә. Алар әтием белән кулларын юып, битемдәге һәм башка җирләремдәге укмашкан кан төерләреннән арындырып, дуңгызның эретелгән эчке маена стрептоцид порошогы кушып ясалган мазь белән, ат тоягы умырып төшергән һәм ертылган кәгазь кисәге кебек муеныма кайтарылып төшкән бит тиремне саклык белән урынына җәеп, ачык калган авыз куышын һәм ялтырап торган сөт тешләрен кеше күзеннән яшергәннәр.

Әтием һәркөн, бисмилласын әйтеп, яраларымны төзәтү гамәлләрен оста хирург дәрәҗәсендә, зур осталык һәм төгәллек белән, камил итеп башкарган. Битемдә бернинди дә яра эзләре калмаган. Күз төбемдә бары тик ике җөй сузылган: берсе – әтием истәлеге, икенчесе – теге атның дага эзләре. Алар икесе дә шул аяныч фаҗиганең ядкарьләре булып, сул битемдә саклана.

Мине савыктыруда Шәйхулла абыйның хезмәте зур булган. Ул һәрчак өебезгә керә-чыга, хәлемне белешеп йөргән. Файдалы киңәшләре һәм кирәкле дарулар белән дә ярдәм иткән. Аңа бик рәхмәтлемен.

Кырык көн аңсыз рәвештә, мәрткә китеп ятканмын. Кырык көн буе авыл зиратында казылган каберем үзенең хуҗасын көткән. Кырык көн буе чатырдатып кысылган тешләремне, кашык сабы белән каерып ачып, баллы су һәм сыек тавык шулпасы эчерткәннәр. Кырык көн буе әтием янымда булып, җан җылысын өреп, ярымүле гәүдәмне назлы ата мәхәббәтенә төргән. Көне-төне дога кылып, исән калуымны Аллаһыдан ялварып сораган. Кырык көннән соң, ниһаять, аңыма килгәнмен. «Теге дөнья»дан кайтып, күзләремне ачканмын. Икенче кат туганмын. Кояшның шифалы нурлары балкыган бу якты дөньяны кабат күргәнмен.

Шуңадыр: могҗизалы бу серле дөньяның никадәрле кадерле икәнен белеп, күңелләргә хуш килгән, җаннарны назлап иркәләгән искиткеч гүзәллеген күреп, ничәмә-ничә үлемнәрдән исән кала-кала, инфаркт, инсульт кичереп, Аллаһының рәхмәт-шәфкате белән, бүген дә шөкерана кылып, шыпырт кына яшәп торам.

Берәү дә мине тере калыр дип уйламаган. «Вафаты хәерлерәк булыр иде», диючеләр дә аз булмаган. «Тере калса да, үз акылында яшәүче чын кеше була алмас», диючеләр дә булган. Әтием исә: «Көтүче-мазар булса да, шушы якты дөньяда исән-сау гына яшәсен иде», – дигән. Һәм мин әтиемнең өметен намуслы хезмәтем белән тулысынча акларга тырыштым. Тугыз яшемнән авылдашларымның бозауларын, казларын көттем. Гомерем буе кеше көтүчесе булып хезмәт иттем.

Бүгенгедәй хәтеремдә: җәй көннәренең тын иртәләрендә, җылы юрган астында, балалыкның татлы йокысы кочагында рәхәтләнеп йоклар чагымда мин, 9-10 яшьлек малай, кырык ямау салынган ыштанымны киеп, иртүк Хәсәннәр тыкрыгына көтү җыярга барам. Кояш әле офыктан бер киртә күтәрелеп, җылы нурларының Рәхимҗан абыйларның өйләре кыегыннан кыяр-кыймас елмаеп, каз үләннәренә кунган ялтыравыклы чык бөртекләрен җемелдәтеп шаярган чаклары була. Мин шул иртәнге чык төшкән салкынча үләннәрне «чебиләнеп» кутырланган яланаякларым белән ерып, йокылы-уяулы хәлдә, төш күргәндәге кебек барам. Чык тамчылары бармак араларындагы яраларга кереп чеметтерә. Кутырлар йомшарып, аякларым җәелеп киткәндәй була. Мин дә йокыдан айный башлыйм. Акрын-акрын авыл халкы да торып чыга. Әнә берәүләрнең сыерын саварга әзерләп куйган чиләге мәтәлеп төште кебек. Ә берәүләр савыт-саба шалтыратып алды. Тын һавага, тамакларны кытыклап, яңа сауган, өсләре парланып, күбекләнеп торган ләззәтле сөт исе тарала. Ул исә – сыер, кәҗәләрнең тугай-болыннардагы бернинди агулы матдәләр сибеп агуланмаган үләннәр ашап, көмештәй чиста чишмә сулары эчеп җыйган, газаплы сугыш елларында һәм аннан соң да ач үлемгә дучар ителгән меңләгән кешеләрнең гомерен саклап калган могҗизалы тереклек сөте иде. Ул сөт – яңа бәрәңге әле өлгермәгән ачлык көннәрендә, безнең һәм безнең ишләрнең, кычыткан һәм башка файдалы үләннәр салып пешерелгән ашы, төп ризыгы булды.

Әнә шул сыер, кәҗә, сарыкларның, көтү булып, авыл урамнарын иңләп чыгып баруларын күрү – үзенә бер хозурлык, шатлыклы тамаша. Чөнки аларның һәрберсе авылдашларымның бердәнбер ышанычлы яшәү чыганаклары булган бәхет-шатлыклары, кайгы-хәсрәтләре дә иде. Көтүчеләргә шушы мал хуҗаларының тирән өмет баглаган терлекләрен күз каралары шикелле итеп саклау бурычы йөкләнгән. Шушындый ук бурыч, бозау көтүне, килешү төзеп, үз җаваплылыкларына алган кадерле әниемнең һәм күршебез Фәгыйлә апаның намус эше иде. Ә без, Фәгыйлә апаның миннән өч яшькә өлкән улы Кәрим белән икәү, бозаулар артыннан йөгереп йөрүчеләр генә идек.

Ниһаять, бозауларны муенчакка тагып, берәм-берәм китерә торгач, безнең көтү дә тулыланып, чишмә елгасы тарафына юл алды.

Гадәттә, бозауларны көтүгә яшьтәшләрем китерә. Алар минем белән сүз

катмаска тырыша. Ә инде этиләре өйләрендә булганнарның кайберләре үзләрен өстен куеп, мине салкын битарафлык белән читләтеп уза иделәр. Бу ваемсызлыкларга хәтерем калмаса да, аларның өйләренә кайтып, ашап-эчеп, җылы, йомшак урынга ятып йоклый алулары бик тә көнләштерә, үчекли иде. Аларга кызыгып калам. Минем дә өйгә кайтып, бала булып, туйганчы йоклыйсым килә иде.

Дөрес, иртәнге эш-мәшәкатьләрен беркадәр җайга салгач, көтүгә әниләребез дә килә. Бу вакытта инде төш вакыты җитеп, бозаулар да ял итәргә яткан була. Мин дә әниемнең алдына башымны куеп, тирән йокыга талам. Ә инде Аллаһының рәхмәте белән авылыбыз күгенә болытлар куерып кунакласа, көне буе яуган яңгырларның сихри шыбырдавын тыңлап, печәнлектәге йомшак печән өстендә аның күңелләрне иркәләп, җаннарны сөеп назлаган искиткеч хуш исләреннән ләззәт алып, рәхәтлек кичереп яту – әкияти хозурлыкка тиң иде. Сирәк тәтегән андый көннәрдә мин ашау-эчүдән калып йоклыйм. Мин аңа үтә мохтаҗ идем. Ул миңа тансык. Сырхау башым тынлыкка чумып, рәхәтлек кичерә. Ул әле һаман да үзенең сырхау икәнлеген белдереп, кисәтеп тора иде. Һәм мондый искә төшереп торулар әле дә дәвам итә.

Бернәрсә дә эзсез генә үтми шул. Ат тоягы мине күп нәрсәләрдән мәхрүм итте. Мин үткәнемне оныткан, хәтерсез кеше булып калдым. Баш мием бөтен үткәнемне миннән яшереп тотты.

Әйе, тормыш тылсымлы могҗиза диеп соклансак та, ул гаҗәеп кырыс могҗиза да икән шул. Кешеләрне утка-суга салып, кайгы-хәсрәтләр, бәхет-шатлыклар күрсәтеп тә сыный.

Шундый сынауларның бик ачысы, кайгы-хәсрәтлесе, 1962 елның 1 Май бәйрәменә каршы көнгә билгеләнеп, кунаклар чакырылган туебызны да бергәләшеп, туганнар белән җырлый-бии шатланып, эти-әниләребезнең хәер-фатихаларын алып үткәрергә ирек бирмәде.

Атна-ун көн элек бер бетчәнең өздереп кычытып китүеннән башланып, кычытуларыннан шашар хәлгә китереп, бәгырьләргә үтеп керә торган, адәм балаларын күзле бүкән сыман итеп калдыра торган экзема чире мине баштанаяк каплап алды. Хисапсыз бетчәләрдән саркып чыккан сыекчалар, шешенеп киткән тәнемне суга манчыды. Йөри алмагач, җәймәгә төренгән хәлдә, юеш тәнемнең чымырдап туңуыннан дер-дер калтырап, урын өстендә ятарга мәҗбүрмен. Әнием белән хатыным бертуктаусыз елый-ыңгыраша. Әле өстәл янында, әле мич буенда йөреп, туй кунаклары өчен бәлешләр һәм башка төрле таба ашлары хәстәрли. Әниемнең хәле бигрәк тә авыр. Гомере буе йөрәк чире белән интеккән, яраткан ирен, сөекле улын сугышта югалткан ил анасы, бу аяныч хәлне күргәннән ава-түнә йөри торгач, аңын җуеп, урын өстенә ауды. Ул арада, төн уртасы булуына карамастан, ян-як күршеләребез дә хәл белергә кереп җитте. Киров районының Җиләк бистәсендә (Ягодная слобода) үз йортлары белән торучылар, тирә-як күршеләрен генә түгел, ә бәлки башка урамнарда гомер итүчеләрне дә белеп, бер-берләрен хөрмәт итеп яшәде. Көтелмәгән бу хәлдән нишләргә белмәгән күршеләребез дә башларын иеп, аптырашта калган. Нишләргә? Туйны үткәрергәме, юкмы? Әнә шундый сораулар һәммәбезнең күңелен чорнап алган иде.

Ниһаять, әнием аңына килде. Су сорап алды һәм: «Авырмый торган кеше юк. Безнеке дә, иншалла, терелер. Барысы да Аллаһы Тәгаләнең ихтыярында. Ул безгә шушы авыр сынавын үтәргә язган икән, без шуңа риза булып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәт-шәфкатьләренә ирешүне сорап, туйны әйбәт кенә итеп үткәрергә тиеш. «Ашыгыч ярдәм» машинасын чакырып, Рәис улымны хастаханәгә озатыйк. Бу кызганыч хәлдә кунакларның аны күрмәүләре хәерле булыр», – диде кадерле әнием, өзек-өзек җөмләләр әйтеп.

Зур Кызыл урамындагы тире авырулары хастаханәсенең 35-40 яшьләрдәге дежур табибы һәм шәфкать туташлары аяк-кулларымны, тәнемнең җәрәхәтле урыннарын марля белән бәйләп, киптерә торган хлорлы махсус эретмә белән чылаттылар. Дүрт сәгать саен кадалган өч төрле уколның шифалы тәэсире тәнем кычытуларын баса төште, үземне тынычландырып җибәрде. Хәтта черем итеп тә алдым. Төшке ашны да капкаладым.

Иртәдән алып, Ирек мәйданы аша үткән (1 Май бәйрәме бит) демонстрациядә катнашучыларның музыкалы шау-шулары тына төшкәч, җир-әнкәне ягымлы җылы нурлары белән назлап иркәләгән май кояшы зәңгәр офык кочагына якынлашып килгән бер мәлдә, авыруларны гаҗәпкә калдырып, хастаханә ишегалдына гармуннар уйнатып, җырлап-биеп, бер төркем бәйрәмчә киенгән халык кереп тулды! Көтелмәгән бу тамашадан аптырап калган авырулар, хәтта урын өстендә ятучылары да дәррәү килеп, тәрәзәләргә капланды. Өздереп уйнаган тальян гармунның сихри моңнары аякларында йөргәннәрне генә түгел, таяклыларны да урамга тартып чыгарды. Гармунчы бию көйләрен уйный башлауга, кешеләр түгәрәк ясап, берәүләп тә, күмәкләшеп тә тыпырдатып биергә кереште. Түгәрәк зурайганнан-зурайды, җыр-бию кызганнан-кыза барды. Очына-очына дәртләнеп биючеләр аяк асларыннан ут чыгарды. Бии алмаганнары такмаклар әйтеп, куллар чабып, дәртләндереп торды. Барысы да рәхәтләнеп күңел ачты, кешеләрне шатландыру хәйран озак дәвам итте.

Тәрәзә янында басып, шушы тамашаны марляга уралган мескен хәлдә күзәттем. Күңелләрем тулып китте. Тамырларым буйлап әле башымны әйләндергеч кайнарлык, әле тәннәремне чымырдатып, салкынлык йөгереп үтте. Бугазыма тыгылган төер күз яшьләрем булып акты. Кем уйлаган: гомер эчендә бер була торган яшьлегем туен, мәхәббәтемнең ихлас тантанасын хастаханә палатасында тәрәзә аша ялгызым күзәтермен дип. Әй язмыш, язмыш!..

Шушындый хәсрәтле уйлардан араларга теләп, ике ир кеше култыклап, мине урамга алып чыкты. Ә монда җыр-бию, шаяру-көлешүләр һаман да дәвам итә иде. Йөрәкләрне җилкендергән бию көйләренең дәртеннән, урыннарында тыныч кына басып тора алмаганнар, кысташа-кысташа, түгәрәк уртасында бөтерчек булып әйләнде. Авыру икәнлекләрен дә онытты. Мине шундук бердәнбер кадерле Рәисә сеңлем күреп, очынып килеп: «Абыем, җаныем, хәлең ничек? Сине аяк өстендә күрүемә бик шатмын. Мин сине бик яратам, яныңа көн саен килеп йөриячәкмен. Ә син тизрәк савыгып чыгарга тырыш», – дип кочып алды. Аңа туй кунаклары һәм башкалар да кушылганлыктан, мин чолганышта калдым. Барысы да хәл-әхвәлемне сораша, туем белән котлап, тизрәк сәламәтләнеп чыгуымны

тели. Арттарак басып торган, инде туемда булып, туганлашкан кодагый-кодачалар елашып та алды. Берәүләре килеп, шикләнеп кенә булса да, бинтка чолганган бармакларымны капшап карады. Нәҗип һәм Рәшит абыйларым гармун уйнаудан туктап: «Энекәш, бирешмә. Без – данлыклы гармунчы Габдулла малайлары. Күңелеңне төшермә, башыңны югары тот. Җырлардагы кебек, «Кызганыч көннәргә калган бу бала димәсеннәр», дип, кулларымны кысты. Әби белән бабай да сүзсез калмады: «Дөнья булгач, төрле хәлләр була, борчылма. Хәере белән уза торган чир булсын. Киләчәктә күркәм тормыш корып, тату яшәргә, игелекле балалар тәрбияләп үстерергә насыйп итсен», – дип, хәер-фатихаларын бирде.

– Кияү, син безгә ошадың, үзебезнең кеше икәнсең, – диделәр.

Әмма янәшәмдә басып торган хатыным гына ни актан, ни карадан бер сүз әйтмәде. Балтасы суга төшеп югалган кешедәй, башын иеп, әрнүле тирән уйларда йөзә иде, ахрысы.

Әйе, мин аны яхшы аңлыйм. Укытучы, инженер булып эшләгән егетләр ялынып йөреп тә, аларны читтә калдырып, миңа кияүгә чыккан чибәр кызның ире, бер ай үтәр-үтмәстә авырып китте, минем бүгенгедәй кызганыч хәлдә ятуым хатынымны гарьләндерә булса кирәк. Оттырдым, дип үкенәдер. Туган-тумачалар, дус-ишләр алдында хурлыкка калдым дип, җаны сыкрана, үзәге өзгәләнәдер. Көндәшләренең гайбәт сатачакларын күз алларына китереп уйланадыр. Ә бәлкем...

Ләкин рәхимсез рәвештә аяктан егып салган бу шәфкатьсез сырхауны мин дә бит сорап алмадым. Аңа хәрби бурычымны үтәгәндә мәҗбүри рәвештә юлыктым.

Әйе, халыкларны кызыктырып, серлелеге белән күңелләрне үзенә тартып торган, дастаннарда макталып, җырларда җырланган биек Памир тау-кыяларындагы, СССР дигән социалистик дәүләтнең чик буйларын уратып алган заставаларның «Башгөмбәз» дигәнендә чик сакчысы булып хезмәт иткәндә ияртtек без гомерлек авыру-чирләрне. Берәүләрнең чәчләре коелды, тешләре төште, ә берәүләр йөрәк-кан авыруына дучар булды...

Мин хезмәт иткән «Башгөмбәз» дигән застава диңгез өсте тигезлегеннән 5200 метр биеклектә булып, кыш көннәрендә анда салкыннар илледән дә артып китә иде. Без, чик сакчылары, атларыбызга атланып, төнге дозорга – 8-10 сәгатькә (бәйрәмнәрдә 12 сәгатькә) чик буен сакларга китәбез. Бөтен дөньяны үлем тынлыгындагы дөм караңгылык каплаган. Атларыбыз таныш сукмаклардан абына-сөртенә алга атлый. Атлар һәм без – баштанаяк коралланган ике чик сакчысы, арабызны 5-6 метр калдырып, колакларыбызны торгызып, тирә-якны тыңлыйбыз. Безнең ышанычлы юлдашларыбыз – аяз күктә, күз кыскандай җемелдәгән йолдызлар гына.

Билгеләнгән урынга килеп җитүгә, атларыбызны ташлар ышыгына яшереп, үзебез туңып үлмәс өчен чиратлашып, бер өемнән икенчесенә таш ташып җылынабыз. Бер урында гына басып торган малкайлар кызганыч. Өшегәндер, туңгандыр алар. Үз хәлләрен үзләре генә белгәндер. Кайтыр юлга чыккач, дәртләнеп, башларын айкый-чайкый атлый иде алар. Салкында иреннәремне кыймылдатырга да куркам. Алар чатнап китәр кебек тоела

иде. Шушындый салкын төннәрне нарядта уздырган солдатлар, ашханәбез өстәле өстендә һәрвакыт була торган ит, май һәм башка төр ризыкларга да исебез китмичә, тик куертылган сөтне болгатып, чәй эчәбез дә тизрәк җылынып йоклау ягын карый идек.

Яхшы хуҗа этен дә куып чыгармаслык гыйнвар салкыннарының берсендә, нарядтан өшеп кайткач, мине каты авыру егып салды. Температурам куркыныч дәрәҗәгә менеп җиткән. Озак кына аңымны җуеп торганмын. Ә беркөнне, төкерек һавада чакта ук бозга әверелгән салкында, яланаяк, яланбаш хәлдә саташып, урамга чыгып киткәнмен. Застава начальнигы өлкән лейтенант Пётр Шилов солдатларга мине саклап, күз-колак булырга кушкан. Заставада бердәнбер хатын-кыз булган хатынына, булган даруларны биреп, хәлемне белеп торуны йөкләгән. Мине үләр дип курыкканнар. Шулай авыр хәлдә калып, урын өстендә бер айга якын ятканмын. Аякларым нечкәреп калган, гәүдәмне дә тота алмаслык хәлгә килгән. Ничекләр генә түзгәнмендер?..

Әйе, бернәрсә дә юктан бар булмый, бардан юк булмый, ди философлар. Барысының да үз сәбәбе, үз язмышы бар. Һәм аларның берсе дә эзсез генә үтми икән шул. Тәнемне каплап алган юеш экземаның да килеп чыгышы, әлеге дә баягы, Памир тауларының тешкә теш тидерми торган салкыннарының аянычлы нәтиҗәсе икәне ачык инде. Бигрәк тә безгә, кышлакларда яшәп, тау шартларына ияләшмәгән, тәннәребез мондагы кебек салкыннарга күнекмәгән, шул кырыс һава шартларын, безнең ише черек бәрәңге ашап, кычыткан шулпасы чөмереп үскән бичара сугыш чоры балаларына кичерү бик авыр, русча әйткәндә, «не по зубам» булды шул. Памир таулары үзләренең борчулы күчтәнәчләрен гомеребезгә җитәрлек итеп, җан-тәннәребезгә салып калдырган икән. Ул бүләк-күчтәнәчләр хәзер дә, бетчәләр булып, тәнемне борчып тора. Аларның үзәкләрне өзәрдәй булып кычытуларыннан нишләргә белмисең. Ялгыш кына кулың кагылып китсә, бөтен тәнеңне кычыту чолгап ала. Шашар хәлгә киләсең.

...Ә минем ишегалдындагы туем тормышымның кайгы-хәсрәтләрен, борчу-мәшәкатьләрен вакытлыча оныттырып, кунакларны җырлатып-биетеп, авыруларның күңелләрен күтәреп, очынулы рәвештә дәвам итте.

– Нәҗип кода, – диде янәшәмдә басып, минем белән сөйләшеп торган абыема урта буйлы, какча гәүдәле Насыйбулла баҗам, сөйкемле елмаеп. – Киявнең без – кунакларны шатландырып, җырлашып-биешеп, туй хуҗасы булып утыра алмавы – күңелләребезне әрнетеп, йөрәкләребезне сыкратты. Аллаһы Тәгалә аның үзенә күркәм сабырлык биреп, тиз көннәрдә савыгырга язсын. Син, Нәҗип кода, без – кунакларны чын күңелдән ихтирам итеп, уен-көлке белән туйны матур гына, җай белән генә алып бардың. Без барыбыз да канәгать. Сиңа ихлас күңелдән рәхмәт, дибез. Афәрин. Син безгә бик ошадың. Ә инде җыр-моңнарны җиренә җиткереп, үзәкләргә үткәзеп уйнавың, тальян гармуныңның сокландыргыч яңгыравыклы моңлы тавышы безне үзенә гашыйк итте. Уйна әле, зинһар, үзебезнең әби-бабаларыбызның дәртле-моңлы бию көйләрен. Биим әле бер истә калырлык итеп, үземнең яраткан балдызым Самияга, хөрмәтле кияү Рәис баҗайга багышлап. Сау-сәламәт булып, озак гомер итсеннәр.

– Амин. Шулай булсын, дип, кулларыбызны кысышып, Насыйбулланың сүзләрен җөпләп, без дә кушылабыз, – диде кунаклар.

Мин дә, туемның дәвамын үземә бүләк итеп шатландырган кунакларыма чиксез рәхмәтләремне әйтеп, изге теләкләремне юлладым. Нәҗип абыемның салмак кына итеп башлаган, күңелләрне җилкендереп, аякларны ирексездән тыпырдарга мәҗбүр иткән тылсымлы бию көйләре кешеләрне түгәрәк эченә чыгара торды, бию кызганнан-кыза барды. Һәрберсе үзе белгән кадәрен, башкалардан арттырып, матуррак итеп, төрле фигуралар ясап биергә тырышты. Чирлеләр дә зыр-зыр килеп әйләнде, күңелләрен чарлады.

Шушы тамашаларны җанландырып җибәргән Насыйбулла баҗам исә, кулларын як-якка җәеп, аякларын тыпырдатып торды да очына-очына биергә кереште. Ул «Василий Тёркин» поэмасыннан өзекләр такмаклап, «Я согласен на медаль» дип, түгәрәктәгеләрне шаккатырды! Ул кайсы урында нинди бию алымнарын куллануны белеп, биюнең тәмен тоеп, аннан рухи ләззәт алып, үз-үзеннән канәгать булып биеде. Армиядә хезмәт иткәндә, хәрбиләрнең аңа «татар Тёркин»ы кушаматы тагып, «кызыл почмак»ларда, бәйрәм концертларында биетеп алкышлаулары да юкка булмагандыр.

– Менә хәзер, чыннан да, күңелем булды, – диде ул, еш-еш сулыш алып. Ә син, баҗай, кем әйтмешли, баш бетмәгән, күз чыкмаган. Барына шөкер ит, – диде ул, иңнәремә кулын салып. – Килер вакыт, син дә савыгырсың. Синең дә биер чакларың булыр, иншалла. Мин үзем дә 1956 елгы Венгрия чуалышларында каты яраланып, озак кына госпитальдә дәваланып яттым. Минем дә вәсвәсәле күңелсез уйларга чумып, әллә ниләр уйлап йөргән чакларым булды. Бу дөньяда һәрнәрсә дә хәрәкәттә булып, бар нәрсә дә үзгәреп тора. Иртәгә нәрсә буласын, кемнең үләсен, кемнең исән каласын тик Аллаһы Тәгалә генә белә. Кеше авырудан түгел, әҗәл җитүдән үлә. Әле без – яшь кешеләр. Алда хәерле гомерләребез булып, дус-туганнарча бер-беребезгә кунакларга йөрешеп гомер итсәк иде... Тиз көннән савыгып, кунакка кайтуыгызны көтәбез, – диде баҗай, мине кочагына алып.

– Әнинең хәле ничек?

– Аягына басып калды. Сиңа сәлам әйтеп, борчылмаска кушты, – диде сеңлем, бинтлар белән чолганган кулларымны кулларына алып.

Бабай белән әби дә (Самиянең эти-әнисе) яныма килеп: «Бу чирне бик бәйләнчек, диләр. Син үзеңне сакларга тырыш», – диделәр.

Тик Самия генә миңа, каты хаста хәлендәге иренә, игътибар биреп, хәл-әхвәлләремне сорашмады. Аны ишегалдында кадерле кунакларыбыз белән бергәләшеп дәвам иткән туебыз тамашалары кызыксындырмый, ул боларның барысын да ташлап китәргә тели кебек тоелды. Ул тирән уйларда, вәсвәсәле халәттә иде сыман. Минем сорауларыма да җавапларны теләр-теләмәстән генә, карашларын читкә борып, гаепле кеше сыман итеп бирде. Боларның барысын да кунакларның сизгер карашлары күзәтте. «Дәвалан. Безнең өчен кайгырма», – диде ул китешли.

Кичке аштан соң авыруларның хәл-әхвәлләрен белешеп, кирәкле дарулар билгеләп, киңәшләрен әйтеп йөргән дежур табибә ханым минем яныма да сугылды.

– Нихәл, кияү? Туегызда булу шатлыгыннан кәефләрегез яхшырып, күңелләрегез бераз күтәрелеп киткәндер, шәт?

– Бераз булды кебек. Яңа туганнар белән таныштым. Әйбәт кешеләр. Барысы да хәлемне белеште, ярдәм итәргә дә әзерләр. Рәхмәт инде аларга. Тик хатыным гына сәер тотты үзен. Күңелгә ятышлы бер сүз әйтмәде. Минем сүзләремне дә тыңламады кебек. Аңламадым...

– Борчылма. Барысы да җайланыр...

– Шәп тамаша булды. Хәтта үзем дә сикергәләп алдым, – диде палатадагы авыруларның берсе.

– Миңа бигрәк тә «Я согласен на медаль» дип биюче ошады. Молодец мужик! Булдыра, яхшы бии.

– Сез – бик бәхетле кеше. Хәер, мондый ышанычлы, сезнең өчен барысын да эшләргә әзер туганнары булган кеше бәхетсез булырга тиеш тә түгелдер. Ә чирләр – берсен-берсе алмаштырып торган, табигый күренеш ул. Ә менә озак еллар хастаханәләрдә эшләү дәверендә сырхау кеше янына берьюлы бу хәтле кешенең килгәнен хәтерләмим. Ишеткәнем дә булмады. Тормышта сирәк була торган уникаль күренеш дияр идем.

– Бәлкем, үзенең сөекле кешесе белән кавышу шатлыгын туганнары, дус-ишләре белән туй иткән тантаналы көнне, минем шикелле чирләп, хастаханәгә эләгүчеләр булмагандыр?

– Дөнья булгач, төрле хәлләр була. Бәлкем андыйлары да, хәтта үлеп китүчеләре дә булгандыр. Ләкин туй хәтле туйда, дәррәү күтәрелеп, хастаханәгә килүчеләрне хәтерләмим. Ишеткәнем дә булмады.

– Бу вакыйганы тарих битләренә теркәп куярга кирәктер, – дип шаяртты кайсыдыр.

– Кәҗәсе түгел, мәзәге мөһим, дигәндәй, минем чирләп китүемне табигый күренеш дип исәпләсәк, туй көнне хастаханә хастасы булуым – чыннан да уникаль буладыр шул, – дидем мин.

– Туйның монда килүе, безгә – табибларга һәм сезгә рухи-әхлакый бурычлар да өсти бит әле. Бу күренешне туй кунакларының изге уй-теләкләре итеп кабул итәргә һәм дәвалау-дәвалануның уңай нәтиҗәсен күрсәтергә тиеш булабыз. Шулай түгелме?

– Сырхау кеше хәмер эчү, тәмәке тарту, төрле наркотик матдәләрдән ваз кичеп, тозлы-ачы ризыклар ашаудан да тыелып торырга тиеш була. Вакытында ашау-эчүне дә тәртипкә салу мөһим. Юкка-барга кәефсезләнү, ызгыш-талашлар да тире авыруларының ялкынсынуына сәбәпче булуы мөмкин.

– Сез санап киткән барлык бу таләпләрне үтәп яшәргә мөмкин дип уйлыйсызмы?

– Мөмкин дип уйлыйм. Хәтта таләп итәм. Яшисегез килсә, сезгә, һичшиксез, шул таләпләрне, хәрби уставны үтәгән кебек, яшәргә туры киләчәк. Чөнки гомер – Аллаһы Тәгалә тарафыннан тик бер тапкыр гына бирелгән иң кадерле, иң гүзәл, иң кыйммәтле һәм тиңе булмаган бүләк. Гомерләре буе урын өстендә кузгалалмый яткан сырхаулар да яшисе килеп яши. Берәүнең дә үләсе килми. Ә сезнең тире авырулары – гыйбрәт алып, тәртип кысаларында яшәүнең кирәклеген искәртүче, вакытлыча сезне борчып торган язмыш сынавы гына ул. – Аннары, күз карашын

безгә төбәп, сүзен дәвам итте: – Дөрес, сезне авыруга сабыштырган тире авырулары баш бетерә торганнардан булмаса да, үзләренә кадер-хөрмәт белән карауны таләп итә торган чирләрдән санала. Алар кабатлана-кабатлана, кычыту-сырхаулары белән үзәкләргә үтеп, теңкәләргә тиеп газаплый. Шуның өчен сезгә дә, без – табибларга да, кем әйтмешли, «җиде кат үлчәп, бер кат кисеп», алдын, артын карап эш иткәндә генә, уңышка ирешеп булачак. Иң мөһиме – һәрберегез белән бергәләп, үзегезнең җан-тәнегез кабул иткән майны табу кирәк. Чөнки берегезгә файдалы булган бер үк май, икенчегезгә зыян итүе мөмкин. Әнә шул, чирегезне уңышлы дәвалый торган майлар белән башка төр дарулар һәм процедуралар кулланып, тәртип саклап яшәгәндә генә, авыруны җиңеп була. Юкка гына әйтмиләрдер, «Чир уптым килә, мыскаллап кына китә» дип. Ә берәүләрнең гомерләре буе дәваланып та, тире авыруларыннан бөтенләй үк котыла алмаулары күз алдыбызда.

– Сөйләве генә ансат, – дип, сүзгә кушылды түрдә ятучы псориаз дигән чир белән авыручы ир. Ел саен хастаханәләрдә дәваланмыйча калганым юк. Шушы каһәр төшкән авыру аркасында тынычлыгым бетте. Гаиләмдә ызгыш-талаш. Эшләгән җиремдә дә миңа кирәкмәс кеше итеп карыйлар. Авырмыйча гына, хатыным, балаларымны сөеп, яратып яшисем килә дә бит... Ләкин безнең ишеләр өчен Кавказ кояшы нурларында кызынып, Кара диңгезнең шифалы тозлы суларында коенып кайтырга мөмкинлек юк. Сез әйткән таләпләрне үтәү белән беррәттән, санаторий дәвасы да бик ярап куяр иде.

– Мин дә ел саен кабатланып торган экзема белән интегәм. Нинди генә майлар сөртеп, халык дәвалау чараларын кулланып карамадым. Тик берсенең дә ялмап алырдай файдасын күрмәдем. Берара беткән кебек була да янә бүртеп чыга. Ни сәбәптән? Белгән юк. Инде сез әйткән таләпләрне дә үтим. Физкультура, спорт белән дә шөгыльләнәм. Ә уңай нәтиҗә юк.

– Без сезгә яраклы майны таптык шикелле. Иншалла, сөенечле нәтиҗәсе озак көттермәс...

* * *

Табибә ханымның авырулар белән уздырган ихлас әңгәмәсе һәм еллар буе иза чиккән кешеләрнең әрнүле-сыкранулы сүзләре, үземнең дә киләчәк тормышымның кайгылы-хәсрәтле, сагышлы күз яшьләре аша үтәсе икәне ачыкланды. Димәк, бу каһәр суккан чирдән тиз генә котыласым юк икән. Мин дә дәвалanучыларның тәннәренә сылаган төрле майлар, череп таркалган тире һәм эрен-үлекләр кушылмасыннан: күңелләрне айкап укшыта торган ачы-төче исләр белән аңкып торган палаталарда ятып, әле ата-бабалар кулланган барлы-юклы дарулар белән дәваланырга мәҗбүр булачакмын. Башкалар шикелле миңа да, язмышка буйсынып, ыңгыраша-сызлана яшәргә туры киләчәк. Ә мондый тормышның мәгънәсе бармы һәм аның бер чиге булырмы? Үзгәртергә кеше хәленнән килмәгән бу бәхетсезлекләрдән ничек котылырга? Ничек тормышны үземә дә, башкаларга да кызыклы һәм файдалы, күңелле һәм эчтәлекле итеп корып, гаиләмнең бөтенлеген саклап калырга? Бу һәм башка һәр ир кешенең күңелендә Дамокл кылычы сыман эленеп торган бу җавапсыз сораулар җир-әнкәгә беренче мәртәбә аяк

баскан акыл ияләренә тынгылык бирмәгән. Ләкин богылдан энә эзләүгә тиң булган, көч-кодрәткә ия җавапны табучы юк әле. Һәм бу – яшәешебез кебек табигый да. Чөнки без һәрберебез үзенә бертөрле. Һәрберебезнең тормышка үз карашы, үз уй-фикере бар. Һәркем үзенчә кәсеп итә. Берәүләр маңгай тирен түгеп тапкан хәләл мал-мөлкәтен булдырып яшәсә, ә икенче берәүләр кеше талап, кан-яшь коеп яши.

Әгәр бер кыз бала максатчан исәп-хисапны күзалдында тотып, тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка сыман, кочаклашып йоклаудан рәхәтлек алып, тәҗрибә туплау өчен генә кияүгә чыккан икән, аның уй-фикерләре сөрешен ничек үзгәртергә? Тормыш бит ул – үтә катлаулы механизм. Аның кайгы-хәсрәтләрдән, борчу-мәшәкатьләрдән, авыру-сырхаулардан торганлыгын ничек аңлатырга?

Әнә бит, хатыным да минем белән теләр-теләмәс рәвештә угалана-боргалана, карашларын аска төбәп, гаепле кеше сыман сөйләште. Үзе нидер әйтергә тели, тик кыюлыгы җитми. Башында кайнаган уйларын теле әйтергә ояла кебек. Әйтерсең лә ул: «Ялгышма», – дип кисәтә кебек. Мин аңардан сорадым: «Әйт дөресен: минем яныма килергә теләмәвеңнең төп сәбәбе нидә? Әгәр, үзең әйтмешли, тәнемне дәвалаучы майларның күңел болгаткыч исләре генә булса, савыгырмын. Авыруларым белән ул исләр дә җилгә очар. Әгәр инде, берәүләр ишеттергәнчә, чыннан да, аерылып, араларны өзәргә уйлыйсың икән, монысы инде, бөтенебез дә киңәшеп хәл итә торган җитди мәсьәлә. Син базардан сатып алып кайткан кәҗә бәтие түгел. Без кануннар тарафыннан расланып, язылышкан затлар. Өстебезгә өстәмә юридик хокук һәм бурычлар алдык. Аларның барысын да канун кысаларында хәл итү зарури. Дөрес, һәркемнең кебек, синең дә минем белән аерылышырга тулы хокукың бар. Мин дә синең кануни хокукларыңны хөрмәт итеп, шәхси теләкләреңә каршы килә алмыйм. Ләкин, кемнәрнеңдер коткысына бирешеп, бик зур хата эшләргә җыенасың түгелме? Бу дөньяда авырмаган кеше юк. Һәркемнең үз чире бар. Ул чирләрнең барысын да дәвалап була. Ә менә мәхәббәт чире дигәне – мәңгелек чир. Бел: минем кебек ихлас күңелдән, җаным-тәнем белән, бердәнберем итеп, берәү дә сине яратмаячак. Тагы шуны да исеңнән чыгарма: гафу ителгән мәхәббәт чын була алмый. Чын булмаган мәхәббәт эргәсендә бәхетле, тату гаилә дә корып булмый. Чөнки Күкләрнең хәер-фатихасы белән укылган никахлы гаиләләр генә бәхетле һәм тормыш итәргә сәләтле була. Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән Илаһи мәхәббәт, хис-тойгылар бәрәкәтле яшәешне дәвам иттерә. Безнең һәрберебезне әти-әниләребезгә, әби-бабаларыбызга, туганнарыбызга, кендек каныбыз тамган бердәнбер туган җиребезгә, сөекле ярларыбызга карата булган хыянәтсез мәхәббәтебез яшәтә.

Бу турыда борынгы ата-бабаларыбыз яхшы белгән. Алар шушы изге тойгы-хисләрне, тәртипле гореф-гадәтләрне, дини йолаларыбызны күз карасыдай саклап, татулыкта гомер кичергән. Чөнки тормыш ул – урам аша чыгу гына түгел. Ул – үтә катлаулы, һәрчак үзгәрүчән табигый күренеш. Ул бүген болай, иртәгә башкача булырга мөмкин тере организм. Бүгенге халәтеңнән чыгып, бер мәсьәләне дә төгәл хәл итеп булмый. Шагыйрь әйтмешли: югары баскычлар түбәнгә, түбәндәгеләр югарыга әйләнергә мөмкин. Борынгылар шушы тормышчан дөреслекне аңлап, сабыр,

түзем булганнар. Үзләренең күркәм кешелек сыйфатларын барлап, әби-балаларның гореф-гадәтләрен саклап, хөрмәт итеп яшәгәннәр. Өйләнгән, кияүгә чыккан парларын ихластан сөеп-яратып, кадерләп гомер иткәннәр. Китү-кайту, аерылышу кебек ямьсез, әдәп-әхлаксыз күренешләр бик сирәк булган. Аерылып кайткан, хатын аерган кешеләргә авыл халкы бармак төртеп күрсәткән. Аларны гаепләгән. Андыйларны хөрмәт итмәгән, кырыйдан әйләнеп узган.

– Ярату төрлечә һәм күптөрле булса да, саф мәхәббәт хисе тик бер кешегә генә багышлана. Әгәр синдә татлы-ләззәтле, утлы-ялкынлы хис-тойгылар юк икән, булып та сүнгән, сүрелгән икән – аерыл. Тик әледән үк башка ирләр белән очрашып, минем эчкерсез мәхәббәтемне хурлама, намуслы исемемне әхлаксыз тәкатьсезлегең белән мәсхәрәләмә, – дидем.

Дәшмәде. Димәк, ул минем сүзләремне күңеле белән раслады. Тик бу турыда теле белән әйтергә генә кыймады.

Кешенең кем һәм нинди икәнен беләсең килсә, хакимлек биреп сына, диләр. Дөрестер шул. Кайберәүләрнең чын йөзе авыр вакытыңда, ярдәмгә мохтаҗ чагыңда, үзеңне дә хәйран калдырып, һич көтмәгән сыйфатта ачылып китүе сер түгел ич.

Шәһәр пропискасына ничек итеп керергә аптырап йөргән кичәге самими авыл кызы да 180 градуска борылыш ясарга мөмкин икән шул. Минем дә хастаханәдә авырып ятуым араларның бозылуына сәбәп булды. Кияүгә чыгуы да ниндидер максатларны күздә тоткан курчак уенын хәтерләтте.

Хәер, бөреләнеп тә, чәчәк атарга өлгермәгән мөкатдәс өметләрнең беренче кыраудан ук бөрешүе, бәлкем, хәерлегәдер дә...

Табигатькә бәйле яшәешнең дә үз кануннары, үз кагыйдәләре бар. Телибезме, теләмибезме, без аларны тормыш кушканча итеп үтәргә мәҗбүрбез. Үтәмәгән очракта, бүгенге кешелек дөньясы тартылган җәзага һәркем тартылып, яман шешләр кебек фаҗигале авырулардан, табигать һәлакәтләреннән зыян күрәчәкбез.

Аягымда көч-хәл белән басып торган мин ул халәттә чарасыз идем әле. Ләкин вакыт дәвалый икән шул. Мин дә, инде тәнем кипшерә башлап, акрынлап, аякка баса башлаган идем. Хатыным Самия төрле сәбәпләр аркасында яныма килеп йөрмәсә дә, туганнарым эзләрен суытмады.

Гадәти иртәләрнең берсендә яныма Рәйсә сеңлемнең ире Камил килде. Күрешеп, хәл-әхвәлләр сорашкач:

– Мин синең иртүк килүеңнең сәбәбен беләм, – дидем.

– Белсәң, әйт.

– Сеңлем Рәйсә үлде.

– Каян белдең?

– Төштә күрдем. Әнием аны юып, яңа күлмәк кидерде.

Камил ике кулы белән битләрен каплап, үксеп елап җибәрде. Күз яшьләре бармак араларыннан чыгып, беләкләре буйлап акты:

– Кем уйлаган... Сау-сәламәт кеше шулай кинәт кенә үлеп китәр дип. Бернинди сәбәп тә юк иде югыйсә. Нәрсә булды? Әйбәт кенә эшләп, тыныч кына яшәп ятканда үл дә кит инде, менәтерә. Кызыбыз Резидәне кочагына алып, имезеп ятканда, миенә кан сауган. Ни сәбәптән? Дөрес, ул синең

авырып, хастаханәгә кереп ятуыңа бик борчылды, бик кайгырды. Ике сүзнең берендә телендә син булдың. Бигрәк тә якын күреп, өзгәләнеп яратты сине. Миңа әйтмәсә дә, нindидер яшерен сере бар иде кебек...

Бердәнбер кадерле сеңлемнең үлемен төшемдә күрсәм дә, аның чынлыгына ышанып бетмәгән идем. Инде ире Камил килеп әйткәч, тәнемнән салкын дулкыннар йөгереп үтте. Мин катып калдым. Телемне әйләндереп, бер сүз әйтерлек хәлдә түгел идем. Тамак төбенә таш кебек утырган төер тынымны кысты. Җаным сыкрап әрнесә дә, эсселе-суыклы дулкын, бөтен тәнемне дер селкетеп, каядыр ашкынды.

– Кызым – әнисез, үзем хатынсыз тома ятим булып калдык, – диде Камил, күз яшьләрен сөртеп.

Тәнем марля-бинтлар белән уралган хәлдә өйгә кайтып кергәндә, тумыштан йөрәк авырулы әнием урын өстендә, бик иртә, тик 23 яшендә безнең белән бәхилләшкән кадерле Рәйсә сеңлем колашада ята. Туган-тумача, күрше-күлән җыелган. Минем кайтуымны гына көткәннәр. Барыбыз да елау-ыңгырашулар белән бәхилләшеп дога кылгач, сеңлемне Пороховой зиратына алып киттеләр. Күзләрен бер ноктага төбәп, вакыт-вакыт аңын җуеп, бер сүзсез яткан әниемне ашыгыч ярдәм чакырып, хастаханәгә озаттык. Өебез нәүмизләнеп, мәет чыккан йорт сыйфатында, бушап калды. Бернәрсә турында уйларлык, нидер әйтерлек хәлдә булмаган килеш, хастаханәгә юл тоттым. Бу дөньядан шулкадәр күңелем кайтты ки: «Әгәр сеңлең Рәйсә янына китәргә ризамы?» – дисәләр, берсүзсез риза булыр идем. Чөнки мин әйтеп, сүземне аңлата алмаган, елап, эчемне бушата алмаган шәүләгә әверелеп калдым. Мине инде хәтта авыруым да кызыксындырмый иде.

Яшәү белән үлем арасында гомер итеп маташучы мине, янымда еш булып, җан җылысын биреп, күңелемне юатып тәрбияләүче – палата табибәсе Нажия ханым: «Синең әле алда балалар үстереп, бәхетле-шатлыклы, борчулы-мәшәкатьле гомер итәсең бар. Сине ике күзен дүрт итеп кадерле әниең, җаннарын ярып бирергә риза булган өзлексез яныңа килеп торучы, ышанычлы туганнарың, түземсезлек белән көткән хатының бар икәнен онытма. Егет бул. Нык бул. Бирешмә! Тормыш безне кайгы-хәсрәтле, бәхетле-шатлыклы сәгатьләре белән сыный. Ул шундый төрлелеге белән безне илтифатлы итеп тәрбияли, тәртиптә тота. Без аны шушы сыйфатларда яратып, аның кадерен белеп, рәхмәтләр әйтеп яшәргә тиешбез. Сынатма!» – дип рухландырды ул мине.

Табибә Нажия ханымның сүзләре рас килде. Чыннан да, экзема чире мине уникe ел эзәрлекләде. Дөрес, ул инде беренче мәртәбә авырып, Зур Кызыл урамындагы хастаханәдә дәвалангандагы шикелле дәһшәтле һәм дәвамлы итеп түгел, елдан-ел көче кими барып, офыгына таба тәгәрәсә дә, ел саен, кояшлы язның җылы нурларын тоеп, шытып чыккан умырзаялар кебек, кычытучан сусыл бетчәләр дә аяк-кулларымны һәм тәнемне яулап ала иделәр. Һәр елны, бигрәк тә Толстой урамындагы республика дәрәҗәсендәге чиста, тыныч хастаханәдә дәвалану тәнемне генә түгел, җанымны сихәтләргә дә булышты. Һәрчак дару һәм файдалы киңәшләре белән ярдәм итәргә әзер торган һәм профессорлар күзәтчелегендә эшләгән югары белемле табиблар, бездәй авыруларга игътибарлы булдылар. Биредә,

Зур Кызыл урамындагы шәһәр хастаханәсендәге кебек теләсә кайда хуҗасыз аунап яткан дәвалану майларының күңелләрне укшыткан исләре дә, авыруларның тәртип бозулары да юк дәрәҗәдә иде.

Ни генә димәсеннәр, Советлар заманында кысынкылыкта яшәп, дөньяның Аллаһы Тәгалә бәндәләренә бүләк иткән нигъмәтләренең игелеген тоеп, рәхәтен күрә алмасак та, хөкүмәтнең эшче халыкка карата игътибары бар иде. Уналты яшемнән заводта слесарь булып эшләгән кеше буларак, мине дә шәфкатеннән аермады. Хастаханәгә хәлемне белергә килгән комиссия әгъзалары аяныч хәлемне күреп, ярдәм итәргә вәгъдә бирделәр. Заводның профсоюз комитеты акчалата ярдәм күрсәтеп, дәвалану өчен бушлай юллама да бирде. Аягымда басып йөри башлагач, Кавказ санаторийларының берсенә юлым төште.

Сүз уңаенда тагы шуны да әйтеп үтим: заводта эшләгән дәверемдә заводның профсоюз комитеты һәр елны миңа юллама бирергә тырышты. Ул юлламаларның күбесе, һәр елдагыча, хастаханәдә ятып чыкканнан соң, дәвалануны дәвам итү максатында искиткеч гүзәл Кавказның йөзек кашы булып саналган Сочи-Хоста шәһәрләрендәге данлыклы мацест ванналарындагы мөлдерәмә суларның тылсымлы шифасын сеңдереп дәвалану өчен бирелә иде.

Инде партия оешмаларында эшләгән дәвердә дә, Үзәк Комитетның бөтен уңайлыклары белән танылган курортларында дәвалану бәхетен тату да насыйп булды миңа. Ләкин профсоюз санаторийлары белән чагыштырганда, ашау-эчү, яшәү шартлары, хезмәткәрләрнең игътибарлы мөнәсәбәтләре, дәвалау ысулларының төрлелеге ягыннан җир белән күк арасындагы аерма кебек булса да, аларның берсе дә Мацест елгасы суларындагы шифаны алыштырырга сәләтле түгел иде.

Шушы минем гомеремне киләчәкле иткән дәваны мин беренче мәртәбә 1962 елның июль аенда әкияти Кавказ шифаханәләренең берсендә алдым, тәнем-җаным белән тоеп, рухланып кайттым.

Ел саен аяк-кулларым һәм башка урыннарым бинт-марляга уралып Хоста шәһәренә килгән мин, мацест ванналарының тылсымлы суларында шифа табып, янә сәламәт кешегә әвереләдем. Хәтеремдә, бер елны поезд Хоста шәһәренә якынлашып килгән бер мәлдә, мәгърур тауларның бәллүрдәй саф, чиста һавасы белән Кара диңгезнең әчкелтем-төчкелтем дымлы һавасын тоеп, җаным-тәнем сискәнеп, күңелем күтәрелеп китте. Иңнәремне басып торган авыр йөк төшеп, бушанып калгандай булдым. Кул-аякларымны һәм башка урыннарымны бәйләп торган бинт-марляларны чишеп, вокзалдан турыдан-туры диңгез буена йөгердем. Аннан-моннан чишенеп, диңгезгә чумдым. Чирканчык алудан чымырдаган гәүдәм буенча эсселе-суыклы дулкыннар йөгереп үтте. Диңгезнең тозлы сулары, тәнемдәге җәрәхәтләрне ялмаудан, җан рәхәте тоеп, хозурлык кичергән бер мәлдә, чик сакчыларының: «Хәзер үк диңгездән чыгыгыз!» дигән боерыгы буйсынырга мәҗбүр итте. Баксаң-күрсәң, төнге унбердән соң диңгез буе чик буена әйләнеп, суга керү – чикне бозу булып санала икән.

Әйе, Кавказ кояшының кызу нурлары, Кара диңгезнең тозлы сулары әле элпәкләнергә дә өлгермәгән җәрәхәтле яраларымны өтәләп, ачыттырып

талаганда – түздем. Берәүгә дә зарланмадым. Бу авыруларның язмыш сынавы икәнен һәм аларның кайда, ничек башланганнарын да яхшы белә идем.

Бу исә тәннәребезнең иң яшерен җирләренә үтеп, аркылыга-буйга йөргән, бәгырьләребезне өшеткән ачы, мәрхәмәтсез «әфган җиле»нең дә гомерлек истәлеге иде.

Берне югалтмый, икене табып булмый, диләр. Кырыс холыклы Памир тауларында югалткан сәламәтлегемне, юмарт табигатьле, ягымлы Кавказ тауларының мәрхәмәтле мацест ванналарының тылсымлы шифасын сеңдереп, июль кояшының кызу нурларында өтелеп, эссе табадай таш өсләрендә пешә-яна, Кара диңгезнең тозлы суларында коенып дәвalandым. Югалтканымны таптым.

Ерак офыклар белән тоташкан Кара диңгезнең дулкын очларында, искиткеч гүзәл төсләргә әверелеп, энҗе бөртекләре сыман җемелдәп, су өстен көмеш белән япкан кояш нурларының чагылышын күреп сокландым. Хәтта диңгез төпләреннән умырылып, йортлар биеклегендәге дәһшәтле дулкыннары котырынып, ярларга бәрелгәндә дә, ул үзенең буйсынмас горур сөйкемлелеге белән сокландыра. Әлбәттә, тирә-якка ак күбекләрен бөркеп пошкырган чагында коенудан тыелып тору хәерле. Ләкин мин коендым. Дулкыннарның өстендә түгел, асларына кереп коендым. Аста аларның көч-куәте бермә-бер кими икән.

Диңгезгә таба карап торган безнең шифаханәнең як-ягын шакмаклап киселгән яшел куаклар белән бәҗралаган юллар челтәрләгән. Шифаханәнең ал ягында, хуш исләре ачык тәрәзәләр аша бүлмәләргә кереп, дәвалanучыларның күңелләрен күтәреп иркәли. Орчык кебек төз кипарислар горур кыяфәттә басып, һавага ашкан очларындагы яшел эшләпәләрен кырын салып, җирне күләгәли.

Бүлмәләр чиста, саф. Бизәкле чүлмәкләрдә төрледән-төрле гөлләр үсеп утыра. Өстәл өстендәге графинның да суы салкын, һәрчак саф. Кем әйтмешли: «Ашау – байдан, үлем – Ходайдан», дигәндәй, хастаханәнең сөрсегән палаталарын онытып, үземне җәннәттә кебек хис иттем шушы көннәремдә.

Ашханә өстәле кырыенда без дүртәү утырабыз: 50 яшьләр чамасындагы ике нәзберек ханым, дәрт-дәрманын кая куярга белмәгән ир-ат һәм мин. Ханымнар һәрчак пөхтә һәм зәвык белән киенеп, шифаханәнең эчке кагыйдәләрен үтәп яшәүчеләр. Ашханәгә дә вакытында килеп, үзләре заказ биргән ризыкны гына алырлар. Ул ризык нинди генә сый булмасын, пычак, чәнечке белән коралланган ханымнар аларны ботарларга керешә. Астын өскә әйләндереп, нәрсәдер эзләп казыналар, актарыналар. Итнең майсыз, тавык итенең ак җирен генә чемченәләр. Ашның да бәрәңгеләрен читкә этәреп, шулпасын кашык очларына элеп, аз-азлап, этикет саклап кына капкалыйлар.

Шушы бик җитди һәм җаваплы шөгыль белән мавыккан арада, шифаханәдә булган барлык яңалыкларны: кем килгән, кем киткән, кем белән кем кочаклашкан, кем төнлә соңга калып кайткан, фәлән кем фәләнгә гашыйк булган, танышкан ирне елый-елый өенә озаткан. Кем кичәдә үзен ничек тоткан, нинди күлмәк кигән булган... Һәм башка шушындый

мәгълүматларны ишетеп торам. Юкса аларның миңа һич кенә дә кирәге юк. Минем үз борчу-хәсрәтләрем дә баштан ашкан.

Ә теге ир-егетнең үз кагыйдәсе, үз тормышы. Ул кайчакны тәүлекләр буе югалып тора. Иртәнге ашка арыган-алҗыган кыяфәттә килә. Ханымнар бер-берләренә карашып: «Төнне кунакханәдә уздырган икән», – диләр елмаешып.

Ә үзем, тәртипле кеше буларак, иртүк торып, диңгездә коенырга йөгерәм. Кыймылдый алганча, физзарядка ясыйм. Иртәнге ашка ачыгып киләм. Официант ханымнар хәлемне аңлап, өстәмә китерәләр. «Аша, егет. Сиңа ныгырга, сәламәтләнергә кирәк», – диләр. Мин дә сынатмыйм. Ризыкларны ялмап, тәлинкәләрне ялтыратып куям. Төшке ашка кадәр көн саен 15 минут мацест ваннасында дәваланудан тәнемнең рәхәтләнеп китүен тоеп, хозурлык кичерәм. Төштән соң, Кавказ кояшының 35-40 градуслы нурларында кызынып, Кара диңгезнең шифалы суларында коенып, тәнемә сихәт алам. Көннән-көн экзема чиренең югала баруын һәм дә тәнемнең табигый төсенә кайтуын күреп, чиксез шатланам. «Синең чирнең дәвасы: мацест ваннасы, Кара диңгезнең тозлы суы, Кавказ кояшының шифалы нурлары. Әгәр 3-4 ел бирегә килеп дәвалансаң, экземаңның эзе дә калмаячак. Сәламәтлектән дә кадерле бернәрсә юк бу дөньяда. Көтәрбез. Килергә тырышыгыз. Бу хакта рекомендациямдә дә ачык итеп әйтермен», – диде шифаханә табибы.

## Мөһаҗир

Хатынымның: «Ирлеге дә ташка үлчим», – дигән сүзләре күзләремне ачып, сискәндереп җибәрде. Моңарчы да аның еш кына әле кемнеңдер туган көнен билгеләп, әле кемнеңдер ялга китүе уңаеннан укмашкан мәҗлесләрдән сыйланып, кайчак салмыш хәлдә соңга калып кайтулары шикләндерсә дә, әллә ни игътибар итми идем. Бүген исә еш кына кабатланган бу бәйрәм ясауларның сәбәпләре башка максатлар өчен икәнлеге ачыла төште кебек. Аның йөрәгемә ук булып кадалган сүзләрен ишетүдән аптырап калган кардиолог табиб кулларын угалап алганнан соң, яныма килеп, кулларын иңемә куйды: «Зинһар, урынсызга әйтелгән бу сүзләргә хәтерең калмасын. Ул аларны кәефе кырылып киткәннән генә әйтеп җибәрде. Ә сиңа, – диде ул Самиягә үпкә белдереп, – табиб буларак, шуны әйтер идем: барлык ирләрнең дә дәртләре ташып тормый. Аңарга карап, хатыннары урамга чыгып, ир эзләп йөрми. Бәхетне дә читтән эзләми. Сырхау булуны сорап алмыйлар. Ләкин күпләребез чирле. Безнең бу тормышта син әйткән «ташка үлчим»нәргә дә мохтаҗлар аз түгел. Чөнки ир-егетләрнең бик күбесе сугышта кырылды. Әти-абыйлары урынына калган, бүген «сугыш чоры балалары» дип аталган буын үсмерләре арык атлар белән, үзләре дә кычыткан шулпасы чөмереп, басу-кырларны сукалады, тырмалады. Колхозның барлык эшен тартып барды. Ач-ялангач хәлдә эшләп, саулыгын югалтты. Аларның янәшәбездә булуларына рәхмәтләребезне әйтеп яшәү кирәктер. Хыянәтчел уйлар уйлап, көфер сүзләр әйтүнең чиге үкенечле булырга мөмкин. Алла сакласын», – диде Наил Кадыйрович, карашларын аска төбәп, үзенең дә уңайсыз хәлгә калганын сиздереп.

– Мин берәүгә дә дәгъва белдерергә, берәүне дә гаепләргә теләмим. Тик үземне генә әрлим. Сукыр булганмын икән, дим.

– Миңа кияүгә чыкканыңа үкенәсеңме? – дидем мин турыдан-туры.

– Үкенәм. Бик үкенәм. Бер дигән һәм акчалы егетләрне ташлап, синең хатының булуыма үкенәм. Очы-кырые булмас авыруларыңнан туйдым, гарык булдым. Бер уйлагач, туйдан соң тәвәккәлләп, җыелган төенчегемне алып, табанымны ялтыратырга кирәк булган мин юләргә. Бу турыда әйтүчеләр, кисәтүчеләр дә аз булмады. Ә мине Насыйбулла җизни тоткарлады. «Чир килә дә китә. Төзәлер. Ирең уңай кеше, түз», – дигәч, ул чакта туктап калдым.

– Бәлкем, бүген дә соң түгелдер? – диде табиб.

– Соң шул. Хәзер безнең ике улыбыз бар. Ничек булсаң да, ирем саналган син бар.

– Димәк, балаларыгызны сөеп-яратып, барына канәгать булып яшәргә язсын сезгә, – диде Наил Кадыйрович, урынына утырып.

Ләкин табиб әфәнденең: «Яшисең килсә, шәһәр ыгы-зыгысыннан арынып, авыл җиренең тынычлыгында, саф һавасын сулап, шифалы чишмә сулары эчеп яшәүне иң сихәтле дарулар да алыштыра алмастыр. Миокардтагы яра да тизрәк сәламәтләнер иде. Ә кирәкле даруларны табып бирүне мин үз өстемә алам. Сине бик тә сау-сәламәт хәлдә күрәсем килә. Синең кебек шәфкатьле, киң күңелле кеше, һичшиксез, яшәргә тиеш дип уйлыйм», – дигән сүзләре мине һаман җилкендереп, өметле уй-хыялларда яшәтте. Мине һичшиксез булачак үзгәрешләргә әзерләде. Чөнки Ленин исемендәге Казан университетының журналистика бүлеген тәмамлап та, әле һаман да завод слесаре булып йөрүем мине канәгатьләндерми иде инде.

Дөрес, берәр журнал яки газета редакциясендә урнашып, эшкә керешергә дә мөмкин булыр иде. Ләкин төрле жанрда аяк терәп язарлык тәҗрибәң булмаганда, (минем язу сәләтем утыз елдан соң, пенсиягә чыккач кына уянды) өйрәнчек булып йөрүгә күңелем тартмады.

Табиб Наил Кадыйровичның авыл җиренә кайту турындагы уй-фикерен бөтен гаиләбез белән уртага салып сөйләштек. Абыйларымның, акыл иясе әниемнең һәм хатыным Самиямнең да «үзеңә кара, мин каршы түгел» дигән хәер-фатихаларын күңелем түренә салып, шәһәр янәшәсендәге бер районның партия райкомына юл тоттым. Хәерле сәгатьтә булсын!

Минем, шәһәр кешесенең, авылга мөһаҗирлеккә китеп яшәү һәм эшләүләрем әнә шулай башланды.

Район партия комитетының беренче секретаре, олпат гәүдәле, җирән чәчен кыска итеп алдырган, ягымлы йөзле, кысынкырак соргылт күзләренең кызыксынучан карашлары мине беркадәр каушатса да, кыскача автобиографиямне игътибар белән, сүземне бүлми тыңлады.

– Димәк, Казан университетының журналистика бүлеген, ике еллык югары марксизм-ленинизм университетын яхшы билгеләргә тәмамлагансыз. Партиябезгә сездәй әзерлекле кадрлар бик кирәк. Шул исәптән безгә дә. Ләкин авыл хуҗалыгы – бик авыр өлкә. Монда заводтагы кебек сигез сәгатеңне эшләдең дә кайтып киттең түгел, үзеңне һәрчак эштә кебек итеп яшәргә туры киләчәк. Шушы шартларда эшләү өчен нык сәламәтлек һәм тәвәккәллек кирәк. Әйе, – диде беренче секретарь, бик мөһим нәрсәне

исенә төшергәндәй итеп. – Сез бу кыю эш-гамәлләрегезне гаиләгез белән килештереп кыласыз булыр бит?

– Әйе. Сөйләшеп, алар рөхсәте белән.

– Юкса, без – ирләр, үзебезне гаилә башлыгы дияргә яратсак та, соңгы сүзне хатыннарыбыз әйтә, алар нәтиҗә ясый.

– Сез әйткән барлык таләпләрегезгә ярашып бетмәсәм дә, ниятем нык. Эшли алырмын дип уйлыйм, – дидем, үземә нык ышанып.

Беренче секретарь алдындагы кәгазьгә нидер сызгалап, уйланып утырганнан соң: «Ярар, килештек. Сез безгә үзегезнең кем һәм нинди икәнлегегезне тасвирлаган, Ленин районы партия комитетының беренче секретаре кул куеп, мөһер сугып раслаган характеристиканы алып киләсез. Калган мәсьәләләрне очрашкач хәл итеп бетерербез», – диде һәм урыныннан торып, көрәк кадәр зур кулын сузды.

1969 елның 6 апреленнән мин, 7нче разрядлы слесарь, унтугыз ел эшләү дәверендә җыелган эш коралларымны, еллар буе игелекле хезмәт иткән тискием беркетелгән верстагымны бер тумбалы гап-гади канцелярия өстәленә алыштырдым. Эш коралларым: каләм, карандаш, линейка, бетергеч кебек әйберләр булып, үзем район партия комитетының оештыру бүлеге инструкторына әвереледем.

* * *

Район комитетының оештыру бүлегендә эшли башлавыма нәкъ тугыз ай булган көнне «Ленино-Кокушкино» совхозы коммунистлары миңа ышаныч белдереп, совхозның партия комитетын җитәкләүне тапшырды.

Һәрчак шулай була. Хәерчегә җил каршы, дигәндәй, кеше дигәнең тауга күтәрелә генә башлый, шундук аның чабуыннан зәхмәти көчләр эләктереп ала. Минем белән дә шулай булды.

Өлкә газеталарының берсендә танылган журналистның «Сукбай хатын» исемле мәкаләсе басылып чыга. Автор хатыным Самия авызыннан «Ленино-Кокушкино»да партком секретаре булып эшләүче ирен, ягъни мине, булдыра алганча яманлап, гаиләсен ташлап китүче, балаларын тәрбияләмәүче, аларның тамаклары тук, өсләре бөтен булсын өчен акча бирмәүче итеп сурәтләгән. Хатыным Самиянең, өйдән чыгып китеп, атналар буе сукбайлыкта йөрүендә мине гаепләп, бер хатынын тәрбияли алмаучы кешенең башкаларны да әдәпле-әхлаклы итеп тәрбияли алуына шик белдергән. «Ул әле, коммунист буларак, үзе мораль яктан өлгермәгән. Мондый кешенең җитәкче булып эшләргә хакы бар микән?» дигән сорауны куя журналист җәмәгатьчелек алдына. Һәм җәмәгатьчелек тә җавапсыз калмады. Кайтавазларның күбесе: компартиянең үз сафларына, бигрәк тә җитәкчелек органнарына, ата-бабаңның җиде буынына кадәр тикшереп, энә күзеннән үткәннәре генә лаек булганын һәм үз кадрларын һәрчак күз алдында тотуларын әйтеп, авторның әлеге мәкаләне кемнеңдер заказын үтәп язганлыгын билгеләп, ә мине, ул әйткән начар сыйфатларның нәкъ киресенә ия булуымны чын фактлар белән исбатлаганнар иде. Әлбәттә, авторга теләктәшлек күрсәткәннәре дә булды. Дөрес, ул көннәрдә үзем дә ике ут арасында яшәдем. Эшемне яратып, ихлас күңелдән башкарсам да, гаиләне бернәрсә дә алыштыра да, аның белән тиңләшә дә алмый

шул. Улларымның һәрчак тамаклары тук, өсләре бөтен булды. Чөнки алар һәрчак Казан шәһәренең танылган абыстае – әнием Хәбибҗамал тәрбиясендә булып, оят-намусның, тәртип-тәрбия һәм әдәп-әхлакның нәрсә икәнлекләрен белеп үстеләр. Гомерем буе әниемә, улларыма рәхмәт әйтеп яшәдем. Әйткәнемчә, һәр партоешма, һәр коммунист партиянең күз алдында булды.

Әнә бит, җәмәгатьчелекнең колагын торгызган усал мәкалә газета битендә үз йөзен күрсәтүгә, партиянең өлкә комитеты секретаре иптәш Вәлиев, корт чаккандай, Георгий Константиновичка шалтыратып, нәрсәнең ничек икәнен белешкән.

– Газетада басылган фактларның дөресме, түгелме икәнлеген җәмәгатьчелек кайтавазлары һәм вакыт ачыклар. Ә хәзергә, әйтелгән бу фактларны башкалар ялгыш кабатламасыннар өчен кисәтүле чаралар күрү мөһим. Үзең дә әйтәсең ич, газетада басылган фактларга Сафинның бернинди катнашы юк. Аларның барысы да аның холык-фигыленә, үз-үзен тотышына, тәртип-тәрбиясенә, әдәп-әхлагына капма-каршы килүче сыйфатлар, дисең. Ләкин аларны мәкалә авторына уйлап табарга, бастырып чыгарырга кирәк булган. Әгәр без бу мәкаләгә карата битараф калып, дөрес бәя бирмәсәк, иртәгә башкалар турында, моннан да зәһәррәк мәкалә басылып чыкмас дип әйтә алабызмы? Юк, әйтә алмыйбыз. Гарантия дә юк, – дигән иптәш Вәлиев.

– Юк икән шул. Бу инде партия матбугатына көя төшүгә бәрабәр күңелсезлек.

– Бик дөрес әйттең. Тиктомалдан кешегә нахак ягып, ялган язып, аның намуслы исеменә тап төшергән журналист, мәкаләдә язылганнарны кат-кат укып, дөреслеген тикшермичә, басарга биргән редактор да җәмәгатьчелек алдында җавап бирергә һәм җәзасыз калырга тиеш түгел.

– Әйе, нәкъ шулай булырга тиеш. Журналист ялган язган. Гаепсез кешенең намуслы исемен пычраткан. Болай эшләргә ярамый. Элек кемнең кем икәнен белергә кирәк иде. Сафин – һәртөрле ихтирамга лаек кеше. Ул һәр эш-вазифаны җиренә җиткереп үти ала торган әзерлекле кадр. Партком секретаре булып та озак эшләмәс, дим. Андыйларга районда башка эшләр дә җитәрлек. Хәер, совхозның да киләчәге өметле. Совхоз аңа кирпеч йорттан өч бүлмәле фатир бирде. Җиһазлар алырга булышты. Булганның игелеген күреп яшә рәхәтләнеп югыйсә. Тик йөгәннән ычкынган хатыны районга кайтырга теләмәде. «Мин шәһәргә, авылга кире кайтыр өчен килмәдем», – дигән. Ә хәзер гаиләсеннән китеп, азып-тузып, сукбайлыкта йөри икән. Үзе дә адәм актыгына калып йөри, гаиләсенә рәхәтләнеп яшәргә, иренә эшләргә ирек бирми, – дип җаваплаган безнең Георгий.

– Беләбез. Аның кем һәм нинди икәнлеге турында мәгълүматыбыз бар. Аның үз кадерен белми, якыннарына сөенеч китерми яшәве кызганыч, әлбәттә. Шуның аркасында Сафинның да зыян күрүе, югарыга юлы киселүе мөмкин. Бер пычрак сыер бөтен көтүне пычрата, дип юкка гына әйтмиләрдер шул.

Туйлар узгач, Сафинның туны киелгән, якасы кыршылган инде. Аның, гаиләсен калдырып, совхоз коммунистларын җитәкләргә дәрәҗәсе дә, хакы

да юк. Андый кеше башкаларга үрнәк була алмый. Дәүләтнең ныклыгы – гаиләләрнең бердәмлегенә, әдәп-әхлак дәрәҗәсенә бәйле.

– Ә хуҗа абзый нәрсә ди?

– Балалары янына кайтсын, ди. Сиңа аның белән иплэп кенә сөйләшергә кирәк булыр. Мәсьәләне хәл итүне сузма...

Утыз көн уразаның бәйрәме бер көн булган кебек, хатыным Самиянең дә озак вакытлар өйгә кайтмый, сукбайлыкта йөрүләренә чик куелды. Ул әрәмтамаклыкта гаепләнеп, ике елга хөкем ителде. Свердлау өлкәсенең Түбән Тагил шәһәре төрмәсендә утырып чыкты. Шул ук елны Ирек улымны да хәрби хезмәткә чакырып алдылар. Ул да шул ук шәһәрдә гражданлык бурычын намус белән үтәде.

Һай, бу илаһи көчнең кеше язмышлары белән курчак уены уйнаулары. Кем уйлаган, Казанда яшәп, үзара сирәк очрашкан ана белән ул ерак Себер җирендә күрешерләр дип? Бу бит кеше ышанмаслык гаҗәп хәл. Искиткеч могҗиза лабаса. Әллә бу... Күкләрнең серле галәмәтеме?

Ана белән ул үзара күрешеп, хезмәт срокларын кыскарткан берчакта, мин ике бүлмәле фатир алу бәхетенә ирештем. Тик ордер алу өчен әнә шул ана белән улның яңа фатирга язылып теркәлергә риза икәнлекләрен белдергән һәм шул ризалыкларының дөреслеген җитәкчеләре раслап, кул куйган, мөһер сугып беркеткән белешмәләр кирәк булды. Мин дә шул белешмәләр артыннан Түбән Тагилга юл алдым.

Халыкта: «Күрәчәгең күрми, гүргә кереп булмый» дигән бик тә гыйбрәтле гыйбарә бар. Язмыш безне дә башыбызга да килергә мөмкин булмаган, чәнечкеле тимер чыбыклар белән уратып алынган, тәрәзәләре тимер рәшәткәләр белән нygытылган төрмәнең күрешү бүлмәсендә очраштырып тетрәндерде. Бу аяныч хәл кызык та, кызганыч та булды. Бер-беребезгә әйберләр бирмәскә кисәтелеп, кирәкмәгән артык сүзләр сөйләшмәскә кат-кат әйтелгән хәлдә, күзәтчеләрнең үтә уяу карашлары кисешендә, әдәпсезлек булып, килешеп бетмәсә дә, бер-беребезне бик тә сагыну-сагышлы мөлдерәмә сөю хисләребез эчтән ургып, күз яшьләребез булып тамды. Без бер-беребезне үбә-коча бер җан, бер тәнгә әверелгән кебек булдык. Тансыклаган җан-тәннәребезнең бер-берләренә тартылуларын, йөрәкләребезнең шатлыктан дулкынлануларын тоеп, күңелләребез, тамырлардан ургып аккан нәсел каннарыбыз сыман аерылгысыз икәнен без Себер туфрагына аяк басып аңладык. Язмышларыбызны гомерлеккә беркетеп бәйләдек.

Әйе. Язмыш ул – Аллаһы Тәгаләнең һәр бәндәсенә, әле әнисенең карынында чагында ук иңдерелгән директивасы. Ә кеше исә, шул директиваны үзе сайлап алган эш-гамәлләре аркылы тормышка ашырырга тиеш. Моның өчен кешегә бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган. Иң мөһиме: юлның дөресен сайлый белү кирәк.

Самия дә, бераз соңга калып булса да, кайту белән үзенең яраткан эшенә керешеп, диннең асылын чагылдырган тирән эчтәлекле вәгазьләре белән халык арасында ихтирам казанган Вафа хәзрәт дәресләренә йөри башлады. Еллар буе Сөмәя абыстай һәм Юныс хәзрәт таифәсендә булып, укуын дәвам итте. Биш вакыт намазын төгәл башкарды. Изге китабыбыз – Коръәннең бөтен кагыйдәләрен үтәп укырга өйрәнде. 1985 елны бик

тә теләгән хәлдә Мәккә шәһәренә барып, хаҗ гыйбадәте кылып кайтты. Кадерле республикабызның мөстәкыйльлеге өчен каһарманнарча көрәшкән атаклы журналист, «Мөслимә» газетасының редакторы Әлмира ханым белән танышып, хаҗ вакытының башыннан ахырына кадәр бергә булганнар. Әлмира ханым аның милләтебезгә хас күркәм сыйфатларын, игелекле гамәлләрен, үтә кешелекле булуын һәм, әлбәттә, дингә ихласлыгын исе китеп сөйли иде. Самия өч ел буе урын өстендә яткан әниемне чын күңеленнән хөрмәт итеп тәрбияләде.

...Кадрлар бүлегеннән документларымны алып, Георгий Константинович белән хушлашырга дип, кабинетына кергәндә, янында партия өлкә комитеты инструкторы Филимонов Фёдор Степанович та бар иде. Мөлаем йөзле, тыныч холыклы, һәр сүзенә мәгънә салып сөйләшкән бу акыллы кеше белән без кошчылык фабрикасы мәсьәләсен партия өлкә комитеты бюросында карау өчен әзерләгән чакта танышкан идек.

– Менә өметле кадрыбызны сезнең тарафка озатырга булдык. Кыерсытмый гына игелеген күрегез, – диде Георгий Константинович, Филимоновка карап.

– Нишләмәк кирәк. Канатлары ныгыгач, кошлар да балаларын очыра. Барысы да табигый хәл. Табигать-әнкәй безнең һәрберебезнең язмыш юнәлешен алдан ук билгеләп куйган. Берәүләр юкны бар итеп яши, ә берәүләр бар булганның кадерен белми, әрәм-шәрәм итә, гомерләре заяга үтә. Без, ирләр, үз язмышыбыз белән генә түгел, хатыннарыбыз язмышы белән дә бәйле. Алар өчен дә җавап бирергә, гөнаһ-хаталарын өстебезгә алырга тиеш. Шуның өчен дә без – ирләр, Күкләрнең директиваларын үтәүче гали затлар, – диде Филимонов эчке бер горурлык белән.

Без Георгий Константинович белән бер-беребезгә сәламәтлек теләп, һәрберебезнең бәхетле-шатлыклы көләч йөзләрен күреп яшәргә насыйп булсын дип хушлаштык. Мәрхәмәтле бу кеше белән без озак еллар аралашып, бер-беребезнең хәл-әхвәлләребезне, рухи халәтебезне белешеп, киңәшеп яшәдек. Олы җанлы, киң күңелле, ачык йөзле бу кешегә мин бик рәхмәтле. Ул мине эшкә алып, мәгънәле тормышка юл күрсәтте, йөрәк авыруымны җиңеләйтте. Табиб Наил Кадыйрович әйткән авыл җирендә булып, саф һавада, челтерәп аккан чишмәләрнең шифалы суларын эчеп, дәвалану курсын үттем. Үземнең кем икәнлегемне аңладым.

Миңа хәзер инде язмыш икенче бер капкасын ачарга җыенып тора иде шикелле. Хәерлегә булсын.

Имеш-мимешләрнең дә рас килгәне була икән.

Мәскәү шәһәренең азык-төлек кибете директоры, зур суммада акчалар урлап тотылган Юрий Соколовның атып үтерелергә хөкем ителүе, СССР Главторг рәисе Трегубовның кулга алынуы һәм Казан рестораннар трестының элеккеге җитәкчесе Хәсәнов Таһир Нәбиевичның, «Волга» ресторанының директоры булган Кошелёв Юрий Петровичның «Блинная» кафесы производство җитәкчесе, өч бала анасы Әминә ханымның ришвәт алуда гаепләнеп хөкем ителүләре югары партия органнарын уйланырга мәҗбүр иткән булыр. Алар, бәласеннән баш-аяк дип, рестораннар тресты партия комитетын кыскартып, эш күрсәттеләр. Шулай итеп, рестораннар

трестында ренессанс чоры тәмам булды. Ә мине моннан бер ел элек ремонтка ябылып та, кыл да кыймылдатылмаган «Казан» ресторанына директор итеп билгеләделәр.

## Гыйбрәтле сабаклар сәхифәсе

*Кеше булган кешенең,*
*Кеше белән эше бар.*
*Кеше булмаган кешенең,*
*Кешедә ни эше бар?*

«Казан» ресторанын һәм аның бер почмагына урнашкан кунакханәсен өлкәнрәкләрдән кем генә хәтерләми икән!

Бер ел буе ташландык хәлдә калып, заллары тузанга баткан, ватык өстәл, урындыклар һәм башка чүп-чар белән тулган, урыны-урыны белән диварларының штукатуралары купкан, түшәмнәрен пәрәвез сырып алган, әле узган гасырның урталарында, архитектор Петонди тарафыннан проектланып, эклектика рәвешендә төзелгән һәм революциягә кадәр «Казанское подворье» дип аталган, шәһәрнең горурлыгы саналып, данлыклы «Щетинкин номерлары» йортының урам якка караган чатында урнашкан «Казан» ресторанын, үзенә генә хас элеккеге төсенә кайтарып, тәүге рухында калдырып, ләкин бүгенге күзлектән чыгып «ретро» стилендә һәм сәнгать әсәрләре белән бизәлгән, элеккеге аристократик бай түрәләрнең зиннәтле күркәм сарайларын хәтерләткән купшы купец рестораны итеп барлыкка китерү кирәк иде.

Бу эшләрне башкарырга тотынган кешеләрнең иң кимендә азмы-күпме тарихи белемнәре, ихлас күңелдән булган ялкынлы теләкләре һәм, әлбәттә, үз һөнәрләренең осталары булуы мөһим иде. Кайбер җитәкчеләрен искә алмаганда, бер ел буе ябылып торган ресторан коллективы таралган, берәүләре вакытлыча үзебезнең трест предприятиеләренә күчкән. Кайберәүләр бөтенләй китеп барган. Ләкин ресторанның филиаллары урак өстендәгедәй эшли иде. «Бегемот» дигән данлыклы сыра бары гамәлдә булып, казанлыларны кысла белән дә сыйлый иде. Ресторанның арткы өлешендәге янкормасында Ленин ордены кавалеры Каюм абый җитәкчелегендәге кондитер цехы да эшен туктатмады. Алар Бауман районындагы барлык кинотеатрларны кондитер һәм башка төр таба ризыклары белән тәэмин итте. Директор урынбасары Нәфикъ Юсупов ресторанны товар һәм башка төр кирәк-яраклардан өзми ташып торды.

Ресторанның сату-сәүдә эшләре туктаусыз һәм уңышлы барсын өчен кондитер цехында һәм ресторан кухнясындагы, шул исәптән, филиаллардагы эреле-ваклы техника һәм җиһазларның төзек хәлдә булып эшләп торулары, ресторан инженеры Мансур Зариповка йөкләнгән. Данлыклы КАИны тәмамлаган, техниканы һәм электротехниканы биш бармагыдай белгән, 30-32 яшьләр тирәсендәге бу күндәм кеше, техника белән беррәттән, сәнгатьне дә яхшы үзләштергән. Ул әле меховщиклар клубында, композитор Рәшит Абдуллин оештырган «Сәйяр» труппасының солисты да иде. Шуңадыр, холык-фигыльләребез һәм уй-фикерләребезнең тәңгәллеге безне берләштерде. Без бер-беребезне аңлап, тырыша-тырмаша эшләрне җайга салырга керештек.

Әйтергә кирәк, хуҗалык аяныч хәлдә. Коллектив таркау, тәртип юк. Кем кая теләсә, шунда китеп бара, ни теләсә, шуны эшли. Иртән эш күпләрнең баш төзәтүе белән башлануын да яшермичә әйтик.

Озак еллар буе бергә, бер трестта эшләгәнлектән, ресторан коллективы мине яхшы белә. Үземә дә алдынгылар рәтендәгеләрнең күбесе яхшы ук танышлар. Беренче көннәрдән үк ныклы хезмәт тәртибе урнаштыруга керештем. Арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит, дип, эленке-салынкы йөрүчеләрдән әкрен-әкрен арына бардык. Ә җаны-тәне белән булсынга эшләүчеләр иркен сулыш алып, үз эшләрен дәвам иттеләр. Ремонт эшләре бик авырдан булса да, көннән-көн җанлана барды. Партиянең шәһәр һәм Бауман районы комитетлары кирәкле ярдәмне һәрчак күрсәтә тордылар. Җәмәгать туклануы идарәсе башлыгы Кашиф Ибәтуллин да еш кына килеп, йә булмаса урынбасары Трифонов Фёдор Кузьмичны җибәреп, эш барышын һәрдаим күзәтеп торды. Бөтен кирәк-ярак белән булышты.

Җәяүле юл барыр, тәвәккәл таш ярыр, диләр. Күмәкләшеп тырыша торгач, бер ел дигәндә, РСУ эшчеләренең тырыш хезмәте, үз һөнәрләренең чын осталары булган Татарстан Худфонд сәнгать әһелләре, Мәскәү рәссамнары белән берлектә, «Казан» ресторанын элеккеге буржуаз Россиянең данлыклы купец ресторannары көнләшерлек итеп, ефәк, хәтфәгә төреп, алтын-көмеш белән бизәде. Борынгылыгын саклаган хәлдә, «ретро» стилендәге совет ресторанны барлыкка китерелде. Һәр дүрт залы, үзләренә генә хас купшылык, зиннәтле бизәлешләре, искиткеч сәнгать әсәрләре белән сокландыргыч кызыл, яшел, зәңгәр, алсу төстәге заллар булып, бер-берләреннән аерылып торсалар да, азәрбайҗан шагыйре мәшһүр Низаминың «Җиде гүзәл»ен чагылдырган бер әсәрнең дүрт бүлеге булып, тирән эчтәлекле һәм күркәм иделәр. Ресторанибыз картиналар галереясын хәтерләткән музейга әверелде, менәтерә.

Гаҗәеп осталык белән Казан шәһәре туграсы сурәтләнгән ишек тоткаларыннан башлап, фойедагы тылсымлы гүзәллек, мәхәббәт алиһәсе сыны сихерләп, күңелне әсир итә. Икенче катка сузылган яшел келәм ирексездән сине ресторан оҗмахына алып менәр. Ә анда масус заказ белән эшләнгән, бизәкле ашъяулык бөркәнгән затлы приборлар һәм чәчәкле вазалар куеп бизәлгән өстәлләр каршы алыр. Шәһәребезнең энәдән-җептән киенгән иң яхшы официантлары, ресторанибыз пешекче, кондитерлары уйлап тапкан һәм иң югары бәһа алган ризыклары белән сыйлар.

Ресторанибыз, рәссамнар күрергә теләгән люстра-бра, төрле рәвештәге яктырткыч лампалар нурында коенып, коеп эшләнгән искиткеч зифа буйлы нәфис антик сыннар белән балкып, витражлы тәрәзәләренең зиннәтле чаршауларына төренеп, Казаныбызның мактанычлы горурлыгына әверелде.

* * *

Бөтен ресторан халкы дәррәү килеп, ресторанны тантаналы рәвештә ачарга әзерләнгән көннәрнең берсендә Фёдор Кузьмич Трифонов сүз катты: «Син эшеңне чын егетләрчә, татар халкына хас тырышлык белән, оятка калып, йөз кызартырга туры килмәслек итеп, намус белән башкардың. Афәрин! Бу, чыннан да, мактауга һәм хөрмәткә лаек, искиткеч хезмәт булды.

Ләкин безнең заманда, яхшы җитәкче булып, эшеңне дәвам итәр өчен бу сыйфатлар гына аз. Хәзер эшен белеп эшләүчеләргә кытлык юк диярлек. Алар әнә чират торалар. Хәзер югарыда утыручы абзыйлардан берәрсенең туганы яисә әшнәсе булып, аның сине саклап, яклап торучы кешең булуы мөһим. Ә синең шундый, кем әйтмешли, «йонлач кул»ың бармы?

– Андый кешем юк.

– Минеке дә юк.

– Бүген шундый кешеләр заманы. Колхоз көтүен ышанып тапшырырга ярамаган булдыксызларның җитәкче булулары куркыныч.

– Дәүләтне аудармагайлары...

– Ә бит нәкъ шундый булдыксыз кешеләрнең берсе сине алыштырырга җыена кебек. Әйтүләренә караганда, синең урыныңа, обкомның да, Кремльдә утыручы агайларның да үз кандидатуралары бар икән. Ишетәсеңме?

– Ишеткәләдем. Ләкин ул хәбәрләр мине бер дә борчымый. Һәр эшне үз һөнәр ияләре җитәкләргә тиештер.

– Һай, дөрес фикер йөртәсең дә үзең. Син мине тагы бер кат сокландырдың. Афәрин. Дөньяга җәмгыять күзлегеннән караучы киң карашлы кеше икәнсең.

– Өзергә бәзер булып, бернинди борчу-мәшәкатьсез генә директор кәнәфиендә корсак киереп утырырга теләүчеләр аз түгелдер. Минем урынга дәгъва кылучылар үзебезнең трестта да бардыр. Мин моңа бер дә пошынмыйм. Киресенчә, шатланам гына. Димәк ки, югары партия органнары рестораннар трестында партия комитеты булдырып, дөрес эшләгән.

– Килешәм, – ди Федор Кузьмич, әңгәмәне дәвам итеп. – Тик шул ук партия органнарының мәктәп баласы кебек өтәләнә-кабалана, үзләренең дөрес карарларын юкка чыгарып, партия комитетын бетереп ташлаулары аңлашылмый. Кем алдында акланырга теләде икән алар, чираттагы хаталарын ясап? Мин моны җитәкче коммунист буларак әйтәм. Чөнки югары партия органнарының бу гамәлләре бернинди мантыйкка сыймый.

– Анысын киләчәк күрсәтер. Ә менә партия комитеты, башлангыч партоешмалар белән берлектә, шәһәребезнең күренекле рестораннарын җитәкләргә лаек кадрлар тәрбияли алган икән, предприятиеләрдәге башлангыч партоешма секретарьлары һәм, мин дә, партия комитеты секретаре буларак, җил куып йөрмәгәнбез икән – бу инде, һичшиксез, трест партоешмасының күркәм эш нәтиҗәләре, аның асыл хезмәт җимешләре һәм намус горурлыгы.

– Дөрес сүзгә җавап юк. Сүзләрең хак. Безнең идарә җитәкчелеге дә шушындый ук фикердә. Трестның менә дигән үз кадрлары була торып, «Казан» ресторанын директоры үз урынында яхшы гына эшләп торган хәлдә, нигә әле читтән директор эзләргә? Руслар әйтмешли: «шило на мыло» алыштыруның нигә кирәге бар? Бу бит акылсызлык бәласе була, – диде Фёдор Кузьмич, канәгатьсезлек белдереп.

– От добра добра не ищут, дип тә әйтәләр. Ләкин син әйткән акылсызлык галәмәтләре туктаусыз кабатланып тора. Һәм моңа беркемнең дә исе китми. Ул безнең көндәлек тормышыбызның аерылгысыз бер гадәтенә әверелеп,

каныбызга сеңгән, уй-фикерләребезне яулап алган. Без әнә шул мәнсез гадәт буенча эшнең башыннан түгел, еш кына ахырыннан тотынабыз. Эшләп бетергәч кенә, хатабызны аңлап, фидакарь тырышлык белән хатабызны төзәтергә керешәбез.

– Һәм без аны милли горурлык дип саныйбыз. Чөнки без – акыл белән аңлый, аршин белән үлчәп булмый торган халык дип аталабыз. Шуңа күрә без тик тә тормыйбыз, эш тә тоҗырмыйбыз. Күп сөйлибез, аз эшлибез...

– Шунысы гаҗәп: барлык бу хата-кыланмышларыбыз ил җитәкчесенең һәм эреле-вaклы түрәләрнең хәер-фатихасы белән тормышка ашырыла бит. Мисал өчен, әлеге дә баягы, үзебезнең хәлләрне алыйк, ди. Әгәр ресторанны бер ел буе тузанга батырып тотканчы, башта ук аны төзәттереп, киләчәктә үзе директор булып калырдай кешене билгеләргә иде бит. Ул адәм, сәүдә эшенең белгече буларак, ресторанны үз тәкъдимнәрен кертеп, әллә кайчан ремонтлаткан булыр иде. Борчу-мәшәкатьләр дә кимер иде.

– Шулай булырга тиеш иде дә бит...

– Димәк, минем «Казан» ресторанына директор итеп билгеләнүем югары партия органнарының, әлеге дә баягы, без әйткән акылсызлыкның күзгә күренеп торган хаталы бер чагылышы, дисәк, дөрес булырмы?

– Бу очракта дөрес булыр дип уйлыйм.

– Алар миңа трест партия комитетын таркату белән беррәттән, аның секретаре булган Рәис Сафинга, үз дәрәҗәсенә тәңгәл килгән, үз профилендәге эш урыннары тәкъдим итәргә тиеш иделәр. Эшнең ахырыннан түгел, ә башыннан башлаган булсалар, ул чагында бүреләр дә тук, сарыклар да исән калыр иде. Бүгенге ыгы-зыгы да булмас иде. Мин дөрес әйтәмме?

– Нәкъ шулай. Ләкин шушы рәвештә яшәеш дәвам итсен өчен, ике якның да бер-берләренә карата намуслы булулары шарт. Алдаусыз, ялгансыз рәвештә бер-берләрен ихлас хөрмәт итүләре мөһим. Хаҗәте калмагач, кешене генә түгел, хайваннарны да шлак сыман чыгарып ташлау – җинаять, гаделсезлек.

– Кайчак үземнең дә аптырашта калган чакларым булды. Шундый авыр вакытларымда хәлемә хәлдәш булып, тормышымны лаеклы дәвам итәргә мөмкинлек тудырган хезмәттәшләремә чиксез рәхмәтлемен. Алар мине, амбразурага ташланган каһарманнар сыман сакладылар, якладылар. Бер карусыз, көнне төнгә ялгап эшләделәр. Һәм, әлбәттә, һәрчак ярдәмчел кочагына алып, миңа ярдәм итеп, барлык мәсьәләләрне уңай хәл итүдә зур булышлык күрсәткән җәмәгать туклану идарәсе хезмәткәрләренә, бигрәк тә сиңа, кадерле Фёдор Кузьмич, ихлас күңелемнән рәхмәтләремне әйтәмен. Сау-сәламәт бул.

– Үзеңә дә рәхмәт. Үзе җаны-тәне белән бирелеп, булсынга эшләгәннәргә ярдәм итү авыр эш түгел. Без барыбыз да уртак максатка хезмәт итәбез.

– Шулаен шулай да. Ләкин шул уртак эшкә таяк тыгучылар да бар бит. Алар, әнә, ресторанның һаман да ташландык хәлдә булып, элеккечә тузанга батып ятуына да борчылмас иделәр кебек.

– Без барысын да беләбез. Андыйлар бар һәм булачаклар. Һәркем үз

язмышын үзе яза. Син аңарга бер дә аптырама. Бернәрсә дә эзсез генә үтми. Барысы өчен дә җавап бирергә туры киләчәк.

– Эш тәкъдим итми генә, кешене куу – хезмәт кодексын бозу булганлыктан, бер иш җитәкчеләр тапшырган эшне башкара алмауны сылтау итеп, мине хурлыклы рәвештә җибәрү иде уйлары. Ләкин хыянәтчел ниятләре, мәкерле планнары тормышка ашмый, кысыр хыял булып калды. Хәзер инде алар, минем сәүдә буенча махсус белемем юкны дәлил итеп, үзләренең кешесен директор итмәкчеләр.

Яңа җитәкчелек өчен минем кирәгем бетте. Ярар дим, минем дә тамырларым трестка берекмәгән. Күптәннән инде күңелемә хуш килгән эш эзлим. «Гаугалы йорттан бәрәкәт кача», диләр, эшләр мондый күңелсез төс алган шикле урыннан вакытында китүең хәерледер. Ресторannarда булып үткән маҗаралардан исән-имин булып, үз калебемдә мине саклап торган язмышыма баш иеп, миңа эчкерсез ярдәм иткән коллективыма ихлас күңелемнән чиксез рәхмәтләремне әйтәм. Һәрчак теләктәшлек күрсәткән сиңа да, Фёдор Кузьмич, зур рәхмәт. Барыгыз да исән-сау булыгыз.

– Камытны эш атына киертәләр. Син дә эшсез калмассың – диде Фёдор Кузьмич китеп барышлый.

– Иншалла, – дидем мин.

* * *

Ниһаять, ачылырына берничә көн кала ресторанныбыз кырмыска оясына таяк тыккандай булды. Официантлар, администраторлар, пешекче-кондитерлар, производство җитәкчелеге, сменаларга бүленеп, ресторанны чүп-чардан арындырды. Юды, сөртте, паркет идәннәребезне киез әйберләре белән ышкып ялтыратты. Мәш килгән ресторан кияү көткән гүзәл кәләш бүлмәсенә охшап калды.

Иртәгә комиссия киләсе көннең төнендә, күпләребез үз урыннарында калып, ресторанны саклап уздырды. Ләкин язмыштан узмыш юк икән. Иртә белән кызыл залдагы берничә картиналарның аскы ягы бозылганлыгын күреп, телсез калдык. Чәчләребез үрә торды! Кемдер аларны, юри ни беләндер сызгалап киткән иде. Ресторан халкы бу вәхши вандалның кабахәтлеген күреп, тораташ булып катты. Шушы кадәр әкияти гүзәллекне, картиналардагы тылсымлы күркәмлекне бозарга, кемнең шакшы кулы күтәрелгән? Кемгә үч итеп эшләнгән бу акыл белән аңлап булмас, оятсыз эш?

Соңгы елларда борчып, үзен бик белгертә башлаган йөрәгем чәнчеп-чәнчеп сыкрый башлады. Калак сөяге астын нидер боргычлап куйды. Тыным кысылды. Күз алларым караңгыланып китте. Аңымны җуеп, мин идәнгә ауганмын...

Хастаханәдән чыкканда, мин инде ресторан директоры түгел идем. Картиналардагы сызыкларны, шул ук көнне, рәссамнар килеп, төзәткән һәм икенче көнне комиссия, ресторанга югары бәя биреп кабул иткән. Ә мин ул сызыкларны кемнәрнеңдер янаулары, каршылыклы мөнәсәбәтләрен чагылдырулары дип кабул иттем. Кемнәрдер Таһир Нәбиевичка карата булган ачуын, беткә үч итеп, тунын утка яккан

агай кебек миннән алуны кирәк тапкан. Аяк астыннан чыккан бу нахак бәладән бары тик югарыда утырган берәр абзыйның минем турыда әйткән яхшы сүзе генә коткара алыр иде. Ләкин андый шәфкатьле, дөреслекне әйтүче кешеләрем юк иде шул. Шуның өстенә хатынымның да үзен тәрбияле тотмавы һәрчак аяк чалып килде. «Үз гаиләсендә тәртип булдыра алмаган...» дигән һәм башка яла ягулар, гайбәт сүзләр барыр юлымда еш кына киртә булдылар.

Хәер, Биектау районының ул чактагы кырыс, ләкин гадел, үз эшенә жаны-тәне белән бирелгән, чирек гасырга якын районның беренче секретаре вазифасын үтәп, лаеклы дәрәҗәгә ирешеп, республикабызда дан казанган, медаль-орденнар иясе булган хөрмәтле Мортазин Габдерәхим иптәш миңа районның культура бүлеген җитәкләүне тәкъдим иткән иде югыйсә. Металл базасы янәшәсендәге урманга сыланып төзелгән яңа йорттан ике бүлмәле фатир да бирәсе иде. Ләкин әнием дә, улларым да Казанны калдырып, Биектауга күчәргә теләмәде. Мин дә Ленино-Кокушкино гыйбрәтен кабатлауны кирәк тапмадым. Вакытлыча булса да эшләп тору нияте белән җәмәгать туклану идарәсе җитәкчесе Кәшиф Ибәтуллович янына барырга булдым. Ул мине җылы каршы алды. Хәл-әхвәлләремне сорашты. Үз йомышымны әйттем.

– Безнең системада эшләү дәверендә син үзеңне сәләтле җитәкче буларак таныттың. «Казан» ресторанын республикабызның горурлыгы дәрәҗәсенә ирештердең. Комиссия әгъзалары да соклануларын яшерми, канәгать булып калды. Тизрәк сәламәтләнүеңне теләп калдылар. Дөресен әйтим, бу зур эшне башкарып чыга алмас дип уйлаган идек. Булдырдың, егет икәнсең. Рәхмәт сиңа! Эш барышында син, әлбәттә, күп кенә төзелеш оешмалары һәм башка предприятие җитәкчеләре белән танышып, үзара дустанә элемтәләр булдырдың. Тәҗрибәң дә җитәрлек. Шуларны искә алып, әллә дим, Киров районындагы «Кызыл ашханә» дип йөртелгән, озак вакытлар ябылуда торган ашханәне дә берочтан әмәлләп куясыңмы? Үзеңә ипле урын тапсаң, китеп барырсың. Тоткарлык булмас. Уйлап кара. Риза булсаң, әйтерсең, – диде Кәшиф Ибәтуллович.

## Коммунизм корбаны

*Яхшылык эшлә дә суга сал,*
*Халык белмәсә, балык белер.*
Халык мәкале

Коллектив карамагында халык телендә «Кызыл ашханә» дип исем алган бу ашханәдән тыш, «Прибой» рестораны, балык кафесы, Фрунзе урамындагы диетик ашханә кебек үзләре аерым хуҗалык булып, мөстәкыйль рәвештә эш алып барырлык җәмәгать туклануы предприятиеләре һәм барлык мәктәпләрдәге ашханә һәм буфетлар иде. «Кызыл ашханә» ябык булса да, кухня эштән туктамады. Пешекчеләр, кондитерлар әзерләгән пәрәмәч, өчпочмак, кыстыбый кебек таба ашлары, төрледән-төрле чәй ризыклары, тәм-томнар пешереп, Киров районының үзәгендәге тарихи «Кызыл капка» әйләнәсендәге киоскларда, Петров паркында сату иттек. Ә инде шимбә, якшәмбе көннәрендә халыкның гадәти ял итү урыннарында, машиналар

белән барып, сату оештырдык. Аккош күле буена тезелеп киткән барлык ашату-эчертү урыннары да безнекеләр булып, аларда да җәен-кышын эш туктап тормады.

Әйткәнемчә, «Прибой» рестораны, балык кафесы, диетик һәм «Кызыл ашханә»нең үзендә бик акрын барган ремонт эшләрен очлап чыгу һаман сузылды. Йә төзелеш материалларының булмавы, яисә башка сәбәпләрнең чыгып торулары эшкә тоткарлык ясады. Киров районында Бауман районындагы кебек ярдәм юк иде шул. Таныш-белеш бар-барын, ләкин аларның ишекләрен киң ачып кереп, Баумандагылардан алган кебек ярдәмне өмет итеп булмый. Кергән очракта да: «Сезнең үз җитәкчеләрегез бар, шулар кайгыртсын», – дип кенә җибәрәләр. Ә менә җыелышып килеп, бушка ашап-эчеп китәргә дигәндә, без, безнең ашлы табын кирәк.

Районның ашханәләр тресты директоры азәрбайҗан кешесе Мамедовның җитәкчелектә бернинди дәрәҗәсе булмавы да эш барышына, планнар үтәлешенә уңай тәэсир ясамады. Ул заманда планны үтәмәү – закон бозуга тиң иде. Партия кабул иткән директиваларны үтәү – һәр коммунистның изге бурычы саналды. Мондый «закон бозучылар»ны райком, горком бюроларына чакырып пешеклиләр иде. Кирәк тапсалар, партбилетыңны өстәлгә куеп китүең дә гаҗәп түгел иде. Ә бу инде – сине исемлектән сызып ташлау дигән сүз. Синең өчен социализм җәннәте ишекләре ябыла. Хәтта «Җинаять эше» ачарга да бик мөмкиннәр.

Азык-төлек базаларыннан, сөт, ит комбинатларыннан, «Заря» фабрикасы кебек тәм-том ширкәтләреннән наряд буенча бүлеп бирелгән товарларның план үтәлешен, күп дигәндә, 70 процентын гына капларга җитүе дә сәбәп һәм дәлил була алмады. «Булдырган җаен таба, булдыксыз сәбәп таба», – дип кенә җибәрәләр. Мәскәү, Ленинград кебек бай шәһәрләрдән товар ташып, тегесен җайлап, монысын майлап, күп очракта шул чорның кануннарын бозып, бик авырлык белән очын-очка ялгый идек ул планнарның.

Шулай җайлый, майлый торгач, ниһаять, без дә читтән үтә дефицит саналган һинд чәен юнәтүгә ирештек. Инде, иншалла, планнарны үтәп чыга алырбыз, әүвәле-ахыры хәерле булып, исән-имин сатып бетерергә насыйп итсен. Склад мөдире дә, производство җитәкчесе дә бер тавыштан: «Рәис Абдуллович, сату мәсьәләсен үзебез хәл итәрбез. Сез бу эштән читтәрәк торыгыз. Бәласеннән баш-аяк», – диләр.

Беләм мин аларның арт ишектән шыпырт кына таныш-белеш, туган-тумачаларына, итәк астыннан сатып ятуларын. Туктале, мәйтәм: хуш исле тәмле һинд чәеннән дары заводы эшчеләре дә авыз итсен, янәсе. Тиз генә бер сатучыны чакыртып, чәйне машинага төяттем дә эшчеләр эштән чыга башлауга, проходной ишеге төбенә китереп бастырдым. Халык, томырылып, сәүдәбезгә ябырылды. Ә мин кешеләргә игелекле эш кылуымнан канәгатьләнеп, эш бүлмәмә кайтып утырдым. Кәефем шат, күңелем күтәренке!

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, яныма, рөхсәт-мазар да сорамастан, пенсия яшендәге өч кеше килеп керде. Урын тәкъдим итүемә дә исләре китми, эшем кешеләре кебек сорау яудырырга керештеләр:

– Дары заводы проходное ишеге төбендә һинд чәен сезнең кешеләрегез сатамы?

Рус сүзләрен вата-җимерә сөйләвенә караганда, ат дагалаганда, ботын кыстырган бака кебек түрә булу кулыннан килмәсә дә, чабатасын түргә эләргә маташкан бу бәндә, бронь ярдәмендә калып, сугыш вакытында шушы заводта эшләгән кеше булырга охшаган. Аның кара-кучкыл битендәге эленеп куелган кер сыман салынып төшкән, кызгылт күзләре әле айнырга да өлгермәгән.

– Әйе, безнекеләр.

– Син кемнән рөхсәт сорадың? Нигә чәйнең кабына тиешсез өстәмә куеп сатасыз? Бу совет сәүдәсе кагыйдәләрен бозу була. Син аның шулай икәнен беләсеңме?

– Беләм.

– Тамагым чатный. Бар, су алып кер әле, – диде читтә торган иптәшенә миннән сорау алучы.

– Белгәч... Димәк, һәр каптан кергән чумара акчасын кесәңә салырга уйлаган идең, шулаймы?

– Юк. Без кесәгә салу өчен эшләмибез. План тутыру өчен эшлибез. Һәм мин ул тиеннәрне бик теләсәм дә, ала алмас идем. Чөнки һәр товарга накладной языла, алар бухгалтерия аша үткәрелгән. Ә инде өстәмә куюның сәбәбе: чәй товар буларак сатылырга тиеш түгел. Ул планга кухня продукциясе исәбеннән керергә тиеш. Акчасы тегеләй дә, болай да дәүләт кесәсенә керә. Аңлата алдыммы?

– Димәк, хезмәт куймый гына план үтәп, керем алу була. Дөресме? – диде читтәрәк басып торганы.

– Юк. Без халыкны кибеттә сатылмаган әйбер белән шатландырмакчы идек.

– Барысы да аңлашылды, – диде татар кешесе, иптәше алып килгән суны шешәсеннән йотлыга-тончыга чөмереп.

Ул арада милиция бүлегеннән дә чандыр гәүдәле ханым килеп җитте. Барысы да өстәл тирәли утырышып, миннән сорау ала башлады:

– Чәйне бәя өстәп сатарга сез рөхсәт иттегезме?

– Мин.

– Сатучыга сез сатарга куштыгызмы?

– Мин.

– Бухгалтерия накладнойны сезнең рөхсәт белән яздымы?

– Минем рөхсәт белән.

Тагын сораулар бирелде. Бөтен җаваплылыкны үз өстемә алып, милиционер ханым протокол язды. Халык контроле әгъзаларыннан да, шаһитлар буларак, кул куйдырып алгач чыгып китте. Аның артыннан картлар да иярде.

Һай, нинди зәһәр, горур иде алар! Ул миңа карап, хәйләкәр елмаю, дисеңме, зур җинаятьчене тоткан сыман кукраеп, күкрәкләрен киереп торулары, дисеңме, чыгып барышлый, бүлмә ишегенә аяклары белән тибеп, хушлашмый да китеп барышлары, дисеңме... «Знай наших!», имеш. Берлинны алган каһарманнар да болай ук кыланмаганнар булыр. Дөреслектә, бу тәртип «сакчылары»ның барысы да диярлек дары исен

шушы дары заводында иснәп, пенсиягә чыккан эшчеләр иде ләбаса. Алар акны карадан аера белмәсәләр дә, үз кирәкләрен арткы ишектән алырга остарган картлар иде бит.

Нәрсә өчен диген әле? Бу инде «Ит яхшылык, көт явызлык»ның классик үрнәге. Югыйсә, кануннар буенча тыелган гамәл саналса да.

Бу хәлләрдән соң өч ай тирәсе вакыт узып китте. Теге милиция хезмәткәре мине әледән-әле чакыртып, һаман да шул бер үк сорауларны кабатлап, янә беркетмә язды, аңа миннән кул куйдырып, кайтарып җибәрә торды. «Бу ни дигән сүз була соң инде?» дигән соравыма каршы: «Үзем дә белмим нәрсә буласын. Күрәсең, сез кемнедер бик нык рәнҗеткән булгансыз. Хәзер ул сездән үч алырга тели. Әллә инде башка берәрсенең сезнең урыныгызга утырасы киләме? Белмим. Тик ул кемсә гади кеше түгел. Һәм теләгенә ирешми тынычланмас та кебек... Менә шулай, Рәис Абдуллович», – диде тикшерүче ханым, миңа кисәтү ясап.

Менә сиңа табышмак! Менә сиңа аяк астыннан чыккан бәла! Яхшылык эшлим дип, явызлыкка тап булу! Нинди гөнаһ, хаталарым өчен мин җәзага тартылам? Әллә холык-фигылем, уй-фикерләрем, дөньяга карашым белән тәңгәл килмәгән кешеләр арасына кереп адаштыммы? Нидә минем ялгышым?

Үзенең яман максатына ирешү өчен башкаларны оста файдаланып, мәкер белән агуланган хәйләкәр кеше кем ул? Ни тели ул миннән? Сәбәбе нидә? Әгәр инде...

Хәтеремдә. Көннәрдән бер көнне мине горкомның сәүдә һәм җәмәгать туклану бүлеге мөдире Җантимеров Рәшит Бариевич чакырды. Килдем. Ул мине бүлмәсендә утырып торган, ике ягымлы йөзле чибәр ханым белән таныштырып, аларның Совет һәм Ленин районнары азык-төлек сату оешмаларының профсоюз комитеты рәисләре икәнен әйтте. Без өчәү шәһәр җиләк-җимеш, яшелчә сату трестының кибетләрендә булып, коллективларда үткәрелергә тиешле иҗтимагый-сәяси, тәртип-тәрбияви чараларның дәүләт планнары үтәлешендә уңай чагылышлары хакында белешмә әзерләргә тиеш идек.

– Сезгә нинди белешмә кирәк? – дидем татарчалап.

– Дөресен тасвирлаган белешмә, – диде Җантимеров. Һәм без, трестның шәһәр буенча таралган кибетләрендә булып, трест җитәкчелеге һәм халык белән күрешеп, әңгәмәләр корып, трест эшләренең мактанырлык түгел икәнен белдек. Гамәлдән чыгарылган яшелчәләрнең арзан бәядән предприятие ашханәләренә озатылуын күрдек. Иҗтимагый-сәяси, тәрбияви чаралар аена бер мәртәбә – ай ахырында, планнарның үтәлешләренә йомгак ясаганда гына телгә алынуына гаҗәпләнмәдек.

Белешмә язарга керешкәч, чукындырылган кырым татары, мәшһүр тарихчы-галим Карамзинның патша хәзрәтләреннән: «Сезгә нинди тарих кирәк?» – дип сораганы искә килеп төште. Чөнки бөтен сорауларга да тискәре җавап язып булмый лабаса. Рус тарихын яхшы белгән Карамзин әфәнде дә күрше-тирәдә яшәүче башка халыкларның җир-суларын яулап алу, кан-яшь коюдан туктамаган, бөекдержавачыл шовинизм рухы белән агуланган дәүләт турында әйтер сүзе булмагач, Россия тарихын һәртөрле

риваятьләр, әкиятләр белән чуарлап бизәргә мәҗбүр булган. (Моны белмәүчеләр бик сирәктер).

Без язып, өчебез дә һәм җиләк-җимеш һәм яшелчә тресты җитәкчелеге кул куйган белешмә белән горком җитәкчелеге дә танышканнан соң, тикшерү вакытында хастаханәдә дәваланып яткан җитәкче партия алдында җитди җавап тотар, катгый кисәтү алыр дип уйлаган идек. Ләкин алай булмады.

Кечерәк буйлы, чандыр гәүдәле, эчкә батып кергән кысынкы күзле, зәһәр карашлы, сипкелле (сипкелле булса да йөзе ямьсез дә түгел үзе...) җитәкче ниндидер тылсымлы әфсен укып, гаҗәеп могҗизалар ярдәмендә матур гына итеп, судан коры чыкты. Алай гына түгел, аны тәртипле, тәрбияле дип мактап, зурлап, рестораннар трестына җитәкче итеп билгеләп куйдылар.

Дөнья искиткеч серле шул. Шушы кеше «ярдәме» белән мин ресторан директоры вазифасыннан китәргә мәҗбүр ителдем. Инде монда да ул, бүрәнә аша бүре куып, мине ээзәрлекли булып чыкты. Бернәрсә дә эзсез үтми шул. Ул синең күңелеңә язылып бара. Гомереӊ буе аңа җавап эзлисеӊ. Дөрес яшәдемме? Үземнән соң нинди мирас калдырам?

Көннәрнең берендә янә милиция бүлегенә чакырттылар.

– Ниһаять, шаһитлардан сорау алып, аңлатмалар яздыртып, тикшерү эшләрен төгәлләдек, – диде минем «Эш»не алып барган ханым.

– Йөкләнгән вазифаларыгыздан законсыз файдаланган өчен бер елдан җиде елга кадәр, совет сәүдәсе кагыйдәләрен бозган өчен өч елдан биш елга кадәр хөкемгә тартылуыгыз ихтимал. «Эш»егезне хәзер үк судка тапшырачакбыз. Суд утырышы иртәгә иртәнге сәгать унда башлана. Менә чакыру кәгазе, соңга калмый килегез. Ә хәзер «Эш»егез белән танышуыгызны һәм судка чакыру кәгазе алуыгызны раслап, бу кенәгәгә кулыгызны куегыз», – диде тикшерүче ханым.

Иртән эшкә килүемә, «Сине прокуратурага чакырдылар», – диде производство җитәкчесе, гаепле кеше сыман карашларын аска төбәп.

Ни булса, шул булыр, дигән битараф бер тәвәккәллек белән закон сакчысының ишеген барып ачтым. Ул үз каршыннан урын тәкъдим итте.

– Мин сезнең хакта кирәк кадәр мәгълүмат тупладым, – диде ул, исәнләшеп, бер-беребезгә хәерле иртә теләгәннән соң. – Биографиягезне дә өйрәнеп, тормыш һәм хезмәт юлыгызны күздән кичердем. Дөресен әйтим, сезнең турыда яхшы фикердә калдым. Кайда эшләсәгез дә, вазифаларыгызны тырышып, чын коммунистларча, намус белән башкаргансыз. Минем бу фикерләрем белән Кафил Әмиров та уртаклашты. Сезне яхшы кеше, ышанычлы иптәш дип саный. Сезгә уңай бәя бирә. Тик үз эшен эшләми, диде.

Әйе, заманында рестораннар җитәкчесе Таһир Хәсәновны ришвәт алуда гаепләп, тикшерү эшләре алып барган Кафил Фәхрази улы Әмиров янында берничә мәртәбә миңа да булырга туры килгән иде. Юк, Хәсәновның гайбәтен сатып, исемен пычрату өчен түгел, аның хакындагы фикеремне прокурорга җиткерү өчен. Кафил әфәнде миннән, партком секретаре буларак, коллективтагы вазгыятьнең торышын, тәртип-тәрбия мәсьәләләренең ни хәлдә булуын сорашты һәм Хәсәновның иҗтимагый-

сәяси мәсьәләләргә карашын, аның бу җитди проблемаларны үткәрүдәге булышлыгы һәм парткомга күрсәткән ярдәме белән кызыксынды. Бер очтан Хәсәновның әдәп-әхлак ягын, үз-үзен ничек тотуын да сораштырды. Мин үз чиратымда, трест җитәкчесенә карата яхшы фикердә булуымны, аның үз эшен белеп, үтә тырышып башкаруын, эшкә кагылышлы мәсьәләләрдә принципиаль булуын әйттем. Гаепләнүендә шигем барлыгын да искәрттем.

Әйе, трестның элеккеге җитәкчесе Таһир Хәсәновның ришвәтчелектә гаепләнеп кулга алынуы, «Волга» ресторанны директоры Юрий Кошелёвның һәм берничә ресторанның производство мөдирләренең дә кыңгыр эшләре фаш ителеп, суд каршына басулары – трест һәм предприятие җитәкчелегенә карата шик тудырды, шөбһәләнергә җирлек бирде. Мине дә җиз иләк аша үткәрделәр. Әгәр энә очы кадәр гаеп тапсалар да, һичшиксез, кулга алып, суд каршына бастырыр иделәр. Чөнки шулай булуын теләүчеләр дә юк түгел иде. Шөкер, эш урынымнан начар ният белән файдалану, банкет залларында кунак булып типтерү кебек хаталарым булмады. Намусымны чиста хәлдә тотарга кирәклеген һәрчак истә тоттым, шайтан коткысына бирелмәдем. Шушы күркәм сыйфатларымны истә тотып, трест коммунистлары ышаныч белдерде. Шул елның көзендә мине бишенче мәртәбә үзләренең ышанычлы җитәкчеләре итеп сайлап куйдылар. Хуҗалык җитәкчесенең гаебе билгеле булып, эшеннән алына калса, бигрәк тә суд каршына баскан очракта, партия оешмасы секретаре, һич гаебе булмаса да, гадәт буенча эшеннән азат ителә. Һич югында кисәтеп, шелтә бирелә иде.

Әнә шул, үзләрен Алланың кашка тәкәсенә санаган тәкәббер кемсәләр мине эшемнән китәргә мәҗбүр итте. Шул каһәр сукканнар караңгы бүлмәдә булмаган кара мәчене тоттык дип, мине төрмәгә утыртырга маташа.

Прокурор бу хакта яхшы белгән, тиешле урыннардан уңай характеристика алган, күрәсең. Ул сүзен дәвам итте.

– Сезнең намуслы кеше булуыгызны, үз мәнфәгатьләрегезне кайгыртып, пычрак эшләрдә катнаша алмавыгызны аңладым. Ләкин кайчак намуслы кешеләрнең дә хаталанган чаклары була. Әйтик, хәзерге вакытта менә сез, гафу ителмәслек җинаятьтә гаепләнәсез. Әгәр аны чынлыкта, үзегезгә акча эшләү нияте белән кылган булсагыз, чәй саткан акчаларны башкалар белән бүлешеп, кесәгезгә салсагыз, без хәзерге кебек сөйләшеп тә утырмас идек. Мәсьәләне суд хәл итәр иде. Менә шулай, кадерле иптәш Сафин. Йә, инде нишлибез?

Бүлмәдә шомлы тынлык урнашты. Мин чатнап кипкән авызымны ачып, катып калган телемне әйләндереп, берни әйтә алмадым. Башымны игән хәлдә тынсыз калдым. Гаепсезлегемне әйтеп акланырга тырышу урынсыз иде. Ул болай да күренеп тора бит инде. Әгәр, прокурор әйтмешли, чәй саткан акчаларның бер тиененә кагылсак та, монда чакырып тормаслар иде.

Ниһаять, тынлыкны прокурор бозды.

– Сезнең намуслы кеше булуыгызны искә алып, исемегезне каралтмауны дөрес санап, бөтен җаваплылыкны, прокурор буларак, үз өстемә алам. Һәм бу «Эш»не ябарга уйлыйм, – диде ул, миңа карап.

– ...

– Әгәр үзегез риза булсагыз, әлбәттә. Тик бер шарт белән: бүтән беркайчан да сәүдә системасында эшләмәскә сүз бирергә тиеш булсагыз. Чөнки сез сәүдә кешесе түгел, сәнгать кешесе, әдәбият әһеле. Сезнең ишеләрнең сәүдә рәтләрендә буталып йөрүенең һич кирәге юк. Сезне батырырга теләүче дошманнарыгыз күп һәм алар кайчан булса да, үзләренең мәкерле кара эшләрен эшләячәк. Бу комедияне кем әвәләде дип уйлыйсыз? Әнә шул, сезнең бу эштән китүегезне теләүчеләр. Алар «Эш»не ахырына кадәр җиткерүне таләп итеп, югары органнарга шикаятьләр язудан туктамаячак. Сезне Хәсәнов артыннан җибәрмәкче булалар. Әгәр миңа биргән вәгъдәгезне бозып, сәүдә эшенә керешәсез икән, анда сезне тагы да зуррак бәла-казалар урап алачак. Ул вакытта инде сез болай гына котыла алмассыз. Менә бу «Эш»егезне дә искә алып, гаепнең зурысын әмәлләячәкләр. Сәүдәдә сезнең кирәгегез юк. Ул – сәүдә эшләренең асылын, без белмәгән яшерен серләрен белгән, кирәк чакта, күзеңә туры карап: акны – кара, караны ак дип әйтә алучылар эше. Аның язылмаган үз кануннары, үз гадәтләре бар. Аларны үтәү өчен сәүдәгәр булып туу кирәк. Аларча уйлый, фикер йөртә, аларча уйный белү мөһим. Шунда гына син сәүдә кешесе була алачаксың. Аңладыгызмы?

Көтелмәгән бу хәлдән, бу хакыйкатьне ишетүдән мин тагы бер тапкыр өнсез калдым. Шатлыктан башым әйләнеп китте. Тотлыга-тотлыга, башка беркайчан да сәүдә системасында эшләмәскә сүз бирдем. Мине бу хурлыклы бәладән йолып калучы бу изге күңелле, чын кешегә ихлас рәхмәтләремне әйттем. Күңелем йомшарып китте.

– Тынычланыгыз. Мин сезгә ышанам, – диде прокурор. Ә хәзер барыгыз, комбинат директорының эштән китүегез турындагы приказын миңа китерегез.

Кат-кат рәхмәтләремне әйтеп чыгып барышлый мине туктатып:

– Менә сезгә бер визитка. Әгәр кирәксенсәгез, минем исемнән, шалтырата аласыз, – диде ул.

Моңарчы күрмәгән-белмәгән изге күңелле, мине анкетам буенча гына белгән кеше нәселебездә булмаган кара тамгадан, хурлыклы исемнән коткарып калды. Гаебем булу-булмавы – икенче мәсьәлә. Анысын суд күрсәтер иде. Иң кадерлесе – хакыйкатьнең өстен чыгуы! Нинди генә чор булмасын, дөреслекне яклап көрәшүче саф күңелле, батыр йөрәкле, халыклар язмышын үз өсләренә алудан курыкмаучы каһарман затлар, игелекле фидакарьләр билгели шул бу тормыш агышларын.



*Гөлназ Нуриева белән мин әүвәл Чаллы шәһәрендәге Нур Баян исемендәге гимназиядә танышкан идем. Алабугада яшәп, иҗат белән җенләнгән әлеге яшь ханым инде ул чакта ук авторлык «Сабыйга» программасын булдырып, мәчет каршында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар теле дәресләре укытуы, онлайн татар теле дәресләре алып баруы хакында сөйләгән иде. Язучылар берлегенең Яр Чаллы төбәге бүлеге җитәкчесе – остазы Факил Сафин да Гөлназны өметле шагыйрә буларак таныштырды, тәүге шигырьләренең «Көмеш кыңгырау» битләрендә урын алуын, шәһәрдә булган төрле әдәби чараларда актив катнашып килүен искәртте. Баксаң, ул үзе Яр Чаллы кызы икән. Факил абый аны шәһәрнең 52 нче татар мәктәбе укучысы булган чагыннан ук белә булып чыкты. Ул инде «Алтын каләм», «Шигъри сабантуй», «Иделем акчарлагы», «Яңа дулкын» кебек яшь иҗатчыларны барлаучы төрле проектларда да катнашырга өлгергән, Казанда КФУның татар филологиясе һәм тарихы буенча югары белем алып, төрки телләр юнәлеше буенча филология магистры булуга ирешкән, шигырьләре инде «Ялкын», «Идел», «Мәйдан» журналларының битләрендә урын алырга өлгергән. Аның әлеге шигъри шәлкемнәрен исә безгә шагыйрә Лилия Гыйбадуллина юллады. 1991 нче елның 21 нче маенда дөньяга аваз салган шагыйрәбезнең шигъри аһәңен «Казан утлары» журналын укучыларга да ишетер вакыт җиткәндер, шәт. Хәерле сәгатьтә, шигърият мәйданына рәхим ит, Гөлназ!*

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ**

# Гөлназ Нуриева

# СОҢАРГАНЧЫ, БЕР ТЫН АЛСАҢ ИДЕ...

## Әманәт

*Яралтучы Раббың исеме белән укы!*
Коръән, 96:1

Бүген төштә Җәбраилне күрдем:
колач җитмәс канатларын җәйгән;
Күк капусын урталайга ярып,
зың тезелә сүзе сәйлән-сәйлән:

«...Кешелекнең бер төрткесе ул – син,
гамәл булып эзең тама Җиргә.
Җан яралып, күңеләңә ингән
сүз әйтергә җибәрелдең миргә.

Син рәсүле түгел кавемнәрнең,
пәйгамбәрлек Раббың насыйп итмәс.
Хак сүзләре туры юлны саплар,
бик күпләрнең сиңа теше үтмәс.

Синең нәүбәт – бөртек-бөртек гамәл, –
уң дәфтәрең шулай тулып торсын.
Үз-үзеңне кеше итеп таптың,
Кеше булып калу җаен тап соң!..»

Җәбраилне күрдем бүген төштә...

## Азан

Бу мизгелнең кайтавазы кебек
Мәңгелекнең чыңы түгел микән?
Тарих чоңгылыннан табып алып,
Кешелеккә бирәү бүләк иткән.

Аһ-ваһларга карамаган заман,
Узган гасыр бугазыннан буган.
Сүнеп яткан утлы күмерләрне
Тергезергә яңа буын туган.

Башын түбән иеп көйли бер җан:
«Ил-көннәргә, Раббым, бирмә каза».
Таң алдыннан мизгел кайтавазы –
Манарадан ишетелә азан.

***

...Колагыңа пышылдады кемдер нидер:
«...Син түгелсең дөнья мәгъшукасы.
Күлмәгең дә бигрәк гади. Киндер.
Тавышың да артык каты түгел,
Һәм өздереп әйталмыйсың сүзне.
Усал белән усал булу яхшы, –
кыек карауччылар булса, түзмә!
Син бу гасыр өчен артык тыйнак,
китап укып, кемгә була ярап?
Хыялыйлар – башка галәм заты.
Абау инде! Хет үзеңне ярат!»
...кемдер нидер пышылдады кебек...

***

Мин башка бүгеннән. Үзгәрәм.
Дөньяның иң төсле көннәрен
ашыгып сәйләнгә тезәм дә,
урамнан чәчәкләр өзәм дә,
күгемнән йолдызлар сөзәм дә,
елмаймый яшәүдән бизәм дә –
үзгәрәм. Үзгә мин.
Хәзер мин иң шыксыз көннәрне,
үтәли яңгырлы төннәрне,
үткәннән кайтаваз өннәрне
үз итәм, –
һәрнәрсә күңелгә бик якын.
Аңласак яшәүнең чын хакын,
һәр мизгел, һәр караш, һәрбер таң
тик безнең өчен дип яралган.
Мин башка бүгеннән. Үзгәргән.
...Мин тудым бу Җиргә яңадан.

***

**1**

Бу – минем җиһаным. Бик калын китапны
бер ачам, бер ябам, – вальс бии хәрефләр, –
укырга тырышам, күзләрем камаша, –
бу нурга түз бары, түз бары.
Ә уйлар кайдадыр югары...
Бу – минем җиһаным нибары.

**2**

Бу – синең җиһаның. Дөньяның бер читен
кесәңә бөгәрләп сал да куй.
Күгеңдә йолдызлар биюгә тезелгән,
Ай белән Кояшка бүген туй.
Түм-түмгәк Җир-тупны кулыңда әйләндер;
канунда – җеп-җепкә, оч-очка бәйләнер.
Бу җиһан – синеке, әй, бәгырь!

**3**

Бик оста укчының кулында бер җәя –
Бу Галәм туктаусыз һәр секунд киңәя...
Меңләгән җиһаннар очышта.
Кисешү чигендә – Син һәм Мин, –
Үзгәрмәс бер канун тормышта...

***

*Без – җәяүле җайдак токымыннан.*
*Иярләрдән төштек, калды атлар.*
Л.Гыйбадуллина

Без бу җирне танымабыз инде:
Ничә калкып, ничә яткан илләр...
Аксакаллар корган тирмәләрдә
Үзәкләргә үтеп улый җилләр.

Бездән бизгән еллар кайтавазы:
Эндәшкәнгә – тынлык кала ятып.
Мең яшәргә йөзлекләрне җыйган
Чал Хәтернең кылын өзгән Вакыт.

Без күптәннән җайдак түгел инде:
Узды тузан куып чабышкылар.
Ә төшләргә гел әкият керә:
Җир җимертә атта безнең уллар.

Безнең йөздә – еллар салган сырлар,
Тик хәтердә – ни эз, ни адымнар.
Биштәреңне иңнәреңнән төшер, –
Ерак бабаңнарның сәламе бар:

«...сез бу җирне танымассыз инде:
Ун калыкты һәм ун ятты илләр.
Дога белән корган тирмәбездә
Уламасын иде ачы җилләр...»

Тик чашасы килә! Онытасы!
Бу ядкарьне очырасы җилгә!
Без тарихта яңа туган бүген.
Юлга чыктык... Үзебезнең илгә!

## Вакыт

**1**

Вакыт дилбегәсе кем кулында,
Күчәреннән кемнәр төшеп калган?
Әллә кемнәр төшләреңә кереп
Тәкрарлыйлар һәр төн: дөнья – ялган.

Гасыр яткан мүкле чылбырларга
Һәм күгәргән зынҗырларга ябыш.
Соңарганчы, бер тын алсаң иде;
Юкса һәр көн ыгы-зыгы, чабыш.

**2**

Китекләнгән кабер ташларыннан
Үзгә хәрефләрне берәм-берәм җыям.
Йөзлекләргә бүлгәләнгән Вакыт,
Мин дә синең күчәреңә сыям.

Тукта, Вакыт, ышан: мин дә – синең алда
Гаҗизләнеп бер тез чүккән жаның:
Соң гасырның үкчәсенә бастым,
Китаплардан беләм фаҗигасен-данын.

**3**

Дауладылар сине башкисәрләр,
Җанкыярлар буйсындырды сыман.
Гөнаһсызлар Җирдән сөрелгәндә,
Ак-карадан башка нәрсә белдең,
                                        Заман?
Тик тормыйсың, син аяусыз һаман!
Бер карасаң – яхшы, яңакласаң – яман.


**4**

Син һәркемнең – үзенеке генә,
Кешелеккә бирәү генә төсле.
«Вакытым бар! Вакытым тар!» – диеп,
Берәү фәрман бирә аслы-өсле.

Вакыт – дәва,
                    Вакыт – сихәт.
Вакыт – җәза,
                    Вакыт – михнәт.
– Вакытым юк!
– Бер мизгел бар!
– Кыска тот, әй,
                    Вакытым тар!

***

Көтәсеңме син дә,
Башың кырын салып,
Боз киткәнен,
Үзәннәрдә карлар эреп,
Яшел үлән шытып чыгып,
Яз җиткәнен?
Җилләр белән җылы килер,
Дерт кабынып туңган күңел –
Өметеңдә.
Кочак-кочак чәчәк сиңа,
Җир айныгач.
Өй кыегын яратырмы яр-карлыгач...
Башың кырын салып, син дә көтәсеңме?
Тынмас кышта чәчәк коя
Җан-алмагач...



*Улугбәк Хамдам (Улугбәк Абдулвахоб улы Хамдамов) – күренекле үзбәк язучысы, тәрҗемәче, журналист. 1968 елның 24 апрелендә Үзбәкстанның Әндиҗан өлкәсе, Мәрхәмәт районы Юкори Равват авылында туган. Ташкент дәүләт университетының филология факультетында югары белем алган. Әдәби иҗат белән бер үк вакытта үзбәк язучыларының әсәрләрен төрки телләргә һәм төрки телле язучыларның әсәрләрен үзбәкчәгә тәрҗемә итү белән шөгыльләнә.*

Улугбәк
Хамдам

# БЕР ЧЫНАЯК СУ

ХИКӘЯ

Көтмәгәндә, миңа сәер бер йомыш куштылар. Нигә миңа куштылар? Белмим. Кем тарафыннан һәм ниндирәк вакыйга уңаеннан кушылган йомыш булды бу? Монысы да хәтердә калмаган, нигәдер исемә дә төшми. Хәтердә калганы шул – кичке караңгылык төшкәнче пар атка җигелгән иске-москы төялгән арбаны каядыр илтеп җиткерергә тиешмен икән. Һәм вәссәлам! Ни өчен караңгылык иңгәнче? Җавабы билгесез иде. Өстәп, тагын шуны да искәрттеләр: «Иң мөһиме: юлда адашып калмаска һәм йөкне вакытында илтеп җиткерү лязим». Шул рәвешле, миңа йөкләнгән вазифа сер йомгагына уралган башваткыч булып чыкты.

Әйе, сәер эш иде бу. Хан заманындагы әлеге арба кемгә кирәк инде? Хәзер машиналарның ниндие генә юк, теләсә кайсына утыр да, җилдер генә. Төялгән йөген әйтер идем инде, нәрсә бу? Йөк өстенә чүпрәк-чапрак капланган һәм ул сүстән ишкән бау белән бәйләп куелган. Бик теләсәм дә, шуннан артыгын сөйли алмам.

Сәфәр ярыйсы гына күңелле башланып китте. Биек күктә яшь тәнемне иркәләп, кояш көлә. Атлар бер көйгә җай гына юыртып баралар. Ара-тирә дилбегә каккалап алам, акыллы хайваннарга тизлек чамасын җуймаска шул җитә. «Йа Ходам, шундый зирәк акыллы итеп яраткансың син атларны! – дип сөйләнеп алдым үзалдыма. – Әйтерсең, бу эшнең бөтен мөһимлеген миннән дә артык аңлап алганнар!»

Җырлыйсы килә башлады, юлда беркем юк, бөтен тавышыма җыр сузып җибәрдем. Көн эссе, болай кычкырып җырлап барсаң, ярты юл үткәнче көч-куәтне исраф итеп бетерермен дип, тавышны басып кына көйләп маташкан булам. Нинди көй искә төшә, шуны мырылдап барам инде. Күңел күтәренке, юл ерак, тирә-якка күз салам, кая бакма иркенлек, җаным куанып туя алмый. Иксез-чиксез офыкка карап алуга, бу манзарага гаҗәпләнеп, дулкынлана башлыйм. Хисләрем ташып, тышка бәреп чыга, беләктә көч, күкрәктә җегәр җитәрлек, тирә-юньне яңгыратып кычкырып җибәрәм: «Ууу–лууу–ууг!» Күз ачып йомганчы кайтаваз ишетелә: «Гууу–лууу–ууу–ууу». Кинәт күз алларым караңгыланып китте, челлә үзәге булуга карамастан, маңгаема боздай суык тир бәреп чыкты, тәнем өши башлады. Ниндидер яклау эзләп, як-ягыма каранам. Бүтән кычкырасым да килми. Күпмедер вакыт тыныч кына барам, әмма бертөрлелек тиз туйдырды. Табигать һәрнәрсәгә битараф тынычлыкта иде.

Ә көн, бөтен дөньяны кочагына сыендырып, торган саен көчен ныгыта тора. Эчем кайный, әкренләп тамак кибүен сизә башладым. Берәр чишмә, кое күренмиме? Каранам да каранам. Бер генә су булырдай җир күзгә чалынмый шул. Кибегү көчәя, инде бу халәт мине гомер буе озата барган сыман тоела. Мең чакрым җир киткән шикелле сизелсә дә, юлга кузгалганга күп вакыт үтмәде. Су эчәсе килү теләге шундый күзаллауга китерә. Ярый, ни булса, шул булыр. Хәзер юк-бар уйларны читкә куып, ничек кенә булса да, су табарга кирәк. Каян гына табасы инде аны? Уйларга кирәк. Бу кибеп-көеп беткән чүлдә коега тап булсаң иде ул, көмеш суын эчеп туеп булмас иде дә бит. Бер чынаяк суга да риза булыр идем әле. Бер чынаяк су...

Мине чолгап алган зәңгәрсу ераклыкка карап алам, ярты көн дә җитмәгән ләбаса. Күк йөзендә ара-тирә ак болытлар күренгәли. Атлар, эссе көнгә игътибар итмәстән, бер җайга гына баруларын дәвам итәләр. Баш өстеннән чыркылдашып ике-өч кош очып китте. Исемә төште, юлга кузгалганнан бирле алар мине озата баралар бит, көтмәгәндә, юлдашларыма әйләнеп куйдылар. Гаҗәп! Шундук тынычланып калдым, алай гына түгел нининдидер күтәренке кәеф барлыкка килде хәтта. Ахыр чиктә, барысы да: шушы юл, биек ком таулары – барханнар, болытлар, һавада очкан кошлар алдыма куелган бурычны үтәп чыгарга булышалар бит! Әлеге уй-хисләрдән күңел очынып китте. Тагын да чүлне яңгыратып кычкырасым килә башлады, әмма эчке курку биләп алды: баягы сыман күңелсез уйлар иркендә кала күрмәгәем...

Әйе, җәй – җәй инде, иртәдән үк кыздыра. Эчәсе килү бөтен барлыгымны биләп алды, күз алдымда галәмәт олы, сап-салкын сулы күлләвекләр хасил була, шул су кочагына ташланып, бер генә мизгел рәхәтләнеп ятасы иде. «Са-гы-м... Ми-ра-аж...» – дип үз алдыма пышылдыйм, кибеп чатнаган иреннәремне ялаштырган булам, җанда шөбһәле уйлар өермәсе кузгала. «Нинди тинтәк мин, – дип, үземне тиргәп алдым. – Бер генә көпшән су алсам да, ничек шәп булыр иде! Челлә көнне юлга чыгасымны белдем ләбаса!» Миңгерәүләнеп калуымны тоеп, котылу чарасын эзләгәндәй, тирә-якка каранам. Атларым да, нидер сизенеп, адымнарын әкренәйттеләр.

Инде дилбегә белән каккалап барудан туктадым, бичаракайларым, алар да эсселектән интегәләр, үзләре теләгәнчә генә барсыннар. Ни булса да, булыр инде! Вакыт ипләп кенә алга шуыша, йөк төялгән арба әкрен генә тәгәри, тәгәрмәчләрнең шыгырдаулары тешкә тия. Алга бару торган саен авырлаша. Сүгенергә тотындым: «Тәгәрмәчләрне майлап та маташкан булган идем бит инде! Акчаны җилгә очыру гына булды». Маңгайга бәреп чыккан тирне кулъяулык белән ныклап сөртеп алдым. Мин кайда да, барасы җир кайда! Барган саен офык артка чигенә, барган саен юл ерак тоела. Тәк, тынычлан, адәм баласы! Юлга кузгалыр алдыннан яхшылап аңлатканнар иде: «Әгәр, бер якка да кереп китмичә, шушы туры юлдан гына барсаң, кичке караңгылык иңгән мәлдә барып җитәрсең. Юл үзе сине барасы җиреңә илтеп җиткерер, читкә генә каерма!» Мин моңа ышанган идем. Кояш болай ук кыздырмаса һәм тамагым түзә алмаслык кипмәсә, ышанычым бер генә мыскал да какшамас иде. Эчәсе килү теләге тора-бара бөтен зиһенемне биләп алды. Әйтерсең эчемдә, дөя өркәче шикелле кайнар ком барханы хәрәкәт итә.

Кинәт еракта җәелеп яткан күл күренде. Күзләремә ышанмый торам, бусы да мираж булып чыкмаса иде дигән уйдан йөрәк өзелеп төшәрдәй булды. Чыннан да, бу мин көткән күл булмады. Тик шул арада галәмәт олы бер корылма күземә чалынды. Әлеге бина юл читенә үк салынып куелган кәраван-сарай икән бит. Шатлыгымнан, атларымны ничек туктатканымны да сизми калдым, тиз генә арбадан сикереп төштем һәм шыр ачык капка алдына килеп бастым. Ух, син! Шул мәлдә яңадан туган кебек булдым.

Капка төбендә мине алсу иреннәренә елмаю кунаклаган, зур кара күзле, зифа буйлы сылукай каршы алды. Авыз ачып сүз әйтергә өлгермәдем, кыз якында гына челтерәп агып яткан чишмәгә борыла төшеп, ым какты. Аякларым, ирексездән, чишмәгә табан атладылар. Чишмәнең бер ягына, кеше-фәлән алып китмәсен диптер инде, нәзек кенә бауга төрле сурәтләр төшереп бизәлгән бакыр чынаяк элеп куйганнар. Чишмәдән тутырып су алдым да йотлыга-йотлыга эчә башладым. Бер-бер артлы дүрт-биш чынаяк су эчәрмен кебек тоелган иде, бер чынаякны эчеп бетерүгә кибегүем бетеп тә куйды. Бу хәл бик гаҗәпләндерде. Мин, яшермим, нык бәдәнле, буйчан егет, иртәдән бирле тамак кибүдән җәфа чигеп беттем, баксаң, бер чынаяк су эчүгә бөтен интегүләргә нокта куелды. Чынаягы да уймак кадәр генә бит әле аның. Ярый, бу хакта сүзне читкә куеп торыйк. Иң мөһиме, мин кибегүдән котылдым. Күз алларым яктырып китте – бу халәттә су эчүдән дә ләззәтлерәк нәрсә юктыр ул! Инде сәфәрне дәвам итсәм дә була. Салкын, шифалы су белән юынып алгач, рәхәтлек тагын да артты. Һәм шуның белән шул!

Хәзер алга да алга! Инде монда да, башка җирдә дә туктап торырга вакытым юк, каударланмыйча, бер мыскал да читкә тайпылмыйча, юлны дәвам итәргә кирәк! Миңа мөһим бурыч йөкләнде, аны бөтен йөрәгем, җаным белән кабул итеп, үтәп чыгарга тиешмен! Кушылган йомышны шул дәрәҗәдә җаваплы рәвештә кабул итмәсәм, юлга кузгалып та тормас идем. Монда аңлашылмый торган нәрсә юк. Вакытны сузмастан, кесәдән беркадәр акча алып, кызга суздым. Әмма тыйнак кызый, акчага

күтәрелеп тә карамады, ишарә белән генә йортка төртеп күрсәтте, янәсе, су өчен шунда кереп түләргә тиешмен икән. Җавап көтмәстән, үзе алдан өй ягына атлады. Ирексездән аның артыннан иярдем. Ай-яй-яй! Кая килеп эләктем мин! Күз явын алырлык ике катлы йорт, зур ишегалды, андагы утыргычларга карлыгачлар сыман бәйрәмчә киенгән кешеләр тезелешеп утырган. Аларның үтә канәгать йөзләренә караш ташлап алгач, күңел түрендә көнләшү хисе барлыкка килде. Әх-ти, әгәр дә бик тә кирәкле йомыш үтәп йөрмәсәм... әх-ти... ике дә уйламый шушында калып, ашап-эчеп, кәеф-сафа кылып ятар идем. Әгәр дә җаваплы бурыч булмаса...

«Кайсы төшкә барып, кемгә акча түләргә?» дигән сорау башыма да килеп өлгермәде: бер почмакта рәт булып, чиратка тезелгән кешеләр төркемен күреп алдым. Вәкарь генә, үз дәрәҗәләрен белеп торалар болар. Йөзләрендә куаныч та сизелми, канәгатьлек чаткысы да чагылмый. «Йа Хода, – дип гаҗәпләнеп, үз-үземә сорау биреп ташладым. – Нинди сәерлек! Бу сүрән чырайларны күргәч, әлеге бинаның сокландыргыч гүзәллеге дә, мондагы халыкның күтәренке кәефләре дә чынлыкка туры килми түгелме соң? Болай, карап торуга, барысы да шат, барысына да рәхәт сыман тоела иде бит әле». Уйларыма чик куеп, почмактагы төркем янына киттем, минемчә, акчаны нәкъ шунда барып түләргә кирәктер инде. Шәраб эчеп йомшаган, истирәхәт кылып утыручы кешеләр яныннан үткән чакта тамак төбенең кибүен сиздем.

Чыннан да акчаны мин уйлаган почмакта түлиләр икән. Чиратка килеп баскач, башка шундый уй килде: бер чынаяк суга акча түләү өчен бу кадәр кыйммәтле вакытны сарыф итәргә кирәк микән? Мин бит кирәкле, мөһим, җаваплы йомыш үтәү юлында! Эшне ашыктырып булмасмы дигән өмет белән, әле бер, әле икенче хезмәтчегә мөрәҗәгать итеп карадым, алар исә кәттә кыяфәтләренә тузан кадәрле дә шик төшмәсен дигәндәй, ярты сүзне дә тыңлап тормастан, ашыгып, галәмәт зур чиратка төртеп күрсәттеләр. Синең ишеләр бетмәс монда, чиратка бас та, көт, янәсе. Шушы эшкә алуларына сөенечтән көязләнеп йөргән бу вак-төяк йомышчылардан нинди дә булса рәхим-шәфкать көтәсе юк иде. Шунда гына чиратта торган кешеләрнең ни өчен бу кадәр дә сүрән йөзле, изелгән кыяфәттә икәнлекләрен аңлап алдым. Тавыш-тынсыз чиратның койрыгына килеп бастым.

Әгәр да мин бер чынаяк су өчен шул кадәрле вакытны исраф итәчәгемне белгән булсам! Кушылган йомышны вакытында үтәп чыга алмау куркынычын тоеп, күпме вөҗдан газабы кичердем монда, күпме бушка көч түктем, күпме газаплы уйлар эчендә бәргәләндем. Боларны белгән булсам, бу йортка таба аяк та атламас идем. Әйтүе генә җиңел. Үзем кебек зар-интизар булып торучыларга сүз кушып карыйм, ләм-мим, эндәшүче юк. «Барысы да авызларына су капкан сыман, әллә телсез-чукраклар җыелганмы монда?» дигән гарьлекле уй үтте башымнан.

Утыртып куелган багана шикелле, селкенергә дә кыенсынып, бер урында тору ялыктырды. Бераз ял итәргә теләп, чүгәләп карыйм, әмма болай да тиз ардыра, оета, кабат аякка басам. Хәзер инде үземнең дә сөйләшәсе килү теләге бетте, бер тамчы көчем калмады. Минем артыма

килеп баскан бер адәмнең ниндидер сораулар биреп, башкаларны бу тикторыш халәтеннән чыгарырга омтылыш ясавын күреп, эчтән хәсрәтле генә көлемсерәп торам. Үзем дә телсез һәм чукрак хәзер. Шул ук вакытта, кызыксынып, ишегалдында кәеф-сафа коручыларны һәм чиратта торучыларны күзәтәм. Чиратта торып, ниһаять, акча түләү бәхетенә өлгәшкән кешеләрнең күзләре ялкынга уралып кабына, куанычларыннан нишләргә белмичә, бәйрәм итүчеләргә килеп кушылалар, ә чираттагыларны өметсезлек чолгап алган. Мескен кыяфәт белән, ишегалдын һәм йорт эчен тутырган бәйрәм коручыларны күзәтәм. Әгәр дә алар шушы әкәмәтне үз тиреләрендә татып карамасалар, бу кадәр бәхетле хис итәрләр идеме үзләрен?

Вакыт үтә тора. Арудан башлар әйләнә. Чүгәләп, күзләремне йомдым. Бераз вакыт үтүгә, тамак чатнап кибә башлады. Бик тә таныш нәрсә бу миңа. Йә, Аллам, нәрсә инде бу? Мин бит бая эчкән бер чынаяк су өчен акча түләргә торам, әле түләргә өлгермәдем, тагын кибегүдән интегеп торам. Чираттан чыгып, тагын су эчеп килсәм? Сабыр ит, чишмәдән урап килгәнче, чиратым да юкка чыгачак бит. Мондагы чиратның очы-кырые юк. Шушы чиксезлекне күреп кенә дә, акылдан язарга мөмкин. Бер генә кеше дә чиратын калдырып китәргә теләк белдерми. Тешләремне кысып, чиратта торуымны дәвам итәм.

Вакыт коточкыч әкрен үтә, кешеләр чылбыры әле тизрәк, әле әкренләп, алга шуыша. Ара-тирә алда торучыларны ашыктырырга теләп, бераз төрткәләп куйгандай итәм, ул да булмый, әллә кибегүдән, әллә талчыгып, эч пошудан, саташа ук башлыйм, андый мәлдә үземнең кайда, ни өчен торуымны да аңлаудан мәхрүм булам. Артта торучы бичаралар мине дә эткәләп-төрткәләп алалар, алга сөрлегеп, ярты гына адым булса да алгарак үрмәлим. Күпме вакыт үтте? Белмим. Кемдер нык кына иңсәмә төртеп куйды, күзләремне ачсам, кечкенә тәрәзә каршына килеп басканмын. Уф-ф-ф! Янчыгымнан алдан ук әзерләп куелган акчаны алып, кассирга сузам һәм тизрәк бу тирәдән ераккарак таю ягын карыйм.

Адымнарымны кызулаган саен, үземнең коточкыч аруымны тоям, тәмам хәлсезләнгәнмен, җеп өзәр җегәрем калмаган. Гәүдәм авырая, адымнарым ышанычсыз, тигезлекне югалтам. Нигә шулай? «Монда шулкадәр күп вакыт сарыф ителде, шуңа күрә бер хәлем дә калмаган, арыдым, алҗыдым», – дип уйлаган булам. Нинди вазгыятькә килеп капканны чамалау лязим бит.

Юк сүзләр бит инде болар! Мин чиратта тордым! Инде бу газап чигү артта калды, шушы хистән куанып, сикерәсе, мәтәлчек атасы килә. Тик моңа минем көчем-җегәрем җитмәячәк шул. Гаҗәпләнеп, үз-үземә читтән карап торган сыман булдым. Нәрсә бу? Сихергә юлыктыммы? Кәрван-сарайга кергәндә, үземдә бетмәс-төкәнмәс куәт барлыгын тойган идем, хәзер изелеп-сытылып беткән бәндә кыяфәтендә калдым. Тән тиресе изрәп төшкән, сөякләрем төртеп чыккан, чак кына этеп җибәрсәләр, авып китәрмен кебек. Гаҗәпләнеп, авыз ачып тора идем, карашым теге хезмәтче кызга килеп төртелде. Карадым да катып калдым – кызый бер тамчы да үзгәрмәгән иде, гүзәл, сылу сынлы, иреннәрендә шул ук елмаю, юлчылар туктаусыз килә тора, ул исә ягымлы карашын

җәлләми, аларны кәрван-сарайга озата тора. Ару да юк анда, талу да сизелми. Чыннан да, бер генә арба да бу йортка тукталмыйча үтеп китми. Атлар туктарга өлгерми, арбабашы сикереп төшә дә чишмә янына йөгерә. Кыз юлчыларга ягымлы елмаеп, ым кага, һәр юлчы, бер чынаяк су эчүгә, кибегүен басып та куя.

Башым әйләнә, аякларымда җегәр бетте, нишләгәнемне дә абайламыйча, җиргә сыгылып төштем. Күзләремә, авызыма кайнар ком тулды. Иреннәрем чатнап ярылды, алар әрнеп авырталар. Яткан килеш, кармалана-кармалана, алга шуышырга маташам. Кулыма бер таяк килеп эләкте. Аны нык кына тотып, шуңа таянып аякка басарга азапланам. Көч-хәл белән аякка бастым, бәбәкләремне ачтым! Арбам янында басып торам икән. Шушы мизгелдә барысын да исемә төшердем. Соң... соң... миңа мөһим йомыш кушылган иде бит! Аннан... аннан кич җитте, кояш баеды, аптырашта калдым: минем вакыт чыгып килә икән бит! Йомышны үтәп өлгермим, соңга калам! Изге бурычны тиешенчә башкарып чыга алмадым?! Шушы хәлгә әрнеп, кычкырасым килде, әмма булдыра алмадым, ыңгырашу гына чыкты, баш миемдә нидер шартлады сыман...

Таякка таянган хәлдә, авырлык белән берничә алдым алга атладым, арба янына җиткәч, үземне гаепле санап, башымны аска идем. Кинәт күкрәк тирәсеннән алып, бар гәүдәмнең салкын суга чыланганын сиздем. Читкәрәк тайпылып, күзләремне киереп ачып, арба ягына янә караш ташладым: арбадан ком өстенә шыбыр-шыбыр су ага иде, инде кечкенә күлләвек хасил булырга өлгергән. Гаҗәпләнеп, соңгы көчемне җыеп, калтыранган, хәлсезләнгән кулларым белән арба өстендәге йөкне каплаган иске-москы чүпрәкне читкә алып ташладым... Йә, Илаһым, шушы мәлдә башымда кайнашкан уйларымны белсәгез иде! Бүген күргән бөтен газапларымны кабат кичердем. Йөрәкнең әрнүенә чама юк иде...

Арбага су тутырылган көпшәннәр тезеп утыртылган. Шуларның берсе ватылган да, мең гасыр буе дымга тилмергән чүл комына су тамчылап тора иде...

*Үзбәкчәдән* **Факил САФИН** *тәрҗемәсе.*

# НОКТАЛЫ ӨТЕР, ЯГЪНИ МИЛЛӘТНЕ САКЛАУ СЕРЛӘРЕ

## 1. Җанисәпнең шаккатыргыч саннары

2023 елның гыйнвар ае татар халкы тарихына керәчәк. Киләчәк буын галимнәре нәкъ шул көннәрдә матбугатта, телевидение язмаларында һәм Интернет челтәрендә күренгән кайнар фактларны, кискен фикерләрне табачаклар. Бу тема тарихи китапларда, журналист репортажларында, телефильмнарда чагылдырылачак. Ул дәүләт тарафыннан махсус оештырыла торган халык саны алу – җанисәп йомгакларына бәйле.

Эш шунда ки: XXI гасыр башында татарлар үзләренең тарихи Ватаны Россиядә юкка чыга башлаганнар; аларның саны бер дистә ел эчендә 11-12% кимегән. 2010 елда илдәге татарлар саны 5 310 649 булса, хәзер Россия Федерациясендә 4 млн. 713 мең татар яши дип, ташка басылды. 597 мең татар «югалган». Татарча сөйләшүчеләр 1 миллионга, ә соңгы 20 елда 2 миллионга азайган. Халык санын алганда бирелгән җаваплар шундый тәэсир калдыра. Эшләр болайга китсә, Гаяз Исхакый әсәрендә фаразланган инкыйраз (татарның юкка чыгуы) алдагы 100 елда түгел, 50 елда килеп житәр кебек.

Мондый кискен борылыш ханнар заманында да, патша чорында да, совет елларында да күзәтелмәгән. Этнолог Дамир Исхаковның «Историческая демография татар» (2014) монографиясендә әйтелгәнчә, XVIII-XIX гасырларда һәм XX гасыр башында Идел-Урал төбәгендә яшәүче татарлар саны 11 тапкыр арткан булган. Романовлар династиясе хакимлек иткән патша заманында да татарлар яшәгән, хәтта үрчегән булып чыга! Ә хәзер... Төбәкләрдә кимү көчлерәк.

**2021 елда татарлар саны иң күп кимегән 10 төбәк**

| Төбәк | 2021 ел | 2010 ел | Үзгәреш, саннарда | Үзгәреш, процентларда |
|---|---|---|---|---|
| Мәскәү шәһәре | 84373 | 149043 | -64670 | -43,4% |
| Чиләбе өлкәсе | 120242 | 180913 | -60671 | -33,5% |
| Свердловск өлкәсе | 93516 | 143803 | -50287 | -35% |
| Ульяновск өлкәсе | 111365 | 149873 | -38508 | -25,7% |
| Оренбург өлкәсе | 116605 | 151492 | -34887 | -23% |
| Башкортстан Республикасы | 974533 | 1009295 | -34762 | -3,4% |
| Самара өлкәсе | 94452 | 126124 | -31672 | -25,1% |
| Удмуртия Республикасы | 67964 | 98831 | -30867 | -31,2% |
| ХМАО | 79727 | 108899 | -29172 | -26,8% |
| Пермь крае | 92472 | 115544 | -23072 | -20% |

## 2. Кая киткән безнең милләттәшләр?

***«Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының татар редакциясе баш мөхәррире Рәмис Латыйповның мәкаләсендә әйтелгән саннар:***

«2010 ел белән чагыштырганда, 2020 елгы (чынлыкта 2021 елда үткәрелде) халык санын алуда Татарстанда татарлар саны 78 604 кешегә арткан. 2010 елда 2 012 571 булса, соңгы җанисәптә 2 091 175 кеше үзенең милләтен «татар» дип күрсәткән. Бу Россиядә яшәүче 4 713 000 татарның 44,36 проценты Татарстанда яши дигән сүз. Элек Татарстанда дөньядагы татарларның 25 проценты гына яши дип санала иде. Хәзер Татарстаннан читтәге Россия төбәкләрендәге милләттәшләр гомуми санның 75 проценты түгел, 44,36 процентын тәшкил итә. СССР илләрендә һәм ерактагы чит илләрдә яшәүче татарларның саны төгәл билгеләнмәгән. 2009 елның статистик мәгълүматлары буенча чит илләрдә яшәп, татарлыкларын саклаган милләттәшләребезнең якынча саны 1 150 000 кеше. (Бу санга Әфганстан, Пакъстан кебек илләр вәкилләре кермәгән).

Татарстанда яшәүче җирле халыкларның кимүе күзәтелә. Чувашлар (116 212 – 90 474), марилар (18 848 – 15 666), удмуртлар (23 454 – 21 327), мордвалар (19 156 – 12 065), керәшен татарлары (29 962 – 25 189), башкортлар (13 726 – 11 029). Ә менә Урта Азия халыклары арткан. Үзбәкләр (8 881 – 14 970), таҗиклар (5 859 – 12 541), кыргызлар (1 156 – 2 406)».

## 3. Татар телен белүчеләр

«Интертат» басмасында әйтелгәнчә, «2010 һәм 2020 (чынлыкта – 2021) елгы җанисәпләр арасында татар телен белүчеләр 1 019 563 кешегә кимегән. Росстат сайтында чыккан җанисәп нәтиҗәләре шуны күрсәтә.

2010 елда «Россия Федерациясе халыкларының телләрен белү» пунктында 4.280.718 кешенең татар телен белүе әйтелгән иде. 2020 елгы җанисәптә бу пункт башка төрлерәк тәкъдим ителә – «Телләр белү һәм халык тарафыннан телләрне куллану». 3 261 155 кеше татар телен белүен, 2 917 685 кеше татар телен көндәлек тормышта файдалануын әйткән.

«2010 елда Россиядә 5 310 649 кеше милләтен «татар» дип күрсәткән иде. 2020 елда бу сан 597 меңгә кимегән – соңгы җанисәптә 4 713 669 кеше үзен «татар» дигән».

«...2020 елгы җанисәптә 4 073 253 кеше туган теле дип, татар телен күрсәткән. Милләтен «татар» дип күрсәткәннәр һәм татар телен туган теле дип санаучылар арасында аерма – 640 416 кеше».

«Татар телен туган теле дип күрсәтүчеләр һәм татар телен белүчеләр саны арасында аерма – 812 098 кеше. (Монда башка милләт кешеләренең дә татар телен белүен исәпкә алырга кирәк)».

Шул рәвешчә, татарлар саныннан гына чыгып нәтиҗә ясаганда (башка милләт вәкилләре арасында татар телен белүчеләрне исәпкә алмаганда), 2020 елгы җанисәп нәтиҗәләре буенча 69,18 % татарлар үз телен белә. 61,89 % көндәлек тормышында татар телен файдалана. Милләтен «татар» дип күрсәткәннәрнең 86,41% туган телен татар теле дип саный.

2010 елгы җанисәптә татарларның 80,6 % татар телен белүен әйткән булган. Шулай итеп, татар телен белүче татарлар саны 11,42% кимегән. Туган телен татар теле дип санаучылар саны процент нисбәтендә 5,81 % арткан.

Телләрне белүчеләрнең кимүе башка милләт халыкларында, шул исәптән, җанисәп вакытында халык саны арткан чеченнарда да күзәтелә.

Россиядә яшәгән 1 571 879 кеше милләтен башкорт дип күрсәткән, башкорт телен белүчеләр – 1 086 423».

## 4. Татарстанның халык язучысы, ТР Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдулланың фикерләре:

***Балалар аз туа.*** «Халык саны кимүенең төрле сәбәпләре бар. Төп сәбәпләрнең берсе – балаларның аз тууы. Хәзер бит авылларда да гаиләдә бер-ике бала. Нинди артым, үрчем турында сүз баруы мөмкин?!»

***Милли мәгарифнең хәзерге хәле.*** «Әлбәттә, ассимиляция соңгы егерме елда коточкыч кимәлдә артты. Милли мәгариф системасы җимерелү аңа шулай киң юл ачты. Ләкин бит элекке тәҗрибә күрсәткәнчә, инде руслашкан, тамырыннан аерылган кемсә дә, гадәттә, үзен барыбер татар дип белдерә. Хәер, хәзер аларның балалары, оныклары инде ул атамадан да ваз кичәргә мөмкин».

***Башкортстанда татарлар саны кими.*** «Башкортстанда татарның кимүе аңлашыла. Анда, минемчә, административ ресурс үз эшен эшли».

«...Җанисәп алуны үз көенә куйсаң, яки бернинди тыкшыну булмаса, барысы да үз урынына утырачак. Безгә татарның – татар, башкортның башкорт булып калуы кадерле... Ләкин ничек кенә сансызланмасыннар, башкорт милләтчеләре нинди генә яңа ыру исемнәрен күтәреп чыкмасын, ул җирләрдә татар барыбер татар булып, башкорт исә үзе булып кала. Анда алар бер-берсен бик яхшы таный. Халык зирәк бит ул…»

***Сәбәпләрне эзләү – хурлау түгел.*** «...Аз санлы халыклар бик тиз арада юкка чыга. Шуңа мин ачыктан-ачык әйтергә мәҗбүр: *соңгы җанисәп алуда халкыбызның саны киму илдәге вазгыятькә турыдан-туры бәйле* Мин – конгрессның Милли Шурасы һәм бюросы әгъзасы да. Әлбәттә, бер оешма бөтен эшне башкарып та чыга алмый. Конгресс хәленнән килгәнчә тырышты. Ләкин ул бит халыкны арттыруда турыдан-туры катнаша алмый!»

***Ерактагы татар утраулары һәм үз арабызда адашкан яшьләр***. «Әлбәттә, ерак Чита якларында әбиләр ансамбленә милли костюмнар бүләк итеп кенә әллә кая ерак китеп булмый, яшьләр белән күбрәк эшләргә кирәк. Яшьләр белән эшләү мәсьәләсе арткы планда кала бирә. Яшьләрнең игътибарын яулау, яшьләрдә милли үзенчәлеккә басым ясап, ниндидер үзгәрешләр кертү шактый авыр. Чын татар җанлы яшь активистлар җитми».

Ркаил Зәйдулла үз фикерләрен Дәүләт Советы мөнбәреннән дә яңгыратты. Ул татар конгрессының эшчәнлеге турында дәлилле итеп актуаль тәнкыйди фикерләр дә әйтә. Турысын әйтеп, эшне вакытында төзәтүгә ни җитә!

## 5. Этнолог галим Дамир Исхаков: «Кайчан милли эшләрне төптән аңлап, системалы рәвештә башкару чоры җитәр?»

«Мәдәни җомга» газетасына биргән әңгәмәсендә Бөтендөнья татар конгрессының «Тарих һәм заман» комиссиясе җитәкчесе Дамир Исхаков узган халык санын алуны «Сыйфатсыз җанисәп» дип атый. Ул шундый үзгәрешләргә игътибар итә:

***– миграция.*** Татарстанга татар булмаганнарның күчүе арткан, шунлыктан татарлар өлеше 1 %ка кимегән;

– ***Уралда татар кими, кемнәр арта?*** Чиләбе өлкәсендә татарлар 180 меңнән 120 меңгә калган. Ә өлкә башкортлары кимү алай ук түгел. Хәзер Чиләбедә, Башкортстандагы кебек үк, башкортлар сан ягыннан татарларны «узган» – 128 меңгә җиткән. Идел-Уралда татарлар саны нык кимегән;

***– дини үзаң һәм милли үзаң.*** Бүген татарларның 80 % ы үзен мөселман дип саный. Мәчетләргә йөрүчеләр – 5-6 % (бу оптимистик карашка!);

***– туган телне куллану.*** Татарларның 70 % теге яки бу дәрәҗәдә туган телне куллана;

***– кемнән сорарга?*** Җитәкчелек без барлык татар милләте өчен җавап бирәбез дип сөйләргә ярата. Әмма татар җәмәгатьчелеге: «Мәскәү безнең 600 мең татарны кая куйды?» – дип сораганда, федераль хакимият ничек җавап бирә ала;

***– гыйлем артканмы?*** Татарстанда татарлар белем дәрәҗәсе буенча руслар белән тигезләшкән;

– ***Себердәге безнекеләр кая китә?*** «...Ә Казан Себер татарлары турында тирәннән фикерләмичә, культур-мультур (сабантуйлар вә фестивальләр) уйнау ысуллары белән генә чикләнеп, бу төбәктә өстән-өстән генә йөреп эш алып бара. Әмма нәтиҗә үтә дә тискәре – монда коточкыч тизлек белән тел ассимиляциясе дәвам итә, милли мәгариф системасына үлем яный, халык каршында торган икътисади мәсьәләләр дә авырая бара;

– ***үзебезнең хаталарны үзебез төзәтик***. «Халыкны исәпкә алу нәтиҗәләре милләттәшләрне сискәндереп, уятып җибәрде, чөнки Гаяз Исхакый әйткән инкыйраз инде бүген үк каршыбызга басты. Шул уңайдан республикабыз мәгълүмат чараларында зур сөйләшүләр үткәрелеп, шактый саллы мәкаләләр дә басылды. Әмма, беренче чиратта, сүз «кем гаепле» төененә тупланып, гаеплене тыштан эзләүгә күп урын бирелде. Хафалану өчен сәбәпләр җитәрлек һәм уйлый белүчеләр өчен алар яңалык та түгел. Ә мәсьәләнең икенче ягы – үзебездәге кимчелекләрне, фундаменталь җитешсезлекләрне әйләнеп үтәргә маташабыз;

– ***айсберг кузгалырмы?*** Инде өлкән яшькә җиткән һәм күпне күргән шәхес буларак, хәзер уйга талам: берәр вакыт республикабызда милли эшләрне төптән аңлап, аларны системалы рәвештә башкару-оештыру айсбергы урыныннан кубармы икән?

## 6. Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, язучы Вахит Имамов:

«Татарлар – руслардан кала Россия күләмендә элек әллә ничә мөстәкыйль дәүләт тоткан бердәнбер милләт. Безнең йөрәкләрдә яңадан да хөр вә азат булу хыялы күмер сыман пыскый, аны бернинди полиция яки жандармерия көчләре белән дә изеп ташлап булмый.»

«...Генерал Краснов, адмирал Колчак яки генерал Деникин кебек бердәм һәм бүленмәс Россия турында хыялланган карагруһчы көчләргә иң беренче чиратта татар милләтен юкка чыгару отышлы булган. Алар йөз мең итеп, безне Беренче бөтендөнья сугышына ташлап та карады, Икенче бөтендөнья сугышына 700 мең итеп куды. ...Мәскәү академигы В.Тишков: «Җанисәптә, ким дигәндә, 500 мең татар исәпкә алынмаган», дип белдерү ясый икән, димәк, асыл йөрәкле зыялылар да безнең халыкның талануын раслый...»

«...Татар халкын мондый мәкерле адым көтүен кисәтеп, республика җитәкчелеге ни эшләде? Бөтендөнья татар конгрессы, барча өлкәләрдәге милли-мәдәни автономия җитәкчеләрен җыйнап, нишләп һич югы ике-өч тапкыр булса да уку уздырмады? ...Менә соңгы җанисәптә без – халык санын югалту буенча Россия күләмендә лидер... Бездә һәр биш кешенең берсе югары белемле, татарның дөньякүләм танылган галимнәре дә хәтсез. Аннан да мөһимрәге – татар, руслардан кала, Россия күләмендә элек әллә ничә мөстәкыйль дәүләт тоткан бердәнбер милләт.» («Мәдәни җомга» 27.01.2023).

## 7. Владимир Зорин: «Рәсми җанисәп саннарына альтернатива юк»

Шулай итеп, РФ татарларының саны 11-12 процентка кимүнең сәбәбе – 2021 елда халык белән юньләп очрашмыйча, милләт, туган тел турында сорашмыйча гына җанисәп үткәрү. Башка сәбәпләр арасында аерылып торган төп гаеп – пандемия

зәхмәтендә! Әмма милли оешмаларда моны гына тану мәсьәләгә ачыклык кертми дип саныйлар. Татарларның һәм кайбер РФ халыкларының кимүендә башка җитешсезлекләр, инкыйраз чалымнары да юкмыни? Татарларны киметә торган факторлар үзебезнең милли тормышта да бихисап!

Төгәлрәк саннарны каян алырга соң? Элекке елларда Россиянең милли эшләр министры булып эшләгән В.Ю.Зорин сыйфатсыз үткәрелгән җанисәпнең нәтиҗәләрен танырга туры килүен әйтте. «...Чтобы говорить о провале, надо предоставить альтернативные (лучшие) результаты переписи. Нет у нас в стране ни одного другого источника данных о населении такого охвата и степени подробности».

Шулай булгач, 2021 ел җанисәбен никадәр тәнкыйтьләсәк тә, аның саннары бердәнбер рәсми мәгълүмат булып кала. Хакимият органнары, гадәттә, татар-башкорт-мариларның саны кимүгә борчылмый. Миллионлап кешенең «россиян» дип язылуына федераль үзәк каршы түгел, чөнки гомумдәүләт ватандашлыгы үзаңы («гражданская идентичность») үсү уңай күренеш дип санала.

Менә шушы урында хикәяткә нокта куеп, җанисәп тирәсендәге шау-шуга йомгак ясарга була. Халык санын алу беркемне дә шаккатырмаска тиеш: РФ татарларының саны 11-12 % кимүнең сәбәбе – пандемия зәхмәтендә!

Ләкин киләчәктә инкыйраз өчен җанисәпне генә гаепләү халыкны акламас. Без бит сарык түгел. Безнең кебек дәүләтсез халыкларның арту-кимүе халыкның үзенә бәйле! Чираттагы җанисәпкә 8-9 ел калып бара. Нидер эшләргә кирәк. Шуңа күрә бу темага куелган нокта янына зур гына өтер куеп, яңа фикерләр, яңа проектлар эзләп карыйк. Шул максат белән бу әңгәмәдә **нокталы өтер** куеп, милләт турында сөйләшүне дәвам иттерәбез.

## 8. Халыкны санау кемгә кирәк?

Җанисәп – сәяси гамәл. Халык саны алуның көтелмәгән нәтиҗәсе фаҗигагә китергән очраклар да бар. 1937 елда СССР да яшәүчеләрнең саны, яшәү шартлары турында мәгълүмат Сталинга ошамаган, диләр. Социализм төзеп ятучы халыкның саны һәм яшәү рәвеше сокландыргыч булырга тиеш. Күпме халык кырылганын әйтергә ярамый. Ямьсез статистиканы кулланып «санаучылар» җәзаланган. Җанисәпне 1939 елда яңадан «дөресрәк» итеп үткәргәннәр.

Җанисәпнең «милләтсез» сораулары да мөһим. Ул саннар, төгәл мәгълүмат һәрвакыт кирәк. Мәсәлән, 2021 елда Россиядә 153 мең авыл булган, шуларның 25 меңе бушап калган. Мәсәлән, 35 мең авылда бер дистәдән кимрәк кеше яши. Татарларның «оясы» да авылда иде бит. Мондый «күп нульле» саннар белән нишләргә?

Җанисәп саннары халыкның социаль хәлен күрсәтә. Әйтик, төбәктә яки район-шәһәрдә яшәүчеләрнең ничә меңе (проценты) суны урамдагы коедан ташый? Күпмесенең фатирына сүүткәргеч суы кертелгән, күпме йорт газ белән җылытыла? Әйтик, күрше төбәктә йортларның 10 процентына газ кертелмәгән, ди. Ә безнең Татарстан торакларында тулысынча диярлек газ үткәрелгән. Уйландырамы? Уйландыра. Ә Россиядә күпме халык мичкә утын ягып, кыш чыга? Җанисәп анкетасында шундый сорау да бар: бәдрәфегез фатир эчендәме, ишегалдындагы такта бәдрәфкә йөрисезме? Менә мондый социаль тормыш күрсәткечләре һәркемгә милләт графасыннан җиңелрәк аңлашыла.

Гражданнарның дөньяга килү-китүен теркәү җиңел түгел: ел саен миллионлаган ватандашлар вафат була, туучылар саны кими. Күпме ир-егетләр үсә, армиягә, завод-фабрикага, төзелешкә кемнәр киләчәк?

Анкетадагы «милләт» графасына берәүләр кызыксынып караса, икенчеләр битараф кала. Белгән кеше милләтен белә, белмәгәне ничек язсалар да, риза. Паспорт өстәле

документлары буенча тутырылган анкеталарга ышаныч зур. Андый ысул белән санаганда, статистика китабы эчендә каршылыклар булмый, халык санын арттырып күрсәтү куркынычы кими. Әмма анда милләт, туган тел күрсәтелмәгән. Ә милләтне төгәл итеп исәпкә алу хакимият башындагы зур милләтләргә яисә империячел шовинистларга, маңкортларга кызык түгел.

Татар милләте кемгә кирәк? Үзебезгә. Шулай булгач, үзебезне үзебез барларга, сакларга тиеш булабыз. 100–150 ел элек беренче татар мәдрәсәләрен, театрын, матбугатын патша самодержавиесе оештырмаган, аларны ачучылар да, «спонсорлары» да татарлар үзләре булган. Хәзер дә безнең халыкка татар үсешенең объекты гына түгел, милли тәрәккыятьнең субъекты булып калу хәерледер?

## 9. Стратегия юл күрсәтәме?

Милләт үтәргә тиешле катлаулы юллардан барырга компас, юл күрсәткеч кирәк. Татар халкының «Гамәл стратегиясе» РФ татарларын (шул исәптән аларның санын һәм сыйфатын) саклап калу, милли үсеш өчен нинди чараларны күз алдында тота соң? *Күпләп үрчетелгән һәм төрле югары инстанцияләрдә расланган бу стратегиянең асылын төшендерәсе бар. Аның авторлары да билгесез. Хәзер аның үтәлеше ничек баруын ачык итеп әйтүче белешмәне кемнәр төзеп бирер икән? Шуны һаман өзелеп көтәбезме инде?*

Татар конгрессының рәсми идеологы булып торган Дамир Исхаков татар халкын яшәтү стратегиясенең бөтенләй булмавы турында матбугатта һәм «Яңа гасыр» телеканалы тапшыруында әйтеп салгач, без шаккатырга тиеш идек. Ләкин мондый бәяләү дә бәхәс уятмады...

Бер караганда, 2020 елда кабул ителгән «Гамәл стратегиясе» трактатында хаталы фикер юк. Ләкин бу «стратегияне» укыганнан соң милләтне яшәтү ысулларын аңлап та булмый шул. Булмаган яки аңлашылмаган стратегиягә таянып, ерак китәрбезме икән?

Хакыйкатьне тормыш үзе ачып сала, аны туры сүзле шәхесләр күрсәтәләр. Җанисәп үткәрүчеләрнең халык белән очрашмыйча гына безне санавы турында матбугатта, телевидениедә, Интернетта күренгән Дамир Исхаков, Вахит Имамов, Илнар Гарифуллин, Рәмис Сафин, Фәвия Сафиуллина фикерләре игътибарга лаек. Алар «Яңа гасыр» телеканалының «Ком сәгате» тапшыруын алып баручы Данил Гыйниятов сорауларына ихлас җавап бирделәр. Татар телевидениесе экранында Ләйсәнә Садертдинова, Эльвира Хөснетдинова һ.б. журналистлар яздырып алган репортажларда үз тормышларын тасвирлаучы милләттәшләрнең чыгышларын тыңлагач, күзләр ачылып китә. Күренгәнчә, чит төбәкләрдә татарлар исән, ләкин андагы яшьләргә татарлыкны «йоктыру» авыр!

Җанисәп уңаеннан килеп чыккан бәхәстә милләтне яшәтү проблемалары ап-ачык күренә башлады. Шул ук «ТНВ» телеканалының «Таяну ноктасы», «Заман көзгесе», «Татарлар», «Халкым минем» тапшырулары, «Татар-информ», «Интертат» кебек абруйлы Интернет ресурсларында, «Мәдәни җомга», «Ватаным Татарстан», «Безнең гәҗит», «Шәһри Казан» һ.б. басмаларда ике ай дәвамында чыккан язмаларның иң мөһимнәрен бер шәлкемгә җыйгач, 170ләп бит кайнар текст, зур күләмле аудиовизуаль тамашалар җыелмасы килеп чыкты. Бу бит милләт язмышы турында күләмле китап, телевидение сериалы дигән сүз! Өстәвенә, төрле басмаларда яңа язмалар чыга тора. Аларның күбесе татарча иҗат ителгән. Саллы һәм зур күләмле русча текстлар да очрый. Аларны кабат-кабат укыйсы, өйрәнәсе бар. Өйрәнгән кадәресе татар стратегиясенең барлыгына, аның үтәлешенә бернинди дәлил яки өмет калдырмый. Киләчәктә кайда, ничә татар яшәячәген фаразлау мөмкин түгел. Аяныч хәл...

## 10. Инкыйраз тизлеге һәм башка актуаль сораулар

Җанисәпнең милли-мәдәни юнәлештәге сораулары буенча нәтиҗәсе – милләтнең югалу-саклану күрсәткече ул! Авыл хезмәткәре өчен икмәк уңышына, ит-сөт җитештерү саннарына, заводларда чыккан машиналар санына охшаш күрсәткечләр алар. Бу саннар мәгариф, мәдәният, мәгълүмат хезмәткәрләренең эш нәтиҗәсен чагылдыралар. Инкыйраз темпларын да шул ук саннар күрсәтә.

Кайда күпме татар яши, аларганиләр җитми, һәр төбәктәге татарны нинди киләчәк көтә? Шул турыда күмәкләп баш вату матбугат битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында, җыелышларда бер минутка туктап тормый. Димәк, бу фикер-хәбәр дулкыннарын бөтен милләткә, яшь буынга җиткерергә кирәк.

Мәскәүдә яшәүче Наил Гыйльмановның рус телендә җентекләп язылган шактый тирән эчтәлекле аналитик мәкаләләре milliard.tatar интернет-ресурсында басылып чыкты. Шул ук tatar-inform.ru порталының татарчасында җанисәп нәтиҗәләре Рифат Каюмовның тирән эчтәлекле язмаларында тасвирлана.

Гадел бәяләргә, тирән анализга сәләтле милли зыялыларыбыз да бар. Рәнҗү, борчылу һәм сукрану белән генә чикләнмичә, фәнни һәм хокукый аргументлар көтелә. Әйдәгез, милләт таркалуның тизлеген үлчәп карыйк.

Татарлар ел саен 1,5 процентка кимесә (10 елда 600 мең кимүне 10 елга бүләбез), ел саен якынча 60 000 кеше «югала» дигән сүз. Ай саен 5000, көн саен 480 кеше. Бу саннар иң оптимистик варианттан алына.

Татарча белүчеләр 20 ел эчендә 2 миллионга азайса, ягъни ел саен 100 000 татар телсез кала. Бер айда 8 220 кеше дигән сүз. Әйдәгез, сез яшәгән урында ничә укучы татар телендә белем алганын санап карыйк. Ничә сыйныф, ничә укытучы бар, дәреслекләр күпме? Аларның тиражына күз салсагыз, 2-3 мең данәгә куанырсыз. Шул ук вакытта күңел дәфтәрендә «санга кермәгән» 600 мең татар барлыгына, халкыбызның тирән тарихына, мәдәниятенә өмет югалмый. Без бар! БТК башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров ТНВ каналында игълан иткәнчә, объектив санаганда, Россиядә якынча 5,5 млн татар булырга тиеш. Барыбер Россиядә татар икенче халык булып кала. Шулай була күрсен! Ләкин без тагын ике тапкыр кимеп, 2-3 млн. калсак та, сан буенча илдә икенче урында кала алуыбыз юатмый. Сан буенча түгел, сыйфат, тәэсир буенча югары рейтингны сакласак иде! Мәгърифәтчелек, фән, игенчелек-малчылык, сугышта ватан өчен арысландай көрәшкән каһарманлык кына бүген җитми. Үз халкыңны саклау, Конституция нигезендә милли үзенчәлекне, кабатланмас рухны кадерләү Ватан иминлеге кебек үк изге төшенчә...

## 11. Сигез миллионлык милләт булып калыйк, дисәк...

Чыннан да, алты нульле санда булган милләтебезне (дөнья татарлары 6 000 000-8 000 000, Россиядә 5 000 000 дип санасак) барлау өчен конкрет үлчәмнәргә, ап-ачык күрсәткечләргә таянырга кирәк. Милләткә багышланган һәрбер җыелыш-киңәштә бер-берегезгә сораулар куегыз: без ничек яшибез? Без күпме? Исән калу өчен татарларга ниләр җитми? Аларга төгәл җаваплар кирәк.

Мондый сорауларны журналистлар көн саен биреп торсалар, милләт түрәләре нәтиҗәлерәк эшләр иде. Журналистларның үзләреннән дә төгәл җаваплар көтелә: басмагызның тиражы, тапшыруларыгызның рейтингы күпме? Рус, инглиз һәм башка халыкара телләрдә татар халкы турында объектив хәбәр тараламы? Татарча чыккан мәкаләгезне, тапшыруыгызны күрүчеләр саны үзегезнең төбәктәге татарларның 1-2 процентын гына тәшкил итсә, милләт шул санга калып бара дигән сүз. Нәтиҗәдә яңа җанисәпләрдә милләттәшләр саны алты яки биш нульле булудан төшеп калачак. Шул рәвештә инкыйраз тегермәнендә тартылып, онга әйләнәчәкбез.

## 12. Татарстан + төбәкләрдәге татарлар = милләт формуласы

Иң мөһим, четерекле сорауга җавап бирер чак җитте. Татарстан ничек? Үз исемен аклыймы ул? Татар халкына терәк булып, рухи байлыкларны сакларга ярдәм итәме?

Милли эшләрне никадәр тәнкыйтьләсәк тә, шуны танырга кирәк: Татарстанда татарларга милләт булып калырга кирәкле шартлар тудырыла (Милли университеттан башкасы). Менә дигән уку йортлары, Фәннәр академиясе, тикшеренү үзәкләре, мәдәният учаклары, федераль карамактагы мәгариф системасы, татар гимназияләре, профессиональ һәм үзешчән сәнгать коллективлары, музейлар, күргәзмә үзәкләре, иярченле телеканаллар, көчле матбугат холдингы һәм газета-журналлар, «Безнең гәҗит», «Акчарлак», «Ирек мәйданы» кебек зур тиражлы хосусый матбугат эшләп тора. Бу милли инфраструктураның еллык бюджетын, меңнәрчә хезмәткәрләрен күз алдына китереп карагыз. Араларында фидакарь милли затлар да бар. Шунлыктан, Татарстанда, Казанда яшәп тә, телне, әдәбиятны, милли мәдәниятне белмәгән һәм, иң аянычы, белергә теләмәгән татарларны милләттәш дип атарга тел дә әйләнми. Андыйларның бер аягы башка мохиткә баскан, икенчесе безнең тарафта. Этномәдәни упкын өстендә чайкалабыз...

Матди ярдәм күрсәтелми дип зарлану урынлы булмас иде. Татарстанда милли тормыш бюджеты тугыз нульле саннар белән үлчәнә! Республикада гына түгел, башка төбәкләрдә дә мәчетләргә, мәдәният үзәкләренә ярдәм ителә, милли костюмнар, музыка кораллары бүләк ителә. Татар конгрессы бертуктаусыз зур форумнар үткәрә. Сораган төбәкләргә дәреслекләр, китаплар җибәрелә, чит төбәкләрдә Сабан туен зурлап үткәрергә ярдәм итәр өчен Татарстаннан район-шәһәрләр беркетелә.

Россиянең 80 төбәге белән Татарстан арасында социаль-икътисади, мәдәни хезмәттәшлек турында килешүләр төзелгән. Татарстан вәкиллекләре Россиянең ике дистәләп төбәгендә һәм чит илләрдә эшләп тора. Боларның күбесе патша заманында да, совет чорында да булмаган. Хәзерге Татарстанда бар.

«Патшалар»ның татар милләтенә уңай мөнәсәбәте 2005 елда Казанның 1000 еллыгы тантанасында Владимир Путин чыгышын татар телендә башлап җибәргәндә күренде. Шаккаткан татарлар гына түгел, өлкә, край, республика башлыклары да бу хәлне күреп, тыңлап торды. Татар төбәкләре түрәләренең 1992 елда татар конгрессының беренче корылтаенда катнашуларын, хәтта чыгыш ясаганнарын хәтерлибез. Тарихка керде бу вакыйгалар! Пётр патша, Николай Беренче яки Икенче, Александр I яки II, хәтта Әби патша һәм Хрущёв та, Брежнев та моны булдыра алмаганнар иде. Безнең халыкны бәхетле итү өчен аңа татарча сәламләү дә җитәдер. Һәрхәлдә моңа кадәр тарихта Россия патшаларының, Генераль сәркатипләренең татарларга туган телебездә эндәшкәннәре булмады. Безнең халыкның җаны балавыздай эреде ул мизгелләрдә. Ләкин дәүләт һәм җәмгыять тормышында гел генә бәйрәм кәефе булмый, агы да, карасы да, эссесе дә, салкыны да алмашып тора. 2017 елда Йошкар-Олада зур утырыш вакытында милли телне башка милләтләргә өйрәтмәскә дигән фәрман «айныткыч» тәэсир ясады. Шулай да РФ Конституциясенә милли мәдәниятләрне, телләрне саклау декларатив рәвештә булса да язып куелды. Шуңа тотынып атлаган көнебез... Милли хәрәкәтнең, татар оешмаларының халык һәм хакимият белән аралашып эшләвен беркем дә алыштыра алмый.

*Мәрҗани, Максуди, Акчура, Исхакый кебек акыл ияләре, милли аң, дин, мәгърифәт һәм сәясәт фикерен өйрәтеп, милләткә юл күрсәтүчеләр никадәр соклandырсалар да, аларга татарга таяныч булырлык дәүләт бирәмлеген төзү насыйп булмаган. Язмышка зарлану, уфтану, үткәннәрне сагыну белән генә халык язмышын хәл итеп булмый. Чикләнгән вәкаләтле, Россия Федерациясе субъекты, ягъни федерация өлеше булган Татарстан 4-5 гасыр ватансыз яшәгән татар халкының бүгенге дәүләте ул! Аны үстерүчеләр, яклаучылар тарихи*

*юлбашчыларбыздан калышмый, алар кебек үк юл күрсәтүчеләр – проект төзеп, аны гамәлгә куючылар буларак хәтергә сеңәчәкләр.*

Чит илләргә барганда, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов шул илдәге татарлар белән очраша. Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе В.Г.Шәйхразиев төбәк җитәкчелекләре белән очрашканда, татарларга ярдәм иткән өчен рәхмәт әйтә, планнар белән бүлешә. Гомуми карарларны үтәү, практик гамәлләр белән шөгыльләнүче БТК Башкарма комитетында милли эшләрдә тәҗрибәле шәхесләр эшли. 470тән артык милли оешма татар халыкының ихтыярын чагылдырып, милләтне үстерә алыр иде.

Җитәрлекме бу мөмкинлекләр? Әгәр дә милли университет ачылып, педагоглар әзерләү, милли мәгариф тә җайга салынса, татар язмышы өчен борчылмас идек. Ләкин нинди генә идеаль шартлар булса да, татар халкының үзеннән башка, милләт ул-кызларының теләгеннән һәм фидакарьлегеннән башка инкыйраздан котылып булмый. Бу көн кебек ачык.

Татар халкы үсеше өчен йөзләрчә оешма, уку йорты, мәдәният учагы эшли, шул ук милли-мәдәни инфраструктурада меңнәрчә кеше хезмәт куя. Әмма күпсанлы милли затларның хезмәт нәтиҗәләрен, гыйлем-тәҗрибәсен куллану саннары чамалы: татар телен өйрәнүче, татар Интернетын, матбугатын карауччы балалар һәм яшьләрне күрсәтүче саннар бик кечкенә һәм алары да кимеп бара. Менә кайда югала милләттәшләр безнең статистиканың нульләре...

## 13. Милли-милли миллионнар?

Җанисәп китергән саннар якынча булса да, аның икътисади тормышка тәэсире зур булмаса да, бу күрсәткеч хакимиятнең гуманитар тармаклары, милли оешмалар өчен гаять әһәмиятле. Җанисәпнең милли-мәдәни сораулары буенча нәтиҗә – милләтнең саклану-югалу күрсәткече ул! Авыл хезмәткәре өчен икмәк уңышы, ит-сөт җитештерү, заводларда чыккан машиналар саннарына охшаш күрсәткеч кебек. Бу саннар мәгариф, мәдәният, мәгълүмат хезмәткәрләренең эш нәтиҗәсен чагылдыралар. Инкыйраз темпларын да бик ачык күрсәтәләр.

Әйдәгез, милләт таркалуның тизлеген үлчәп карыйк. Татарлар ел саен 1,5 %ка кимесә, ел саен илебездә якынча 47 000-50 000 мең кешебез «югала» дигән сүз. Татарча белүчеләр 20 ел эчендә 2 миллионга азайса, ягъни бер айда 8 220 кеше «ычкына» дигән сүз. Әйдәгез, сез яшәгән урында ничә укучы татар телендә белем алганын санап карыйк. Ничә сыйныф, ничә укытучы бар, дәреслекләр күпме? Аларның тиражы 2-3 мең данә булса, куанырсыз.

Шулай булгач, ни өчен без җанисәптә кимегән 597 мең татар санына, 11-12 процент югалуга гаҗәпләнәбез? Үзебезнең никадәр тырышуыбызны, ничегрәк туган телгә, татар матбугатына, милли театрга ябышып яту-ятмавыбызны, ул-кызларыбызны, оныкларыбызны татарча аралашырга өйрәтүебезне күзаллап карыйк әле. Чамалырак түгелме? Күп нульле саннар күренми анда! Татар интернеты сәхифәләрендә йөз меңләгән «лайк» милли миллионнарның исәнлеген күрсәтер иде. Кайвакыт һич югы «Like!» – баш бармагын өскә юнәлткән кул рәсеме – пәйда булса, ягъни берничә дистә «дизлайк!» дигәне баш бармагын аска таба юнәлтеп бәхәс уятса, бусы да милли тормышы барлыгын күрсәтер иде. Менә шундый җанлы, бәхәсле көзгедә күренгән милләттәшләр саны җиде-сигез миллионга җитәр иде. Сез үзегез татар интернет сәхифәсенә көн саен керәсезме? Күңелегезгә ошаган язмалар астына «Лайк!» тамгасын куясызмы? Әгәр челтәргә сирәк керсәгез, «лайк» тамгасына төртмәсәгез, алар онытылып калачак бит? Нәкъ татар милләтенең үзе кебек.

«Туган телне белүчеләр – халыкның яртысы» дигән гыйбарәне төгәл тикшереп

булмый – бу социологлар эше, аны оештыру, түләү мәсьәләсе кемгә карый? Татар сыйныфлары, якшәмбе мәктәпләренә йөрүчеләр потенциаль татар мохитенең 3-5 %ына якынлашадыр бәлки. Шулай да Интернетта татарлар карый торган мәйданчыклар бар. Татар җыры, концертлар, җыр язмаларының 500 мең кеше карау, кайбер җырларның рейтингы 4-5 миллион уникаль карау җитүе татар милләтенең яшерен потенциалын ачып сала. Бар андый җырчылар һәм тыңлаучылар! Интернеттан җыр тыңлаган күп миллионлы аудитория дә бар. Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Хәния Фәрхи, Гүзәл Уразова, Салават, Вәсилә Фәттахова, Эльмира Сөләйманова, Габделфәт Сафин һәм башкаларның җырларын тыңлаучылар дистә миллионнан артык. Интернетка куелган бер җырны 3-4 миллион уникаль тыңлаучы яратып тыңлаганда, бу моң яратучы кавемнең татарлыгы күренә. Татар телендә мәктәптә укымау да, коронавирус пандемиясе дә миллионнарча кешегә моңлы җырлар тыңларга комачауламаган бит! Димәк, татарлар һаман исән, аларның саны алты нульле.

## 14. Халыкара хокук субъекты булу Россиядән аерылып чыгу түгел

Татар конгрессына 20-30 ел элек кабул ителгән милли оешмаларның хәзерге чорда нинди хәлдә икәнлеген кайбер экспертлар белә. Конгресска кергән 470 ләп оешманың һәркайсына якынча 10 000 татар туры килсә, аларның һәрберсенең милләт турында хак мәгълүмат бирергә, милләтнең килеп чыгышы, мәдәнияте, аерым шәхесләр һәм проектлар турында әйтергә мөмкинлеге бар. Булдыклы милләттәшләрнең гамәлләре, тәкъдимнәре, иҗади һәм иҗтимагый энергиясе дә шул татар оешмалары аша Казанга, мәдәни үзәкләргә килеп җитә дип фаразлыйк. Шулай булгач, татар җәмәгатьчелегенең хәлен дә, кайда торуын барлау, санын белү дә кулдан килмәслек эш түгел.

Бөтен Россия күләмендә җанисәп вакытында кешеләрне Росстат санаса, аерым яшәү урыннарында, милли чараларда татарларны заманча коммуникацияләр аша үзебез барлап тора алабыз. Безнең барлау мөмкинлекләре, нинди милләтне үз итү-итмәвебез, туган телебез, милли үзаңның ни хәлдә булуы төрле саннарда күренеп тора: матбугат алдыручылар, радио-телевидение тапшыруларын көтеп алучылар, милли мәктәптә татар телен өйрәнергә теләүчеләр, театр-музейларга барып, Россиядә яшәүче җирле халыклар, шул исәптән, Татарстан тарихын өйрәнүчеләр саны... Бу эшләрдә киртәләр булган очракта, татар халкының хокук субъекты буларак кемдер фикер тупларга тиештер бит?

«Сез дәүләт агентлыгымы, иҗтимагый оешмамы?» – дип шаккатырган иде берәү, татар конгрессына килеп. Уставта язылганча, безнең Иҗтимагый берлек татарларның телен, мәдәни мирасын сакларга ярдәм итүче көч булырга тиеш. Ниндидер канунга сыймаган гамәлләрдән тотылып калып, сәламәт көчләрне туплар өчен кирәк бу гамәлләр. Оешмалар күп, аларның максатлары, идеологияләре төрле. Кайбер төркемнәр кискен сәяси проектлар күтәреп, дәүләт төзелеше, чикләрне үзгәртү максаты белән башка милләтләр, дәүләт белән каршылыкка керергә дә мөмкин.

Татар конгрессы ул юлдан китми торган хәрәкәт корды. Туган тел, милли мәдәният, тарих буенча конструктив, максатчан эшләү юлларын күрсәтүчеләр, башка милләтләр, дәүләт белән эшләрне тәңгәлләштерү, килештерү вазифаларын үтәүче структура кирәк иде. БТК шундый юлдан бара. М.Ш.Шәймиев 1992 елда Башкарма комитетның беренче утырышында ук татар конгрессы башка милли оешмаларны үз артыннан ияртергә тиеш дип әйткән иде. Уставка, программаларга да шулай дип язылды. Эш алымнары, сәяси кыйбланы билгеләүче әйдаманнар составы да моңа яраклы. Милләт исеменнән чыгыш ясаучылар Татарстанны якларга, үзенең һәр адымын халыкка аңлатырга тырышалар.

## 15. Дәүләт чикләре, патшалар-башкалалар алышынып торгач...

Бер милләт кешеләренең бер генә илдә яшәве турында хыялланучылар ялгыша. Алман халкы Германиядә, Австриядә, Швейцариядә, Бельгиядә һәм башка дәүләтләрдә яши. Гарәпләр, кытайлар дистәләгән илдә төп халык буларак гомер итәләр. Безнең татар халкы урта гасырларда 4-5 ханлыкта укмашып яшәгән, хәзер дистәләгән илләрдә «милли утраулар» булып, төрле кардәш милләтләр белән бергә гомер итә. Халык санын алган саен татар милләтеннән мишәр, себер татары, ногай, типтәр һ.б. этник төркемнәрне тартып алырга, аларны аерым милләт дип игълан итәргә тырышулар дәвам итә. Тарихны, этнологияне аңлату, урыннардагы милләттәшләрне барлау һәм санау, милли иҗтимагый эшләргә җәлеп итү, социологик тикшерүләр үткәрү мәшәкатьләре үзебезгә кала. Үзебез яшәгән авылда, районда татар милләтен саклау чаралары, гуманитар инфраструктураны булдыру һәм яшәтү өчен тотылган матди чыгымнар күләмен (федераль, төбәк, муниципаль һәм җирле хакимияттән, аерым химаяче-спонсорлардан алынган матди ярдәм) үзебез белеп торсак, кирәк чагында үзебез кайгыртсак урынлы булачак.

Ата-бабаларыбыз төзегән, яшәгән дәүләтләрнең берсен дә онытмыйбыз, берсеннән дә ваз кичмибез. Аларның һәркайсы тарих битләрендә, безнең күз алдында: Һуннар империясе, Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан, Кырым, Әстерхан, Себер, Касыйм ханлыклары, Ногай урдасы, Россия патшасы империясе, Советлар Союзы, хәзерге Яңа Россия Федерациясе – болар барысы да безнең ил... Әйе, патшалар, дәүләт мәркәзләре үзгәргән, ләкин милләт һәм ил калган. Хәзер шул ук «татар иле» күпмилләтле Россия Федерациясендә. Кая чыгып китсен шул халык үз җирен, тарихын, мәдәни мирасын ташлап? Аңа фәкать тик кануннарда язылган чын федерация һәм азмы-күпме демократия кирәк.

25-30 ел элек Бөтендөнья татар конгрессының Уставына һәм программасына татар яшәгән илләр, төбәкләргә, башка халыкларга мөнәсәбәте хокукый яктан нигезләнеп, съездларда һәм Башкарма комитетта расланган иде. Татарның тарихи Ватаны Россиянең милләтләргә мөнәсәбәте, татарларның статусы турында да БТК Уставында, РФ һәм ТР Кануннарында язылган, бу карарлар инкарь ителгән очрак булмады. Мин моны бу четерекле таләпләрнең үтәлешенә өч дистә ел шаһит буларак раслый алам. 1990 нчы еллар ахырында БТК башкарма комитеты рәисе Индус Таһиров белән миңа да БДБ илләренең Парламентара Ассамблеясе утырышларына Санкт-Петербург һәм Ереван шәһәрләренә барырга насыйп булган иде. Ул вакытта Бөтендөнья татар конгрессы әлеге парламентара Ассамблеягә күзәтүче булып та кабул ителгән иде. РФ Федераль Җыены аша Бөтендөнья татар конгрессы һәм, гомумән, БДБ татарлары дистәгә якын илнең парламентлары белән элемтәдә торды. Татарлар дәүләт кору, хакимият, хезмәттәшлек тәҗрибәсен мең ярым ел элек туплый башлаган һәм хәзер дә Конституция нигезендә зур сәясәттә катнаша алалар.

## 16. On-line иҗтимагый оешмалар – социаль челтәрләрдә

Совет чорының татар иҗтимагый оешмалары төзелгәнгә 30-40 ел үтеп киткән. Милли оешма кәгазьдә генә калса яисә 2-3 идарә әгъзасы һәм рәис булып саналучы спонсор-эшкуардан гына торган оешмалар яки бер-берсе белән ярышып-көрәшеп йөрүче көндәш милли төркемнәр белән нишләргә соң? Алар Казанга барганда яки губернатор белән очрашканда, гаҗәеп эшлекле булып күренәләр. Шулай да бүген милли оешмаларның программасын, рәсми статусын, планнарын һәм катнашучыларның мөмкинлекләрен өйрәнеп, халыкны оештыру буенча эшләрне заманча итеп кору зыян итмәс иде. Бәлки хәзер милли оешмаларның күбесен Интернеттагы социаль челтәрләр алыштырадыр? Блоглар, стримнар, видеофильмнар, интервьюлар, көндәлек хәбәрләр

меңәр чакрым аралардагы экспертларны уртак сөйләшүгә чакыра. Бармы татарның андый онлайн аралашуы? Минемчә, бу хәзергә сирәгрәк очрый.

Татар блогерлары, милли матбугат, ТВ һәм социаль челтәрләр реклама бирү, акча эшләү киртәсенә абыналар. Шулай да алар бар. Фәгыйлә Шакированың Ютюбтагы видеоканалына 60 мең кеше язылган. «Ютюб-татарочки» каналында хәзер Алсу Хафизова заманча блогер буларак танылды. «Ялкын» журналы тирәсендә җанлану бара, «Татмедиа-юниор» блогерлары үсеп киләләр. Эстоннар милли матбугатын яшәтү өчен бер гаиләгә икешәр балалар журналына яки газетасына языла иделәр. Бер миллионлы халык үзен саклау форсатларын таба. Кайбер милли бәйрәмнәрдә 300-500 мең эстонлы (халыкның өчтән бер яки дүрттән бер өлеше бу!) урман-кырларга чыгып, милләт хоры җырын башкаралар иде.

Ә безнең күп миллионлы халкыбыз, республикабыз икътисады, табигый байлыкларыбыз белән эстоннардан калышамыни? Бары тик берләшергә, яшьләрдә милли проектларга кызыксыну уятырга гына кирәк. Файдалы фикерләрне интернетта хуплау тамгасы белән көчәйтеп җибәрсәк, нинди көчле акция булыр иде! Лайк сүзе «лаек!» дигәнне аңлата. Миллионнарча милләттәшләребезнең кызыклы эшләре шул игътибарга лаек.

Төбәкләрдәге, район-шәһәрләрдәге татар оешмалары җитәкчеләре берьюлы 4-5 миллион татар белән очрашып, сайрашып йөри алмый, әлбәттә. Ләкин алар үз якташларының милли иманын, санын белеп торырга хаклы! Алар ел әйләсенә үзләренен милли җәмәгатьчелеге белән киңәшә алалар. Яшьләрдән сорап карыйк әле: «Милләтең буенча кем син?» «Синең татарлыгың каян килә, ни өчен син татар? Татар гаиләсендә тугангамы? Яисә татар теле мәдәнияте рухында яшәп, милләтнең тарихын, мәдәни мирасын өйрәнгән затмы син? Әллә кайберәүләр кебек үзеңнең татар булу-булмавыңны өздереп әйтә алмыйсыңмы?» Искәндәр исемен Сашага, Кадрияне Катяга әйләндереп, фамилиядән бер «л» хәрефен кыскартып, Габдулин булып йөрүчеләрне дә беләбез. Андый «бывший татар»лар җанисәптә үзләреннән сорамыйча гына башка милләт дип язып куюга риза булачаклар. Аерым шәхесне милләттән, туган авылдан, мәхәлләдән читтә калдырмыйча, һәр гаилә белән рухи җепләр суза алсак. Миллилекне йота торган глобализация һәм заманча техника бергәләп башкарыласы изге эшләргә «лаек!» тамгасы салып, татар дөньясына тарата ала. Хәер, бу гамәлләр барысы да үзебездән тора түгелме?

## 17. Безгә сан гына түгел, сыйфат та кирәк

Дөньяда берничә дистә вәкиле калган яки 150 кешедән торган, хәзер югалып баручы халыклар бар. Берничә мең вәкилне берләштергән милләтләрнең киләчәге дә бик озак булмас кебек. 2010 елдагы җанисәп буенча бисермәннәр – 2200, алеутлар – 482, алюторлар – 12, керек дигән халыкның 4 вәкиле калган булган. Беркем дә аларны үз телләрен, горефләрен сакларга үгетләмәячәк. Үзләренчә яшәү, аралашу хокуклары сакланырга мөмкин. Дәүләттән тагы нәрсә аласың? Үзләренә кирәген сорасалар, берникадәр ярдәм күрсәтелер бәлки.

Ә без? Зур тарихлы, борынгы чорларда күп дәүләтле булган татар милләте ничегрәк саклана? Дистә миллионга якын милләттәше булган, ягъни алты нульле сандагы татар халкы үзенең тарихи дәүләтләрен, мәдәни мирасын онытырга теләми. Кайчандыр Идел-Урал төбәгендә яшәүчеләрнең күпчелеге яки өчтән бер өлеше төрки-татарлар яшәсә, хәзер илдәге милләттәшләребез саны Россия күләмендә 2-3 поцентка калып бара. Глобальләшү чорында маңкортлык, үз милләтеннән ваз кичү чире дә, чамадан тыш милләтчелек, бөек мәмләкәт шовинизмы да, азчылык яки күпчелек синдромы да очрап тора.

Ләкин тезелеп киткән нульләр генә милләтнең куәтен билгеләми әле. Сан

белән сыйфат – аерым төшенчәләр. Матди ресурслары булган Ротшильдлар, Абрамовичлар зур акчалар сарыф итеп, сәясәттә дә катнашалар, дөнья агымына да тәэсир итәләр. Талант, белем, бердәмлек ярдәмендә күтәрелгән һәм тормыш агымына тәэсир итә торган милләтләр бар. Татарлар сан буенча гына түгел, тормышка тәэсирләре буенча да ничәнче урында соң? Татар байлары милләтне үстергән, матбугатлы, мәгарифле иткәнлеген ишетеп-укып беләбез. Ә бүген нинди химаячеләребез милләтне үстерә? Сәяси һәм иҗтимагый мөнбәрләргә күтәрелеп, татар халкын Садри Максуди, Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый кебек яклый алмасалар да, Россиянең федератив дәүләт булуын, Татарстанның кирәклеген дәлилләп чыгучылар күбрәк булсын иде.

## 18. Бүген татар мескен түгел

Милли хәрәкәт вәкилләре, тарих белән кызыксынучылар арасында бүгенге татар халкын артык кызганып ташлаган очраклар бар. Милли мәгарифне чикләү яки аның зәгыйфьлеге милләтне тыю дип аңлатучыларга шундый җавап бирәсе килә. Ә кайчан татарның чикләгән республикасы, фән-мәгариф, матбугат системасы, Бөтендөнья милли оешмасы булган? Беркайчан да хәзерге кебек мөмкинлекләр булмаган. Бөек юлбашчыларыбыз сөргеннәрдә, төрмәләрдә, чит илләрдә гомер иткәннәр. Ә бүген җитәкче урыннарда, бизнеста, завод-фабрикаларда зур вазифалар башкаручы татарлар адым саен. Фәндә, сәнгатьтә дан алучылар күп.

Бәлки кайбер иҗтимагый һәм сәяси мөнбәрләрдә генә тыйнаклык күрсәтәбездер. Телевидение экраннарында, Дәүләт Думасы утырышларында, сәясәтчеләр, сәяси технологлар чыгыш ясап, илнең милли сәясәтен, дәүләт төзелешен тикшерәләр. Россия, рус дөньясы, федерация корылышы, милләтләр язмышы турында бәхәсләрдә татарлар катнашканын күргәнегез бармы? Бер телевидение тапшыруында берьюлы ике әрмән, өч яһүд, бер рус милләтеннән булган экспертлар чыгышын күргәнем бар. Алар барысы да Россия, рус теле, мәдәнияте турында аяк терәп сөйләшәләр.

Сүз дә юк, алар әзерлекле, аргументларга таянып үзләренең зур сәясәттә катнашырлык белемнәре, һөнәри компетентлык ярдәмендә өстенлек яулаган. Безнең татарларга да үзләренең акылы, компетентлыгы, кыюлыгы белән рус илендә яшәүче яһүдләрдән, әрмәннәрдән калышып тору килешәме? Экспертларыбыз актуаль бәхәсләрдә катнашса, аларның әйтер сүзе, аргументы табылыр идеме икән? Талант, компетентлык, фикер һәм кыюлык буенча экрандагы экспертлардан калышмаслык шәхесләребез кайчан үсеп чыгар? Хәзергә татар, башкорт, чуваш, мари кебек җирле халык вәкилләре тыйнак кына читтә тыңлап торалар. Бәлки аларның әйтергә фикерләре юктыр? Россиянең башка халыкларына мөгаллим буларак танылган татарларның шундый хәлгә төшүенә ышанасы килми. Без үзебез бүгенге татарның мокыт, мескен булмавын ачык күрсәтергә, шуны дәлилләргә тиештер?!

Ләкин тормыш тыйнакларны зурламый. Соңгы елларда Президент атамасын алыштыру, РФ кануннары нигезендә федерация субъекты хокукларын саклаган өчен Татарстанга янаулар, нахак гаепләүләр явып торды. Ә бездә ТНВдагы «Таяну ноктасы» ток-шоу тапшыруында туры сөйләүче кыю һәм әзерлекле, конструктив фикерле экспертларны еш кына таба алмый интегәләр. Кая инде Мәскәүгә бару? Үзәк телеканалларда Татарстаннан барган депутат Олег Морозов кына күренә. Ул берүзе ничек татар дип чәчрәп чыксын инде?

Татар халкы хокуклары субъекты буларак чыгыш ясап, милләтебезнең мәнфәгате һәм көнүзәк түрендәге теләкләре турында үзебез әйтеп, язып торырга тиешбез. Дистә еллар буе Татарстан депутаты калачын кимергән, бөтен дөньяны урап чыккан якташларыбыз бар. Татарстанны, татарны күтәрерлек, яклардык сүзләр, төпле киңәшләр ишетәбезме алардан?

## 19. «Бывший татарин»мы, табигый ассимиляциюме?

Руслашкан татарлар, әгәр милли тел, мәдәният, гореф-гадәт белән кызыксынмасалар, татарлык алар өчен гайре табигый, «неудобный» архаизмга әйләнә. Алар үзләренең татарча акцент белән сөйләшүеннән оялалар (инглизләр яки кавказлар русча сөйләшкәндә, алай түгел, Сталинмы ул, Кикабидземы, таҗик мигранты Жамшут яки Равшан сөйлиме, үзенчәлекле яңгырый).

Кайбер яшьләр татар кавеме түбәнрәк («престижсыз») катлам дип уйлыйлар. Моңа тирәлек тәэсир итәме, наданлыкмы, әйтеп булмый. Шулай да туган телен, милләтен яратмаган, мәдәниятен белмәгән, татар тарихы белән кызыксынмаган милләттәшебезгә «син маргинал» яки «маңкорт» дип әйтергә җайсыз. «Просто неудобно». Алар җанисәптә саналырга яки саналмаска, яисә битараф калырга да мөмкин. Әгәр үзләре теләсәләр, татар булалар. Теләмәсәләр – бигайбә. Чынлыкта исә алар бер аяклары белән башка милләт бусагасына басканнар. Менә шушы ике милләт чалымнары булган, урталыктагы «экс-татарлар» яки «полурусскийлар» – ел саен арта баручы кавем аерым игътибарга лаек.

Бәлки, элекке елларда нәкъ менә шундый кардәшләр җанисәпкә татар булып кергәннәрдер? Ә хәзер без аларның югалуын аңларга тиештер, бәлки? Безгә «үле җаннар» (татар җаннары!) бик кирәкме соң? «Кирәкми», дип читләтү дә милләткә зыян китерәчәк. Милләтебездән бизгән затларны хисапка кертеп, ялган статистика белән юанып, «Без күбрәк санлы!» дип әтәчләнү дә татарга файда китерми. Башкорт кардәшләребезнең бу юлдан китеп, татарларны башкорт теленең «төньяк-көнбатыш диалекты» дип игълан итүе чын башкорт милләтенә зыян гына китерә. Тел, мәдәният уртак булса да, һәркем үзе булып кала, кешенең җанына (милли җанына!) мөһер сугу зур бәлаләргә китерергә мөмкин.

Шулай да әйләнә-тирә мохитнең тәэсире көчле. Элекке заманнарда татарларның күпчелеге яшәгән авылларда русча уку һәм сөйләшү сирәк очраган. Татар телен балачактан урамда, ишегалдында өйрәнгәннәр, руслар, чуваш-марилар да шул мохиттә татар телен үзләштергәннәр. Татар балалары башлангыч белемне мәдрәсәдә туган телдә алганнар. Ә менә хәзерге чор балаларының күпчелеге туган телдә әлифба күрмәгәч, хәтсез еллар дәвамында татар телендә укымагач, милли тарих, мәдәният тә читтә калгач, дөньяга карашлар үзебезнең милләткә бәйләнмәгән булып чыга. Башка милләтнең сәнгать әсәрләре рухи азык булып хезмәт иткәч, белем, мәгълүмат алган телләре үзгә булгач, татар туганнары белән башка телдә аралашкач, балаларның милли үзаңы үзгәрү һич гаҗәп түгел.

Милли үзаң урталыкта булган, татар мохитендә кайнамаган яки аны үз итмәгән шәхес җанисәптә язылып кына, татар халкын саклый алмый. Алар гаиләдә «городской» мәдәниятка күнегеп, «Пушкин телендә» сөйләшүче булып китсә, нәрсә әйтәсең? Ул бит мәктәптә укытмадылар ди, авылда үсмәдем, Казанда тордым, дәүләт кайгыртмады, дип уфтаначак әле! Үзе милли кыйммәтләр белән кызыксынырга уйламаса да.

Берни әйтә алмыйсың. Бу күренеш «табигый ассимиляция» дип атала. Элекке җанисәпләрдә татар булып саналган кайберәүләр катнаш гаилә, уку һәм хезмәт коллективы мохите яки милли наданлыклары тәэсирендә рус булып китсәләр, «имеют право». 2021 елда саналмаган 600 мең татар арасында андыйлар да күпмедер өлешне тәшкил итәдер. Мондый үзгәрешләр илнең, төбәкнең, район-шәһәрнең милли сәясәтеннән тора. Һәм, әлбәттә, үзебездән, милли җәмгыятьнең эшлеклелегеннән.

Бәлки, кемдер милләткә ихлас тартылып, урам язмаларын укып, концертлар тыңлап, татар телен, мәдәниятен өйрәнәдер? Милли оешмаларда якташларының үзаңы ниндирәк икәнлеген дә, кардәшләрнең рухи кыйблаларын да яхшы беләләр.

Бөтендөнья татар конгрессы – татар иҗтимагый оешмаларының халыкара берлеге, Татарстан Республикасына таянып, шул процессны җанландырырга тырышты. Ләкин төбәкләрдә милли үзаң, туган тел мәсьәләрен өйрәнү буенча социологик тикшерүләр сирәкнең дә сирәгедер.

## 20. Барлауны якын-тирәдән башлыйк!

Шундый тәкъдим: кардәшләр, әгәр милләттәшләрнең саны арта баруын теләсәк, халкыбызны Россия күләмендә санарга ашыкмыйк. Борынгы Алтын Урда җирләрендә дәүләт тотып, шул вакыттагы төрки телдә сөйләшүчеләрнең хәзер 3-5 % калуы тарихын берничек тә аңлатып булмый. Татар милләтенә нинди этнотөркемнәрне кертү, кайсы төбәктә күпмерәк татар булырга тиешлеге сәяси технологлар аша югарыдан төшерелү бүген генә башланмаган. Милләттәшләрнең яшәү урынында, районда, мәхәлләдә татар гаиләләрен санап, аларның анкета мәгълүматларын шунда эшләп торучы милли оешмада җыю мөмкинлеге бар.

Хәлиткеч фактор – шәхеснең татар мәдәнияте, тарихы, мәгариф, мәгълүмат системасында катнашуы, татар телен өйрәнергә, кулланырга теләге булып, рухи тормышта урын табарга тырышуы әһәмиятле. Андый затлар татар милли оешмасының эшендә катнашалар, җәмгыятьләрдә әгъза булып торалар. Менә аларны барлау, теләкләрен исәпкә алу, иҗтимагый энергияләрен практик гамәлләрдә эшкә җигү 10 елга бер уза торган җанисәпләрдә статистик мәгълүматның кимүенә түгел, киресенчә, артуына, татар тормышының үсешенә ярдәм итәчәк. Төбәктәге татар халкының саны да, сыйфаты да милләтнең абруен арттырачак.

Шулай итеп, җанисәп йомгакларында алты нульле саннар көтеп утырасы урынга, үзебез барлап-санап тора алабыз. Һәркайда яңа саннар булыр, алар еш кына үзгәреп торыр. Ләкин шушы анкета сорауларына үзегез булдырган кадәр җавап таба алсагыз, яшәгән урыныгызда татарларның чын санын һәм яшәү рәвешен саклауга ярдәм итә аласыз. Менә ул «тылсымлы» анкета:

1. Җанисәптә татар булып язылучылар, милли тормышта катнашучы татарлар саны (өлкәдә, районда, шәһәрдә, мәхәлләдә, авылда).
2. Туган телен татар теле дип санаучылар (төбәкләрдә, яшәү урыннарында).
3. Татар телендә сөйләшүчеләр саны.
4. Татарча укый-яза белүчеләр.
5. Татар мәктәпләре, сыйныфлары, аларда агымдагы уку елында белем алучылар саны (якшәмбе мәктәпләре санын аерым күрсәтергә).
6. Татар китапларын сатып алучылар, китапханәдән алучылар саны.
7. Төбәкләрдәге татар театрлары, мәдәният йортлары, сәнгать төркемнәре, ансамбльләр саны һәм исемлеге.
8. Татар газета-журналларының гомуми саны һәм аларның тиражлары – Татарстанда.
9. РФ төбәкләрендә.
10. Сез яшәгән районда, шәһәрдә, өлкәдә.
11. Татар интернет басмалары исемлеге һәм аларның рейтингы.
12. Популяр журналистларның, татар блогерларының язмаларын караучылар саны (яки аерым шәхесләрнең исемлеге).
13. Татар милли оешмаларының интернет сәхифәләре.
14. Милли сайтларны караучылар саны.
15. Рус телендә эшләп, татар тормышын даими яктыртучы интернет басмалар исемлеге һәм рейтингы.
16. Районнарда, шәһәрләрдә үтә торган татар мәдәни чаралары, милли бәйрәмнәр саны (катнашучылар санын күрсәтеп).

17. Татар милли тарихына, мәдәни мирасына һәм атаклы шәхесләргә багышланган музейлар исемлеге.

18. Татарстанның һәм татар төбәкләренең милли эчтәлекле музейларына соңгы 5 ел дәвамында баручылар саны.

19. Сез яшәгән төбәктә, район-шәһәрдә оешкан һәм хәзер уңышлы эшләүче милли иҗтимагый оешмаларның исемлеге, аларның эшендә катнашучылар саны.

20. Мәчетләргә даими йөрүчеләр, ураза тотучылар, дини йолаларны үтәүчеләр саны.

21. Милли оешма җитәкчеләре кайда белем ала? (Тарих, мәдәният, әдәбият, хокук гыйлемнәре, дәүләт төзелеше, эчке һәм тышкы сәясәт, халыкара мөнәсәбәтләр буенча).

22. Татар конгрессы съездлары, милли форумнарда кабул ителгән карарларның, дәүләт программаларының үтәлеше турында белешмәләр, хисаплар, тәкъдимнәр турында белешмә.

Бу анкетаны тутыру һәм милли эшләрдә катнашучылар һәм милли чаралар исемлеген төзү татар зыялыларының кулыннан килер иде.

Милли оешмалар, зыялылар, гомумән татарлар бу турыда мәгълүмат туплап, белешмәләр төзеп, эштә кулланcалар, киләсе җанисәпләрдә дә 5-6 миллион кешеле милләт булып сакланырбыз.

## 21. Глобальләшү безгә ярдәм итсен!

Сибелгәнбез, таралганбыз... Сибелеп югалган кардәшләр хәзерге техник чаралар ярдәмендә табыла, онытылган дуслык яңара, телефон, интернет аша минут саен, сәгать саен аралашып була. Инде кардәшләр табылгач та, милләтне глобальләшү тегермәненә салып тарту килешмәс. Татарларны Росстат санаганда гына түгел, гомумән, милли эшләр алып барганда да, милләттәшләрнең кайда ничек гомер иткәнен, яшәү, уку, эшләү шартларын белү файдалы. Алар белән элемтә урнаштыру өчен милли мәдәният-мәгариф-мәгълүмат үзәкләренең телефон-ватсап-интернет адреслары гына кирәк. Хәзер мәгълүмат ачыклыгы, сәүдә рекламасы чорында алар бездә юкмыни?

Интернеттагы сәхифәләр, социаль челтәрләр, пабликлар милли эшләрне җанландыруда ярдәм итәләр. Узган елда Татарстанда «цифрлаштыру елы» кысаларында онлайн хезмәттәшлек җанланды. Димәк, татар «утраулары» белән һәрвакыт туры элемтә урнаштырып тору мөмкинлеге бар. Зур милли оешмаларның һәр бүлмәсендә веб-камералы компьютерлар аша татар үзәкләре белән язышып утыру табигый күренеш булырга тиештер. Телебезне, мәдәниятебезне «йота» торган глобальләшү үзе дә безнең рухи үзенчәлекләрне саклап калырга ярдәм итәчәк. Мәдәни мирасның, туган телнең милли тәрбия әсбаплары булуын күрсәтү, халкыбызның кайда, күпме өлеше сакланганын ачып салачак.

Әгәр дә төбәкләрдә, район, шәһәр, авылларда татарлар бар икән, аларның хәлен Росстат яки губернатор һәрвакыт килеп белешмәскә дә мөмкин. Аның каравы күрше-күлән, татар җәмгыяте яки милли үзәк, мәктәп, клуб татар тормышын көн саен күреп тора. Балаларын татар сыйныфына яки татар түгәрәгенә бирүчеләрнең саны гына түгел, исемлеге дә безнең кулда булсын иде. Миллион кеше яшәгән шәһәрдә телефон белешмәсе булдырган кебек, татарлар исемлеген дә булдыру кулыбыздан килер иде, мөгаен. Татарлар яшәгән урыннан якын-тирәдә булган татар оешмалары, милли-мәдәни үзәкләренең адресларын, интернет сәхифәләрен төзү гадәти булачак!

...Кол Галиле, «Зәңгәр шәл»ле, Хәлил-Галиябанулы, Тукай, Такташ, Җәлилле, Туфанлы, Атнабайлы, Сәйдәш-Яруллин-Илһам Шакиров моңнары белән сугарылган милләт, Әлмәндәрле, Шәрәфиле татар халкы... Шүрәледән курыкмаган, Кырым-Касыйм-Әстерхан, Себерләрдә дәүләт төзегән, Ташкентларда, Чарджоу, Байкалларда, Балтыйк буенда дөнья көткән, Казан-Мәскәү-Питерларны бизәгән, «КамАЗ»лар, зур очкычлар чыгарган, Гази Заһитов кебек батырлар белән Берлинны алган, туган ил

өчен башларын салган Кормаш-Җәлилләре, Фатих Кәримнәре, сәнгате, мәгарифе булган, Донбасста, чирәм җирләрдә, Мегион-Сургутларда нефть тапкан, Татарстанда нефтехимия, автомобиль заводларын төзегән, чиста, төзек авыл-шәһәрләр корган, бодай, арыш, бәрәңге, чөгендер үстерүдә, мал үрчетүдә осталык күрсәткән татар кешесе! Ике гасыр элек ул дәүләт ярдәменнән башка, чикләүләргә карамастан, үзенең мәдәниятле, мәгарифле татар милләтен корган.

Хәзерге катлаулы чорда безнең мөмкинлекләр кимеми. Милләт буларак, үзебез йоклап ятмасак, татар халкы, һичшиксез, саклаunion.

**Римзил ВӘЛИЕВ,**
*журналист, Бөтендөнья татар конгрессының*
*Милли Шура әгъзасы.*

***Автордан:***

Бу мәкаләне язып, милли эшчәнлекне камилләштерү юлларын эзләргә түбәндәге сәбәпләр мәҗбүр итте:

1. Көнбатыш илләреннән, Мәскәүдән һ.б. РФ төбәкләреннән сөйләүче кайбер экспертлар (либераллар, демократлар, коммунистлар, хәтта кайвакыт «патриотлар» да) «Татарстан Россиядән чыга», «РФ таралачак» дип гайбәт тараталар. 90 нчы елларда Татарстанның суверенлык игълан итүнең, Декларациянең мәгънәсен бозып күрсәтәләр. Татар милләтенең, татар конгрессының, Татарстанның позициясен, федерализмның мәгънәсен аңлату кирәклеге көн тәртибенә килеп басты.

2. Интернетта, матбугатта, телевидениедә чыккан хәбәрләрдә, социаль челтәрләрдә татар телендә яки татар язмышы турында сөйләүчеләр, татар мәнфәгатьләрен яклаучылар, милләткә юл күрсәтүчеләр сирәк очрый. Иҗтимагый темага сөйләүчеләр һәм язучылар, блогерлар, экспертлар күренми. Шул ук вакытта милләттәшләребезнең кайбер сәяси төркемнәре Бөек Британиядә, Америкада һәм башка илләрдә торып, «бәйсез Татарстан» хөкүмәте исеменнән чыгыш ясыйлар. Ә Татарстанда, хәзерге Россия шартларында яшәүче халыкның төрле катламнары һәм дәүләт белән хезмәттәшлек итүче экспертлар күләгәдә кала.

3. БТК составындагы милли оешмаларның югалып бару мөмкинлеген истә тотып, иҗтимагый эшне яңа ысуллар белән, даими аралашуны онлайн режимында алып бару, интернетта күбрәк һәм ешрак аралашу кирәк.

4. Милли эшләрдә, татар матбугатында, ТВ һәм радиода эчтәлекне дә, форманы да заманчалаштыру, модернизацияләү максаты көн тәртибенә килеп басты.

Җанисәп йомгакларыннан соң сөйләшүне туктатмыйча, нокталы өтер куеп, эшне дәвам итү турында фикер алышу, яңа карашлар, проектлар тәкъдим итү өчен бу язма файдалы булачак.

# БОРЫНГЫ МИФНЫҢ ЯҢАЧА УКЫЛЫШЫ

## ИЛГИЗ ЗӘЙНИЕВНЕҢ «МӘДИНӘ» ӘСӘРЕНӘ БӘЯЛӘМӘ

Язучылар үз әсәрләрендә алдагы чорларның әхлакый-тарихи һәм мәдәни-эстетик тәҗрибәсенә, укучының мәдәни хәтеренә мөрәҗәгать итәләр. «Чит сүз», интертекстуаль бәйләнешләр авторларга фикерне, мәгънәне тирәнрәк яктырту, укучы белән уйнау мөмкинлеге бирә. Шул рәвешле интеллектуаль әзерлекле укучыга йөз тоткан текстлар иҗат ителә.

«Урта гасырлардагы Шәрык-мөселман әдәбиятлары, шул исәптән татар әдәбияты да тулысы белән интертекстуальлеккә нигезләнгән. Әмма ул заманда «интертекстуальлек» дигән термин булмаган, аның урынына канунчылык, традиционлык дигән төшенчәләр кулланылган. Әдәби традицияләр күчемлеге, дәвамчанлык, Шәрыктә төрледән-төрле иярүләр язуда, тәкълидчелектә, нәзыйрәләр иҗат итүдә күзәтелгән. Элгәреге шагыйрьләргә, йә булмаса, замандашлар әсәрләренә ияреп, нәзыйрә язуның да унга якын төре булган.

Гарәп, фарсы, төрки әдәбиятлардагы нәзыйрәчелекне шартлы рәвештә интертекстуальлекнең тарихи бер баскычы һәм төре итеп карарга мөмкин», дип яза Р.Ганиева[1].

Коръән сүрәләренә, Библия сюжетларына мөрәҗәгать итүгә, башка язучы тәҗрибәсенә таянып, интертекстуальлек чаралары буларак, цитата, реминисценция, аллюзия, центон, теге яки бу әсәр поэтикасын башка әсәр структурасында куллануга татар әдәбиятыннан күпләп мисаллар китерергә мөмкин булыр иде[2]. Мәсәлән, Р.Сабырның «Яшел һәм кызыл» (2006) драмасы, Ф.Әмирханның «Хәят» (1911) повесте һәм Г.Исхакыйның «Татар гакылы» (1911) хикәясе.

Илгиз Зәйниевнең әсәрләре дә хәзерге драматургиядә текстара бәйләнешләргә караган күренешнең бер кызыклы табышы булып тора. Аның Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында куйган Мәдинә язмышы буларак бирелгән трагедиясе игътибарны борынгы грек мифындагы аргонавтлар турындагы сюжетның бер өлешенә нигезләнеп язылган Еврипид трагедиясенә («Медея» безнең эрага кадәр 431 елда куелган) юнәлтә.

Дөньяда Медея турындагы сюжет интерпретацияләренең 300 гә якын варианты бар дип исәпләнә. Рус әдәбиятында Л.Улицкаяның «Медея һәм аның балалары» (1996), К.Вольфның «Медея.Тавышлар» (1996) романнары, Л.Разумовскаяның «Медея» (2020) пьесасы, Л.Петрушевскаяның «Медея» (2001) реквием-хикәясе борынгы үрнәктән килгән таныла торган кодлар аша хәзерге чорның заман конфликтлары ярдәмендә сәяси, социаль, социо-мәдәни проблемаларны калку күрсәткән әсәрләр булдылар. Татар театрында да Медея борынгы мифның яңача укылышы булып сәхнәгә чыкты. Әйтик, Әлмәт театрында Еврипид трагедиясе һәм Х.Мюллер текстларының компилляциясе буенча «Медея» (2017) спектакле куелды. Алар стилистика буенча төрле булып, сюжет катлаулы трансформацияләр кичерсә дә, барлык әсәрләрне бәйләп торган ракурсны күрми мөмкин түгел. Ул хатын-кызның гаилә кыйммәтләрен саклаудагы роле.

---

[1] Ганиева Р. Нәзыйрәчелектән – интертекстуальлеккә – әңгәмәдәшчелеккә таба // Әдәби мирас һәм текстология. Икенче чыгарылыш. – Казан, 2011. – 56-67 б.

[2] Макарова В.Ф. Габдулла Тукай шигырьләрендә тарихи-дини риваятьләр чагылышы / Роль ислама в стабилизации социальных процессов: сборник статей и тезисов II Международной научно-практической конференции, 18 марта 2017 г. / под ред. Р.Ш.Шайхевалиева. – Набережные Челны: Ак мечеть, 2017. – 49–51 с.

И.Зәйниевнең «Мәдинә» трагедиясе белән борынгы «Медея» арасында бәйләнеш берничә яссылыкта бара. Образлар яссылыгында карасак, төп героиняның Мәдинә исемендә бирелүен шәһәргә китеп, зина кылып яшәүче авыл кызына ишарәләүче текстның исеме белән бәйләнеше – паратекстуальлек дип карарга булыр иде (Мәдинә исеме гарәпчәдән шәһәр дигәнне аңлата). Әмма әсәрдәге төп вакыйга үрнәк текстның фабула элементларын саклаган хәлдә героиняның фаҗигале мәхәббәте турында сөйли. Мәдинә, сөйгәне байлыкка кызыгып башкага өйләнгәч, аңа һәм атасына үч итеп, карынындагы ике баласын юк итә. Борынгы трагедиядәге Медея да яраткан кешесе антын бозып хыянәт иткән өчен үзенең ике баласын үтерә. Шунлыктан, автор махсус аваздаш исемнәр сайлаган дип аңлашыла.

Еврипид әсәрендә комментатор, Медеяның оппоненты, халык авазы ролендә Коринф кызлары хоры чыгыш ясаса, И.Зәйниев спектаклендә Хор пролог һәм эпилогта, фаҗиганең эчтәлегенә, геройларның гамәлләренә аңлатма бирә[3].

Вакыйгалар барышында Хор кешенең көчле, галәмнәрне иңләрдәй горур исем булуы хакында әйтә, тик кешенең бөеклеген бер мизгелдә юк итеп тезләндерә торган нәрсәләр бар – җавапсыз мәхәббәт һәм гөнаһ, ди.

Хор әсәр ахырында адәми затка хаталарны вакытында төзәтмәсә, язмыш куып тотып булышырга мөмкинлеге турында кисәтә: «Ул киертер кәләшләргә кара күлмәк, / Ә кулына бер уч туфрак бирер бары...» [4]. Фаҗигале вакыйгалардан чыккан фикерне дә әсәрнең соңгы юлларында Хор җиткерә: «Хаталардан хали түгел адәми зат, / Тик хатаны төзәтерлек сабыры бар. / Төзәтергә ашыкмасаң, синнән узып, / Язмыш үзе төзәтергә кулын сузар...»[5].

Башында әсәр гадәти мәхәббәт өчпочмагына корылган гап-гади мелодраматик сюжетка нигезләнгән кебек тоелса, алга таба автор Нәфисә авызыннан әсәрдәге вакыйгаларның фаҗига икәнен искәртә: «Мелодраматик бер сюжет, нибарысы, / Әмма шигырь берлән бәян итсәң әгәр, / Тартыр сыман фаҗигагә, җирдән кубып»[6].

Фаҗиганең башы дини, үрнәк гаиләдә үссә дә, никтер юлдан тайпылган талантлы рәссам – Мәдинәнең гөнаһында. «Заманында изгелекне, (...) Тоя идем, сафлык көчен»[7] диюче Мәдинә сөйгәне белән никахсыз гөнаһ кылып яшәве өчен газаплана, гаебен кешегә ягып акланырга маташа (Нәфисә: «Үзебезнең гөнаһ – Аның тәкъдире дип, / Җаваплылык ансат кына өстән шуа!»[8]

Мәдинә сөйгәне белән араны өзәргә омтыла, намазлыкка баса. Җәүдәт аны бу дөньядан ваз кичеп, бакыйлыкны өстен күрүдә гаепли: «Рәссам сәләтеңне кәфенлеккә төреп, / Җирләгәнсең, төрбә сыман тора алар»[9] (күренештә бөтен картиналар ак тукыма белән капланган диелә).

Җәүдәт Мәдинәне сөюнең гөнаһ түгеллегенә инандыра. Сөйгәне башкага өйләнгән булуына карамастан, Мәдинә яңадан аның белән очрашуын дәвам итә, чөнки Җәүдәт ант итә: «Әгәр сине бер чак мин алдаган булсам, / (...) Ходай көттермичә, инде бу дөньяда, /(...) Җәзаласын мине бөтен тәмен табып, / Һәм бу җирдә һич калмасын хәтта эзем, / Корсын токымымның карт агачы, үлсен... / Изгелегең төргән бу яулыкта минә / Кызыл каным – ант итәмен шуның белән!»[10].

Гөнаһ турында фәлсәфә сүздә генә кала – дәрт иманнан өстенлек ала.

Алга таба Мәдинә тирәсендәге кыршау кысыла бара – аңа Җәүдәтнең хатыны, этисе тарафыннан басым башлана. Җәүдәт, этисе белән каршылыкка керәсе килмичә, Мәдинәне авырлы килеш ташлый, мыскыллап чыгып китә. Кан белән биргән антын бозган Җәүдәт җәзасын бу дөньяда ук ала – юл һәлакәтендә янып үлә. Ә Мәдинә, тагы да зур гөнаһ ясап, карынындагы балаларын юк итә. Күргәнебезчә, чыганактагы төп мотив яңа идея-сәнгатьчә интерпретациядә бирелә.

[3] Зәйниев И. Мәдинә / Казан утлары. – 2020. – №12. – 128-153 б.
[4] Шунда ук. – 153 б.
[5] Шунда ук. – 153 б.
[6] Шунда ук. – 134 б.
[7] Шунда ук. – 131 б.
[8] Шунда ук. – 130 б.
[9] Шунда ук. – 137 б.
[10] Шунда ук. – 139 б.

Медея «ясоннарның тамырларын йолкып юк итәм» дисә, Мәдинә «чәчәге дә коелмаган алмагачларны кистертә» («Шәҗәрәнең данлы агачына үзең / Үткен балта чаптың зәһәр телең белән!»[11])

Борынгы трагедиядә Креонт һәм Главканы агулы бүләк җибәреп үтергәннән соң да Медея үч алу сусавын баса алмаган кебек, Мәдинәне Җәүдәтнең хатыны Галия белән авариядә янып үлүе генә тынычландырмый, үч алалмый калуыннан хатын акылдан шаша, хыянәтченең атасы Кәримгә карата үзен түбәнсеткән өчен мәкерле планын тормышка ашыра – нәселен юк итеп үч ала (Галия – Главка, Креон – Кәрим исемнәре бәлки очраклы туры килгәндер, әмма исемнәре җисемнәренә туры килеп тора).

Фаҗига корбаны булган Кәрим ага яхшы нәсел калдыру турында хыяллана, авыру хатынын сәламәткә алыштыра. Ул да бәлки шуңа җәзасын ала.

Мәдинә балаларын хәлле бабалары ярдәмендә үстерә алган булыр иде. Гамәле белән ул үз-үзенә җәза бирә сыман.

Героиня кечкенә чагында песиенең яңа туган, әле сукыр дүрт баласын берәм-берәм үткен тешләр белән кимергәнен күргән була. Ул вакыйгадан соң бала елавын ишетсә, песиләр елавы булып тоела. Әсәр ахырында героиня акылдан шашкач, аңа галлюцинация буларак, песи тавышы ишетелә. Биредә Мостай Кәримнең трагедиясе белән дә текстара бәйләнеш барлыкка килә. Бу – «Ай тотылган төндә» әсәрендә ана кошның балаларын кыядан ташлавы. Шуңа ассоциатив параллель бирелгән күренеш – зина кылган ананың гамәле һәм кыядан ташланган балаларның фаҗигале төстә гомере өзелү. Әлеге күренешләр ике әсәрдә дә психоэмоциональ йогынтыны көчәйтүче чара булып тора. Тик М.Кәрим әсәрендә «акылдан шашу», трагизм кешелексез гадәтләргә сукырларча иярү, шәхес иреге мәсьәләсе белән бәйләнештә бирелсә, И.Зәйниев әсәрендә драматизм аерым шәхес белән язмыш шаяруы нәтиҗәсендә килеп чыга. Мәдинәнең акылын җуюы якын кешеләренең хыянәте, экзистенциаль кичерешләре белән бәйләнгән.

Шул рәвешле, «Медея» һәм «Мәдинә» әсәрләре арасында идея-тематик, образ, сюжет яссылыкларында «әңгәмә алып барыла». Коръәннән китерелгән ахырзаман, җәннәт, тәмуг, үлем фәрештәсе образлары ярдәмендә денсезлек, зина кылу, кан белән биргән антны бозу, кешене рәнҗетү тәнкыйтьләнә. Автор ант белән шаярмаска өнди, кешенең Аллаһы Тәгалә тарафыннан камиллеккә омтылырга тиешле зат булып яратылуын, шул камилләшү юлында гармония җимерелүне (динсезлек), кыргый дәртнең кеше күңелендә өстенлек алуын тормышыбызда очраган күп фаҗигаләрнең башлангычы итеп күрсәтә.

Драматург «Мәдинә»не 2013-14 елларда Шекспирның «Ричард III» спектаклен эшләгәндә язган. Интертекстуаль бәйләнешне хикәяләү стиле яссылыгында карасак, инглиз классигы Шекспирның тыгыз фикерле стиле йогынтысы И.Зәйниев трагедиясендә сизелеп тора. «Мәдинә»дә силлабик һәм силлабо-тоник шигырь системасында кулланыла торган төрле үлчәмдәге рифмасыз тезмәләрдән төзелгән ак шигырь формасын күрәбез. Әсәрдә авазлар билгеле бер оештыру, схема буенча басымлы, басымсыз иҗекләр чиратлаша, юл араларында метафизик паузалар шактый. И.Зәйниев текстын ак шигырьгә кертергә аерым стопаларның ритмик оешкан булуы мөмкинлек бирә.

Геройларның күпкырлы эчке дөньяларын, заман каршылыкларын тирән чагылдырып, ренессанс трагедиясен булдырган У.Шекспир әсәрләрендә образлылык, афоризм, метафоралар гаҗәеп күп. Беренче шигырьләр циклында ук, шагыйрь өйләнергә курыккан дустын үгетләгәндә, аның матурлыгын бай уңыш вакытында ач тору белән чагыштыра. И.Зәйниев тә метафораларны мул куллана: «Өметемнең соңгы көзе, кыштан сакла. / Язым бул син, бул арышым көздән чәчкән! / Шомырт салкыннары белән, әйдә, өшет, / Тик тапшырма зәһәр кышның кулларына!»

Шекспир геройлары хәрәкәтләнүгә караганда күбрәк уйлана, фәлсәфәгә бирелә, фикер алыша, И.Зәйниев әлеге әсәрендә Шекспирдагыча тормыш фәлсәфәсе, пафос, психологик киеренкелек һәм фикер тыгызлыгы сала белүендә ачыла: «Әйе, тугры

[11] Зәйниев И. Мәдинә / Казан утлары. – 2020. – №12. – 153 б.

түгел агач яфракларга, / Күзләр килгән саен кан тамырын төйнәп, / Җанын корта яфракларның, ә яз җиткәч / Яңалары белән бизи үзен, яши»[12]. (Шекспирда да күз, шәрә агач ботаклары метафоралары картлыкны аңлата).

Әлеге әсәрдән фразеологизмнарны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Менә аларның кайберләре: «Ярсу бәхетсезне янәшәңдә тота күрмә. / Бәхетсезгә бәхет – синең бәхетсезлек»[13]; «Бары кайгы фонындагы бәхет кенә / Зур күренә. Тоташ бәхет киләчәктә / Олы кайгы көтү белән изалана»[14].

Әсәрдә чагыштырулар шактый: «Хәтер – ватык чүлмәк, кисәкләре һәрчак / Кара җиргә кереп югала»; «Хәтер – бер җавапсыз суфлёр»; «Бүректәге бүре баласыдай»; «Тормыш – төнге юлдан чапкан автомобиль / Яктылыгы – тик эчендә баручыга. / Ә калганнар – бөҗәк, каршыдагы нурга / Өмет итеп, пыялага сытылучы»[15].

Геройларның үз эчендә барган каршылык, трагедия жанрына хас булганча, эмоциональ күтәренке рухта тасвирлана, сөйләмнәре пафослы, образлы: «Нәсел матур агач булып үссен өчен / Корган ботакларын кисеп ату кирәк»; «Юньле агач үсентеләр җибәрми ул» (биредә никахсыз туган балалар турында сүз бара).

Сынландыру да үзен аклый: «Тик ярату – нишләп күпчак гөнаһ белән / Бер савыттан ашый? Шуңадыр ул йөрәк / Яратканда бер урнына ике тапкыр / Тибә, абынып куя – күреп мәхәббәткә / Илткән юлны гөнаһ асылташлар белән / Түшәгәнен»[16] .

Трагедиянең башыннан ахырына кадәр ак-кара антиномиясе бирелә. Кара канатлар, кара күз пәрдәсе, кара төн һ.б. Бигрәк тә ак төс фәлсәфәсе әсәрдә күп мәгънәләрдә уйнатыла: «Туйда кияр ак күлмәкнең аклыгына / Гөнаһ табы тузан булып кунса әгәр»; «Сукыр хәтер – акның агы, шаян хәтер. / Ак тап белән булганнарны каплап куя»; «Сөяркәнең – һәрчак суык түшәкләре, / Кәфенлектәй бер өметсез ап-ак җәймә»; «Ак күлмәктән юдык төннең гөнаһ эзен» һ.б.

Галиянең сүзләре үзен тасвирлый: «Димәк мөмкин акны – кара, / Караны – ак итеп күрү бу дөньяда?»

Әсәрдә ак, шәмәхә, кара, яшел, кызыл төсләр турында фәлсәфә рәссам Мәдинәнең эчке дөньясын ачуда роль уйный: «Шуның белән яшәү кызык тадыр һаман. / Кемгә кара – ул тик кара гына, ләкин / Һич язып булмый карага кара белән, / Һәрчак кара аркасында ак бит ята...

Галия: «Кызык, алайса әйт: / Туй күлмәге нигә соң ак? Бәхет төсе / Безнең башта нигә акка гел бәйләнгән? / Туй күлмәге – аклык-сафлык үрнәге бит? / Ак күлмәкнең кай чабуы алсу? Йә, әйт?».

Әсәрдә алма образы берничә мәгънәдә кабатлана: « ...бер алманы ярып, / Кортлы ягын, билгесездер кемгә бирә?» (ягъни, хатынгамы, сөяркәгәме?). Мәдинә белән Иржанның кыргый җенси якынлык кылуы геройларның комсызланып алма ашау күренеше аша бирелә («Менә алма! Беләкләрең кебек тыгыз / Һәм ялтырап тора шәм сөрткәндәй тәне! / Авыз итеп кара, ул шытырдап тора! / Тешләгәнне көтә, чәчрәп чыгар суы!»[17])

Билгеле булганча, алма образы төрле мәдәниятләрдә күпчелек очракта яшьлек, үлемсезлек мәгънәсендә яки гөнаһ кылу символы буларак кулланыла. Адәм белән Һаваның җәннәттән куылуына сәбәпчеләрнең берсе булган җимешкә ишарә дип тә аңларга була (гәрчә, ул җимешнең гранат булу ихтималы хакында бәхәсләр бара).

Әсәрдә сәнгатьчә алым буларак «уен» мәгънәви роль уйный. «Бутаганбыз / Мәхәббәтне дәрт уены белән... / Уен? Синең өчен бу тик уен булдымыни? / Син бит антлар иттең кызыл каның белән...»[18]

Галия исеме гарәпчә «бөек, олы, югары, дәрәҗәле, кыйммәтле» дигәнне аңлата. Галия байлыкка кызыгып өйләнгән ирен «ауга» җибәргәндә, сер бирми торган, эчтән

[12] Зәйниев И. Мәдинә / Казан утлары. – 2020. – №12. – 146 б.
[13] Шунда ук. – 144 б.
[14] Шунда ук. – 140 б.
[15] Шунда ук. – 132, 140, 141, 149 бб.
[16] Шунда ук. – 131 б.
[17] Шунда ук. – 135, 139, 140, 141, 142, 143, 153 бб.
[18] Шунда ук. – 150 б.

янса да, сөяркәләре булуына күз йомучы көчле хатын ролен уйный («Ролем тик минеке, үзем уйныйм!»[19]) Аның битлеге һәм ироник интонацияле сүзләре астына гаилә бөтенлеге хакына хыянәт итеп йөргән ирен аклап, үзен бәхетле күрсәтергә маташкан икейөзле, гаҗизләнеп беткән мескен ялгыз хатын яшеренгән.

Салкын акыллы Нәфисә дуслык уены уйный – аның өчен Мәдинә бары язылачак әсәре өчен персонаж. «Тавышыңның кайгырулы / Яңгырашы – тик ясалма уйнау гына»[20] – ди аңа Мәдинә, һәм иптәш кызына үч итеп, Ирҗан белән уйный. Әсәр ахырында исә Кәрим белән уен кора – «Тыңлап кара, эткәй, оныкларың, кил, / Кендек турыма куй еллар кунган башың»[21].

Язмыш, чынбарлыкның кешеләр белән уйнавы түбәндәгечә бирелә: «Элпә артын сәхнә итеп уен кора. / Хәтер – бер җавапсыз суфлёр. Шул сәхнәдә / Роль уйнаган артистларның сүзен бутап, / Вакыйгалар муенсасын тартып өзә / Һәм чәчелә энҗеләре кайсы кая. / Һәм финалда кем үләсен белеп кара...»[22] Шул рәвешле әсәрдә «уен» заманның, кешенең асылын аңлатучы, яшәештәге абсурдлыкны күрсәтүче билгегә әйләнә.

Мәдинәнең сөйләмендә экзистенциаль ирония ачык чагыла: «Сизмичә дә канатлардан баш тартканбыз, / Шуңа дучар без җәяүле мәхәббәткә...» Теле төртмәле: «Тешләшергә киңәш итмим. / (...) «Сезнең йөрәк тимер дип ишеткән идем, / Тешләремне җимерергә теләгем юк»[23].

Көнчыгыш фәлсәфәсендә яшәештәге камиллек мәгънәсендә йөри торган тынлык образы әсәрдә берничә мәгънәдә бирелә. Беренчесендә Шекспирның «Гамлет»ындагы кебек («Остальное – тишина...») экзистенциаль тынлык, бушлык турында сүз алып барыла сыман. Яшәүнең чикле булуына, хаостан торуына төшенгән Мәдинә: «Бәхет, мәгънә эзләп яшәү инде үзе, / Миңа калса, мәгънәсезлек үлем барда. / Бары тынлык кына мөһим бу дөньяда» [24].

Тынлык – тынычлык, югары серлелек, яшәү мәгънәсендә дә кулланыла. Бәлки рәссам Мәдинә өчен тынлык – тынгысызлык, иҗат итү, югары гармония, серлелек (латин телендә тынлык һәм сер бер мәгънәдә йөри), яшәү – илһамланып иҗат итүдер. Рус шагыйрьләре А.Бальмонт та бит, тынлыкны хәрәкәт («Здесь тишина цветёт и движет»), А.Ахматова иҗади процесс («Творчество») буларак күзаллый.

Әсәр герое Кәрим өчен «салкын тынлык» – өметсезлек, нәселе өзелү.

Шул рәвешле, әсәрдә кулланылган поэтик һәм интертекстуаль чаралар автор тарафыннан билгеләнгән идея-сәнгати бурычларга ирешүгә хезмәт итеп кенә калмый, алар әсәрнең мәгънә чикләрен киңәйтә. Әйтергә кирәк, әсәрдә милли менталитет, үзенчәлекләр, халык язмышы чагылмый, ә шәхес трагедиясе, гомумкешелек кыйммәтләре бирелә. Кайбер сәнгать белгечләре тарафыннан заманча Европа театрының алдынгы тенденцияләренә тәңгәл килерлек сәнгати эзләнүләр булуы милли театрлар өчен кулай күренеш буларак билгеләп үтелә.

Е.Н. Шевченко Әлмәт татар драма театры сәхнәсендә алман драматургиясе хакында язганда болай ди: «...Эстетик аерымлыклар булу сәбәпле, багланышлар гел шома гына бармаса да, башка сәнгать традицияләрен кертеп җибәрү һәрвакыт уңышка илтә: ул кызыклы сәнгати нәтиҗәләргә китерә, татар театрының мөмкинлекләрен киңәйтә һәм аны Европа контекстына алып керә...»[25].

Бәлкем галимә хаклыдыр... Ничек кенә булмасын, татар драматургиясендәге кызыклы табышларда И.Зәйниевнең роле зур. Борынгы мифның яңача укылышында бу яхшы күренә.

**Венера МАКАРОВА,**
*филология фәннәре докторы.*

[19] Зәйниев И. Мәдинә / Казан утлары. – 2020. – №12. – 142 б.
[20] Шунда ук. – 129 б.
[21] Шунда ук. – 152 б.
[22] Шунда ук. – 140 б.
[23] Шунда ук. – 148 б.
[24] Шунда ук. - 140
[25] Шевченко Е.Н. Әлмәт татар дәүләт драма театры сәхнәсендә немец драматургиясе / Фәнни Татарстан. – №2(34)2022. – №2(34). – 128-134 с.

# ИЛГИЗ ЗӘЙНИЕВНЕҢ «ӨЙЛӘНӘМ.ТАТ» КОМЕДИЯСЕНДӘ КӨЛКЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Хәзерге драматургиядә көлке төрле вариантларда чагылыш таба – абсурд юморы, фарс, буффонада (З.Хәким «Бармы ришвәттән дәва?»), пародияләргә корылган миниатюралар (И.Зәйниев «Мәхәббәт FM»), лирик комедия (И.Зәйниев «Бабайлар чуагы»), моңсу комедия (И.Зәйниев «Мәхәббәт турында сөйләшик»), музыкаль комедия (И.Зәйниев «Бию пәрие») трагикомедия, водевиль һ.б.

Хәзерге татар комедиясендәге эзләнүләргә күз салсак, Илгиз Зәйниев иҗаты жанр төрлелеге, заман проблемаларының киңлеге, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан аерылып торуын күрербез[1]. Республика театрларында бара торган күпсанлы спектакльләр режиссёр-драматургны көлке тудыру остасы итеп танытты (алга таба көлке дигәндә, без «смех, смешное» мәгънәсендә түгел, ә «комическое»ны күздә тотарбыз). Соңгы елларда И.Зәйниевнең «Өйләнәм.tat» комедиясе Камал театры сәхнәсендә уңыш белән бара. Аны өйрәнү әдип иҗатының художество алымнарын гына түгел, XXI гасыр башы татар драматургиясендә көлке үзенчәлекләрен билгеләргә дә мөмкинлек бирә.

«Өйләнәм.tat» комедиясе социаль челтәрдә видео-көндәлек алып баручы Раннурның хатын эзләве, аның белән танышырга килгән хатын-кызлар «кастинг»ы, ябылырга торган газета журналистларының төрле кешеләр белән интервьюлары төсендәге миниатюралардан тора.

Журналистлар таксист Шөһрәт, Гөлсем апа белән Һидаять абыйлар, икенче хатын алган Гали, күрәзәче Гайсә, тракторист Мулланур белән очрашып, интервью ала. Нәкъ менә шушы геройлар исеменнән автор җәмгыятьтәге төрле ямьсез күренешләргә шелтә белдерә, социаль, милли, фәлсәфи, сәяси проблемалар күтәрә. Илдәге эшсезлек, ирексезлек, ялганга, күз буяуга күпчелек журналистларның, халыкның дәшмәве, газеталарда мөһим проблемаларны яктырту урынына мәхәббәт өчпочмагы, көндәлек ызгыш-талашлар турында язу, җитәкчеләрнең, милләт исеменнән йөрүчеләрнең үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртуы тәнкыйтьләнә.

Эстрадада түбән сыйфатлы җырлар һәм җырчыларның күбәюе («Бигичев кадәр җырлый алмагач, анда ник буталып йөрергә») халыкның газета, китап укымавы, ир-хатын мөнәсәбәтендәге каршылыклар, рухи кыйммәтләрнең югалуы тәнкыйть объектына әверелә.

Журналистларның күбесе акча өчен генә язуы турындагы фикерне («Милләт исеменнән, беләсеңме, күпме акча эшләп була!») журналист Хәбибрахман образы җиткерә. Җиңел кәсеп белән баерга омтылучы әлеге персонаж хакында элекке хезмәттәшенең репликалары сөйли: «Райондагы коррупцияне ачыкларга дип китәсең, главаларга мәдхия язып кайтасың».

И.Зәйниев – көлке ситуация тудыру остасы. 60 ел бергә гомер кичергән Гөлсем, Һидаять башта соклану хисе уяталар. Көлкенең уйдырма мотивы – күз буяу, ялган, иллюзия (тойгы алдавы сәбәпле чынбарлыкны бозып күз алдына китерү) эшкә җигелә. Журналист Раннур белән матур гына итеп сөйләшеп утырган әби белән бабай тора-бара кызып китеп ачуланыша, әллә нәрсәләр әйтешә, бер-берсенең

[1] Закирзянов А.М. Авторские жанровые формы в современной татарской драматургии // Жанрово-стилевое развитие национальных литератур в XX–XXI вв.: материалы Международной научно-практической конференции (4 декабря 2020 г., г. Казань). – Вып. 2 / сост.: А.Ф. Ганиева, Ф.Х. Миннуллина, Л.Р. Надыршина. – Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2020. – С. 132-140.

серләрен ачарга тотыналар. Көтелмәгәнлек эффекты, «иллюзия җимерелү» көлке барлыкка китерә[2].

Сатирик образ тудырганда, драматург үзиронияне куллана. Идея өчен милициягә эшкә кергән, әмма «анда тәртипнең төрлесе» булуын күреп китәргә булган, «дәүләт акчасыннан читтәрәк булсаң, үзеңне иректә итеп хис итәргә мөмкин» дип санаучы, «миллионерларның акча эшләвен карап утырырга» яратучы таксист Шөһрәт үзенең асылын сөйләмендә ача. Үзен «иректә чыпчык» итеп хис итсә дә, гипербола һәм карикатура аша тудырылган образ ул – усал хатыны үкчәсе астыннан чыга алмый, пластик операцияләргә акча өчен көне-төне таксида чаба. Эчке мәгънә белән тышкы форма туры килмәве көлке тудыра.

Шөһрәт тормыштагы шактый абсурд күренешләрне бәян итә (үзләре куйган, әмма турысын әйткән кешене өстәгеләрнең кысуы һ. б.). Вакыйгаларны сөйләп бирү, фикернең җанлы вакыйга аша бирелмәве әсәрдә хәрәкәт аз булган очракта аның сыйфатына хилафлык китерер иде, ә биредә сөйләп бирү хисабына фикер тыгызлыгына ирешелгән.

Күрәзәче Гайсә – халыкның алданырга яратуы, кешенең үзе уйлыйсы, көч түгәсе килмәве, ап-ачык булган әйберләрне дә кемдер әйтергә тиешлеге турындагы фикерне куәтле торган персонаж. Биредә кешеләрнең аңнарына йогынты ясаучы манипулятор күрәзәче һәм массакүләм мәгълүмат чаралары арасында охшашлык күрми мөмкин түгел.

Күрәзәчегә ир табу хыялы белән килгән хатын булып уйнаучы журналист Румия көлкегә кала, чөнки үзе дә симуляция белән шөгыльләнә – тормышта ир кирәкмәгән кебек кылана, үзен карамый, эшкә бирелгән, ирләргә охшап бара. Биредә көлкенең уен һәм уйдырма мотивлары – күз буяу, ялган, буш хыял, өмет, үз-үзеңне алдау һәм иллюзияләрнең җимерелүе күзәтелә. Күрәзәче дә башта аның белән уйнаган кылана. Аннан «Тирә-ягыңа күзеңне ачыбрак кара... Үзеңә ир, балаңа ата табасың килсә, ерак йөрисе түгел», – ди. Румия: «Нишләп сез башта ук белгәнегезне әйтмәдегез?» дигәч, Гайсә: «Кәмит уйнарга килгән кешегә – кәмит (...)», «кайтып, чәчеңне ю, киен-ясан, иреңнеңне буя... Куян кәкәе ашап кына бәхетле булып булмый», – дип җавап бирә.

Алда сүз барасы хатын-кыз типлары көлке алымы буларак, абсурд ситуацияләрдә бирелә. Матур сөйли торган ирне ашатыр өчен 3 җирдә эшләп, кредитка баткан, баласы белән ташлап киткәч тә, «шомыртын» көтеп ята торган Айнур, лабораториядәге «микробларны ирләргә караганда, якынрак күргән», «свиданиега» абыйсы белән килгән Фәридә, ир белән торганы булмаса да, кешеләрне кавышырга өйрәтеп йөрүче корректор Сәлимә («үзем яза белмим, ләкин кешенекен төзәтәм инде»), кемгә булса да, гашыйк буласы килгән, интернет аша гына эшләп, дөнья буйлап сәяхәт итү хакында хыялланган яшь стажёр Әлфия – теләкләренең абсурдлыгын аңламыйлар. Югары максат – капма-каршы гамәл нәтиҗәсендә (каршылык мотивы) комик, абсурд ситуацияләр туа.

«Тормыш агымына бирелгән» әлеге геройлардан аермалы буларак, җир кешесе Мулланур образы фокуста социаль-иҗтимагый проблемаларны яктыртырга мөмкинлек бирә. Эчкәч, курыкмыйча дөресен сөйли торган трактористны авылның бетүе борчый («юлга якын булганга бөтен көтүлек җирләрне сөрдерделәр дә, анда чәчсәң, юлдан күренеп тора бит – матур, имеш, бөтен җир чәчелгән! Ә тирәнгәрәк керсәң – нәрсә?»). Аның «Миндә логика бар, ә сездә белем генә. Василә апаның указкасы төшсә, мәңге онытмаслык буласың», диюе һәм соңрак әйткән: «Сталин булса, ул главаны майонез белән сылап, шашлык итеп кыздырыр иде» дигән сүзләре, халык фикерен җиткерә: «каты куллы» җитәкчеләр булганда гына, тәртип урнашачак.

[2] Рюмина М.Т. Смех как виртуальная реальность. Изд.2-е, испр. М.: КомКнига, 2006. – 320 с.

Мулланурның «Сез институт бетергән, ә мин – мәктәп, шуңа логикам бар, ә сездә юк ул», – дигән сүзләре рефрен булып кабатлана. Ягъни сезне уку йортларында идеология белән агулаганнар. Гади кешегә бар да ачык, аның логикасы буенча «яратмыйча өйләнеп булмый», «ир, хатынга караганда, майонез банкасын күбрәк алырга тиеш» һ.б.

Көлке белән драматизм үрелеп китә – айлык эш хакын майонез белән түлиләр икән («район башлыгының кибетендә сатылмый яткан товар»). Геройның «президент белмидер бу хәлләрне» (ирония аша кире кагу), «әшәке инвестор гаепле» диюе халыкның Россиядә гомер буе гадел патшага ышануын яки шүрләвен күрсәтә. Мулланур телевизордан яхшы кешеләрне генә күрсәтәләр дип ышана. Биредә драматург массакүләм телевидение-радио-матбугат чаралары аша халык аңында формалашкан җитәкче образы – симулякр белән эш итә (драматургның «Мәхәббәт FM» комедиясендә исә радиога «килгән» кунаклар – халык аңында формалашкан күренекле җырчы, артист, җитәкчеләрнең образлары уен белән кушылып пародия аша көлүгә китерә). Нәтиҗәдә, сатирик «кечкенә кеше» образы туа. Мулланур ихластан «глава килер дә белер, может юлларны рәтләрләр ул килгән төшкә...» дип ышана. Айныгач, интервьюны бастырырлар дип куркып, редакцияне шартлату белән яный. «Халыкны бер яктан тегеләр кыса, икенче яктан сез. Сез бит безне бер-берегезгә атып уйнарга туп итәсез. Сезгә кызык, ә тупка авырта» – бу аның, хәзерге авыл кешесенең җан авазы, чынбарлык.

«Кәкре каен» газетасының баш мөхәррире Даян Солтанович монологы әсәрнең кульминациясе: «Бер яктан сез, икенче яктан тегеләр. Җиңел дисезме әллә? Кайчан ябарлар икән, лицензияне алмаслармы икән дип калтырап торырга. Халык укырмы икән? Тираж булырмы? Әз генә булса да, бу тормышны үзгәртер өчен күзләрегезне бераз ачар өчен барыннан да мәхрүм булырга: тынычлыктан, ялдан, шәхси тормыштан, мәхәббәттән... Шартлат әйдә! Монда көн саен шартлаталар! Куркып туйган. Тәгәрәп китсен дөньясы. Без биргән мәгълүмат сезне бәхетсез генә итә икән, без күрсәткән дөреслек белән сез нишләргә белмисез икән – көле күккә очсын! Шартлат!»

Даянның газета ябылмасын дип, хезмәткәрләргә эш хакын түләр өчен фатирын сатуы шартлыча гиперболалаштырып бирелә. «Коммунистлар вакытында да идея өчен күп эшләдек», «Куркаклар шигырь язмыйлар, юк инде шигырьләр» – Даян образына ачкыч репликалар.

Романтик чишелештә «саргая башлаган» газета ябылмый кала, һәркем үз ярын таба. Шул рәвешле, бер газета тарихы фонында заманның шактый четерекле мәсьәләләре күтәрелә. Куелышта стенадагы эвакуация планы уңышлы – хәлдән чыгу юллары буталып беткән, әмма ул бар мәгънәсендә аңлашыла.

Җор телле репликалар, эчке мәгънәгә бай гыйбарәләр («мине кыскартып булмый, минем әле өйләнәсем бар»), гипербола («сүгенгәндә дә өтер-нокта85ларны куеп сүгенә иде», «мин дә еладым... гонорарны алгач...») алогизмнар (сөйләшә белми торган профессор, судьяны судка биргән кешене төрмәгә утырту, «мәһабәт» белән «мәхәббәт»не, «охшый» белән «ошый»ны, «-мыни, -мени»не аера белми торган журналист-филолог), югары-түбән категориядәге төшенчәләр белән эш итү (травестирование) мәхәббәт турындагы «Урман бете» шигыре) сүзне бозып әйтү (маноез-майонез), мәлгүматың-мәгълүматың), төрттерү («билең юк та бит инде, нәрсәң генә ычкына соң шунда гомер буе»), күрәзәче Гайсә такмаклары ( «ышанмагыз депутатка, баеп булмый эш белән») – һәммәсе көлке тудыра.

Сәнгатьчә алым буларак, әсәрне милли орнамент-афоризмнар, такмаклар, мәкаль-әйтемнәр («эт өрә тора, бүре йөри тора», «карга күзен карга чукымый», «укаң коелмас», «татарның бүреге башы белән генә салына» (Т.Миңнуллин әсәреннән куллануга кереп киткән) бизи. Милли ноталар яңгыраганда, С.Рәмиевнең «Таң

вакыты» шигыреннән алынган юллар төрттерү төсмере ала: «Булма надан, ту яңадан, мәгърифәтле анадан».

Комедиядә алабута образы берничә мәгънәдә килә: таксистның «недострой» хатыны (ул «Нигә ул гомер буе алабута булып яшәргә тиеш? Матур булсын, табигать каян белеп бетерсен монда безнең моданы?», «Дөньяны матурлата белсәң, матур» дигән фикерне куәтли); «алабута дурак кебек – чәчмәсәң дә үсә»; авылда чәчелми калган җирләрне баскан алабута.

Мэрилин Монро образын кертеп, автор стереотипларны кабатлау, тиражлау идеясен бирә. Янәсе, масскультураның төп идеясе – рәхәтлек бирүче стандарт. Әлеге образ кешеләрнең омтылышларын, үз йөзләрен югалтуны бер фокуска җыя, алар шатланып көлә-көлә, масскультураның йогынтысына бирелəләр. Икенче төрле әйткәндә, үз-чит, шәхес-җәмгыять каршылыгы һәм шуннан туган газап урынына кешенең масскультурада үз йөзен югалткан, суррогат формадагы кеше-җәмгыять идентификациясе барлыкка килә. Хайдеггер[3], күрсәткәнчә, кеше бергәлек хисе хисабына шәхесен югалта. Кеше инде ирек, мәгънәләр югалган өчен борчылмый, чөнки ул, суррогат формада булса да, аларның симулякрларын алды, алар белән канәгатьләнергә өйрәнде. Мондый шартларда көлке дә тыныч, ә сатира юмор төсен ала.


Шул рәвешле, мондый стереотип образлар бераз абсурд театрына хас булганча, ирек, югары төшенчәләр турында уйлап, борчылырга теләмәгән апатияле буын кәефен бирүдә татар комедиясендә И.Зәйниев кулланган яңа комик чара булып чыга.

«Өйләнәм.tat» әсәрен автор усал комедия дип атаган. Тик ул тулысынча усал нигилистик ирония, усал сарказмнан гына тора дип әйтә алмыйбыз, татар көлкесенең милли үзенчәлеге булган «яшь аралаш көлү»[4] дә юк дәрәҗәсендә (Мулланурның репликаларын санамаганда). Комедиядә сатирик тәнкыйть объектлары, ситуацияләрнең абсурдлыгы тамашачы тарафыннан яшәешебезгә, илебезгә хас көндәлек типик күренеш буларак кабул ителә. Ләкин әлеге комедия социаль мәсьәләләр күтәрүе, көлке алымнарына бай һәм көлдерә торган булуы белән бүгенге күп кенә «тешсез» комедияләрдән аерылып тора.

**Венера МАКАРОВА,**
*филология фәннәре докторы*

[3] Липовецки Ж.Ж. Эра пустоты. Эссе о современном индивидуализме. СПб.: «Издательство Владимир Даль», 2001. 330 с.

[4] Макарова В.Ф. Национальное своеобразие комического в татарской литературе XX века / В.Ф.Макарова // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – Тамбов: Грамота, 2014. – № 1 (31): в 2-х ч. Ч.II. – С. 123–125.



*Язучы-прозаик, публицист, мөхәррир, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Флүс Латыйфи (1943-2010).*



*Флүс Латыйфи (сулда) Татарстан радиосының монтажлау бүлмәсендә. 1980нче еллар башы.*



*Флүс Латыйфи (сулдан беренче) үзе эшләгән «Казан утлары» журналы редакциясе коллективы белән. 1980нче еллар ахыры.*



*«Казан утлары»нда ПЕН-клубның Татарстан бүлекчәсенең чираттагы утырышында. Утырганнар (сулдан уңга): Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рафаэль Мостафин, Миркасыйм Госманов, Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин. Басканнар (сулдан уңга): Харрас Әюп, Зөлфәт, Ркаил Зәйдулла, Зиннур Мансуров, Нур Әхмәдиев, Флүс Латыйфи, Мөдәррис Вәлиев, Әхәт Мушинский, Тәлгат Бариев, Газинур Морат. 2003 ел.*



*«Казан утлары» журналы редакциясе коллективы табигатьтә чәй табыны янында. Беренче рәттә (сулдан уңга): Тәгъзимә Шиһабиева, Асия Рәхимова, Гөлзадә Бәйрәмова; икенче рәттә: Флүс Латыйфи, Эльвира Камалова; өченче рәттә: Флёра Сабирова, Алмаз Гыймадиев, Лилия Гатауллина, Марат Закир, Мансур Вәлиев. 2000 нче еллар.*

*Фотолар редакция архивыннан алынды.*

# ТҮЛӘК КИТАБЫ

Бу әсәр шактый борынгы сюжетка нигезләнгән. Барлыкка килү вакыты җәһәтеннән «Түләк» дастанын XIII – XV йөзләргә үк нисбәт итәләр. Мифологик үзенчәлекләреннән аның архаик тамырларының Кытай территориясендә яшәгән борынгы төркиләр фольклорына барып тоташкан булуы күренә. Түләк исеме белән бәйле әсәрләр татарлар һәм башкортлар яшәгән төбәкләрдә мәгълүм булып, башкорт халкында дастан, гадәттә, телдән башкарылган, ә татарларда, сөйләмә вариантлары белән бергә, кулъязма нөсхәләре бик нык популярлашкан. М.Госманов сүзләре белән әйткәндә, «бер эпосның ике халык репертуарында булу факты бик аңлаешлы: татарлар белән башкортлар борынгы заманнардан ук бергә аралашып, һаман янәшә яшәгәннәр. Гасырлар буена сузылган менә шушы янәшәлек, күршелек, хәтта гел яңарып торган кардәшлек нәтиҗәсендә фольклорда андый уртак сюжетлар барлыкка килүе әллә ни гаҗәп нәрсә түгел»[1].

«Түләк китабы» («Түләк белән Сусылу») фән дөньясына күптәннән таныш. XIX гасырда ук бу сюжет рус галимнәренең игътибарын җәлеп иткән. В.Даль[2], Л.Суходольский[3], Р.Игнатьев[4], Г.Потанинның[5] бу өлкәгә турыдан-туры кагылышлы хезмәтләре мәгълүм. XX гасыр башында дастанның янә бер вариантын Солтангәрәй Солтанов рус матбугатында бастырган[6], 1910 елда мәшһүр шагыйрь Мәҗит Гафури әсәрне аерым китап итеп чыгарган. Китап «Заятүләк берлә Сусылу: башкорт хикәясеннән» дип атала *(Уфа: «Кәримев, Хөсәенов вә шөрәкәсе», 1910. 24 б.)*. Соңгы елларда М.Гафури вариантының иске татар кулъязма китапларыннан алып төзелгән җыйнама текст булуы ачыкланды[7].

Татарларның элек-электән укып, «мәгънә һәм фикер, юаныч һәм ләззәт алып килгән» «Түләк» дастаны сюжетына мөрәҗәгать эле XX йөздә дә дәвам итте, әдип һәм галим Н.Исәнбәт бу бөек әсәргә өр-яңа яшәеш бирде[8]. «Түләк китабы» – үзебезнең борынгы җирлегебездә иҗат ителеп, гасырларны кичкән кулъязмалар аша безгә килеп ирешкән чын мәгънәсендә милли китаби дастаныбыз.

Бүген татар «Түләг»енең алты варианты билгеле. Текстлар бер-берсеннән нигездә күчерелү вакыты һәм урыны, тулы яки өзек-өзек булуы, текстта очрый торган борынгы сүзләр яисә чорга бәрабәр яңартылган лексика кулланылган булу һәм шигъри өлешләрендәге кайбер үзенчәлекләр һ.б. белән аерылып торалар. Беренче вариант – 1910 елда М. Гафури төзегән җыйнама текст. Татар телендәге китапчыкның «Сүз башы»нда ул үзенең 1909 елда Бәләбәй өязенә баруы, анда «Заятүләк»нең көен җырлап уйнаулары, «Заятүләк» дигән китап та бар дип ишетүе турында яза. «Мин элек

---

1 Госманов М. Г. Каурый каләм эзеннән..., 1994. – Б. 235.
2 Даль В. Башкирская русалка// Москвитянин. – 1843. – №1. – С. 97 – 119.
3 Суходольский Л. Легенда о Туляке// Вестник императорскоко Русского географического общества. Ч. 24. – СПб, 1858. – С. 65 – 72.
4 Игнатьев Р. Сказания, сказки и песни, сохранившиеся в рукописях татарской письменности и в устных пересказах у инородцев-магометан Оренбургского края// Записки Оренбургского отдела императорского Русского географического общества. Вып. 3. – Оренбург, 1875. – С. 207 – 211.
5 Потанин Г.И. Дочь моря в степном эпосе// Этнографические обозрение. Кн. XII. – 1892. – № 1. – С. 38 – 69.
6 Султанов С. Зоя-Тюляк и Су-сулу: башкирское предание// Самарская газета. – 1902. – № 83.
7 Бу турыда кара: Түләк китабы: дастан / төз. – авт. Мәрданов Р.Ф. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. Б. 4 – 5.
8 Исәнбәт Н. Түләк батыр: опера өчен либретто// Совет әдәбияты. – 1944. – № 4. – Б. 27 – 36; № 5. – Б. 25 – 33; Исәнбәт Н. Сайланма әсәрләр: өч томда. Т. 1. – Казан: Татар. китап нәшр., 1960. – Б. 311 – 367.

бу китапның Уфада мәшһүр бер зат тарафыннан русчага тәрҗемә ителеп, үзе вафат булуы сәбәпле бастырылмый калуы турында ишеткән идем. Монда да буның барлыгын ишеткәч, аны шундук эзләп таптым. Кулыма төшкән мөтәгаддид (күп санлы. – Л.М.) нөсхәләрне бергә китереп караганда, китапның әһәмияте мин уйлаганча булмаса да, түбәндәге сәбәпләр өчен язып алып, тугры килсә табигъ кылдырырмын (нәшер итәрмен. – Л.М.) дип уйладым» – ди ул. Әсәрнең шигъри өлешләре, стиле аның өченче вариант (Олы Кариле нөсхәсе) белән кайбер уртаклыгы турында сөйли. Дастанның М.Гафури варианты язучының соңгырак басмаларында яңадан дөнья күргән, ул башкорт халык иҗаты җыентыкларына да кертелгән *(Башкорт халык ижады. Эпос. Беренсе китап. Өфө, 1972).*

«Түләк»нең тагын бер варианты – Н.Исәнбәтнең шәхси архивында саклана торган кульъязма. Шуларга нигезләнеп, әдип «Түләк» исемле драматик поэма иҗат иткән[9]. Әсәр XX йөзнең утызынчы елларында ук языла башлаган. Беренче мәртәбә 1944 елда басылган[10]. Бу әсәрнең нәкъ менә кайсы чыганакларга таянып язылуы хакында, кызганычка, әлегә мәгълүмат бик аз. М.Госманов әлеге күчерү вакыты билгесез кульъязманы «Түләк» «эпосының татарча язма версиясенең дефектлы, соңгы өлеше югалган бер күчермәсе» дип тасвирлый[11].

Янә бер вариант – Олы Кариле нөсхәсе. 1969 елда Казан (Идел буе) федераль университетының (ул вакыттагы исеме – Казан дәүләт университеты) Миркасыйм Госманов җитәкчелегендәге археографик экспедициясе вакытында Кама Тамагы районы Олы Кариле авылында табылган кульъязма вариант. Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегендә саклана: шифр 4474Т. Бары 64 бите сакланган, 32 кәгазьдән гыйбарәт бик иске, таушалган тулы булмаган нөсхә. Бигрәк тә ахыргы өлеше фрагментар рәвештә генә килеп җиткән. Кульъязма XIX йөзнең икенче яртысында күчерелгән. Күчерүче – Олы Кариле авылыннан Хәсән атлы татар шәкерте. Текстны табып өйрәнүче, укып, беркадәр реконструкцияләп, хәзерге язуга күчерүче – академик М.Госманов. «Түләк»нең бу кульъязмасы хакында галим этрафлы мәкаләсендә бәян итте һәм җиңеләйтелгән транскрипциядә текстны бастырып чыгарды: Госманов М.Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Казан: Татар. китап нәшр, 1984. Б. 180 – 198. Шушы ук текст «Татар халык иҗаты» (1984, Б. 123 – 135) һәм «Татар эпосы. Дастаннар» (2004, б. 227 – 242) җыентыкларына кертелгән, шулай ук башкорт телендә дә дөнья күргән: Башкорт халык ижады: өсөнсө том. Эпос. Өфө: Башкортстан «Китап» нәшр., 1998. Б. 368 – 384, 388 – 393; Заятүләк менән Һыуһылыу// Ватандаш. 1998. № 2. Б. 67 – 74.

Дүртенче вариант – Олы Мәңгәр кульъязмасы. 1994 елда Татарстанның Әтнә районы Олы Мәңгәр авылында М.Әхмәтҗанов тарафыннан табылган нөсхә. Галимгә аны шушы авылда яшәүче Закировлар гаиләсе тапшырган. Кульъязма дүрт кәгазьдән тора. Текст тулы түгел, дастанның фрагментларыннан гыйбарәт. Теленең борынгылыгы, кәгазь-карасының кулланылу дәвере әлеге нөсхәне XVIII йөзнең икенче яртысына нисбәт итә. Күчерүчесе турында мәгълүмат юк. Кульъязма Мирасханәдә саклана: колл. 39. Текст М.Әхмәтҗанов тарафыннан матбугатта басылды.

Бишенче вариант – Камышлы нөсхәсе. Аны 1996 елда археограф, текстолог Р.Мәрданов Самара өлкәсендәге Камышлы авылы мәчетеннән табып алып кайткан. Бу нөсхә турында мәгълүматлар, җентекле махсус фәнни мәкалә һәм текст үзе табыш иясе тарафыннан матбугатта дөнья күрде[12]. Дастан тексты XIX йөзнең беренче яртысында

[9] Исәнбәт Н. Сайланма әсәрләр: өч томда. Т. 1. – Казан: Татар. китап нәшр., 1960. – Б. 311 – 367.
[10] Исәнбәт Н. Түләк батыр: опера өчен либретто// Совет әдәбияты. – 1944. – № 4. – Б.27 – 36; № 5. – Б. 25 – 33.
[11] Госманов М. Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Тулыландырылган икенче басма. Казан: Татар. китап нәшр., 1994. Б. 233.
[12] Мәрданов Р. Якутлар табыладыр вакыт белән...// Бердәмлек. – 1996. – 2 – 8 июль; Мәрданов Р. Ун еллык археографик хезмәт// Китапханә хәбәрләре.Библиотечный вестник. – 2002. – №1. – Б. 15; Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда...// Казан утлары. – 2002. – № 3. – Ю.127 – 128; Түләк китабы: дастан/ төз. – авт. Мәрданов Р.Ф... – 76 б.

күчерелгән җыентыкта теркәлгән, барлыгы 10 кәгазьдән гыйбарәт. Текст мулла Сибгатулла бине мулла Фәхретдин мөдәррис, мөхтәсиб Багданов (Сибгатулла Багданов (1820 – 1875), төп чыгышы Казан губернасы Чистай өязе (хәзер районы) Мөслим авылыннан, хәзерге Әлки районы Олы Тигәнәле авылында яшәп, муллалык иткән) исемле кеше тарафыннан күчерелгән. Шактый тулы вариант, башка нөсхәләренең һәркайсы белән аерым-аерым уртаклыгы бар. Сюжетлары тәңгәл килә диярлек. Төп аерма – гарәп язулы сүзләрнең төрле вариантта төрлечә язылышы, бер үк сүзнең төрле фонетик яки синонимик вариантта кулланылган булуы, егет белән кыз диалогындагы лексиканың соңгы нөсхәдә эмоциональрәк, җанлырак төсмер алуы, имля төрлелеге һ.б. Р. Мәрданов бу хакта җентекләп язган, китап ахырында кулъязманың факсимилесын, хәзерге язуга күчерелмәсен һәм М.Гафури, М.Әхмәтҗанов, М.Госманов тапкан вариантлар белән чагыштырма таблицасын тәкъдим иткән. Дастан теркәлгән кулъязма җыентык Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана: шифр 1761т.

«Түләк китабы» ның һәрбер татар нөсхәсе һәм варианты бердәй газиз һәм фәнни әһәмиятле. Биредә китерелә торган текст – «XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия» җыентыгыннан. *(Казан, 2006. Б. 267 – 284)*. Ул – «Түләк китабы» кулъязмалары һәм, гомумән, язма китаби дастаннарның әлегә мәгълүм иң күләмлесе. Бу – М. Әхмәтҗанов тапкан һәм, текстологик эшкәртеп, басмага әзерләгән нөсхә. Шартлы исеме – Казан варианты. Текст 1985 елда Казан шәһәрендә яшәп бакыйлыкка күчкән, һөнәре белән инженер, язучы Зөфәр Кормашев архивында сакланган. Кулъязманы Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге (Мирасханә) фондына мәрхүмнең хатыны Мөнирә Җәләлетдин кызы Кормашева тапшырган.1887 елда күчерелеп, безнең көннәргә тулы килеш килеп ирешкән нөсхә. Күчерүче – Минзәлә ягындагы Теләнче Тамак авылы Габделҗаббар хәзрәт мәдрәсәсе шәкерте Мөхәммәтгәрәй бине мелла Шакирҗан. Текст 162 кәгазьдән торган кулъязмада теркәлгән. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә (Мирасханәдә) саклана: колл. 39, сак. бер. 5011, оп. 1. «Түләк»нең Казан кулъязмасына багышланган берничә мәкалә матбугатта дөнья күргән[13].

*«Түләк» дастаны, аның вариантлары хакында мәгълүматны һәм дастан текстын журнал өчен әзерләүче – филология фәннәре докторы, Г.Ибраһимов ис. ТӘһСИның баш фәнни хезмәткәре, доцент*
**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА.**

[13] Ахметзянов М.И. Казанский список дастана «Туляк и Суслу»// Старотатарский литературный язык: исследования и тексты. – Казань, 1991. – С. 89 – 97; Әхмәтҗанов М. Түләк белән Сусылу. Түләк китабы// Әдәби мирас. Дүртенче китап. – Казан: Татар. китап нәшр., 1997. – Б. 14 – 33.

***

Хикәйәти алтынчы – Бачман хан берлә Җаждар хан. Алтынчы хикәйәтини тәвабигълары[14] берлә Түләк пәһлеван кыйссасы бәйан идәр.

Әүвәл заманда Йайык сулаган[15] Бачман хан дигән бер хан, аның бер Түләк исемле угълы бар ирди. Нигъмәти[16] мул, йорты киң иди. Алтмыш йегет хезмәтчи нүкәри бар ирди. Һәрберсин кызлар тик бизәнеп йөртер ирди. Алтмыш беренчиси Мирказый би угълы Түләк ирди. Түләкни үз хезмәтинә алды. Түләк бер йалгыз угыл иди.

Бачман хан даим кош чөйә йөрер иди. Һәр кайу йегетләрниң алтмыш башка кошлары бар иди. Түләкниң кошы Ак Йабалак иди. Кошы алмакда зерә дә һиммәтли иди. Ул алтмыш йегетниң кошлары һәр ни алса, Бачман ханга килтерип сынар ирдиләр. Хан ул йегетләргә сөйургап ун тәнкә алапа[17] бирер иди.

Көнләрдә бер көн Бачман хан ауга чыкты, һәрни кошы кийек очса-калса, Түләкниң Ак Йабалакы алды. Ул йулда ханның барлык алапасын Түләк алды.

Ул алтмыш йегет Түләкни көнләп, пычакка төшеп үлгү тик булдылар, һәр даим Түләк Хак Тәгалә коллыгындин хали булмаз[18] ирди, күнли пакь иди. Кич кунар булдылар. Түләкниң менгән атын Акбүзчә Йилйитмәс дийерләр ирди. Ул кичә кател кылып[19], алтмыш йегет Түләкниң Акбүзчә Йилйитмәс атының дүрт айакының йөрәк итедин үткәрә тимер кадак суктылар, йөрмәгә дәрманы булмасын дип. Түләк бу эшни һәргиз белмәс ирди. Түләк йокыда ирди. Төш эчиндә Хозыр галәйһи-с-сәлам килди. Түләккә «Исме әгъзам» догасыны үгрәтти, әйди: «И угълым, алтмыш йегет дошманлык кылып, атның дүрт тойагын үткәрә тимер кадак суктылар. «Исме әгъзам» укып, дәм бирсәң[20], кадаклары төшеп, атың айаклары саг булгай!» Йәнә әйди: «И угълым Түләк, һәркайчан сәңа мөшкел[21]эшләр төшәр булса, ушбу «Исме әгъзам» догасын укып сорасаң һәм килтерсәң, мөшкел эш асан[22] булгай», – тиди. Ул сәгать уйганды, хәзрәти Хозырны күрмәди, торды, барды, атын күрде, дүрт айакына дүрт тимер кадак сукмышлар. «Исме әгъзам» догасын укып дәм бирди исә, кадаклары төшди, айаклары уңалды[23], саг булды, һичкем ирсәгә бу серни әйтмәди. Иртә булды, атландылар. Түләк бер күлгә кушыл[24] карый китти. Бу алтмыш йегет таңга калып әйдиләр: «Бу Түләк ни гамәл берлә атының айагын уңалды?!» – тидиләр. Әйдиләр: «Безләр бу Түләкни үлтермәйенчә бәһамез булмаз!» – тидиләр. «Имди безләр өч йегет баралым, ике йегет йөгәнининң ики йаныдин алып, бер йегет Акбүзчәни камчыламак кирәк, ул сәгать Йилйитмәс алып очкай, агач йә тагъ-ташка сугып үлтергәй, аның хурлыгындин котылгаймыз!» – тидиләр.

Өчени хазир кылып[25] бардылар. Икеси Акбүзчәнең йөгәнин суйдылар, берси килеп камчылады. Йилйитмәс Акбүзчә Түләкни алып, иллә очды кем, алты көн, йити төн туктамады. Йитинчи иртә, көн тугар вакытда бер олуг дәрйаның йаныга килеп туктадылар. Түләкниң һичкайда киткәнин белгән кеши булмады. Ул сәгать Түләк карап күрди, бер су пәрисиниң падишаһы бар ирди – Җаждар хан. Аның бер кызы бар ирди, бигайәт сахибе җәмал[26] ирди. Һәркем күрсә гыйшкындин җан биргү дик булыр ирди. Җаждар хан кызы ушбу Түләкниң аты туктаган йирдә һәр иртә килеп, сачин тарар ирди. Үзини, йөзини йөз мең төрлик бизәкләр берлә бизәр ирди. Ул кыз

[14] Тәвабигълары – иярүчеләре.
[15] Йайык сулаган – Җаек елгасы буенда яшәгән.
[16] Нигъмәти – байлыгы.
[17] Алапа – бүләк.
[18] Хали булмаз – буш булмас.
[19] Кател кылып – һәлак итеп.
[20] Дәм бирсәң – өрсәң.
[21] Мөшкел – читен.
[22] Асан – ансат.
[23] Уңалды – төзәлде.
[24] Кушыл – (кушил) талчыбыктан яки юкәдән үреп ясалган ау.
[25] Хазир кылып – хәстәрләнеп.
[26] Бигайәт сахибе җәмал – чиксез гүзәллек иясе.

ул йирдә сачини тарай ултырыр. Түләк, кызны күреп, атындин инди. Кыз тоймады, сачиниң озынлыкы алтмыш карыш буйы бар ирди. Сачин ики йаныга ачып, йөзиндин китәреп тарап торган вакты ирди. Түләк килеп кызга сәлам бирди. Кыз сачини йөзиндин китәреп торганы берлән әйләнип карады, Түләкниң йөзини күрди. Аһ кылып әйди: «Әгәр иңсәмни биреп торган вакытым булса иди, йөзимни сәңа кайда күргәзгәй идим», – тиди. Түләкниң йөзинә карады, гайәт дә зифа йегет торыр. Түләккә кыз андагъ гашыйк булды, сүз әйдер хали калмады. Ул йардин китәр дәрманы булмады. Күңлендин әйди: «Бу йегетни бер заман алдайын, шайәт ки котылып китәйен», – тип әйди. Кызның ул сәгать Түләкни күреп тәни калтырап торыр булды, һич кузгалыр дәрманы калмады. Түләк кызга анда кушак[27] әйди:

*Инеп килдим атымдин*
*Имди сәниң үзиңә.*
*Сәлам бирдем бән сәңа*
*Ай тик күрекли йөзиңә.*
*Гашыйк булдым бән сәңа –*
*Нәзек зифа буйыңа,*
*Сүзең әйтчи, Сусылу!*

Кыз йәнә Түләккә каршы кушак әйди:

*Мән усалның үзинә,*
*Гашыйк булма, бай угълы!*
*Алтын сыргам[28] бирәйен,*
*Бүләк булсын, бай угълы.*
*Безнең йирләр катыдыр,*
*Түзәлмассың, бай угълы!*
*Госса[29] булып үләрсин,*
*Кайтып киткел, бай угълы!*

Андин Түләк кызга кушак әйди:

*Сәфәр кылдык йөз кеши,*
*Йөгәним суйды өч кеши.*
*Атым килди йарышып,*
*Кулым килди карышып.*
*Атың-йулың[30] белмәсмен,*
*Атың әйтчи, Сусылу!*

Андин йәнә кыз Түләккә кушак әйди:

*Атың килсә йарышып,*
*Кулың килсә карышып,*
*Ат-йулыңны белмәзсин,*
*Атың әйтеп бирәйен,*
*Атың үзен беләсен:*
*Әрмезәлик кыламын,*
*Сары Мирказ угълысын,*
*Хәйба Түләк угълысын!*
*Атым-йулын белмәйси,*
*Кайан эзләп йөрәйси?!*

[27] Кушак – җыр.
[28] Сыргам – алкам.
[29] Госса – кайгылы-сагышлы.
[30] Атың-йулың – исемең, нәселең.

Андин соң Түләк кызга әйди:

*Бер дигәндә бил[31] алган,*
*Били салып суна[32] алган,*
*Канат какмай каз алган,*
*Агъзы канлигъ бүри алган,*
*Айагы сипкел төлки алган,*
*Муйны озын торна алган,*
*Арту кошны очырмаз*
*Ак Шоңкардан йазайын,*
*Суның кызы, Сусылу,*
*Сәнең берлә булайын,*
*Атың әйтчи, Сусылу!*

Андин кыз Түләккә әйди:

*Атым сорап нидәрсин?*
*Куш хәмаил[33], куш йөзек –*
*Менә сәңа бүләгим!*
*Безнең йирләр катыдыр,*
*Торалмазсын, Түләгем,*
*Госса булып үләрсин!*
*Мән дә сәнлик түгелмен,*
*Кайтып киткел, Түләгем!*

Андин кызга Түләк әйди:

*Артык кошны очырмаз*
*Шоңкарымдин бизәйем,*
*Айлык йирдә бер баскан,*
*Йыллык йирдә бер баскан,*
*Кигәй йалы таралган,*
*Түрт айагы каралган,*
*Аргамакдин бизәйем!*
*Суның кызы Сусылу,*
*Сәнең берлә булайым!*

Андин кыз Түләккә әйди:

*Акча йөзем күрсәткән,*
*Арув сачим тараткан,*
*Толым буйым сылаткан,*
*Алтын тарак, ал көзги –*
*Мона сәңа бүләгим!*
*Шуны ал да йулың ал,*
*Кайтып киткел, Түләгем!*
*Мән дә сәнлек түгелмен,*
*Ышанмагыл, Түләгем!*

Андин кызга Түләк әйди:

*Ун ай төгәл күтәргән,*
*Уң утакдин йөгертелгән,*

[31] Бил – калкулык.
[32] Суна – киек.
[33] Куш хәмаил – куш хәситә.

*Аләли*[34] *кулда талчыктан,*
*Алтын кийездә ултырткан,*
*Төн йокысын өч бүлән,*
*Төнлә торып имезгән,*
*Айадан*[35] *каймак йидергән,*
*Ирү имчәкдин сөт биргән*
*Инәйдәнме*[36] *бизәйен!*
*Караңгига утырткан,*
*Алтын кийезгә ултырткан,*
*Айыры сакал үстерткән*
*Атадин мән бизәйем!*
*Суның кызы Сусылу,*
*Сәнең белән булайым!*

Андин кыз Түләккә әйди:

*Куш хәмаил, куш йөзек*
*Алмадың сән, Түләгем.*
*Алтын сыргам, ал йөзкем –*
*Йәнә бирдем бүләгем.*
*Бүләк биреп алмазсың,*
*Нидер мәндин теләгең?*
*Сүзең әйтчи, Түләгем!*

Андин Түләк кызга әйди:

*Куш хәмаил, куш йөзек –*
*Зифа буйың бизәкең.*
*Алтын тарак, ал көзге –*
*Мән нитәйен бүләгиң?*
*Бүләк мәңа кирәкмәз,*
*Зиба буйың – теләгим!*
*Сүзем шулдыр, Сусылу.*

Андин кыз Түләккә әйди:

*Аптырапсын, бай угълы,*
*Тимтерәпсен, бай угълы.*
*Ана, аргы йагыңдин*
*Киләдер лә биш кеши –*
*Күрмәймисән, бай угълы?! –*

дип алдап каратып, кыз үзи суга чумды, качар булды. Түләк әйләнеп карады. Кыз суга чуммыш, алтмыш карыш саченең алты карышы суга кермәгән ирди. Түләк кызның сачини урап алып, беләгинә урай барып, судин килеп чыкканча йилкәсинә йитди. Бер фәлән ай-көн күренмәз йиргә чыкты. Пер пулат сарай торыр. Сарайның алды йаныйндан балдин бер дәрйа агып барыр. Йәнә сарайның арт йагындан сөтдин бер дәрйа агып барыр. Сарайның дүрт йанындан дүрт олугъ дәрйа барыр, – Түләк күрди. Түләк кызның сачиннин айырылмаз ирди. Андин Түләккә кыз әйди: «Әй, йегет, имди сән мәним, мән сәниң булдык, сачимни йибәргел. Мән сарайга инәйен түшәк салайын, андин соң чыкып алайын», – тиди ирсә, андин Түләк кызга кушак әйди:

[34] Аләли – хәләл.
[35] Айадан – аяктан, җамыяктан.
[36] Инәйдәнмен – анамнан.

*Алты көн дә йити төн*
*Атым алып килепдер.*
*Алдамачы, Сусылу,*
*Ай йөзиңдин бер эчәм,*
*Айрылмамдыр, Сусылу.*

Андин Түләккә кыз кушак әйди:

*Алты көн дә йити төн*
*Атың алып килепдер.*
*Ашыкмачы, бай угълы,*
*Урын-түшәк салайын.*
*Тарыкмачы, бай угълы.*
*Җөмлә буйым сәнеңдер,*
*Сабыр кылчы, бай угълы,*

– тип әйтди. Дәрхаль Түләк кызның сачини йибәрди. Кыз сарайга инди, ишегендин керди, сарайның ишекени беркетти. Ул пулат сарайның бийеклеки һавага чыкмыш ирди. Кыз һәргиз[37] чыкмаз булды. Өч көн, өч төн анда калды, дәрмани булмады, дүртинчи көн иртә намазы кылгандин соң ике рәкәгать хаҗәт намазы кылды, «Исме әгъзам» догасыны укып, башыны сәҗдәгә куйып, андаг әйди: «Илаһи, бу кызны һәм кавеми-халкыны һәм барча туарыны көн эсселеги берлә дәрмансыз кылтайсын!» – тиди. Ул сәгать догасы мөстәҗаб булды[38]. Өч көн-төн һава эсселек булды. Көн кайнар булды. Ул сарай алдындин акган бал дәрйасы, артындин акган сөт дәрйасы, дүрт тарафындин акган су дәрйасы кордылар, һичбер эчим су калмады, тәкатьсиз булдылар, барчасы йанып үлү тик булдылар. Ул кызның сарай тигрәсиндә ултырган кырык эвлик хезмәтчи нүкәрләри бар ирди. Барчасын кызның үзи тик зиба гына йунлык пәриләр ирди. Барчасы кыз сарайыга килдиләр, кычкырышдылар. Һәргиз сарайның ишекин-тәрәзәсин ачып бакмады һәм аваз бирмәди. Бу җәмәгать Түләкни карап күрдиләр: бигайәт сахибҗәмал йегет торыр, белдиләр, имди ни кылмак кирәк тийү, иттифак кылып[39] әйдиләр: «Кызның атасы Җаждар хан падишаһта бармак кирәк, бу әхвальни аңа аймак кирәк!» – тидиләр. Гакыйбәт[40] шаһга барып әйдиләр. Җаждар хан падишаһ кызына катыйг ачыйгланып берәкүни йибәрди, әйди: «Ни өчен алдаг кылып, халыкны һәлак кыла торыр. Әүвәлиндә йегетни үзи кабул кылмаса ирди, адәмнең бу йиргә килергә ни дәрманы булгай? – тиди. – Үзи алып килепдер, имди халкыны ни өчен һәлак кыладыр? – тиб. – Ул адәмнең догасы мөстәҗаб охшайыр, барып кызымга әйтеңезләр, сарай ишегин ачсын, ул йегетни үз катына алсын, гыйзулар[41] кылып, яхшы догасын үтенсин», – тип, бунлары ул бер кәс[42] илә йибәрди.

Ул кемсәнә килеп, атасының сүзин айгач[43], кыз сарайның ишегини-тәрәзәсини ачды. Ул заман кызның тәнигә көн[44] төшди, күкрәкендин кереп, аркасындин чыкды. Кыз йанып үлгү тик булды. Пулат сарай ут кебек кайнар булды. Шул заман Түләк сарайга керди, кызны күрди, сачиндин урап алып, күтәреп пулат сарайның ишегинә сукды, йәнә кайтарып түринә орды, кызның гаклы китди.

Бер замандин соң кыз исен йыйып алды, күзин ачып карады. Түләкни күрди, әйди: «Әй, йегет, мән сәни сүмәзлекдин мондаг эши кылмадым. Мән зирдә[45], бер падишаһның

[37] Һәргиз – һич.
[38] Мөстәҗаб булды – кабул булды.
[39] Иттифак кылып – берләшеп.
[40] Гакыйбәт – соңында.
[41] Гыйзулар – олылаулар.
[42] Бер кос – бер кеше.
[43] Айгач – әйткәч.
[44] Көн – кояш.
[45] Зирдә – аскы якта (җир астында).

кызымын, ушбу эшдә атамга билгелик булсын дип, мондагъ эш кылганмын. Морадым җәдаллыкдыр, – дип, йегетниң күңлисин алды вә йәнә әйди, – әй, йегет, мончага кадәри безниң эшемиз хәтәр иди, имди Хак Тәгаләгә шөкер, эшемиз күни булды[46]. – дип сүйүг-мәхәббәт берлә Түләкниң муйныга кулын салды. – Атамдин дәстүр[47] булып хәбәр килди, сәни җефетлеккә үз йаныма алмага», – тиди, вә йәнә Түләк, кызның бу сүзләрин ишетип, кызның бу гыйшкындин башын-җанын корбан кылу тик булды. Андагъ сүйүг-мәхәббәт берлә кыз муйныга кул салды, мәгәр дигәйсән күкдин ай-көн инеп бер йиргә кушылды. Мәхәббәт сүйүгликләри андагъ булды. Аллаһы Тәгаләдин гайре кем ирсә белмәгәй.

Анда кыз Түләккә әйди: «Имди, әй йегет, бәнем гайебемне кичрү биргел», – тиди. Каты гозерләр кылды, үтенди, әйди: «Әй, йегет, ушбу көн эсселегиндин хәлемез мөшкел булды. Имди Хак Тәгаләдин теләп, сез дога кылыңыз, безләр амин дисәк, Хак Тәгалә, шайәт, гафу кылтай!» – тиди. «Михнәти безләрдин китәргәй!» – тип, кыз Түләкниң айакына төшип үтенди.

Түләк анда кызга әйди: «Әй, җан мәхәббәти, бер сәгать сабыр кылгыл, мән хәлвәт йиргә барып, Хак Тәгаләдин хаҗәт теләйен, сән һәм теләкдә булгыл!» – тиди. Сарайдин чыкып, йир йөзинә инди, хәлвәт йиргә барды, тәйәммем кылды, ики рәкәгать хаҗәт намазы кылды. «Исме әгъзам» догасыны укыды, башыны сәҗдәгә куйып һәм әйди: «Илаһи, барча мөшкелләр сәңа асан торыр», – тип, Хак Тәгаләгә мөнәҗәт кылды, әйди: «Бу кавемни бу көн эсселекдин китәреп, сихәт бирмәк сәңа асан торыр!» – тип йалбарды ирсә, шул заман коңгыр салкын җил исеп, ул бал дәрйасы, йәнә ул сөт дәрйасы, йәнә ул дүрт су дәрйасы ага башладылар, тәмамысы иссез булып өч кичә-көндез йокладылар. Өч көндин соңра тордылар. Малларының өч өлешдин бер өлеши һәлак булмышлар көн эсселекедин. Андин соң Түләк кыз берлә көн-бикөн мәхәббәтләри зийадә[48] улып гыйш-гыйшрәттә улдылар.

Кыз әйди: «Әй йегет, мәңа дәстүр биргел[49], һәр иртә хәлвәтә[50] чыкып, сачем тарап, йөзим бизәп киләйен!» – тиди. Түләк кызга дәстүр бирди, һәр иртә хәлвәтә чыкып, сачин тарап, йөзин бизәп килер ирди. Бер көн Түләк кызга әйди: «Ни йиргә чыкып сачиң тарарсың?» – тиди. Кыз Түләккә әйди: «Ни йирдә мәнем сачимдин урап алдың, – тиди, – шул йирдә тарармын», – тиди.

Анда Түләк әйди: «Әй, җан мәхәббәте, андагъ ирсә мәнем атым берлә кошымны күрмәзмисән?» – тиди.

Кыз әйди: «Сән бәңа гашыйк булмышда аймадыңмы, атымдин, кошымдин бизәрмен димәдеңме?»

Түләк әйди: «Ул көн аның кебек ирди, бу көн йәнә үзгәдер, күрер булсаң айгыл!» – тиди.

Анда кыз Түләккә әйди:

*Атың аты Йилмайа,*
*Аңа китәр йул кайа?*
*Атың торыр абыгып,*
*Кошың торыр йабыгып,*
*Үзиң салып киткәнсән.*
*Такый нигә сорарсән?*

Андин соң кызга Түләк әйди:

*Атым торса ул йанда,*
*Мәним өчен зарыгып,*

[46] Күни булды – дөрес булды.
[47] Дәстүр – рөхсәт.
[48] Зийадә – артык.
[49] Дәстүр биргел – рөхсәт бир.
[50] Хәлвәт – аулак.

*Айлык йиргә бер баскан*
*Дүрт айагы талыгып,*
*Йыллык йирни караган*
*Ике күзи карыгып,*
*Атым алып килергә*
*Дәрман итчи, Сусылу!*
*Халең йитсә, атымны*
*Алып килчи, Сусылу!*

Анда кыз Түләккә әйди:

*Кошың бу йиргә безниң*
*Килеп йитмәз, бай угълы.*
*Бу хезмәтиң итмәгә*
*Халим йитмәз, бай угълы.*
*Хакдин теләк теләгил,*
*Ашыкмачы, бай угълы!*
*Хак теләгиңни бирер,*
*Тарыкмачы, бай угълы!*

– дип, кыз Түләккә әйдие. Түләк торды, йәсигъ намазыны кылды, андин соң ики рәкәгать хаҗәт намазы кылды, «Исме әгъзам» догасыны укып, мәһим[51] килтердие, андин соң башын сәҗдәгә куйып әйдие: «Илаһи, барча агырлар сәңа асан торыр, атымны, кошымны ушбу йиргә килтерсәң кодрәтең бар. Мән бичараның халини һичкем белмәгәй, – тиди. – Рахманым[52], сәндин йөрдәм!»- тип, ул кичә кыз берлә йатды.

Иртә таң намазы улып ирде, намазга тордыкы вакытда Йилмайа кешнәп ирди, кош шангылтаб аваз бирди. Ул сәгать Түләк пулат сарайның тәрәзәсиндин карады, Акбүзчә аргамак килеп торыр, алтын ийәре өстиндә. Карады, Ак йабалакый ийәр кашында күрде. Ул сәгать Хак Тәгаләгә шөкерләр кылып, башый сәҗдәгә куйып, әйди: «Бу мөлкәт, бу гыйнайәт[53] сәндин торыр», – тип, атының, кошының катына барды.

Аты, кошы Түләкни күрдиләр ирсә, ат селкенди, кош кагынды, борынгы тик симереп күрекләндиләр. Ул сәгать Хак Тәгалә ул пулат сарай каршында ут-үлән үстереп чыкарды. Һәр кичә ул туйгу тик йәшел үлән үсәр ирди. Вә йәнә ул кош тагъ тигрәсиндә очып йөреп, кош алып ашар ирди. Гакыйбәт[54] Түләк кыз мәхәббәти берлә гасәлдә[55] булып, йөзинә сап-сарыйгъ койылды. Үзи белмәз иди. Бер иртә кыз көзгесин түшәк өстинә куйып чыкты. Бу йегетниң булмышын үзин-үзи күрсен-белсен тип, кыз сачин тарамага чыгып китти.

Анда Түләк күрди кызның көзгесин – түшәк өстиндә калмыш. Көзгесини алды, ачып карады, үзиниң йөзини күрди: сарыйгъ койылмыш, гайәт усал булмыш иди. Аһ, дәрига, гасәлик[56] булып, үлем халигә килепмен, тиди. Торды, бер гөлстан дигән уйын йасады, бер думбра йасады, бер кыл кубыз йасады, вә йәнә бер үртәкә йасады. Ул үртәкәниң мөйезләрин[57] алтындин төзди, айакларын көмешдин төзди, ики күзләрин данә гәүһәрендин[58] төзди. Ул үртәкәни бу җиһан бизәкләри берлә бизәди. Торды, ики рәкәгать хаҗәт намазы кылды. «Исме әгъзам» догасыны укыды, мәһим килтерди[59], башын сәҗдәгә куйып әйди: «Илаһи, барча хаҗәтләри кабул кылгучы Падишаһсын,

[51] Мәһим – нык иман.
[52] Рахманым – Аллам.
[53] Гыйнайәт – ярдәм.
[54] Гакыйбәт – ахырында.
[55] Гасәлдә – авыруда, чирдә.
[56] Гасәлик – чир.
[57] Мөйзләрин – мөгезләрен.
[58] Данә гәүһәрендин – бөртекле гәүһәрдән.
[59] Мәһим килтерди – таза, нык иман күрсәтте.

сән ушбу төзгәним уйын сәнгатени мәңа сона биргел[60]! Йа, Рабби, ушбу үртәкәгә җан биргел! Бары, Ходайга ушбу йиргә сониң хикмәтиң берлә грифтар[61] булдым, шайәт ки уйын кылсам, күнлим мәлүй[62] булмагай», – тип Хак Тәгаләгә йалбарды.

Шул сәгать Хак Тәгалә хаҗәтин рәва[63] кылып, уйын сәнгатини биреп, ул үртәкәгә җан багышлады. Хак Тәгаләгә шөкерләр кылып, уйнын уйнамага кул орды, гөлстанның, думбрасының, кыл кубызының кондакыны[64] бер кылды. Өчисин һәм бергә уйнар ирди. Үртәкәси бийер ирди, барча халкы җыйылды, сарай эчинә йыгъмаз[65] булдылар, һәр кичә-көндез Түләк катындиз[66] китмәз булдылар. Сарайдан тышкары чыкып ултырып, уйын йасадылар. Һәр көн тышта сарай кашында ултырып, мәҗлес корып, Түләкнең уйыныга гыйшык булып җийарындин[67], эчәрендин биздиләр, иртә торсалар, кич булганын белмәз ирдиләр. Түләкниң уйыныга гыйшык булып, һавадагы кошлар, йаландагы кийекләр барчасы монда йыйылып кичә-көндез китмәз булдылар: боланлар, күп ноугы[68] хайванлар, хәшәрәтләр – барчасы Түләкнең уйыныга гашыйк булып, йиймәк-эчмәкдин калдылар.

Көнләрдә бер көн Түләк күңелендин зарилык кылды: «Кәриме рәхим, бу монча пәриләр, кошлар, кийек хайван-хәшәрәтләр берлә сау булып тора-тора, йалкыз[69] җаның тузан басып, сурәтим азып, җенләр, пәри сурәтинә әверелер ирмешмен!» – тип зар-зар йыгълады. Ул кичә кыз катына йатды, такы кызга әйди: «Аһ дәрига, сәниң зиба сурәтеңә алданып, асылларымдин айырылдым, җенессез булдым, үләр булсам, кайда ата, кайда ана? Кайда җенесем адәм?» – тиди.

Анда кыз әйди: «Әй, йегет, гаклың киттими? Бу гыйнайәт бу дәүләт кемдин тиди, белмәзмисән? Бу дәүләткә тигеркүчи падишаһлар падишаһы – Тәңре Тәгаләни оныттыңмы? – тиди. – Айырылганларны куштырмак аңа асан торыр», – дийү күп үгет кылды. Бу сүзләр берлә йегетниң күңлин авытдый[70].

Йатдылар. Иртә намазыга тордылар ирсә, күрдиләр бер алтын тәхет сарай кашында корылмыш. Тәхетниң айаклары көмешдин төзелмеш. Тәхетниң башы гәүһәрдин төзелмеш. Ул тәхетниң өстинә бер олугъ бийек, башы һавага чыкган тау урнашмыш, сикез кыры, дүрт тарафы тимер берлә тайаган[71], тәхетдин йукары калкып, сайә[72] кыйлып торыр. Ул тау алтын берлә кушаган[73], башыны ак мәрвәр[74] берлә йапкан. Түрт йаны агач үскән чыбыклык урман булган. Барча боланлар, коланлар айу-бүри, төлкиләр, кош-кортлар анда урнамышлар[75]. Бу эшләрни күреп, кыз берлә Түләк, Хак Тәгаләгә шөкерләр кылди. Түләк килеп, ул алтын тәхет үзә[76] менип ултырды. Уйынлар кулына алып, дибрәб, кубсаб, сарнаб уйный башлады. Андагъ дибрәб әйтер ирди:

*Гөлстаным көйләсин,*
*Думбрам бәнем сөйләсин,*
*Кыл кубызым сарнасын,*
*Үртәкәм хуш уйнасын,*
*Күрмәгә килгән халайык*
*Үз-үзини белмәсин!*

---

[60] Сона биргел – иңдер.
[61] Грифтар – дучар.
[62] Мәлүй – кайгылы.
[63] Рәва – яраклы.
[64] Кондакыны – төбен.
[65] Йыгъмаз – сыймас.
[66] Катындин – каршыннан.
[67] Җийарындин – ашаудан.
[68] Нәугы – төрле.
[69] Йалкыз – ялгыз.
[70] Авытдый – юатты.
[71] Тайаган – коршаган.
[72] Сайә – күләгә.
[73] Кушаган – коршаган.
[74] Мәрвәр – мәрмәр.
[75] Урнамышлар – урнашканнар.
[76] Тәхет үзә – тәхеткә.

*Уйнай биргел, үртәкәм!*
*Бии биргел, үртәкәм!*
*Алтын тәхет урнаткан,*
*Көмешдин айак йараткан,*
*Тәхет-бәхет төзәткән*
*Хак Тәгалә кодрәте, –*
*Шөкер кирәк, Сусылу!*

Анда ул җыйылган халайыклар әйдиләр: «Бу кемнең тауы торыр? Тау ни тигән тау булыр?» Анда Түләк айларга дыбсаб әйди:

*Мәнем тауым Балкан тау,*
*Башы һавага чыкган тау,*
*Тимер берлә тайаган,*
*Алтын берлә коршаган,*
*Ак мәрмәрдән йапкан тау!*

– тип дыбсаган авазын ишетип, кийек-кошлар, хайван-хәшәрәтләр йыйылып килеп, башларын түбән салып дыңлар ирдиләр. Анда Түләк анларны күреп дыбсаб әйди:

*Утлар уты май татыр, –*
*Болан сүвгән Балкан тау;*
*Эчә суы бал татыр, –*
*Колан сүвгән Балкантау!*
*Йатыр йири йакма алтын, –*
*Йылан сүвгән Балкан тау!*
*Тулагы күп, йири киң, –*
*Төлки сүвгән Балкан тау!*
*Җийим җимеши төкәнмәз –*
*Айу сүвгән Балкан тау!*
*Кайаларый кайырчак, –*
*Карсак сүвгән Балкан тау!*
*Кул куйысы камышлык, –*
*Кабан сүвгән Балкан тау!*
*Йири салкын, йимши күп, –*
*Кошлар сүвгән Балкан тау!*
*Су дәрйасы су алмаз, –*
*Сывыр сүвгән Балкан тау!*
*Башымызның өстиндә*
*Сайә булган Балкан тау!*

– тип уйнар ирди. Ул хәбәрләр, ул эшләр кызның атасы Җаждар ханга ишетелди, Җаждар хан падишаһ кызындин йыраклыкы йити төнлик, йити көнлик йир ирди. Түләкни һәм уйынларыны күрмәгә андагъ гашыйк булды. Йимәкдин, эчмәкдин бизди, дийүләрни, пәриләрни алмага йибәрди. Түләкни пәриләр алып китәр булдылар. Анда кыз Түләккә әйди: «Әй, йегет, ушбу үртәкәңи алып бармагыл, ушбу газиз сурәтни җанлыгъ кылып Хак Тәгалә сәңа бирмеш торыр. Нагяһ[77] атам алып калмасын. Мондагъ нәрсә аңа тансык торыр, үзиңә бер үртәкә сурәти йасап алып баргыл!» – тиди.

Түләк аның сүзин хуш күрди, үртәкә сурәтини йасады. Ул җанлыгъ үртәкәсин кыз йанына куйып китди. Җаждар хан падишаһга йакын йитә килди, дыбсаб-кубсаб уйнай башлады. Түләкниң уйын уйнаган авазын ишетип, уйынга гашыйк булып, шәһәргә барчасы каршы чыктылар. Җаждар хан падишаһ үзи уйын авазын гашыйк

[77] Нагяһ – көтмәгәндә.

булып сабыр итәлмәди, бер таз колны үз урныга тәхет үзә[78] ултыртып, үзинә каршы килеп тыңлар ирди.

Кыз Түләккә атасының сыйфатын әйткән иди. Анда Түләк карады, ушбу килгән Җаждар хан падишаһ үзи торыр. Анда дыбсаб Түләк әйди:

*Гөлстаным көйләйдер, –*
*Думбрам мәним сөйләйдер.*
*Кыл кубызым сарнайдыр,*
*Үртәкәм хуш уйнайдыр!*
*Тәхетдә ултырган Җаждар хан*
*Тәхетдин төшеп тыңлайдыр,*
*Ишектәге таз чура*
*Тәхетдә ултырып аңлайдыр!*

Андин Җаждар хан әйди: «Бу Түләк бизәк торыр кеше булмак кирәк, мәни мондагъ белди», – тиди. Рәван кайтып[79], тәхтинә ултырды. Түләк килеп йитди, падишаһ сарайына төшди. Кырык көн-төн йиймәк-эчмәк берлә, уйын-тамаша берлә калдылар. Андин соң Түләк кызны һәм Балкан тауны, урыны-йирини гайәт сагынды.

Җаждар хан падишаһга дыбсаб-кубсаб андагъ әйди:

*Балкан тауым монда йук,*
*Ак кийекем монда йук,*
*Ултырып уйын төзәргә*
*Алтын тәхтем монда йук!*
*Җөмлә буйы җопарлык[80]*
*Зиба йарым монда йук,*

– тип Түләк әйди. Җаждар хан падишаһ дийүләргә, пәриләргә бойырды: «Барыңлар, Түләкниң Балкан тауыны монда алып килеңләр!» – тип йибәрди. Дийүләр, пәриләр бардылар. Хак Тәгалә Балкан тауыны айларга күргәзмәди, йир берлә төп-төз кылды. Дийүләр, пәриләр ул пулат сарай кашында андагъ тауны тапмадылар.Ул сарай йакынындагы олугъ тауларны бер-бери үзә[81] куйдылар, тимер берлә коршадылар, күтәреп алып килделәр. Анда Түләк дийүләр, пәриләр тауны алып килә торганын күрип дыбсаб-кубсаб әйди:

*Мәнем тауым ул түгел,*
*Алтын тәхтем ул түгел,*
*Тауны таүга охшатып,*
*Алып килә торырлар,*

– тип Түләк ирсә, Җаждар хан каршы дыбсаб әйди:

*Тауны таүга охшатып,*
*Тимер берлә коршатып,*
*Торгын монда Түләким,*
*Балкан таүга охшатып.*

Җаждар хан айгач, аңар каршы Түләк дыбсаб әйди:

*Бары барлы бийек тау,*
*Барындин бийек Балкан тау:*

[78] Тәхет үзә – тәхет өстенә.
[79] Рәван кайтып – кире кайтып.
[80] Җопарлык – җофар кебек.
[81] Бер-бери үзә – берсе өстенә берсен.

*Сублаб какган казыкдай*
*Сувыры күп Балкан тау;*
*Майлап салган кайышдай*
*Йыланы күп Балкан тау;*
*Айрыр тойак, шеш мөйез*
*Болaны күп Балкан тау;*
*Алпан-тулпан атлаган*
*Айуы күп Балкан тау;*
*Иксә йоны санчелгән,*
*Башы түбән ийелгән*
*Кабаны күп Балкан тау;*
*Кыз угландай сузылган*
*Төлкиси күп Балкан тау;*
*Күп йәшәгән карый*[82] *тик*
*Карсагы*[83] *күп Балкан тау;*
*Ойа итеп йири хуш*
*Кошлары күп Балкан тау;*
*Йомры тойак, кыл койрык*
*Колaны күп Балкан тау;*
*Дәстүр бирсә Җаждар хан,*
*Күргем микән Балкан тау!*

– тип Түләк әйди ирсә, Җаждар хан падишаһ әйди:

«Китәрмен тикәнни ничәгә тикү тотармыз?!» – тиди. Пәриләргә әмер кылды: «Барың! Түләкне сарайына илтеп куйыңыз!» «Кабул кылса, атамыз йортына барсак булгаймы?» – тиди.

Анда Җаждар хан әйди: «Ир туган йирендә, эт туйган йирендә газиз торыр. Атасы йортын сагынган ирни ирме дип булыр», – дийү дәстүр[84] бирди, йәнә әйдие: «Йортыңызны, сарайыңызны, халкыңызны, малыңызны нитәк кылырсыз?» – тиди.

Анда Түләк әйди: «Әй, падишаһ, барча галәмниң теләгин бирүчи Тәңре Тәгалә торыр», – тиди. Җаждар хан падишаһ әйди: «Сезне Аллаһы Тәгаләгә тапшырдым!» – тип йибәрди.

Пәриләр кызга тапшырып кайтдылар. Җаждар хан падишаһның шәһәри диңгез арасында ирди. Түләк килди, кыз берлә күрешди, халь-әхвaль сорашдылар. Аты, кошы йамансылап йабыгып дора. Үртәкәсин күрди, йабыгыпдыр, күз йәшләре, борын сулары агып торыр. Шул заман Түләк, гөлстанын көйләп, думбрасыны уйнай, кыл кубызын сарнаб, үртәкәсин алдыга алып уйната башлады. Үртәкәси төзәлеп күрекләнди. Түләк анда үртәкәси бийегәндә әйтер ирде:

*Әй, үртәкәм, үртәкәм,*
*Мөйезләрең куш тәкәм,*
*Буынларың буш тәкәм.*
*Күзең йәши агыпдыр,*
*Гарибсәб сән, үртәкәм,*
*Йәтимсәб сән, үртәкәм,*
*Уйнап күңлиң ачылсын,*
*Тугъ тузаның сачилсен,*
*Уйнай биргел, үртәкәм!*

– тип, күп төрлек уйынлар кылып, халайыкның күңелләрин ачып, һәм кийек кошларның күңлени ачылды, шат булдылар.

[82] Карый – карт.
[83] Карсак – төлкенең аерым төре.
[84] Дәстүр – рөхсәт.

Бу кичә Түләк йасигы намазы кылгандин соң, ики рәкәгать хаҗәт намазы кылды, «Исме әгъзам» догасын укып мәхкәм[85] китерди, башын сәҗдәгә куйып әйди: «Илаһи, барча хаҗәтне рәва кылдың, имди бер теләкемни рәва кылсаң, ушбу сарай, тәхет-бәхетемни сән рәхманым[86] төзип бирдең, сән җәббарга[87] шөкер имди. Ушбу тәхет-бәхет халикъ[88] милкемез, вә йәнә ушбу Балкан тауны кийек кошы берлә, урманы-утлавы берлә, вә йәнә ушбу бал, сөт, су дәрйалары берлә атам шәһәринә урнатсаң[89], кодрәтиң бар торыр.

Мондагъ кылмак сәңа асан торыр, әй җәббарым», – тип күзендин йәшин сачти, Хак Тәгаләгә йалбарып, күп мөнаҗат[90] кылды. Ул кичә йатды, иртә таң намазы кылдылар. Анда кыз карады, пулат сарай тәрәзәсендин көн төшди. Андин борын сарай эчинә көн төшә торды дәгел иди, тышкару чыкды. Тиз карап күрди бер олугъ шәһәр йәнәшәсиндә халкы, малик[91] тәхти-бәхти, Балкан тау, урманы, кийек-кошы, пулат-сарайы, бал дәрйасы, сөт дәрйасы, су дәрйасы – барчасы буйлә килеп бер олугъ шәһәр йанында урыннамыш.

Кыз, кайтып, сарайга керди, Түләккә әйди: «Әй, йегет, сән белермисән, бу ни йиргә килдиң?» – тиди. Анда Түләк әйди: «Әй, җаным могътәбәр, мәним йирем-йортым ушбу шәһәр торыр. Атам йортына килдик», – тиди. Андин кыз торды, урынларын төзди, күшәкәсин корды[92], утырды, һичнәрсә сүз әйтмәди. Ул вакытта ул шәһәрниң падишаһы үлгән ирди. Улдин борынгысы көн ул шәһәрниң олугълары йыйылып иттифак кылган идиләр: таңдагы көн бу шәһәргә төш вакытына тикрү һәркем килсә, падишаһлыкка күтәргәймез тип. Олугъ-кечек, алтмыш йәшдин алты йәшкә тикрү бер киңәштә булып, кем килсә дә падишаһлыкка күтәргәймез тип, көтеп торыр ирдиләр. Ул кичә йатып, иртә тордылар ирсә, күрдиләр, ул шәһәргә йәнәшә бер олугъ тау урыннамыш. Ул тау тимер эстиналары берлә йукары калкува урыннамыш. Ул тауның аегында бер алтын тәхет урыннамыш. Ул тәхетниң айаклары көмешдин, башы гәүһәрдин. Ул тауны алтын берлә коршаган, тугының башыны ак мәрмәрдин йапкан. Ул тауның каршысында бер пулат сарайның алдындин бардыр бер дәрйасы – балдин агып барыр, сарайның артындин сөтдин бер дәрйа агып барыр. Түрт тарафындин судин торадыр, агып барыр. Бер акбүз аргамак ул тауның төбиндә утларый йөрир. Бер ак шоңкар кошы, миңезлик кош, тау тигрәсиндә очып шаңгылтай йөрир, барча олугъ-кечек күрдиләр, таң-гаҗәйеп калдылар: бу, мондагъ пулат сарай, җиһанда һичкем күрмеши йукдыр, тидиләр: «Мәгәр безләрә пулат сарайның ийәсин Хак Тәгалә падишаһлыкка йибәрди булгай», – тип гайәт сүвенештиләр.

Андин олугъ вәзирләр вә кәбирләр[93] ни тордылар. Ул пулат-сарайга бардылар. Ул сарайның ишекиндә саклап торган берничә йегетләрни күрдиләр. Мисле ай берлән көн булгай боларның күрекләрин күрдиләр ирсә, гакыллары китти, заил булды[94].

Бер замандин соң гакылларын йыйып алдылар. Анда ул сакчы йегетләргә әйдиләр: «Бу сарай кемниң торыр, вә йәнә бу халикъ милек кемниң торыр? – тидиләр. – Вә йәнә бу тауның аты ни тип әйтерләр», – тип сорадылар ирсә, анда, ул сарай ишекиндә саклап торган йегетләр әйдиләр: «Бу сарай Җаждар хан падишаһның кийәве берлә кызының сарайы торыр, йәнә бу тәхет – бәхет халикъ

[85] Мәхкәм – нык, таза, биредә: иман ныклыгы.
[86] Рәхманым – Аллам.
[87] Җәббарга – бик кочлегә.
[88] Халикъ – бар кылучы.
[89] Урнатсаң – урынлатсан, урнаштырсаң.
[90] Мөнаҗат – Аллага мактау.
[91] Малик – ия.
[92] Күшәкәсен корды – кабул итү бүлмәсен тәртипкә китерде.
[93] Кәбирләр – олылар.
[94] Заил булды – бетте.

милек аларның торыр, вә йәнә бу тауны Балкан тау дип әйтерләр,» – ирсә, иҗазәт[95] теләп эчкәре сарайга иңдиләр.

Ул халайык эчиндә Түләкнең атасы Мирказый би һәм бергә вар ирди. Түләк берлә һәм катындагы кешиләр күрешә башладылар. Анда күрешә килеп, Түләк кочаклашып күрдиләр: Түләкниң барча буынлары калтырап, төси үзгәрди, гяһ[96] кызарды, гяһ уңарды[97].

Анда кыз Түләкдин хәфия[98] сорады: «Ул кеши берлә күрешмәкдә ни өчен калтырап, төсиң үз булды?» – тиди. Анда Түләк кызга әйди: «Әй, җан мәхәббәтем, ул кеши минем атам торыр, аның берлә сәйер күрешмәкдин буынларымның зали китди, шуның өчен калтырадым», – тиди. Кыз белди: кайын атасы торыр.

Андин олугъ биләрнең, вә такый олугъ вәзирләрнең, олугъ кәбирләрнең хатынларыга хәбәр кылдылар: «Ушбу падишаһның кызына күрешергә килсинләр!» – тип. Барча олугъларның хатынлары килди. Түләк берлә һәм кызы берлә күрешдиләр. Ул би хатынлары эчиндә Түләкниң анасы һәм бар ирди. Анасының ике имчәкинә сөт тулып килди. Түләк инәси берлә күрешмәкдә, инәсиниң ике имчәкендин сөт атылып чыкды. Түләкниң йөзинә сачелди һәм агызына керди. Түләк йотды: бал һәм шикәрдин татлыйгъ ирди. Түләкниң сөт ләззәтендин, мәҗлес хушлыкыдан гаклы китеп йыглай йазды. Инәси, сөти сачелгәнгә ойалып, тугъры карый алмады, шайәт угълы иркәнин андагук белгәй ирди, күңлиндә әйтер ирди: «Аһ дәрига, мәним бу ике имчәкимә сөт тулды, булган балага йарику, бу кеми булды иркән?» – тип йәшерин йыгълар ирди.

Кыз йәнә Түләкдин хәфия сорады: «Ул сөти йөзиңә сачилган ни хатын ирди?» – тиди. Анда Түләк кызга әйди: «Әй, җаным йулдашы, шул карый хатын мәним инәм торыр!» Кыз белди: кайын анасы торыр.

Кыз торды, сандык ачды, ики тун алды, алтын-көмеш, гәүһәр-җәүһәр берлә мөрәссагъ кыйлмыш, Түләккә бирди: «Бересин атаңа, бересин анаңа йап», – тиди. Түләк бер тунны атасына, бер тунны анасына йапды. Халайык анда таңга калдылар, әмма Түләкни ата-анасы әгълә[99] белмәйләр, гайреләри[100] һәмишә[101] белмәйләр. Мәгәр йегет илән кыз үзләри генә беләләр. Танышу соңында ул шәһәр халкы йәгъни аңа әйдиләр: «Әй, солтан угълы, безләрниң – улып ханымыз үлди торыр. Түнәкөн[102] барчамыз йыйылып иттифак кылдык, ханымыздин угыл-кыз калмады, ханлыкга ултыртмага барчамыз әйдек: «Таңдагы көн төш вакытында тикрү[103] һәркем килсә, ханлыкга күтәргәймез», – тидек.

Имди, сезни безгә Тәңре Тәгалә килтерди торыр, безни сәңа Тәңре Тәгалә бирди торыр, кил имди, сәни тәхеткә күтәрәле!» – тидиләр. Анда Түләк әйди: «Сез кабул кылыр булсаңыз, мән риза!» – тиди. Шул заман барча халайыклар, иттифак улып, Түләкни ханлыкга күтәрдиләр.

Өч йыл хан булып ултырды. Андагъ гадел хан кылды, барча вәйран йортлар төзәлди, мәгәр куйлар-бүриләр бергә йөреки тик булды. Моның тик гаделлек бәрәкәтиндә һәм шул вакыйгача Түләкни кем ирдикин һичбер кеше белмәз иди. Әмма һәр даим Түләкниң инәси әйтер ирди: «Ушбу хан безниң гаиб булган угълымызга охшар!» – тип әйтер ирди. Мирказый би әйтер ирди: «Әй хатын, гаиб булган угълымызга мондагъ ханлык кайда булыр!» – тип әйтер ирди.

Түләк, җомга көн, Балкан тауга чыкып, алтын тәхеткә ултырып, барча

[95] Иҗазәт – рөхсәт.
[96] Гяһ – бер вакыт.
[97] Уңарды – төссезләнде.
[98] Хәфия – серне.
[99] Әгълә – бик яхшы.
[100] Гайреләри – башкалары.
[101] Һәмишә – һаман.
[102] Түнәкөн – кичә.
[103] Тикрү – кадәр, тикле.

халайыкны җыйып, йимәк-эчмәк биреп, гөлстанын көйләп, думбрасын уйнап, кыл кубызын сарнаб, үртәкәси бийеп, аның гыйшкындин корбан кылгу тик булып торыр ирдиләр.

Бер көн Балкан тауга чыкып йийып-эчип, уйын-тамашалар берлә ултырыр ирдиләр. Олугъ биләр, вәзирләр иттифак кылып сорадылар: «Шаһи җиһан, сән безләргә хан булдың, без сәңа халык илә көтү булдык. Өч йыл булды сорарга кыймадык, имди безләр сорармыз, кемниң нәслисән, үзиң кемниң угълысән, атыңыз ни торыр?» – тип сорадылар. Анда Түләк әйди: «Мән сезниң үз нәселеңездинмен вә йәнә үз угълыңызмын!» – тиди. Анлар әйдиләр: «Безнең барча угълымыз үз катымызда торыр, мәгәр күп йыллар булды, бер угълымыз гаиб булып[104] торыр, сәниң атың кемдер?» – тип сорадылар. Анда Түләк әйди: «Мәним атым – Түләк торыр, атам аты – Мирказый би торыр!» Сорадылар, әйди ирсә, барча халайык кочаклашып күрешдиләр, халь-әхваль сорашдылар. Түләкниң атасы берлә анасы, Аллаһы Тәгаләгә шөкерләр кылып, фәкыйрьләргә күп маллар өләштерди. Алар анда Түләкдин сорадылар ни халь гаиб булып киткәнин, йәнә бу алтмыш йегет, атының йөгәнин суйып йибәргәнин, йити кичә-көндез аты алып киткәнин, атының айакына тимер кадак сукганын – барча әйди ирсә, барча биләр, вәзирләр әйдиләр: «Бу алтмыш кеши әүвәл сәңа көнләшер, дошман булып, андагъ эш кылдылар. Имди бу көн сән икәнин белдиләр, андин йаманрак дошман булыр», – тидиләр.

Анларга Түләк әйди: «Анларны ни кылмак кирәк?» – тиди.

Барча олугълар әйдиләр: «Анларны апал итеп измәк кирәк», – тидиләр. Андин соң анларны илләри берлә апал итеп, ул йы-йылган халайыклар берлә иттифак әйләп изә башладылар. Әүвәл ун өйлесен Иләчте тип атага әйләдиләр, икенчи ун урыс йорты тип Эчтүкәгә, өченчи ун чит халык тип Чиркәскә әйдиләр, гүртенчи унын кыр халкы тип Кыргызга, бишенчи унын башка йорт тип Наҗарга, алтынчы унын Каныш йорты тип Кайага әйдә ирдиләр.

Андин соң Түләк, ул дәүләт эчиндә ултырып, утыз алты йыл ханлык сөрди.

Андин соң Сусылу дөнйадин үтди. Икенчи йыл Түләк үзи дөнйадин үтди. Түләк дөнйадин үткәндин соң Түләкниң угълы Габдулланы ханлыкга күтәрдиләр. Ике йыл хан булып торды. Андин соң Түләк угълы Габдулла дөнйадин үтди. Түләк угълы дөнйадин үткәндин соң, Балкан тау, алтын тәхет, пулат сарай, бал дәрйасы, сөт дәрйасы, дүрт тарафдин акган су дәрйасы, бергә килгән халкы-милке – барча бер кичдә гаиб булып, йук булды, һәм һич адәм кайда киткәнин белмәдиләр. Тәмам.

[104] Гаиб булган – юкка чыккан.



*Марсил Каһир улы Кадыйров тумышы белән Теләче районының Түлешкә авылыннан. 1959 елда дөньяга килеп, Түлеш, Югары Кибәхуҗа, Арча мәктәпләрендә белем алган егет гомерен фән өлкәсенә багышлый, профессор дәрәҗәсенә ирешә. Физика, химия, математика һәм медицина өлкәләрендә ул өч йөздән артык фәнни хезмәт авторы, 18 патент иясе. Өч ел АКШта Детройт университетында эшләп кайткан шәхес. Шул ук вакытта ул татарча көрәш буенча Татарстанның атказанган тренеры, ТР физкультура отличнигы, халыкара категорияле хөкемдар да әле. 1997–2013 еллардагы рәсми көрәш кагыйдәләрен гамәлгә куюда да аның өлеше зур. Ул Бөтендөнья билбаулы татарча көрәш ассоциациясенең президенты булып, әлеге спорт төрен халыкара мәйданга чыгарып, дөнья күләмендә танытуга зур көч куя. Казан универсиадасы алдыннан ике ел дәвамында Җир шарының дүрт кыйтгасының 30 дан артык илендә татарча көрәш федерацияләре оештыруда катнаша. Кыскасы, нинди генә эшкә алынса да, дөньякүләм югары күрсәткечләргә ирешүче журнал укучыбыз, әдәбият мәйданында да каләмен сынап карарга булды.*

**Редакция**

# КӘҖӘ БЕЛӘН ЮЛБАРЫС ХИКӘЯТЕ

***(Тукайның «Кәҗә белән сарык» поэмасына ияреп)***

*«Приморский Сафари» паркында 2015 елның 2 ноябреннән 2016 елның 26 гыйнварына кадәр Амур юлбарысы һәм аңа азык буларак китерелгән кәҗә тәкәсе бер вольер эчендә бергә тотылды. Ерткыч җанварның үз корбаны белән озак яшәве Россия массакүләм мәгълүмат чараларында иң популяр темаларның берсенә әверелде.*

Интернеттагы чыганаклардан

***

Борын заман түгел тышта – бүгенге көн,
Урман эчендәге тыюлыкта – иркен.

Салмак кына атлап, бер Юлбарыс килә,
Иснәштерә ул иренеп сирәк кенә.

Караучылар көн дә азык китерәдер.
Ара-тирә тере корбан да бирәдер,

Аның аучы осталыгы бетмәсен дип.
Корбан исә – куркак куян, йә кәҗә бер.

Бер көн шулай карт Кәҗәне китерделәр.
Шуның берлә үз эшләрен бетерделәр,

Дип уйлады Юлбарысны караучылар.
Ялгыштылар... Дөньяда бит могҗиза бар.

Кәҗә, чынлап, бик борынгы булып чыкты,
Карт булса да, хәтерли ул Идел-Йортны.

Хуҗа хатын берлә Ирне гафу кылып,
Йөртмәс булды күңелендә авыр йөкне.

Эшнең нидә икәнен ул тиз аңлады,
Бу юлы да куркып, югалып калмады.

Үзе башлап сүз кушты ул Юлбарыска.
Мөгез барда, имеш, аның сүзе кыска!

*Кәҗә:*
«Шулай инде: җәза юктан нәфес аза.
Тик урманда сырлы мәче түгел каза

Дүрт бүрене җиңгән батыр Кәҗә өчен –
Тиз тоярсың очлы мөгезләрем көчен».

*Юлбарыс:*
«Тукта – тукта, терәмә ул мөгезләрең,
Курыкмауны аңлатадыр бу күзләрең –

Мин ышанам. Ә шулай да дүрт бүрене
Җиңә алу ышандырмый күңелемне».

*Кәҗә:*
«Шигең дөрес: дүрт бүрене куркытканда,
Үзем генә түгел идем мин урманда.

Ярдәм итте миңа дустым – арык Сарык,
Бүре башын зур капчыктан алып – салып».

*Юлбарыс:*
«Арык Сарык?.. Әле күптән түгел генә
Бер сарыкны китерделәр читлегемә.

Куркуыннан һәр сөяге дөбердәде...
Теш арамда әле дә карт сеңерләре».

*Кәҗә:*
«Сөйләмә юк, синең ишеләрне Сарык
Орып бәрә иде аркасына салып.

Зур капчыкта ул уники бүре башын
Чөеп кенә йөрде, минем арттан ташып».

*Юлбарыс:*
«Сөйләшүең бик гайрәтле, ышандыра.
Күңелкәем инде олы план кора –

Тыюлыкта узып барган гомеремне,
Риза булсаң, ялгыз итмәү синнән тора».

*Кәҗә:*
«Койма берлә уратылган тыюлыгың,
Яшәр өчен монда җитәр кыюлыгым.

Тик яшермим, гомеремнең матур чагын
Кабатлыйсым килә Сарык берлә тагын».

*Юлбарыс:*
«Рәхмәт инде, кире какмый гозеремне,
Риза булдың уртакларга гомеремне.

Таныш булыйк: «Амур» минем кушаматым,
Инде әйтче, бармы синең исмең-атың?»

*Кәҗә:*
«Тимур» булам, әле сәвит заманында,
Карт-корыга булышкалаган чагымда,

Бала-чага такты ошбу кушаматны.
Мәгънәсен һич аңламыйм, тик булдым атлы».

*Юлбарыс:*
«Амур буе безнең яшәү урыныдыр,
Елга яны куе Тайга – нинди хозур.

Тик санныбыз кими безнең елдан-елга,
Шул сәбәпле китерделәр мине монда».

*Кәҗә:*
«Нишлисең бит, язмышка без түгел хуҗа.
Мин дә үзем теләгәннән күрмим нужа.

Ярар инде, зар елаудан юктыр файда.
Хуҗа булсаң, тыюлыгың күрсәт, әйдә».

***

Иртә берлән иртүк торып, таң аткач ук,
Җир өстенә ап-ак йомшак кар яткач ук,

Болар ике туган сыман сәфәр китте.
Нәрсә языйм?.. Хикәям дә шунда бетте.

**Марсил КАДЫЙРОВ.**
*Казан.*

*Венера Гәрәеваның тууына – 80 ел*

# «ТАТАР МОҢЫН ЯШӘТЕРЛЕК ЯШЬЛӘР КИЛӘ...»



Бөтен гомерен халык җырларының сафлыгын саклау, аларга безнең заманның рухын, эчтәлеген салып, шул энҗе-мәрҗәннәргә тиң хәзинәне халыкның үзенә кайтарып бирү өчен җан атып яшәгән, данлыклы музыкант, озак еллар дәвамында Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле хормейстеры булып эшләгән җитәкче, Татарстанның халык артисты Венера Хәсән кызы Гәрәеваның тууына – 80 ел.


Ул 1943 елның 25 июнендә Арча районының Өчиле авылында туа. Халкыбызның җыр-моңнарына гашыйк булып үскән кыз Алабуга культура-агарту училищесына укырга керә. Җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Җәүдәт Айдаров аның матур тавышын ишетеп, җитәкләп диярлек үз янына эшкә алып китә. 1961 елда була бу хәл. Һәм менә шул көннәрдән алып, гомеренең соңгы чигенә чаклы Венера ханымның иҗат юлы шушы коллективка аерылгысыз бәйләнгән.

Юбилее уңаеннан без журнал укучылар игътибарына 2017 елның 7 декабрендә эфирга чыккан бер тапшыруны тәкъдим итәргә булдык. Ул Җыр һәм бию ансамбле оешуга 80 ел тулу уңаеннан әзерләнгән иде, һәм анда Венера Гәрәева шушы иҗат коллективының үткәненә, бүгенге көненә, киләчәгенә бәйле уйлары, хатирәләре белән уртаклаша: «Хәзерге вакытта хорның, оркестрның яңгырашы да, биюләрнең куелышы да ерактан, тамырлардан килгән традицияләргә нигезләнеп, милли йөзләрен югалтмадылар. Безнең озак яшәвебездән дә киләдер инде бу. Оркестр җитәкчесе Рәшит Мостафин да, хормейстер Раилә Гарипова да, мин үзем дә ансамбльгә 1960 нчы елларда ук килгән кешеләр бит. Мин әле пенсиягә киткәндә дә, ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов та, Нияз Гәрәев та шушы юлдан тайпылмаска сүз бирделәр.

Мин әле шуңа сөенәм: телебез авыр хәлдә калган, моңны саклау бик авырлашкан шушы вакытта никадәр конкурслар үткәрелә: «Татар моңы», «Татар җыры», Ваһапов конкурсы... Бу конкурслар яшәгән вакытта татар моңы яшәр дип уйлыйм. Чөнки яшь буынны яңадан өйрәтергә кирәк. Моң ул генетика белән, нәселдән килә торгандыр. Әгәр татарның нәселе исән икән, менә бу конкурслар яши икән, аларда катнашкан яшьләр безнең җырларның рухын аңларлар, заманнар үтәр, ә җырлар нәкъ элеккечә моң белән яңгырар дип ышанам мин. Татар милләте – моңа лаеклы милләт, чөнки ул – бөек милләт. Аның нинди зәвыклы сәнгате бар, нинди затлы әдәбияты бар. Минем иң курыкканым шул: әгәр дә гасырлар дәвамында язылган әсәрләрне укырга, җырларны җырларга кеше калмаса, мин аны дөньякүләм зур бер хәсрәт дип кабул итәр идем. Хәзер безнең иң зур бурыч – телне саклау. Ниязга рәхмәт. Ул шушы бурычка бик нык игътибар итә, аның өчен җырның һәр сүзе, һәр иҗеге кадерле. Мин бик сөенәм, хәзерге вакытта безне алыштырырга менә шундый бөек, көчле яшьләр килә...»

Инде әйдәгез, сайтка кереп, язманы тыңлыйк, Венера Хәсән кызының газиз тавышын ишетик. Әңгәмәне музыка белгече Гөлназ Гыйльми алып бара.

# ХУШЛАШМЫЙ ДА КИТЕП БАРДЫ...



Җырлары белән халык күңелендә иң нечкә, садә хисләрне кузгата алган лирик шагыйрь Фәннур Сафинның (1948–1992) тууына – 75 ел. Шул уңайдан Татарстан радиосы шагыйрьнең шигырьләреннән һәм аларга язылган җырлардан төзелгән әдәби-музыкаль композиция әзерләде.

Татарстан Язучылар берлегенең рәсми сайтыннан:

«Фәннур Шәйхенур улы Сафин 1948 елның 27 июнендә Минзәлә районы Күзкәй авылында туа. 1966 елда урта мәктәпне тәмамлагач, ул комсомол юлламасы белән Түбән Кама төзелешенә килә. 1969–1974 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аны тәмамлаганнан соң, бераз вакыт Казан телестудиясендә – мөхәррир, аннары озак еллар «Татарстан яшьләре» газетасы, «Ялкын», «Казан утлары» журналлары редакцияләрендә – әдәби хезмәткәр, Татарстан Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросы хезмәткәре, «Мәгариф» китап нәшриятында мөхәррир вазифаларын башкара.

Фәннур Сафин мәктәптә укыганда ук, беренче шигъри тәҗрибәләре белән «Ялкын» журналы һәм «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталарында күренә башлый. Студент елларында иҗат иткән шигырьләре исә «Беренче карлыгачлар» (1970), «Юл башы» (1972) исемле күмәк җыентыкларда дөнья күрә».

Фәннур Сафинның лирик шигырьләренә күп кенә композиторларыбыз да игътибар итә, узган гасырның 70–80 нче елларында халык күңеленә мәңгегә кереп калырлык җырлар дөньяга килә. Хәзерге вакытта Татарстан радиосы фондында аның шигырьләренә язылган җырларның илледән артык язмасы саклана. Рөстәм Яхин, Зиннур Гыйбадуллин, Фәрит Хатыйпов, Рәшит Гобәйдуллин, Бату Мөлеков, Риф Гатауллин, Тәлгать Бадыйгин, Илгиз Закиров, Әнвәр Шаһиморатов кебек күп кенә затлы аһәңсазларыбыз тарафыннан иҗат ителгән әлеге җырларны иң популяр җырчылар сәхнәгә алып чыккан, радио, телевидение эфирыннан яңгыраткан: Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичев, Римма Ибраһимова, Зиннур Нурмөхәммәтов, Хәмдүнә Тимергалиева, Рабига Сибгатуллина, Зилә Сөнгатуллина, Мирсәет Сөнгатуллин, Клара Хәйретдинова... Шунысы куанычлы, әлеге онытылмас җырлар яшь буын башкаручыларның репертуарында да урын ала. Әйтик, дөньякүләм танылган сандугачыбыз Альбина Шаһиморатова, зәвыклы җырчыларыбыз Бәширә Насыйрова, Рафаэль Якупов, Алинә һәм Азат Кәримовлар, Эльза Заяри һәм Артур Исламов һ.б. заманча аһәңнәр белән баетып, аларга яңа сулыш бирделәр.

Фәннур Сафинның балалар өчен шигырьләренә иҗат ителгән «Соңгы кыңгырау» (Әнвәр Шаһиморатов музыкасы), «Шатлык җыры» (Алсу Гарифуллина), «Мин – Яңа ел» (Илдус Якупов) кебек җырларын мәктәпләрдә, бакчаларда куелган концерт-кичәләрдә еш ишетергә мөмкин.

Фәннур Сафин 1992 елның 30 яки 31 декабрендә ялгыз яшәгән фатирында кинәт вафат була. Үзе язган «Хушлашырга ашыкма» дигән җырдагыча булмады шул, хушлашмый да китеп барды ул...

Инде әйдәгез, сайтка кереп, язманы тыңлыйк. Фәннур Сафин шигырьләрен яраткан артистыбыз Дания Нурлы укый.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире*
**Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

## ФОРУМНАР

«Россия-Ислам дөньясы: Kazan Forum-2023» Халыкара икътисади форумы булып узды. Россия Федерациясе Президенты аңа федераль статус бирү турында карар кабул итте. Казанга 80 илдән, Россия төбәкләреннән 15 меңләп кеше килде. Форумны Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов ачты. «Бу форум илләребез һәм төбәкләребез үсешенә этәргеч булачак», – диде ул, «Kazan Summit-2023» кырларында нәтиҗәле эш теләп. Пленар утырышта катнашучыларга РФ вице-премьеры Марат Хөснуллин РФ Президенты Владимир Путинның сәламен ирештерде. Форумда төрле секцияләр эшләде, түгәрәк өстәлләр оештырылды, йөзләрчә килешү төзелде. «Russia Halal Expo-2023» күргәзмәсе ачылды. Рөстәм Миңнеханов чит илләрнең гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчеләре белән очрашты.

* * *

Форум кысаларында «ТАТМЕДИА» һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы Мәгълүмат агентлыклары берлеге меморандум төзеде. Аны Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев һәм берлекнең генераль директоры Мөхәммәт Абдраббо Альями имзаладылар.

* * *

«Милли тормыш һәм дин» XIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы булып узды. Аңа Россиянең 77 төбәгеннән 1000нән артык делегат килде. Форум делегатлары «Изге Болгар җыены»нда да катнашты. Җыенда ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Россия Ислам дөньясының бер төркем күренекле шәхесләре чыгыш ясады. Болгарда җыен кысаларында Мөхәммәт пәйгамбәрнең (с.г.в.) ядкярләре тәкъдим ителде (алар Кол Шәриф мәчетендә дә күрсәтелде), төрле күргәзмәләр ачылды, билбау көрәше турниры уздырылды, остаханәләр эшләде. Сәхнәдән татар шагыйрьләре (Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Рифат Сәлах) шигырьләрен укыдылар.

## СЕМИНАР

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә язучы, сәясәтче, татар милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 145 ел тулуга багышланган «Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, гамәл» дигән темага халыкара-гамәли семинар булып узды. Аның эшендә Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Төркиядән, шулай ук Казан, Новосибирск, Уфа, Чаллы, Ижау, Алабуга һ.б. шәһәрләрдән галимнәр катнашты. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган бу чара «Гаяз Исхакый һәм XX-XXI гасырлар татар дөньясы» дигән темага утырыш белән ачылды. Аны институт директоры Ким Миңнуллин ачты. Семинарда ТР Фәннәр академиясе вице-президенты Дания Заһидуллина, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, КФУ профессоры Хатыйп Миңнегулов, Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының татар белемен чагыштырма тикшеренүләр лабораториясе мөдире, доцент Марсель Ибраһимов, галимнәр Ләйсән Шахин (Мәрмәрә университеты), Диләрә Усманова, Гөлмира Солтангалиева һ.б. чыгыш ясады. Ике көн барган бу семинар секцияләрдә дәвам иттерелде, түгәрәк өстәлләр оештырылды. Гаяз Исхакыйның өч томлы «Көндәлекләр»енең беренче томы һәм публицистик язмаларыннан торган «Милли куәтләр бардыр» китабы тәкъдим ителде.

## КАЗАНБАШ МӘКТӘБЕНӘ ГАРИФ АХУНОВ ИСЕМЕ БИРЕЛДЕ

Арча районы Казанбаш мәктәбенә шушында укыган Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов исемен бирү тантанасы булды. Аңа Казаннан бер төркем кунаклар – Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, язучылар Сания Әхмәтҗанова, Хәбир Ибраһимов, Вакыйф Нуриев, Нәҗибә Сафина, Йолдыз Шәрәпова, Айрат Бик-Булатов, «Татар-информ» журналисты Рузилә Мөхәммәтова, музей белгече Флёра Дәминова, яшь шагыйрә Маргарита Графова, Г.Тукай исемендәге Дәүләт филармониясе җырчысы Ригина Вәлиева, Г.Ахуновның кызы, шагыйрә Наилә Ахунова, Г.Ахуновның туганнан туган сеңлесе Сания Ахунова кайтты. Аларны Арча районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Инсаф Габделгазизов, мәдәният бүлеге җитәкчесе Илфар Әюпов, мәктәп директоры Ришат Камалов сәламләде. Кунакларны әдип әсәрләренең геройлары да каршы

алды. Укытучылар һәм укучылар Г.Ахуновның тәрҗемәи хәле һәм балачак хатирәләре белән бәйле инсценировка күрсәттеләр. Кунаклар Гариф ага турында истәлекләрен уртаклашты, мәктәп музеенда булды, Ахун чишмәсенең суын авыз итте, район үзәгендәге Язучылар аллеясына тукталды, Арча зиратына кереп, Г.Ахунов, аның җәмәгате язучы-тәрҗемәче Шәһидә Максудова, уллары язучы-тәрҗемәче Рәшит Ахунов каберләрен зиярәт кылды.

### ЮБИЛЕЙ

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык язучысы, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт, Г.Исхакый премияләре лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, прозаик, драматург, актёр, режиссёр, җәмәгать эшлеклесе Рабит Батуллага 85 яшь тулуга багышланган кичә (сценарий авторы Нурбәк Батуллин, режиссёры Айрат Җаббаров, рәссамы Булат Ибраһимов) булды. Ул халык алдына бик күп «Батулла»ларның чыгуы һәм аларның зал тутырып күмәк биюе белән башланды. ТР вице-премьеры – Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев Р.Батуллага ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев котлавын ирештерде, шулай ук аны Милли Шура исеменнән дә тәбрикләде. Яңа форматта оештырылган бу кичәнең үзәгендә шигъри дәрес иде. Бу җәһәттән бәйрәмдар кичәне алып баручылар, Г.Камал театры артистлары Искәндәр Хәйруллин белән Фәннүр Мөхәммәтҗановның бихисап сорауларына җавап бирде. Татар шигъриятенең тарихы, татар шагыйрьләренең уй-гаме, фаҗигасе турында иде бу дәрес. Кичәдә Г.Камал театры артисты Фәнис Җиһанша Рабит Батулланың «Сөембикә» романыннан Кол Шәриф вәгазен укыды, язучы-сатирик, җырчы Алмаз Хәмзин, язучы-тәрҗемәче Фатих Кутлу, Рабит аганың уллары Нурбәк белән Байбулат Батуллиннар, җырчылар Зәйнәп Фәрхетдинова, Илгиз Мөхетдинов, Руслан Габитов, «Риваять» төркеме, Казан театр училищесы укучылары чыгыш ясады.

### ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасарлары Илсөяр Иксанова, Факил Сафин (Чаллы), берлекнең Әлмәт бүлеге җитәкчесе Рәфкать Шаһиев, әдәби консультант Газинур Морат узган утырыштан соң башкарылган эшләргә хисап тоттылар. Утырышта Роза Туфитуллова – Гаяз Исхакый, Марат Кәбиров – Һади Такташ, Рафис Корбан – Фатих Хөсни, Рәхимә Арсланова, Фирдәвес Әһлия – Абдулла Алиш, Төркиядә яшәүче татар галиме Чулпан Зариф – Җамал Вәлиди, Зөлфәт Хәким – Туфан Миңнуллин, Алёна Кәримова, Йолдыз Шәрәпова, Миңзифа Әхмәтшина – Саҗидә Сөләйманова, Алмаз Хәмзин Гамил Афзал исемендәге әдәби премияләргә тәкъдим ителде. Утырышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды.

### РӘНИФ ШӘРИПОВ УКУЛАРЫ

Кукмара районы Березняк мәктәбендә традицион Рәниф Шәрипов укулары булып узды. Анда якташлары шагыйрь, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты иҗатын ятуларын шигъри сүз, җыр белән ирештерделәр. Бу чарага Казаннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, якташлары Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, әдәбият галиме, язучы-прозаик Фоат Галимуллин да кайткан иде.

### ЕГЕРМЕНЧЕ КИТАП

«ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да язучы Зиннур Хөсниярның «Әтием кайда, Суслонгер?!» китабын тәкъдим итү булды. Бу – «ТАТМЕДИА» ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсеннән» сериясендә басылып чыккан егерменче китап. Яңа китап тәкъдим итү чарасында «ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, автор үзе чыгыш ясады. Бу китап туе шунысы белән үзенчәлекле булды: аңа әсәрнең прототиплары – Һадия Хөснетдинова (авторның әнисе) белән Зәйтүнә Җамалиева да килеп, Суслонгер газап-афәте турында үз сүзләрен әйттеләр. Соңыннан Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Аюпов сугышларда шәһит киткәннәрнең рухына дога багышлады. Китап тәкъдим итү бәйрәмен Алсу Габдуллина алып барды.

### ХӘТЕР ӨМӘСЕ

Татарстан Язучылар берлеге Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында хәтер өмәсе оештырды. Каләм ияләре Габдулла Тукай, Әмирхан Еники, Атилла Расих, Илдар Юзеев, Нури Арслан, Әминә Бикчәнтәева һәм башка күренекле язучыларның каберләрен чистартты.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

15 июнь – язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Зөфәр Дәүләтов**ка 70 яшь.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повесть Н.ГИМАТДИНОВОЙ «Два художника», повесть Р.САФИНА «По тропам судьбы»; стихи Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, Г.ГАРИПОВОЙ-ДЕНИЗ, Ф.ДАВЛЕТБАЕВА.*
*«Литературный конкурс «Учитель – прекрасный человек на земле!»: повесть А.ЮНУСОВОЙ «Прекрасная».*
*«Новые имена»: стихи Г.НУРИЕВОЙ.*
*«Литература родственных народов»: рассказ У.ХАМДАМА «Стакан воды».*
*«Публицистика»: статья Р.ВАЛИЕВА.*
*«Литературная критика»: статьи В.МАКАРОВОЙ.*
*Фотоархив, посвящённый к 80-летию Ф.Латифи.*
*«2023 год – год дастанов»: «Книга Тюляк» с предисловием Л.МУХАМЕТЗЯНОВОЙ.*
*«Творчество наших читателей»: рассказ в стихах М.КАДИРОВА «Коза и тигр».*
*«Бесценные голоса»: статьи к 80-летию В.Гараевой и 75-летию Ф.Сафина.*
*Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: национальный комплекс «Туган авылым». Фото И.АБРАМОВОЙ; писательница, журналист Айзиряк Гараева-Акчура .*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: story by N.GIMATDINOVA «Two artists», story by R.SAFIN «Along the Fate Paths»; poems by F.ZAMALETDINOVA, G.GARIPOVA-DENIZ, F.DAVLETBAYEV.*
*Literary contest «Teacher is a Wonderful Person on Earth!»: story by A.YUNUSOVA «Beautiful».*
*«New names»: poems by G.NURIEVOY.*
*«Literature of kindred peoples»: story U.KHAMDAM «A Glass of Water».*
*«Publicism»: article by R.VALIEV.*
*«Literary criticism»: articles by V.MAKAROVA.*
*Photo archive dedicated to the 80th anniversary of F.Latifi.*
*«2023 is the year of the Dastans»: «The Book of Tyulyak» with a foreword by L.MUKHAMETZYANOVA.*
*«Creativity of our readers»: story in verse by M.KADIROV «The Goat and the Tiger».*
*«Priceless voices»: articles dedicated to the 80th anniversary of V.Garayeva and the 75th anniversary of F.Safin.*
*The column is led by N.AKMAL.*
*Diary of public and cultural life.*
*On our covers: National complex «Tugan Avylym». Photo I.ABRAMOVA; writer, journalist Ayziryak Garaeva-Akchura.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* «Туган авылым» милли комплексы. *И.Абрамова фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы, журналист Айзирәк Гәрәева-Акчура.